Наис Гамбәр

Яшәү тамыры

*Шигырьләр,*
*эссе-хикәяләр,*
*мәкаләләр*

КАЗАН • ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ • 2007

УДК 821.512.1451:3
ББК 84(2 Рос=Тат)-5:4
Г19

Төзүчесе
*Гөлфирә Гамбәрова*

**Гамбәр Н.Г.**

Яшәү тамыры: шигырьләр, эссе-хикәяләр, мәкаләләр / Наис Гамбәр; кереш сүз авт. Рәдиф Гаташ. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. — 351 б. — 2000 д. — ISBN 978-5-298-01530-1

Арабыздан иртә китеп барган талантлы каләм иясе Наис Гамбәргә бу елның август аенда 60 яшь тулган булыр иде. Аның әлеге китабына төрле елларда иҗат иткән шигырьләре, эссе-хикәяләре, мәкаләләре тупланды.

ISBN 978-5-298-01530-1

© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Гамбәрова Г.Ә., төзү., 2007

## Яраттыра торган иҗат

Чын шагыйрь булу өчен аның күпсанлы китаплары дөнья күрү кирәк, дияргә мөмкиннәр. Юк, бу мөһим түгел, минемчә. Төп сыйфат: шигъриятькә китергән үз өлешең, аның асыл сыйфатлары, сурәтле фикерләү белән бергә дөньяны күрү, тою, күзаллауда яңалык, укучыны сискәндерерлек яңа буяулар, төсмерләр һ.б. булу шарт. Нык ышанып әйтәбез: Наис Гамбәрдә болар бар, һәм әдәби җәмәгатьчелек моны бик яхшы белә. Шунысын да әйтергә кирәк: бик яхшы, зәвыклы мөхәррир, аннан да элек әдәбият белгече-тәнкыйтьче булып тиз танылган, бигрәк тә шигърият турында, аерым шагыйрьләребез турында саллы һәм өр-яңа сүзен әйтә белгән Наис үз шигырьләрен бастырырга ашыкмады. Тормышның күп сынауларын, күп юллар үткәч кенә башта «Баш очымда — кояш» (1991), аннары «Көзләрем яфрак коя» (2001) исемле ике китабын чыгарды, һәм... укучы аны шулар белән шәп шагыйрь итеп таныды; әдәби мәҗлесләрдә, тәнкыйтьтә аларга югары бәя бирелде. Менә шуннан канатланып, шагыйрь көндәлек матбугатта ун еллар бик актив күренеп, үзе турында фикерне даими ныгытып, сөендереп килде. Соңгы көненә кадәр...
Наис Гамбәр фәлсәфи шагыйрьләр мәктәбен үз күрде. Мөгаен, Шәрык шагыйрьләре йогынтысы да булгандыр, әмма иң мөһиме — үз классик шагыйрьләребез, милли классикларыбыз йогынтысы: Тукай, Дәрдмәнд, Туфан мәктәбе, замандашлары Зөлфәт, Әгъләм шигърияте ирешкәннәргә таяну, алар замандашы булу шатлыгы... һәм, шуны да әйтергә кирәк, бу — хыялый фәлсәфә түгел, нәкъ менә Җир, үзебезнең заман һәм туган җир, табигать фәлсәфәсе. Ләкин ул туган авылы тауЧыгын Фудзияма итеп күргәнедәй, мәхәббәтне дә дөнья, Галәм күзлегеннән карап аңлата... Туфанның «Сиңа» шигыре кебек, аның да кредосы: «син — бер генә, «сеңлем» — итеп башым иярлек»...
Мәхәббәттә шагыйрь бик сак, саф, пакь хисләр белән күренә, горур, нечкә җанлы булып истә кала. Ул — сәяхәтче, мәңгелектә бер юлчы кебегрәк; шуңа да бераз моңсу-сагышлы... әмма бар дөньяны, табигатьне аңлый, яклый, сөя белә. Менә нинди ул лирик герой! Шуңа да анда гөлләр белән сөйләшү, агачлар белән аңлашу, «сентябрь малае яфрак коя» дип, гомер фасыллары, мәңгелек турында уйланулар күп. Алар якты, оптимистик һәм төрле җете төсләргә бай. Кабатлап әйтәм: тышкы вакыйгалар турында сөйләү элементлары белән түгел, эчке дөньясы белән күренгән чордашыбыз сурәтләнә анда.
Һәр шагыйрь өчен табигый булган сурәтләү чаралары, бизәкләр дә мул аңарда, теле бай, сыгылмалы. Шигырь формасы да табигый, укырга рәхәт төрле үлчәүдәге калыпларга салынган. Иң мөһиме: шигъри фикерләвендә, зур шагыйрьләргә хас булганча, шәхси кичерешләр, гамьнәр биографиясен ил, халык җаны белән куша алу, шуңа ышандыру көче бар шагыйрьдә! Һәм бу бик кыйммәтле сыйфат; ул тышкы атрибутлар, псевдомиллилек белән ялтырау түгел, риторика да юк бу хистә, әмма чын милли моң, мәдәният, тарихи аң, рух белән баглы шагыйрь йөрәге бар — бу, һичшиксез, ярылып ята һәм яраттыра...
Минем Наиснең шигърриятенә шулай махсус тукталуым аңлашылса кирәк: ул — барыннан да бигрәк шагыйрь иде. Әмма шигырьдә танылганчы Наисебез әле җитмешенче елларда — студент чагында ук-

тәнкыйтьче буларак үзен танытты. Аның әдәби белемен, эрудициясен күреп, Татарстан китап нәшрияты үзенә эшкә чакырды. Редактор буларак дөньяга чыгарган җитди, саллы китапларда исеме язылып калды аның һәм нәшрият тормышында да матур истәлекләр калдырды ул. Биредә ул тәҗрибәле редактор Рәис Даутов мәктәбен үтте дисәк тә була — әйе, бик рәхмәтле иде Наисебез аңа. ...Соңгы елларда язган әдәби портретлар, бигрәк тә шигъри мәсьәләләренә караган күзәтүләре дә, һичшиксез, әдәбият сөючеләрдә онытылмас тәэсир калдырды. Мисалга: Равил Фәйзуллин, Зөлфәт һ.б. каләмдәшләре турында эссе-уйланулары. Бу жанрда үрнәк булырдай алар! Үзенең лирик хикәяләре, нәсер һәм хатирәләре дә шушы уйлануларының дәвамы кебек.
Кыскасы, Наис Гамбәр атлы каләмдәшебезне әле өр-яңадан ачасыгыз бар. Укыгыз, үкенмәссез!

*Рәдиф Гаташ*

## ШИГЫРЬЛӘР

### КАБАТЛАНА...

Кояш калка да бата, аннан яңадан
калыккан урынына ашыга.

Барлык елга-сулар диңгезгә коя, әмма диңгез тулып
ташымый; сулар кабат башланган җирләренә
әйләнеп кайта, яңадан инеш-елга булып ага башлый.

*Тәүрат. Екклесиаст, яки Вәгазьче китабы,*
*5 нче һәм 7 нче аятьләр*

Үзәннәрдә атлар йөри утлап.
Тояк эзләрендә мүк сулары;
Шатланырга иде, моңсуладым.
Еллар үрә елларымны чуклап.

Беркөн шулай көл булырмын, бәлкем, —
Көлгә кала шәмдәй бүрәнәләр.
Җиргә ятты озын күләгәләр.
Яна-яна китеп бара һәркем.

Исән чакта аны онытасым юк:
Күзләрендә очкын уйный иде, —
Матурлыкны кочып туймый идем.
Хак Тәгаләм! Мәңге онытасым юк.
Ян капканы ачып керермен дә... —
Уйга калып, ялгыз тезләнермен:
Күрмәсеннәр — йомам күзләремне. —
Резедалар үсә кабергендә.

Яшәүдән соң яшәү бармы? Бардыр...
Кичтән бата Кояш, иртән — калка.
Баш очымда яна алтын алка.
Коела орлык... Шытып чыга барыбер.

* * *

Сулар! — күпме яшьләр түктем сезгә карап...
Акты-китте еллар ярык ялгашлардан, —
Юшкын гына калды сөю, ялгышлардан...
Утыра таллар оеп, алтын чәчен тарап.

Җилләр! — сагышымны җилләр җилгәрделәр.
Мамык коя тупыл — уйный җәйге буран.
Бары да элеккечә: капка төбе, урам...
Җилгә язып хатлар, хатлар җибәрделәр.

Җирем! — табанымның эзен яшерегез! —
Тик каплагыз аны яшел чирәм белән.
Мин китәрмен беркөн... Бәлки, бүген китәм...
Җилдә,
Җирдә,
Суда — сүнми Сөю!.. Сүнми, кичерегез...

* * *

Шундый дымык, тонык иртәләрдә
Кошлар канат кагып үтәләр дә, —
Үлән арасына җил керә.
Күкрәк читлегеннән чыгар булып,
Сыкрап яткан җанны авырттырып, —
Әрни-әрни йөрәк җилкенә
...Шундый дымык, тонык иртәләрдә.

Сайрар кошлар — ялгыз...
(Янымда юк беркем!)
Кара кошлар гына төркем-төркем.
Агач башларыннан җил исә.
Гомернең бу кайсы төше икән? —
Еракларда йөзә ап-ак җилкән...
Син кайларда икән, җанкисәк? —
...Шундый тонык, дымык иртәләрдә.

Мескен тургай! — күмелеп бетә инде,
Ут-Кояшка кереп китә инде, —
Күк төбендә ул бит бер нокта.
Башлар тулы уйлар — кибән-кибән,
«Очты күңел кошы...» Ник җилкенәм? —
Хәл җыярга иде бер туктап
...Шундый дымык, боек иртәләрдә.
Ослан өсләрендә күкшел монар*,
Яна йөрәк — юк бер чара моңар, —
Шәмем мае яна савылып.
Кошлар арты язып хәбәр җибәр! —
Мин танырмын сине... Ике җүләр
Очраша калсак, сау булып.
...Кошлар кунар микән киртәләргә
Шундый дымык, тонык иртәләрдә?!

**КАЙТСАМ...**

Кайтамын да... китә алмый ятам,
Көннәр, төннәр ятам интегеп;
Бураннары чыкса — бишмәтем юк,
Яңгырлары яуса — итегем.

Мин гел шулай: кайтсам — китмәс өчен
Бер-бер хәйлә табам, алдашам;
(Йөрәгемдә — утлар, мин су эчәм
Атлар белән агач ялгаштан.)

«Акыллылар» әйтәдер дә (бәлкем?) —
Йөри шунда тик эт сугарып;
Этем түгел, атым сугарулы, —

Кайту белән ташлыйм тугарып.

Тугарылып ташлыйм кайту белән, —
Камыт суккан төшләр ял алсын!
Тик син генә, Ыгым, мәңге тынмас
Яраларны җөйли аласың.

Суың җылы синең, тының җылы —
Синдә генә басам сусынны.
Атлар ялгашыннан сулар эчәм —
Җирсү, сусау әллә шушымы?!

Җиккән атлар тора өй каршымда,
Син сорама: «Тагын кай таба?»
Кайтмам диеп китәмен дә, Мөслим,
Әфсеннәрең тартып кайтара.

**ТЕЛӘҮ**

Чык син, Кояш!
Күтәр әле томан пәрдәләрен...
Ачып куйыйм язгы тын җилләргә
Күңелемнең аяз тәрзәләрен.
Чык син!

Чык син, Кояш!
Ял итсен баш, күтәрелсен иңнәр,
Шатланышсын җанда бар мәләкләр;
Чәчәкләргә кунып уйнасыннар
Аллы-гөлле, саргылт күбәләкләр.
Чык син, Кояш!

Чык син, Кояш!
Коенсыннар нурга урман-кырлар.
Агач-үләннәре, барча хәят... —
Һәм уяныр таңда йокысыннан
Яшәү дигән олуг бер хикәят.
Гөлләр көтә сине,
Чык син, Кояш!

**ОЗАТУ**

Авылда — көз... Дөнья сулып калган.
Кошлар — китә... Бу бер төш кебек.
Ятам кырда — очып барган җирдән
Егылып төшкән бала кош кебек.

Уйга талып, таулар үткелендә
Асылынып торды күк болыт;
Тынып калды урман...
Кырлар тынды —
Кошлар очты ул көн күк тулып.

Бөтерелеп, бәргәләнеп алар
Урадылар кырлар түреннән;
(Илаһи моң — кошлар өне иңә
Бар хәяткә күкләр төбеннән.)

Саргылт монар — ерак атауларда,
Җете алтын — агач башлары...
(Мин нигәдер, кошлар киткән саен,

Моңсуырак була башладым.)

Нилектән бу? Нидән бу сискәнү? —
Җанда үкси киткән кош өне.
Күзләр керер-кермәс үксеп ятам,
Нишләрмен соң ялгыз, кыш көне.

Күтәрелде кошлар иле белән,
Кубарылды кошлар ил белән;
Яфраклар тама шыбыр-шыбыр
Кошлар очып үткән җил белән.

## ИСӘ ҖИЛЛӘР...

Җилләр агач башыннан исә.

*Халык сүзе*

Исә җилләр агач башларыннан,
Сабантуйдан гөрли чаукалык*;
Агачларда — оя, алар җилдә
Бишек сыман тора чайкалып.

Җилләр исә...
Җилгә канат куеп,
Кошлар бүген бала очыра;
Ходай ныклык бирсен,
Аһ, кошларның
Оялары агач очында.

Ә биектә җилләр, ай-һай, хәтәр, —
Бөтерелеп ага ак болыт;
Кошлар туа, күзли киңлекләрне,
Агач башларында атынып.

Анысы бар, —
Кош баласы канат белән туа,
Егыла да баса... җилпенә;
Очар кошлар каурый чыгар-чыкмас
Ташланалар җилләр иркенә.

Оча алар җилгә күкрәк куеп,
Гел биеккә, күккә талпынып.
Тукта, урман, тик бер генә минут,
Кошлар өнен тыңлыйк, тор тынып!
. . . .  . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
...Исә җилләр агач башларыннан,
Үзәннәрдә тынлык, «шым» да юк;

Мең тавышы белән гүли урман...
Шагыйрь җаны да бит шулай ук
Тына белми;
Алар тартым бераз
Оя корган кошлар халкына:
Алар да гел җилләр кочагында,
Гел биектә канат кагына.
(Урман җиле иң беренче булып
Биек агачларга кагыла.)

Исә җилләр агач башларыннан...

## БОЛГАР ТАШЛАРЫНА

XVIII йөздә Болгар кабер ташлары
Успения чиркәве нигезенә салына.

*Газетадан*

Хак Тәгаләм!
Хак сүз!
Тел иңдер дә Болгар ташларына, —
Баш орыйм бер кабер ташларына, —
Тыңлап торыйм... Юкса ничә еллар
Сүз табалмыйм сөйли башларыма.

Чал тарихның тимер капкаларын
Ач та (ташлап нахак япмаларын!)
Ташка сүз бир... Хак Тәгаләм, бер сүз —
Соңгы сүзен үксеп ятканнарның.

Сөйләсеннәр яуда җиңелгәннәр,
Болгар туфрагына күмелгәннәр;
Җимергәннәр генә теллемени,
Хаклымыни «аксак тимерләннәр»?!

Юкса Иблис-кәлтә һаман алдый,
Коерыгын өзеп ялгый-ялгый;
Ялгыша ул: «Имеш, тарих — тузан,
Ташлар — үле, ташлар сөйли алмый».
Ләкин...
Килә дә көн — актарыла сулар,
Өскә калка Бөек Болгар, Сувар;
Тирәннәрдән калка язулы таш —
Тамгалы таш...
(Дөнья шундый чуар!)

Язулы таш — Болгар илчеседер,
Алласыдыр Болгар ташларының;
Һәм ул хәтерлидер кара көнен —
Гарасатның ничек башлануын.

Безгә килеп җиткән бер догадыр
Ташка уеп язылган бу сүзләр;
Ташлар елый белми...
(Нык булырга кирәк!
Таштай нык булырга!!!) Яшьле — күзләр...

Кеше гомере Җирдә мизгел генә,
Халык гомере дә акмый тигез генә, —
Ташка күчә дә җан,
Сөйли үз телендә,
Салсалар да чиркәү нигезенә!

* * *

Сәйләннәр өзек — чәчелгән!
Ватан — көзге! — ватылган...
Ни аяныч: газиз халкым

Киселгән дә атылган.

...Алтын Ай күтәрелә
Балкып чиркәү артыннан.

* * *

Һәрбер халык,
Иле булса — Алла,
Теле булса гына — пәйгамбәр...
Миллионынчы булып имзам куям:
«Татарстаным — бар!
Н.Гамбәр».

*30 август, 1990*

**КОРРИДА**

*(Бәйдән ычкынган үгез монологы)*

Мин тагын «ычкындым» бәемнән, —
Бу утар тар миңа;
Гомернең һәр көне —
Бер Бөек коррида.

Ал байрак шикелле җилферди
Мөгезгә эленгән мулета;
Бу — минем иң соңгы көрәшем, —
Яшәүнең хәлиткеч минуты.

Хәлиткеч минуты язмышның,
Фидаи көрәшнең соңгысы!..
Һәм мине юк итәр (яки мин?!)
Матадор — сугымчы! — сөңгесе.

Мин кабат ташланам әләмгә.
Җанымда юк хөсет, юк рия.
...Йөрәккә төбәлгән, төбәлгән
Меңләгән, миллион бандерилья!

Кан тама, кан тама сыртымнан...
(Кидертмәм өзелгән мунчакны!)
Йә Яшәү, йә Үлем!..
Мин — әзер!..
Эй-й, матадор, то-ре-ро!
Түзәргә ничаклы?!

**ТӨШ**

Сәер төш иде ул... Тора идем
Кыя өстендә — диңгез ярында;
Беркемем юк иде тотынырга —
Дусларым да, сөйгән ярым да.

Мин әзер дә идем ташланырга
Кыя ярдан, түбән атылып, —

Ялгыз торна кебек бәргәләнеп,
Ике кулым җәеп, атынып.

Шулчак
Кайдан тавыш иңде?!
Җилме?!
«Тукта, егет! Сиңа иртәрәк!
Күрәсеңме: алда бер кыр ята —
Синең өлеш, куйган киртәләп.

Син чәчәргә тиеш анда орлык,
Таштан әрчеп, сөреп, йомшартып;
Агар гөрләвекләр, шытар үлән,
Нурга манылыр хәят кыш арты.

Тик тайчана күрмә буразнаңнан:
Язмышыңнан — исәрлегеңнән;
Олау-олау уңыш җыясың бар
Урылмаган кишәрлегеңнән».

Тыңладым да алдым кулыма каләм.

* * *

Таудан гына йөгереп төшәсе дә
Үргә генә сикереп менәсе;
Еракгагы алан, урман, кырлар —
Ымсындырып дәшә һәммәсе.
Баш очында гына якты Кояш,
Өзеп кенә ал бәхет алмасын;
Хыял, өмет, сөю җилкендерә
Гомер бакый адәм баласын.
Киләчәк ул аргы ярда гына,
Басма аша гына чыгасы.

(Утка керәм, упкынын да үтәм, —
Тик йөрәгем генә чыдасын.)

## КӨЗ — МОҢЛЫ КҮЗ

Көзнең күзендә үк уйчан моң бар,
Яшерен сабырлык бар җанында;
Күпреп, кайнап торган хисләр түгел,
Айныган бал инде җанында.

Кошлар булып кошлар сүлпәнрәк,
Сулар агышы да тынырак;
Көзнең дәрте тирәндәрәк ята,
Хәтер кайтавазы — тын, ерак!..

Күк сүрүе тоныграк хәтта, —
Челтер-челтер тутлар ябына;
— Тор-рыйк!..
Тор-рыйк!..
Ялгыз торна сөрән салып үтте
Баш өстемнән Казан ягына.

«Торыгыз, тор!..» — дияр идем,
Юк шул! —
Торна бик еракта.
Ничек иштелсен?!
(Ялгыз кибән тора кыр түрендә,
Күктән төшкән торна шикелле.)

Көзнең йөзендә үк бер сагыш бар,
Кая күз текәмә — сарылык;
Пәрәвезләр ага су өстеннән,
Таллар муенына сарылып.

## МИН ЧЫГАМЫН ЮЛГА...

Выхожу один я на дорогу.

*М.Ю.Лермонтов*

I

Мин чыгамын берьялгызым юлга,
Алда бары таулар шәүләсе
Маяк миңа, ләкин «барыбер җитәм»
Дигән вәгъдәм тукран тәүбәсе
Булып калмас; барыр юлларымда
Очраса да таулар, дәрьялар —
Үтәрмен күк; үткел аръягында
Тукталачак авыл-карьяләр
Бәйрәм табынына җыена,
Анда минем дуслар-танышларым,
Туганнарым бергә җыела.

II

Мин чыгамын юлга берьялгызым...
Төнгә каршы яккан учакның
Уртасына кереп басамын да
Ялкыннарын кысып кочаклыйм.
Очкыннары оча йолдыз булып
Киек Каз Юлына кадәрле;
Әллә алар минем күкрәктәге
Туганнарга әйтер хәбәрме?!

III

Мин чыгамын юлга...
Алда яткан
Таулар шәүләсенә күз төбәп
Кузгаламын; биниһая киңлек,
Үзән, калкулыклар — үз төбәк
Минем җанга; һәрбер агач-ташы
Гел үзенчә якын, кадерле;
Арып егыла калсам, чәчәкләре
Төреп алыр минем каберне.

IV

Мин чыгамын берьялгызым юлга...
Кояш төшкән болын-тугайлары

Ымсындырып дәшә; ярты юлда
Хәлдән тайсам, печән күбәсе
Кәрвансарай булыр; чишмә суы
Сихәт өстәр арган тәнемә,
Баш орырмын соңгы сулышымда
Туган туфрагыма —
Тәнгә яшәү биргән Тәңремә.

V

Мин чыгамын берьялгызым юлга, —
Тауга карап, озын сәфәргә;
Ашыгырга кирәк, йокыдагы кошлар
Уянганчы таңгы сәхәргә.
Мин үтәргә тиеш юлымдагы
Киртләч-киртләч таулар үткелен;
(Язылмаган поэма — һәрбер төнем,
Укылмаган китап — һәр көнем.)

Мин чыгамын берьялгызым юлга...

**БӘЛКИ...**

Бәлки, юкка барлык омтылышлар,
Бушка, бәлкем, сөю-янулар?!
Поезд киткән инде... юллар ябык, —
Алда яна кызыл семафор.

Йөгереп каршы чыктым... Уты гына
Чагылып калды соңгы вагонның;
Һәм күренеп барды — офыккача —
Тәрәзәдән сузылган кулың.

Минме соңга калдым, әллә синме
Иртә киттең?! Кайда буталыш?
Бәлки, минем соңгы вокзалымдыр
Таныш түгел шушы тукталыш?!

Бәлки, шулай үзенеке итәр
Әрем баскан шушы кыр-үзән?!
Без җирнеке барыбер — күкрәгенә
Күкрәк куеп авам йөзтүбән.

Мин ятармын олы юл читендә
Ерак киңлекләргә күз атып:
Килер поездларны каршы алып,
Китәрләрен —
Хәерле юл теләп озатып.

## ЯШӘҮ ТАМЫРЫ

I

...Инде көз. Сентябрь
күңелнең
Бакчасын ахаклады;
Коела гомернең
тын гына
Картайган яфраклары.

Коела... Тамалар
өзелеп
Агачлар керфегеннән;
Аннары яталар
тезелеп
Ишләре төркеменә.

II

Шул «яфрак» — бер көне
мәңгенең —
Яшәеш агачының:
Коела, әйләнә туфракка
Гайбәте,
ялган,
чыны.

Сау булсын тамыры,
яфрак ул
Агачта бөре генә;
Юк, бары төш кенә,
Аның да
Миллионнан бере генә.

## КЫЛГАННАР ЙӨГЕРӘ...

Дала буйлап кылганнар йөгерә...
*Ә.Еники*

Кылганнар йөгерә, кылганнар...
Дулкыннар йөгерә сөрлегеп.
(Акъәби йөридер кырларда,
Ак мамык шәленә төренеп.)
Кылганнар йөгерә сөрлегеп.

Хәтер — җил; мәңгелек җил-давыл, —
Актара учаклар кузын;
Шәфәкъләр — кып-кызыл, кан кебек;
Дала — киң; көн — кыска; юл — озын...
Җил тузгый учаклар кузын.

Офыкта — чатырлар; яна ут, —

Учак та җилпенә, тынгысыз;
Таң белән — сәфәргә, сәфәргә!
Хыял — ук; хис-хәнҗәр — кынысыз.
Чатырлар каршында яна ут.

Акъәби торгандыр сәхәргә,
Җилләрдән көткәндер хәбәр-өн, —
Кылганлы кырлардан Ак атта
Бер кайтыр Ил кичкән хәләлең.
Акъәби көткәндер хәбәр-өн.
«Ир-егет җанында ат ята» —
Акъәби сүзе бу колакта...
Кайсыбыз менәчәк толпарлар
Кешниләр тибенеп улакка?!
«Ир-егет җанында ат ята».

Кылганнар йөгерә, кылганнар...
Кырлардан йөгерә сөрлегеп;
Акъәби учагы сүнгәнче
Булырмы сәхәргә өлгереп?!
Дулкыннар йөгерә сөрлегеп.
Кылганнар йөгерә...
Йөгерә...

* * *

Мин җәйләрдән көзгә кереп киләм, —
Карап калам киткән кошларга;
(Таянырлык дустың булсын икән,
Таянырлык микән дусларга?)

Салкыннары тышта декабрьнең, —
Туңар инде калган кошларым;
(Таянырлык иңең булсын икән,
Таянырлар микән дусларым?)

Мин кышлардан язга чыгып барам, —
Ояларын барлыйм кошларның;
(Җан атарлык җаннар ерак, ерак, —
Колагымда өне шуларның!)

* * *

Апрель...
Апрель...
Гөрләп ага сулар,
Эри туңнар... Хәят сәламәт!
Апрель...
Апрель...

Җаным иркен сулар, —
Ярлар тулы сөю-сәгадәт!

Уйлар...
Уйлар...
Тоташ ташкын инде
Тамырларда уйлар агышы;
Дулар...
Дулар...
Җанда язгы сулар,
Ишетәм гөрләвекләр тавышын.

Хәтер...
Хәтер...
Язгы ташу идек,
Аккан сулармы без бүген дә?!
Хәтер әйтер:
«Сөю — тынмас дулкын,
Мәңгелек бер агым күңелдә».
Истә...
Истә...
Төнге яланнарның
Күкрәгенә ятып еларлык!
Эчтә...
Эчтә...
Эчтә сулыгып тибә
Әкияти бер гүзәл чынбарлык!..

* * *

Барыбер,
            барыбер,
                        барыбер
Бу дөньяда
Караңгыдан якты күбрәк:
Тузаннарны басып, әнә, яңгыр ява,
Җирне керендереп, күкрәп.

Яшеннәрдән сибелә якты очкын,
Очкыннардан ялкын кабына;
Шушы көннән башлап, мәҗүсидәй,
Мин Су белән Утка табынам.

Шуңа, бәлкем, төнем көннән якты, —
Энә табып була төнемдә;
Ә көнемдә?! —
Аллы-гөлле чәчәкләргә кунып,
Күбәләкләр уйный көнемдә.

...Шундый көндә килеп кер син миңа,
Иң бәхетле, якты иртәмдә.
(Юраган юш килә — кунак көтеп,
Песи юынып утыра идәндә.)

Һич тә тартынмый кер! —
төкле аягың белән! —
Синең карамакта гүрнәчәм;
Кара ипи, салкын чишмә суы
Сыем булыр, гаеп күрмәсәң.

Әзер сиңа, — көткән кунагым син! —
Якты чырай, кара икмәгем;
Офтанма да, шикләнмә дә, дустым,
Авыр чакта чит-ят итмәмен.

Ышан миңа:
Барыбер,
                барыбер,
                                барыбер
Бу дөньяда
Караңгыдан якты күбрәк;
Кара, әнә:
Җәйге яңгыр — җылы яңгыр ява,
Җирне керендереп, күкрәп.

...Күз алдымда — биниһая киңлек,
Шатлык белән тулы күкрәк.

**ТӨНГЕ СУЛАР**

Төнге сулар ага, төнге сулар...
Көзге сулар шундый ямансулар, —
Таллар боек, түбән иелгәннәр,
Инде сап-сарыдан киенгәннәр.
Төнге сулар ага, төнге сулар...

Сулар өсте тулы яфрак ага,
Яфракларны дулкын ярга кага;
Ярда кала читкә кагылганнар,
Бер кояшка гына табынганнар.
Сулар өсте тулып яфрак ага.

Айның сузылып төшкән ак җепләрен
Чайкый, юа Ыкның дулкыннары;
Кеше дә бит җирдә яфрак кына, —
Һәр суның бар яшерен упкыннары.
Чайкый, юа Ыкның дулкыннары.

Төнге сулар ага, төнге сулар...
Килер бер көн, Вакыт чаңы сугар, —
Күкрәк елгасыннан аккан еллар
Кайтмас, кайтмас... Тынгы бирми шулар.
Төнге сулар ага, төнге сулар...
* * *

Апрель керә җанга өмет булып,
Кояш булып, ташкын су булып;
Керфегемә кунган салкын бозлар
Катлам-катлам төшә убылып.

Билгесез дәрт иңә күкрәкләргә,
Җанга тула исәр, ашкын ду;
Апрель җитсә — бер көләм дә елыйм,
Аңлап булмый торган ташкын бу.

Кояшның бер җылы нуры җитә, —
Таулар бите буйлап йөгереп
Агам, агам... Агар агышларым
Гөрләвекләр кебек йөгерек.

Бер җылы сүз җитә...
Болыннарны
Баскан сулар кебек җәеләм;
Мин гел иртә сөенәм — апрельдә үк
Чыгып җитәм инде җәемә.

Беләм, әйе — җәй дә үтеп китәр,
Әкрен генә шулай көз керер;
Салмакланыр суның агышлары,
Сагыш басар... анда күз күрер.

Язлар җитсә — ташкын сулар кебек
Юлсыз-нисез агам, очынам;
Очар кошлар оя гына кора,
Ә мин инде бала очырам.

## АРЫШЛАР ШАУЛЫЙ

Бертуктамый шаулый арышлар
Мин үтәсе юллар өстендә;
Басу юлы — тузанлы юллар —
Балачактан калган танышлар.
Бертуктамый шаулый арышлар.

Арышларны сыйпап искән җил! —
Мине тагын сөендер әле.
Йөгереп-уйнап чапкан көннәрдән,
Бар, тиз генә хәбәр алып кил,
Арышларны сыйпап искән җил!

Алар ерак калдылар микән?
Беренче кат күрешкән көннәр,
Йөрәкләрне учларга куеп,
Аерылмаска ант иткән төннәр, —
Алар ерак калдылар микән?

Аны эзләп таңнар аттырдым,
Күрмәмме дип юллар өстендә...
Сары чәчле шаян малайны,
Әйтче, арыш, кая качырдың?
Аны эзләп таңнар аттырдым.

Бертуктамый шаулый арышлар —
Балачактан калган танышлар.
Арышларның башак шавында
Минем җаннан күчкән сагыш бар.
Шаулыйлар да шаулый арышлар.

## САГЫНУ

Тагын төшкә кердең...
Басу буйлап

Камыл ерып килә идең син,
Учма-учма сары чәчләреңне
Җилфердәтеп йөгерә идең син.

Кырга сыймый уйный-чаба идең,
Пәрәвездәй җиңел очынып;
Табаннарың гына ялтырап кала, —
Китәрсең күк җирдән ычкынып.

Китәрсең дә...
Очар чакларың ич, —
Канатлы ат кешни җаныңда;
Син — хыялый, кыргый әле,
Яшьлек хисе ага каныңда.

Оч син, әйдә, очар чакларыңда,
Ике кулың — ике канатың;
Биеклектән хәят киңрәк ачыла, —
Биек очыш телим, канәтем!

Ә мин инде, күпме талпынсам да,
Синең арттан чабып җиталмам;
Яшь тайларга карап сокланcам да,
Камыл-кырдан ары киталмам.

Очу миңа насыйп булмас инде,
Каерылган ике канатым;
Мин аларны синдәй яшь чагымда
Камылларда чабып канаттым.
(Җиргә баскан саен, эзләремә
Сулык-сулык килеп кан акты.)

Сыктау түгел лә бу!
Гөнаһ булыр, —
Еламас ла үзе егылган;
Яраларым әрнеп куйган чакта
Хәтер учагымда җылынам.

Татлы мизгел — камыл буйлап чаптым! —
Өнемме бу, әллә төшемме?!
Очраттым кырда чалымнары белән
Яшьлегемә охшаш кешене.

**ХУШЛАШУ**

Төшеп калдың авыл башында син,
Аермалы юллар чатында;
Басу капкалары, авыл-кырлар
Һәм... син калдың үрләр артында.

Сикереп төштең юллар бормасына,
Сыгылып куйды арба силәсе;
Пошкырына атым — Карлыгачым:
Аерылабыз, дөрес сизәсең.

— Әйдә, малкай!
Тезген кагу белән, туры юргам,
Башын чөеп, алга кузгалды;

Тотылгандай булды Кояш шулчак —
Томанланып китте күз алды.

Уйларыммы шулай, рәшәләрме
Иген кыры буйлап йөгерде?!
Каера атым гел авылга табан,
Чак-чак кына тыеп өлгердем.

Юкса әзер кереп китәргә ул
Юлсыз-нисез, кырлар буйлатып;
Ишелеп-ишелеп агып килә дулкын,
Агып килә ялын уйнатып.
Шул дулкыннар өсләп алып китте
Авылымның кабык арбасы;
Баш астыма учма йолкып салам.
(Истәлеккә булыр — юлым ерак,
Барасы да әле барасы.)
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кул болгадым сиңа, күрдең микән,
Борылмадан кереп күмелгәч?!
Үрәчәгә басып карасам да,
Ах, юк инде,
Таныш гәүдәң инде күренмәс.

Ул көннәрдән сузылып килә бары
Тәгәрмәчтән төшкән ике эз;
Бергә чакта — бер материк идек,
Ике кыйтга хәзер икебез.

Ике кыйтга хәзер... Ике эз без, —
Арабызда ята Гибралтар;
Кем җырлады арба өстенә басып:
«Чит җирләрдә йөреп гыйбрәт ал!»

Йөрдем, алдым —
Чит-ят кырның
мамыгына чаклы
Бәгыреңә килеп кадала;
Кайтсам менә:
Каршы алды
басу капкасыннан
Утырып калган ялгыз багана.

Каерылып-каерылып карыйм
Аермалы юллар чатына;
Чаба атым,
атым — Карлыгачым,
Егылып төшми барам чак кына.

**АККОШ КҮЛЕ**

Без көймәдә йөрдек.
Кич иде.
Аргы ярлар шундый ерак иде, —
Әкияттәге атау шикелле.

Ул ярларга әле таңгача да
Җитмәс кебек идек —
Җителгән;

Ярлар якын икән, алар бары
Ак томаннар белән чигелгән.

Күтәрде җил томан пәрдәләрен,
Зәңгәрләнеп китте күл өсте;
Күңелдәге шикләр китәр микән
Күтәрелгән ак томан төсле?!

(Китәр микән?!)
Аккош каурыйлары
Күл төбендә, нигә үрелдем?! —
Алсу таңда очып киткән ләса
Аккошлары Аккош күленең.

Ак болытлар булып күлдә йөзә
Аккошлары гына күңелнең.

* * *

Артта кала утлар...
Аһ, ул утлар
Ерагайган саен яктырак;
Син — күз яшем.
Садә яшьләр —
Олыгайган саен татлырак.

**КАВЫРСЫН ХАТ**

*(Җыр)*

Киек казлар очып узган саен,
Сине, әнкәй, искә төшерәм;
Алар сөйләр минем хәлләремне,
Сорап йөрмә чит-ят кешедән.

Хәлем әйбәт, булган борчуларым —
Өлешемә чыккан жирәбәм;
Казлар канатына сүзләр язып,
Көн дә сезгә сәлам җибәрәм.

Турыгыздан узган шул казларның
Каурыйлары калыр сибелеп;
Казлар таушын ишетеп чыгарсыңдыр,
Миннән хәбәр барын сизенеп.

Кавырсыннар итеп язган хатым
Таң нурына манып язылган;
Казлар оча сезнең якка, әнкәй,
Мин дә калмам шушы язымнан.

* * *

Ак болытка язып салган идем,
Җитте микән хатым Казанга?

Эфир аша килгән хәбәр әйтте:
Бүген яңгыр яуган Кабанга.

## ЮГАЛДЫ

*(Җыр)*

Атларым чабар сыман ла,
Юлын да табар сыман;
Ничек аерып алаем
Җиде ят арасыннан?..

Башлымы сөлгеләрең лә? —
Ташлама өлгеләрен;
Чигелде күңел түремә
Җуелмас билгеләрең.

Ут мәллә эчләреңдә лә,
Тут кунган төсләреңә;
Башыңны саласыңдыр да
Ак мендәр өсләренә...

Югалды бердәнберем лә, —
Түрдәге яран гөлем;
Янган утларга салдың да,
Сибелде кырга көлем.

* * *

Хәсрәтемне генә түккән идем,
Гайбәт итеп җилгә чәчкәннәр;
Өннәремдә өнсез калып йөрим,
Төшләремдә күрәм чәчкәләр.

* * *

Кипкән чәчәк килеп чыкты беркөн
Актарганда китап эченнән;
Синнән бүләк иде ул, бер истәлек —
Кайчандыр үз, якын кешемнән.

Уйнап кына әйткән идең, көлеп:
«Бер карарсың, мине сагынсаң...»
Бик сагынам, тик гөлләрең генә
Уалыр күк, ялгыш кагылсам.

Салып куйган идем мин аларны
«Сөям» дигән сүзләр янына.
(Сөю... үткән... Ул да, китап кебек,
«Укып» бетерүгә ябыла.)

Китап эчендәге кипкән гөлләр
Сулган сөюемә ишарә;
Ташларгамы миңа ул гөлләрне,
Онтыргамы сине, нишләргә?!

* * *

Ага гына Вакыт...
Яшәү-тормыш, —
Әйтерсең лә тоташ әвернә...

Атлы да юк юлда, җәяүле дә
Синнән соң да булган дәвердә.

**СҮНГӘН ЙОЛДЫЗЛАР**

Кичләре җитсә, күгемдә
Йолдызлар җемелдәшә;
Тарала салпы болытлар,
Борчуым җиңелләшә.

Баш очымда нәкъ бер йолдыз:
Кабына, яктыра да,
Уй гына барып җиталган
Ерак Галактикада...

Кем белә... —
Бәлки, ул сүнгән йолдыздыр;
Миллион еллар элек
Сүнгәндер, көлгә очкандыр, —
Әмма яктысы терек.

Күрәмдер бары үткәнен
Меңләгән
Яктылык елы аша;
Төн... күктә йолдызлар тагын
Янып тора таңгача.

Сүнгән йолдызлар!..
Чынмы бу?!
«Нуры бар, үзе сүнек...»
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Син юк инде минем өчен,
Тик утың бетми сүнеп.

* * *

Баш өстемнән очып узды казлар...
Очтым — җиталмадым, соң инде;
Сызгырышып очкан уклар сыман,
Ак каурыйлар чәчкә соңынды*.

* * *

Сөрән салып узды киек казлар...
Көзге кичләр иңерәп куя;
Мин сөялгән тупыл әйтә кебек:
— Сентябрь малае эзенә
сентябрь
Яфраклар коя.

Җиргә карыйм:
Ышанасы килми, —
Килгән сукмакларым сап-сары;
Күккә карыйм:
Кычкырасым килә, —
«Син кайларда, сөекле ярым?!»

Яшел җәйдә — яшел яшьлегемдә
Без ант эчкән изге урында
Көзге җилләр бүген яфрак сибә...
Уйлыймын да синең турыңда —

Кысылып тибә йөрәк, давыллардан
Карт тупыллар уфылдап куя;
Сары күбәләкләр куна иңнәремә —
Сентябрь малае эзенә
сентябрь
Яфраклар коя.

Яфраклар коя...

**СИН — ОЧАР КОШЫМ!**

*(Хыялый халәт)*

Күкләр биек иде, сулар тонык,
Дөнья иркен иде, садә, тын;
Төркем-төркем кошлар оча иде,
Кояш баешына табатын.

Канат җилен тоеп калды бары
Яфраклары тутлы тупылның;
Баш очымнан кошлар оча иде, —
Мин шуларга карап утырдым.

Оча иде алар тезелешеп
Баеп барган Кояшка табан;
Утыра идем ялгыз, арып-талып,
Юлга чыккан идем мин таңнан.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Таудан төшеп килә иде берәү,
Кошлар юлы буйлап — Син идең...
— Хәерле көн, юлчы! Ардың мәллә?
— Хәерле кич инде, сеңлем!
(Күрәсеңме: Кояш баеп бара, —
Көне үтеп бара гомернең.)

Ә син көлдең генә:
— Юләр абый,
Кайчан картаерга өлгердең?!
Хәзер яшәртәм мин сезне... Су биримме?!
...Һәм чишмәгә төшеп йөгердең.

Кош эчергән кебек, кушучыңа

Су алдың да миңа эчердең;
(Шушы минуттан соң мин мәңге яшь,
Бер йотым су белән... исердем.)

Чынлыгыңа ышанасым килеп
Мин тотмакчы идем кулыңнан,
Талпындың да: «Арма сәфәрдә!» — дип
Китеп бардың килгән юлыңнан.

Кем идең син?!
Фәрештәме берәр?!
Күземә генә мәллә күрендең?!
Төркем-төркем очкан кошлар белән
Кояш аръягында күмелдең.

Кошлар!
Кошлар!
Очар өметләрем! —
Сез кайтырсыз микән кабаттан? —
Аның сынлы сурәтенә кереп,
Кояш чыгып килгән тарафтан.

**ОЧРАШЫРБЫЗ**

Таулар белән бары таулар гына
Очрашалмый... Без бит ир-атлар,
Кан буенча, фикер, җан буенча
Рухани якын «братлар».

Юк, без күрешербез!..
Бәлки,
Таулар итәгендә,
Йә булмаса, урман буенда
Һәм ягарбыз учак...
Тик икәүдән-икәү
Гәпләшербез яшәү турында без,
«Алда» ничек яшәү турында.

Утырырбыз учак каршысында
Соңга калган мосафир кебек;
Үткәннәрне сагынып, якты-матур
Алгы көннәр белән җилкенеп.

Бабайлардан калган гадәт белән
Куыш корырбыздыр... камыштан;
Начар ният, түбән омтылышлар
Уйга килмәс безнең ялгыш та.

Кара ипи булыр ашъяулыкта,
«Мундир» белән пешкән бәрәңге;
Хәмер булыр, гөнаһ шомлыгына каршы,
Дус итмәбез әмма хәрәмне.

Ялган, ялагайлык учакларда
Шытыр-шытыр килеп янарлар.
Икейөзлек, хөсет, шамакайлык
Шул учакта үлем табарлар.

Беләм, беләм!
Безнең бу табында
Эчкерсезлек хаким итәчәк;
Кара-каршы утырып сөйләшерләр
Ерак үткән белән киләчәк.

Ә учак ул, учак — юк, юк! — сүнмәс,
Таңга тикле балкып торачак;
Өстәп торыр хисләр, уй-хыяллар
Кала тавы чаклы — бер кочак.

Тау белән тау гына очрашалмый, —
Без бит таулар түгел ләбаса;
Хәрәкәттә генә бәрәкәт бар,
Хәрәкәтсез җанны мүк баса.

Мин кузгалам алгы көнгә табан,
Иңгә салып язмыш биштәрен.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Учак янып торыр җилфер-җилфер, —
Тукталышлар саен, кичләрен.

* * *

*(Шаяру)*

Көн таң атса ява... менә тагын
Коеп үтте июль яңгыры...
— Зонтың астына ал әле, сеңлем?
— Әйдә алам!
...Алларыңа энҗе яугыры.

Уйнап кына әйткән шушы сүзең
Миңа чындыр кебек иштелде, —
Җылы яңгыр явып үткәннән соң
Балкып чыккан Кояш шикелле.

Көлеп әйткән сүз дә җилкендерә, —
Нишләтәсең аны, күңелне;
Зонт астына алыр кешең булгач,
Яңгыры да хәтта күңелле.

Яу, яу, яңгыр...

**ӘРЕМ**

I

«Түзәрсең — егет ләбаса,
Гәрчә бик ачы мәлең;
Ташландык йорт ишегалды

Тоташтан, энем, әрем.

Әрем — дару, җыеп апкер*
Дәвага учма әрем;
Әрәмгә хәрәм килешә, —
Йә, ничек хәзер хәлең?»

II

Мең яшә — мең ел өйрән, ди,
Бик әйбәт, абый, хәлем;
Тереләсем килә, түзәм —
Ашадым ачы әрем.

...Авыр әкият шикелле
Авыргач күргәннәрем;
Хәзер бер чир дә кагылмас,
Мин үзем тоташ әрем.

* * *

Үткәннәрнең асылмалы, алтын
Күперләре янган-ягылган.
Күпме күз тегәмә, өметләнмә, —
Кояш чыкмый баткан ягыннан.

Сау бул, үткән көнем! Очты көлең,
Яңа көн яктысы тәрәздә;
Башка гөлләр үсә кырларымда,
Бүтән кырлар балы кәрәздә.
(Өстәл өстемдәге кәгазьдә.)

Әмма бал кортларым — уй һәм хисләр —
Таныш гөлгә кунган чагында,
Яңрап* куя серле симфония
Җанның мең авазлы чаңында.

* * *

Йөгем дә юк ат арырлык,
Малым да — ат алырлык;
Бар булганым — урмаган кыр,
«Мөлкәт» дип аталырлык.

Күпме чыгар? Ничә арба?
Бәлки, бер учма гына?!
Йөрәк тә сыя (зур түгел!),
Салсаң, бер учка гына.

* * *

Минем өчен
Әкияттәге Шәмшәрифтән гүзәл
Утыз йортлы туган Бүләкнең
Хәтер томаннары аръягында

Торып калган нәүмиз сурәте.

Көннәр якты монда.
Томаны да
Үтә күренмәле, сөт томан;
Күпереп тора ястык болытлары
Килиманджаро карлары сыман.

Данлы таулар күп ул...
Тик аларны
Ничек кенә җан аямасын,
Газизрәк барыбер
Чана шуып үскән Шәех тавы —
Авылымның Фудзиямасы.

*** * ***

Ян!.. Янылмый. Ян!.. Яналсаң,
Күкрәгем, тик бер кабат.
Мин китәрмен төнгә каршы,
Баткан Кояшка карап.

Китәрмен дә гөлт итәрмен,
Балкып янган күк кебек...
Җитәр кичләр — сискәнерсең,
Кызыл шәфәкъны күреп.

**ӘНКӘЙ ТӨШЕ**

Төш күргәнсең, әнкәй...
Юратырга
Син кергәнсең күрше карчыкка.
(Тышта җилдер, әнкәй, иңнәреңә
Мамык шәлең бөркәнми чыкма!)

Төшең рас килер. Төшләреңдә
Агымсу күргәнсең — юл төше;
Тагын... ялгыз агач: бусы, бәлкем,
Юлда ялгыз калган бер кеше.

Тагын кыр күргәнсең — дулкынлы кыр...
Бусы, бәлкем, йөгрек кылгандыр.
(Гөл чүлмәгең тулы кылган белән,
Бәлкем, төштә күргән кырдандыр.)

Кылганнарны «әби чәче» диләр,
Ул нәкъ синең чәч кебек, әнкәй,
Ак һәм йомшак; сулыш җиле белән
Тибрәнергә тора бит, әнкәй.

Күңелең дә кылган кыры кебек —
Җил дә исмәс борын тирбәлә;
Балаларың олыгайган саен
Кайгың олыгая.
Олы бала, имеш, зур бәла.

Төш күргәнсең, әнкәй,
Бер юл төше —
Кайтыр идем, юлым бүленгән;
Миннән хәбәр булып бара торсын,
Хат булса да салам бүгеннән.

## ӘНКӘЙГӘ

*(Җыр)*

Самавырын ничә яңарткандыр
Безне көтеп әнкәй көненә.
Юлда тузан күрсә, каршы чыга
Яулык чөеп капка төбенә.

Кушымта:
Чәчләрең ак, —
Яшьлегеңдә уйнадыңмы әллә
Кылганнардан такыя үреп?!
Әнкәемнең төсе күз алдымда,
Әйтелмәгән васыять кебек.
Әйтелмәгән васыять кебек.

Чәчкәйләрең йомшак, мамык кына, —
Яңгыр суы белән юылган;
Үләннәрне ерып кайтып килә
Таңда әнкәй чишмә юлыннан.

Кушымта.

Әнкәй көтә безне, каршыларга
Чыгып баскан авыл башына;
Күзләрендә, юк, яшь түгел аның,
Рәшәләр йөгерә каршына.

Кушымта.

## КЫЗЫМА ХАТ

*(Төсле открыткаларга язылган хатлар)*

I

Кыр гөлләре сыеп бетмәс барыбер,
Кочагымны күпме җәйсәм дә...
Хатка төреп, бары бер гөл салам
Чәчәк кебек кызга — Ләйсәнгә.

«Шиңми торган бер чәчәк син миңа!» —
Шуннан башка, йә, ни әйтием?!
Хат эчендә яткан тамчы таҗлар
Соңгы сәлам булсын...

Әтиең.

II

Алларымда — урман.
Күренмәссең
Үрелеп карасам да күз тегеп;
О-о! Юу-ук,
Кар ябынган чыршы арасыннан
Чыгарсың да Кар кызы кебек
Ап-ак киемеңнән;
Син килерсең
Ястык-ястык көртләрне ярып
Һәм салырсың туңган кулларыңны
Учларыма, йөгереп арып.

Ләкин
Мин еракта, Ләйсән...
Урман җылытыр сине, —
Агачларның ябалдашлары
Кар бүректән;
Кышын яшен суккан
Имән генә яланбаш бары.

III

Ничә яздым чәчкә төшкән хатлар,
Әллә барды, әллә бармады?
Ә монысында:
«Кошлар тартып бара —
                    силәләрен
Гөл-чәчәкләр күмгән арбаны».

Хатым аша, кызым, гөлләр салам,
Гөлем аша сәлам җибәрәм, —
Кошлар гына үтеп керә алган,
Нурлар кыйгач төшкән җирләрдән.

Гаҗәпләнмә: беркөн өй каршында
Кошлар җиккән арба туктаса,
Күңел кошлары ул!
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Такыя үр, Ләйсән,
Кошлар биргән гөлдән чук ясап.

Такыяларын үреп кигән бер кыз!..
Бер ятуда аны өч күрәм.
Хатым аша чәчкә салам, Ләйсән,
Мин кышын да чәчкә үстерәм.

* * *

Еллар үтеп, юллар югалса да,
Сүтелсә дә гомер сүсенем —
Мин эзләрмен синең эзне генә,
Җырларыма кергән сеңелем!
Еллар үтеп, юллар югалса да...

## БЕР ХАЛӘТ

Күтеп тормый кем дә канатланып,
Юлга чыгасым юк җыенып;
Тын бүлмәдә янган утка карап
Утырам ялгыз, кашым җыерып.

Тышта буран улый. Ә мин тыныч, —
Тугарылып куйган атларым;
Утырам утка ягып күңелемнең
Тапшырылмый калган хатларын.

Кайда салыйм, кемгә, кай тарафка? —
Адресаты, нишлим, билгесез;
Калмасын ла ятка, янсын утка
Энҗе-асылташка биргесез

Асыл хатирәләр... —
Садә яшьләремнең чишмәләре
Кипкән инде, сүнгән, оеган.
(Су да китә — юлы томалана —
Су алынмый торган коедан.)

Хатларымның канатлары яна,
Күмерләнеп яна... әрнүсез;
Үземә-үзем хуҗа — Алла булып
Яшәп карыйм әле Тәңресез.
...Әшьяларның төсе үзгә!..*
Уты гына,
Уты гына үзенең төсендә;
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Янган утка карап песи ята
Тезгә салган мендәр өстендә.

## СИН — БЕР ГЕНӘ...

Меңнәр арасында син — бердәнбер,
Син бер генә дөнья йөзендә;
Бер гомер ул нәрсә?!
Мөмкин булса,
Бирер идем унын, йөзен дә

Сиңа гына... Син кайларда хәзер,
Җир шарының кайсы төшендә?!
Нинди билгеләрдән танып дәшим,
Очрата калсам төшемдә?!

Чәчкәләрең кайда орлык коя,
Туфрагына нинди түтәлнең?!
Син гөл идең, сеңлем,
                    һичберкайчан
Шиңмәс гөле ерак үткәннең.

Дуслар, иптәш, таныш, якыннардан
Бармы кешең «абый» диярлек?!
Син — беренче идең, син — бер генә,
«Сеңлем» итеп башым иярлек.

**МӘХӘББӘТ ЭВОЛЮЦИЯСЕ**

Әкиятләр укый идем шашып:
«Таһир белән Зөһрә» кыйссасын,
Кешеләрдән качып тын бакчада.
...Аh,
Шул чакта ук уйда син булгансың.

Агачларга менеп, биеклектән
Ерак кырлар түрен күзләдем, —
Ачылдылар хозур манзаралар.
...Аh,
Шул чакта ук сине эзләдем.

Нинди киң бу дөнья, — йөгер, уйна, —
Яшьлек белми кимлек, тарлыкны:
Күге биек, йолдызлары якты.
...Аh,
Белдем шулчак синең барлыкны.

Болыннарга чыктык, таңга каршы
Көлә-көлә сүтеп тараттың
Гөлләр исе сеңгән чәчләреңне.
...Аh,
Мин шул чакта сине яраттым.

Чыкты җилләр, ышыкладым сине,
Кулы каты була ир-атның, —
Кочагымда килеш сулды гөлләр.
...Аh,
Мин шул чакта сине елаттым.

Тынды дөнья, күтәрелде кошлар,
Мин аларга төзәп ук аттым, —
Берсе төште еглып алларыма.
...Аh,
Мин шул чакта сине югалттым.

Мин идем ул сыра залларында
Бер почмакта оеп утырган, —
Яшьләр тулы касә кулларымда.
...Аh,
Мин теләдем сине онтырга.

* * *

Атылып кердең...
Чәчләреңне йолкып,
Күз яшьләре белән илердең;
Бөгелеп төштең аннан үлән сыман:
«...син,

син...
җимердең!..»

Кичә әйбәт идем, бүген менә...
Бу хәлеңне нигә юрарга?
Көләргәме миңа, әллә бергә
Синең белән үксеп еларга?!

Ни кылырга миңа?! Тордым басып
Син илергән өстәл башында;
«Алла алдында кемнең гөнаһы юк, —
Мин гөнаһлы синең каршыңда».

Өнсез тордым карап иңнәренә
Сарылып төшкән сары яулыкка:
«Әйе, гөнаһлы мин, кичер мине,
Булган гаебемне ярлыка...

Ярлыкагыл!..»
Тибрәп куйды пәрдә,
Синең арттан ишек ябылгач;
Ачык тәрәз...
Шыксыз, буп-буш бүлмә —
Күзге алмагач кебек ялангач.

...Борылдың да киттең,
коридорда
Бары көлү тавышы ишетелде.
Нәрсә зеңгелдәде? Кайда? Ничек? —
Коелып төшкән өлге шикелле.

Хәерлегә булсын, рәнҗи алмыйм,
Үткән эшкә, диләр, салават;
Вакыт — табиб, үтә тора көннәр —
Син калдырган җөйне дәвалап.

* * *

Дулкыннар ярны кыйныйлар,
Җилләр бөгә талымны...
Исмә, җил, дулкын, бәрелмә!
Уйлыйм бергә чагымны.

...Ташкыннар ташып туктагач,
Ык төшкәч ярларына,
Безнең сөюнең ташкыны
Чыкты да ярларыннан, —
Таллары калды суларда
Күңелем болынының.
(Аклыдан күбәләк иде
Очында толымыңның;
Янмамын дип белдең микән? —
Утыма томырылдың.)

Күк гөмбәзен өскә ябып,
Дулкыннарда тирбәлдек;
Дулкында йөзә йолдызлар,
Без аларга тимәдек.
Җаныбыз айдан сирпелгән
Юл буйлап күккә табан
Ашты да — көмеш нурларда

Коендык бергә... Аннан
Атты таң... Алсу таңнарда
Зәңгәр томаннар иңде.
(Синең дә ситсы күлмәгең
Нәкъ шулай зәңгәр иде.)

...Ташкыннар ташып туктагач,
Ык төшкәч ярларына,
Безнең сөюнең ташкыны
Чыкты да ярларыннан, —
Суларга калды күмелеп
Күңелем болыннары...
Күкләргә ашар идем мин,
Юл булса толымнарың.

*** * ***

Төн. Яңгыр. Салкын. Караңгы.
Тик синең тәрәзәңдә
Яна ут. Утлар эчендә
Син мине көткәнсеңдер;
Кайтыр ул, тәрәз чиртер дип
Зарыгып беткәнсеңдер.

Күршеләр йоклый. Синдә ут,
Син әле йокламыйсың;
Кайткандыр инде диеп тә,
Мөгаен, уйламыйсың.

Менә мин — тере, исән-сау! —
Тәрәзәң каршысында.
...Күкрәгемә ташланып
Син каршы алырсың да...

Чиертәм... Ә син йоклыйсың,
Өстәлгә башың куеп;
Йә, ничек итеп уятыйм,
Нарасый, сине кыеп.

Йокла син! Җил ни, яңгыр ни! —
Төкерим барчасына,
Син уянганны көтәм мин
Алмагач бакчасында.

Төн. Яңгыр. Салкын. Караңгы.
Тик синең тәрәзәңдә
Яна ут. Утлар эчендә
Син мине көткәнсеңдер,
Минем хакта гына уйлап
Изрәп киткәнсеңдер.

## «ПӘРИ КЫЗЫ» ТУРЫНДА ӘКИЯТ

Пәри кызы гүзәл, сихри була
Әкияттә...
Ул да пәри кызы, ахры;
Акылыннан шашар дәрәҗәгә
Җитеп йөри аның Таһиры.
Башка беркем кирәк түгел аңа,

Күзе — сукыр, аңы — томана;
Чыга да ул юлга, басуларга
Тын кичләрдә, зәңгәр томанда, —
Аны эзли — табып югалтканын,
Шундый сылу «пәри-җен» кызын;
Мәңге сүнмәс газапларга салган,
Бар утлардан якты йолдызын.
Тора да ул карап сүзсез генә
Агачларның яфракларына, —
Кулы белән сыйпый, битен куя
Яшеленә — сафракларына.
Иелә дә аннан үләннәргә,
Үзалдына нидер сөйләнә;
Күзен теки юлга... Ә юлларда
Тузан гына — «пәри өйләнә».
«Юл өстеннән купкан өермәләр
Урлап китә пәри кызларын...»
Әкиятме?! Чынмы?! Барыбер аңа, —
Ул еларга әзер кызганып.
Кала да ул сәер көлемсерәп
Тузгып узган «пәри туена»,
Җеннәр кереп качкан тауга карап,
Чума тагын тирән уена.

## БӘБКӘ САКЛАУЧЫ КЫЗГА

Төш тә, сеңлем, казлар төшкән җиргә,
Хат язарга апмен* кавырсын...
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Бер кыз йөри анда
Һәр көн таңда,
Син беләсең аны — танырсың:
Казлар саклап бәбкә үстерә ул...
Ул үзе дә кызыл томшыклы
Сары йомгакларга охшаш әле, —
Бер бәбкәсе генә тормышның.

Уйный, көлә, йөгерә, сикерә ул
Түмгәкләрдән түмгәк өстенә;
Яшәү аңа тоташ бәйрәм әле,
Үтәр түмгәкләре
Бәбкә чаклы гына, кечкенә.

Төш тә, сеңлем, сиздермәстән генә,
Ындыр артлап кына, тыкрыктан;
Читтән генә күзлә уйнаганын
Бәбкә белән кызның; куркытма,

Ялгыш онытылып дәшә күрмә,
Яшьлегеңә, үзеңә охшатып;
Үткәннәрнең капкалары ябык,
Ачып кына булмый, юк, шакып.

Син карап тор ошбу манзарага
Хәтер аша гына, ерактан;
Су буена төш тә
Кавырсыннар апмен
Истәлеккә, гелгә, озакка.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Очып узды казлар —
канатлары
Ак җилкәннәр кебек тартылган;
Кавырсыннар сибелеп кала җиргә,
сибелеп кала
Күтәрелгән казлар артыннан.

**СУКЫР ЯҢГЫР**

Бүрек кадәр болыт!..
Коя гына
Күл өстенә — су күбек кенә;
Гөлләр суга сусый — суга ява...
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Суга яуган су кебек кенә
Синнән калган соңгы хатирә;
Бу — бер гыйбрәт миңа,
Бу — бер сабак,
Хет ачулан мине, хет тиргә.

...Суга яуган яңгыр — сукыр яңгыр, —
Сөякләргә хәтле чылатмый;
«Чылатмаган яңгыр» үксетсә дә,
Үксетсә дә алай җылатмый.

Аҗагандай, күкрәүсез генә
Үтеп китте синең яшьнәвең;
Нәрсә соң бу: ачы хакыйкатьме,
Бер хатасы мәллә яшәүнең?!

**ТӨНГЕ УЧАКЛАР**

Күкрәп килде яңгыр...
Яфраклардан
Шыбыр-шыбыр тамды тамчылар;
Сусап яткан җиргә түгел, алар
Безнең иреннәргә тамдылар.
(Яшен идеме ул, әллә яшьме, —
Иреннәрне өтеп алдылар?)

Язмышыбыз ничек якын булган, —
Тамчы белән тамчы арасы;
«Мин бер аучы, син бер болан кызы» —
Икебез дә шундый нарасый

Идек лә без... Төнге яланнарга
Яланаяк чыгып йөгердек;
Чирәмнәргә ятып тәгәрәдек,
Сабый бала идек, тилердек;

Юләрләндек, шаштык; таңга кадәр
Таганнарга асылып атындык;
Онытылдык... Иреннәргә кунган
Бәллүр тамчы төшеп ватылды.

Ватылды да... Сулар бүлеп куйды
Кыйтга белән кыйтга арасын;
Менә хәзер...
Мосафирдай уйга калып торам
Гомер уртасында, чарасыз.
Күкрәп килер яңгыр,
еракларда
Утлар күреп каршы чабарсың;
Соңарырсың ләкин,
Мин кабызган төнге учакларның
Урыннарын гына табарсың.

**ТАБИГАТЬ БАЛАСЫ**

I

Табигатьнең тиңсез күкрәгендә
Тына белмәс нинди дулкын бар?
Яшь тал кебек җилдә тибрәп утыра
Колачларга сыймас тупыллар.

II

Тупылларга тиң син үзең юкса, —
Эчләреңдә нинди дулкыннар?!
Өзелергә җиткән тамчы сыман,
Карашларың тора сулкылдап.

* * *

Үтеп киткәч, бер карама икән,
Тартып алыр булып, борлыгып;
Күле кипсен, суы сеңсен икән...
Кайтма икән, киткәч, борылып.

Үрсәләнмә икән үргә менгәч,
Кул болгама икән күмелгәч;
Көянтәңнән килеп тотмам бүтән,
Чиләгеңнән суың түгелмәс.

Барсын оныт, күрмәмешкә салыш
Очрашкач, үтеп барганда:
Әйтерсең лә
Берни дә юк иде, булмады да
Синең белән минем арада.

* * *

Юлымның мин тауга менгән төшен
Җилеп үталмадым Ак атта;
Хәер, бу — «негатив» фото,
Кара белән язган язмаларын
Кояш нуры белән агарта.

Шуңа сабыр, гавам, чыгармый тор
Ялган риваятьләр, уйдырма;
Мин асылда һаман әүвәлгечә,
Кайда гына имзам куйдырма.

Ышанмасаң — сына утта, суда, —
Юләрсетмә биреп тик шөһрәт;
Һәм сынмасам, «Әйдә!» дисә Вакыт,
Читтә качып калмам күк шөлләп.

Уклы җәя бир дә менге ат бир, —
Ир канаты була җитез ат!
(Оч, Дөлдөлем, алга! Укны, кулым,
Җик Мәргәндәй туры төзәп ат!)

Ә беркөнне...
Эзсез югалсам да,
Атым ташласа да иярдән, —
«Ак»ны «кара» иде, диялмәм дә
Дошманыма башны иялмәм.

Юк, баш бирмәм, дулап чапкан атым
Ташлап калдырса да бер чатта;
Бервакытта дусны бирмәм ятка,
Дошманны дус итмәм берчакта.

Әмма, Вакыт, калган юлымда да
Сикреп меналмасам Ак атка,
Гавам көзгесенә төшкән рәсмем
Кара килеш калсын, «агартма»!

*** * ***

Теләсәң дә булмый — онытып булмый,
Минем кулдан килми, нишлим соң?!
Ирексездән синең эзне эзлим,
Туфрагына бассам Мөслимнең.

Менә монда,
Ык ярында учак яктык,
Уйнап кына, кызык өченгә;
Сизмичә дә калдык — ике юләр! —
Торып калдык
Дөрләп янган учак эчендә.

Мәңгелек ут ялмап алды безне,
Ялкынланып яндык учакта;
Һич тә шикләнмичә, тик бер көнгә
Кайтып килер идем ул чакка.

Син дә шулай кабат-кабат урап
Кайтасыңдыр ерак үткәнгә;
Учаклардан җылы алгалап кит,
Юлда, арып, хәлең киткәндә.

Үз-үземне генә алдыйм, ахры, —

Бер янганнар янмый!
Асылда без хәзер икенче:
Күмерләнеп ялгыз утырып калган,
Яшен суккан агач шикелле.

Әнә яшьләр — үсентеләр үсә,
Алар янсын, алар көйсеннәр;
Алар да бер сөю тәмен тойсын:
«Сөю — сәгадәт ул!» — дисеннәр.
Ә без?!

Бик еракта, Ыкның аръягында
Учак яна. Уты сүлпән инде, курыкма;
Кузларын җил кузгаткач кына,
Шәүләләре уйный офыкта.

**ЯКТЫ СЫН**

Урау юллар үтеп, уйга чумып
Кайтып килә идем авылга,
Япа-ялгыз, кичен япан кырда
тардым давылга.

Куна килде буран,
кинәт килде, —
Көтелмәгән кунак шикелле;
Күңелдә дә давыл иде бүген:
Буран белән буран иш килде.

Юллар читендәге читәннәргә
Сырындылар ятты сарылып;
Ерактагы — син җитәчәк утлар
Чак-чак кына китә чагылып.

Адашаммы?! — Ап-ак кар пәрдәсе
Каплап алды ярты дөньяны;
Юл күрсәтер йолдызлар да сүнде,
Шайтан белсен,
Кайда кояш чыгыш, кайда көн ягы?

Буран аръягында этләр өрә,
Безнең авылныкы, мөгаен;
Дөньялыктан бер өн көткән чакта,
Этләр өрүе дә мөлаем.

...Буран тынды таңда,
табигатьнең
Хакимдары — тагын сабырлык;
Карлар ята көлтә-көлтә булып,
Читән буйларына сарылып.

Җан да шулай кайчак —
Буран сыман —
Шашып, тузып, тилереп арыгач,
Тынып кала...

Сеңлем, һич тартынма,
Күңел ишекләрен каерып ач.

Ач та кер син!
Күрим бу дөньяның
Зәңгәр күген, карын — аклыгын;
Таулар төбәгеннән бер эз төшә, —
Ул синең эз микән, акыллым?!

Синең эз ул!
Син ул!
Бу дөньяда
Синдә генә шундый якты сын:
Февральнең бураннары аша
Тәрәзәмә төшә яктысы.

**И МӘХӘББӘТ!**

Һәр тән буйлап ага бер агымсу,
Һәр күкрәктә ага бер җырым, —
Җанны кап урталай ярып үткән,
Телеп-телеп үткән бер җылым.

И мәхәббәт! Шөкер, миндә дә бар
Синнән калган шушы бер яраң:
Аны уйлыймын да үлеп тереләм,
Өр-яңадан туып яңарам.

**ТОРМЫШ ГӨЛЛӘРЕ**

Гөлләр инде, гөлләр үлгәннәр,
Орлыкларын җиргә күмгәннәр, —
Алсуланып торган йөзләре
Салкын карлар кебек — күм-зәңгәр.

Җирдә башлана да Яшәү, Җирдә сүнә,
Соңгы тәхет — Җирнең кочагы.
(Гөл орлыгы җирдә йоклый әле
Төштә күрә-күрә кыз чагын.)

Яшәү — Үлем аша; гөлдән тамган
Бу орлыклар язын гөл булыр;
(...Җаным Сездә кала,
Тән үлгән көн
Яңа тормыш туган көн булыр.)
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Шундый уйлар белән чыгып киләм
Чәчәкләрнең каберлегеннән;
Аһ, яшәгән саен бу Тормыш
Газаплырак...
Кадерле генә!

* * *

Гомер чигеп кенә яши Кеше... Аннан чигә —
Чиккәннәрнең ни газабы бар?!
Ярлар буйларында арып ауган

Өянкеләр — динозаврлар.

Дәрийгъ! Кояш баеп бара... Җилләр
Җилкапканың яба изүен.
...Һәм кузгала Яссы-Саз түреннән
Көтү — Аксак Тимер чирүе.

* * *

Киткәнсең юкса... Көләсең... —
Син инде шундыйрак.

Каберләр — уртак безнең,
Җаныбыз гына — ерак...

* * *

Төтеннәре туры чыкканнарның
Урау була кайтыр юллары,
Дигән иде кырда юлаучы карт.
Мин юлымны озак юлладым,

Ахрысы... Сырындылар сара —
Эзләр күмелә, сүнә, югала.
Кичәгедән калган хатирәләр
Тоныклана бара. Юк алар.

Урамнар буш. Койма ярыгыннан
Өреп торган әрсез җил генә.
Хәбәре юк инде дигән кебек,
Иләгендә карлар җилгәрә.

Ак төтеннәр чыкмый морҗагыздан,
Капкаларга йозак эленгән.
Өянкегез моңсу. Ак йөзләре
Телем-телем булып теленгән.

Төтеннәре туры чыкканнарның
Урау була кайтыр юллары,
Диде юлаучы карт.
Сезгә җиткәч,
Хәлсез калды аяк-кулларым.

* * *

Урман. Тын. Шомлы уфылдый
Бары ябалак кына;
Югыйсә таң аткан иде бит
Әле яңарак кына.

Көн туган иде яктырып,
Бар җиһан нурда иде;
Офыклар көләч... Кояш та
Иң биек турда иде.

Кай ара иңде эңгерләр,
Кай ара җитте киче?
Төн куып җитте юлчыны
Урманга кергәч... Читен.

Сәфәргә чыккан иде ул
Моннан мең еллар элек, —
Сихри атаулар артында
Гүзәл балкышлар күреп.

Барды да барды, — дәштеләр, —
Борылып карамады.
(Төн. Урман. Байгыш уфылдый
Очында караманың.)

Алда — үр... Анда — яктылык.
Үзәндә — күләгәләр.
(Күлмәге — ертык. Юләрлек
Гел шулай түләнә лә.)

Таң белән юлга. Юллары
Чытырман урман аша.
...Уйлый ул. Уен биштәрләп,
Йокыга урынлаша.

Урман. Тын. Авыр уфылдый
Бары ябалак кына.
Таңнарга ерак... Сүнде көн
Әле яңарак кына.

* * *

Әйтәсең кайчак: «Тузгыттың
Бер дигән тормышымны».
Җимердем хәрабә өстенә
Корылган куышыңны.

Өермә... Хәбәр бирсәңме —
Күптән юк булыр идем!
Хәзер билгесез тарафка
Аткан ук кебек инде.

Йә, нигә сиздермәдең бер
Артык йөк икәнемне?
Юкса мин арбам чүмәлеп
Киткәнне көттеримме?

Шикләнмә тагын, юлыма
Аркылы басар, диеп.
Ябып куелган тәрәзне
Вакытсыз кагар, диеп.

Курыкма, төшмә хафага,
Урынсыз борчуларың.
Сиңа да җайсыз түгелдер.
...Мин дә иркен суладым.

* * *

Сүрелде көннең күзләре,
Шым калды әрәмәлек;
Җанымда — тегермән ташы ла,
Суларга бәрәм әле.

Уянсын кошлар, балыклар
Тегермән буасында;
Таң атса, дөнья кендеген
Буардай буласың да...

Иске тегермән...
Җен кызы,
Тор да син, үр дә чәчең, —
Югыйсә синең урманда
Карт дию — ялгыз яшим.
(Чикләвекләр кысыр быел —
Төшләрен алды яшен.)

Тегермән ташы...
Ватылган, —
Суларга бәрәм әле.
Ачылсын көннең күзләре,
Терелсен әрәмәлек.

* * *

Шәраб залларына кереп кенә
Юшкыннарың юсаң икән ул!

Киткән-беткән, каны белән кипкән —
Сөйгән ярым, хуш-сау, исән бул!

**ЦИРКТА**

Исемең генә синең менге ат.
Юкса кол син —
Кырлар ирке сиңа мәңге ят.

**КҮМЕЛГӘН ЭЗЛӘР**

Бурый-бурый ап-ак карлар ява... —
Урый-урый кайта үткәннәр;
Килгән кунакларым күптән киткән,
Килалмыйча калган — көткәннәр.

Кучкарда шәм яна...
Тама-тама
Сабырландым, суындым, ардым.
Төнге буран ак ялларын тарый

Өй түрендә сырындыларның.

Соңгы дулавыдыр — сискәндереп
Читән арасыннан җил бәрә.
(Еллар безне онга әйләнгәнче
«Читән иләк» аша җилгәрә.)

...Һәм шул вакыт ишек ачылып китә.

Шәм алам да, хәтеремә килеп,
Карлы сукмакларга тезләнәм;
Язлар исе килә — яшь кар исе! —
Кичәгедән калган эзләрдән.

Карлар ява... Бу җиһанга Күкнең
Күпме аклыклары түгелгән;
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Эзең атлый минем янәшәмнән,
Үзең генә аерым «күмелгән».

## ТӨШ

Когда же наступит время разлучиться,
Вручи мне яд, прошу тебя об этом.

*Адам Мицкевич*

Сиңа барыбер мине калдырырга
Туры килер, ахры, мәңгегә;
Ә хәзергә — алда якты көннәр,
Эндәшмә лә, дәшмә әлегә.

Дөньялыкның ләззәт-намын татыйм
Бөтенләйгә, гелгә киткәнче;
Үләргә дә риза, назла гына,
Сөякләргә кадәр үткәнче.

Әмма таңнардан да якты төндә
Соңгы юлга сәфәр киткәндә,
Син агу бир миңа — интектермә! —
Тел очларым көеп кипкәндә.

Мин авармын синең кочагыңа,
Сине күреп торган хәлемдә;
Иреннәрем синең иренне эзләр,
Җылы суынгач та... тәнемдә.

Әйе,
Йоклармын мин күзеңә карап —
Керфекләрем ачык көенчә;
Әмма Вакыт агар гел бүтәнчә:
Көнем — төнчә, төнем — көнемчә.

...Һәм бервакыт искә төшерерсең —
(Бәлки, айлар-еллар үтүгә?) —
Тылсымы бар синдә...
Төшәрсең дә күктән — уянырмын
Маңгаемнан иелеп үбүгә.

Каршыларсың аннан пар атларны,

Чыгып басарсың да болдырга;
Мин торырмын тагын әзер булып
Табаныңда туфрак булырга.

**СОҢГЫ ЧАБЫШ**

...Утлап йөри тышауланган атлар.
Соңгы чабышкадыр?! —
Иярләрен барлый ят җайдаклар.

...Өзелделәр тимер өзәңгеләр.
Ничә тапкыр аңа
Өзекләре белән кизәнделәр.

...Уңлы-суллы уйнап торды камчы.
Агып төште күзе —
Соңгы тере күзе — утлы тамчы.

...Бәйгеләрдә туза икән йөрәк.
Көчкә басып тора,
Аумас өчен, җиргә башын терәп.

...Бик еракта тайлар куя кешнәп.
Тик ул ята инде,
Телен аркылыга тешләп.

* * *

*Р-га*

Басмадан чыга идең син,
Мин кереп килә идем,
Сыныңны
Ерак-ерактан ук
Күреп килә идем.
Тирбәлә иде суларда
Көләгән — ак күлмәгең.
Моңсу идең, уйчан идең —
Уйларыңны бүлмәмен!
Дигән идем... тын гына
Үтү иде исәбем, —
Ләкин сиңа җитәрәк
Нәрсә булды, нишләдем?
Үталмадым, туктап калдым, —
Басма мәллә тар иде?
(Чәчеңә үргән тасмалар
Күлмәгеңә пар иде.)
Син чыга идең... Каршыңа
Мин кереп бара идем;
Текәлеп тордың... Арабыз

Кул сузым ара иде.
Аннары бер талпындың да:
«Йә, абый, сау бул», — дидең.
Һәм асылма басма буйлап
Кырга чыгып йөгердең.
...Өлгердем көчкә тотынып, —
Чайкалды басмаларым;
Җилдә җилфердәп калды тик
Чәчүргеч тасмаларың.

**«МЕҢ ДӘ БЕР КИЧӘ»**

Укыдым төннәр утырып
Әкият ничә.
Әкиятемнең исеме —
«Мең дә бер кичә»,
«Мең дә бер кичә».

Галәветдин лампасының
Куыгы ничә?
Мәгарәм эче яктыра
Ул килеп керсә,
Ул килеп керсә.

Бер, ике, өч... Бер, ике, өч...
Санадым ничә:
Бүгенме минем бүгенем,
Кичәме — кичәм?

Бер, ике, өч... Бер, ике, өч...
Санама ничә:
Ир-егет гомере эчендә
Мең юллар кичә,
Мең юллар кичә.

Бер, ике, өч... Бер, ике, өч...
Аңыштым кичә:
Тормышның һәрбер кичәсе
Мең дә бер кичә!
Мең дә бер кичә!

**КАЧАК**

Елады татар агае,
Маңгаен бәрә-бәрә:
— Җилкәнем җилләр җыялмый, —
Теленгән парә-парә.

Таушалдым, энем, күкрәгем,
Мөгаен, челтәр генә.
«Кемең бар?» дисең.
Этем бар —
Кыскасы, читләр генә.

Читләрдә йөрдем, Зимагур...
Менә кыш җитте, энем.
Мәйтәмен, кайтып егылыйм, —
Бу минем соңгы көнем.

Менә мин хәзер, — аңла син, —
Туган җиремдә качак.
«Сытык» диярсең. Ашыкма, —
Үләсе килә кайчак.

Тормыш ул — диңгез, диләрме,
Йөзеп кара җилкәнсез.
Ирләр ул, туган, торалмый
Баш куярлык җилкәсез.
Өйләндем мин дә Кузбассның
Бердәнбер чибәренә...
Юк, җитәме соң, энем,
Безнең як чирәменә, —

Анда бит, — кая карасаң, —
Тузан да күмер генә.
...Чирәмгә ятып елыйммы? —
Үтте шул гомер генә.

Нужа кумаса, авылдан
Мин кубар идеммени?
Торган җир оҗмах булса да,
Ул туган илеңмени?

Елады агай, маңгаен
Өстәлгә бәрә-бәрә.
Кайткан ул...
Җилкәнсез көймә
Ярларга бәргәләнә.

**КӨЗГЕ БИЗӘКЛӘР**

Агачлар очы — буялган төсле пумала кебек.
Яфраклар — суларда. Агымсу — күбек, күбек...

Болытның итәк җилләре уҗымны сыйпап үтә.
Басу түрендә — карама. Карама кемне көтә?

Колыннар үсә чабышып. Бу болын шундый иркен:
Хозурлык һәрбер тарафта — бозалмый моны беркем.

Көтү дә төшкән туплауга. Бәрәннәр йөгереп уйный.
Йокыга талган көтүче, үткәнен уйлый-улый.

Кыр казы үткән юллардан үксү кала сибелеп.
Моңсулык иңә... Алай ук түгел идең син элек.

* * *

Карлар яумый, карлар тик тора.
*Зөлфәт*

Өркәч-өркәч кар көртләрен сыйпап,
Буран уйный урман буенда.
Ничә тапкыр юлга җыендым мин,
Чыга алмам, ахры, быел да.

Җәйдән сабып куйган юлларымны
Ак бураннар күмеп киттеләр.
Үрәчәләр тулы ак хисләрем...
Ах, хисләрем түгелеп беттеләр.

Кызыл төлке... Төлке чабып үтте
Алан аша... Әллә яшенме?
Ак бураннар итәгенә сөртәм,
Итәгенә бозлы яшемне.

**ЯШӘҮ АГАЧЫ**

I

Яшәү мең катлы була,
Сөю бер катлы була;
Сөюнең күңел келәте
Бер орлык белән тула.

II

Орлык эчендә орлык бар,
Орлык тулы күзәнәк;
Күзәнәктә Яшәү йоклый, —
Бу да безнең күрәчәк.

* * *

Авылымның зират башында ук
Чыгып баскан шәрә тупыллар...
Элек монда йорт нигезе иде.
Атлар тора иде тупырдап.

Иртәләрен кошлар сайрый иде,
Утлар терек иде учакта.
Яшь киленнәр, җан бирердәй булып,
Эреп ятыр иде кочакта.

Акъәбиләр ак шәл бәйләр иде,
Чыгар иде кызлар кияүгә;
Нәсел орлыклары — мөлдеркәчләр

Аваз салыр иде биләүдә.

Ир-егетләр ат уйнатыр иде,
Китәр иде аннан... сугышка.
Кычытканнар белән түгел, түгел,
Утлы яуга кереп сугыш та... —
Янма, имеш. Ул елларның
Сөремнәре каба сулышка.

Агач башларында — кара кошлар,
Яланнарда ята сөлдәләр*.
Кара кошлар кызыл томшыкларын
Корыган ботакларга сөртәләр.

...Бу тупыллар шундый мәгърур иде,
Уртасында иде Бүләкнең.
Нигә, Вакыт, кеше язмышларын
Агачларың белән түләттең?..

Чигенә авыл. Урам очына ук
Чыгып баскан мамонт тупыллар.
Әллә тупыл — зиратына бара.
Әллә авыл — качкан тупылдан.

**КӨЗ. КИЧ**

Җилферди киртәгә
Эленгән ак чыптам.
Көлешә кыз-кыркын:
— Ай чыккан! Ай чыккан!

Аранда — чаптарым,
Су буе — кычыткан...
Көнозын әрнедем:
— Юк, чыкмам! Юк, чыкмам! —
Бигрәк усал ла
Картайган кычыткан.

* * *

— Юк, кайталмам әле быел яз, —
Телем кыска хәзер, сүзем аз.

— Юк, кайталмам әле быел җәй.
(Ах, дөнья бу! Урының киңрәк җәй.)

— Юк, кайталмам инде быел көз, —
Тәрәзәмдә генә ике күз.

— Язлар, җәйләр, көзләр, үтте кыш, —
Көтә-көтә үтте бу тормыш.

...Килеп җитте шушы хәбәрең, —
Соңга калдым. Сау бул, хәләлем.

* * *

Җиде ятны сөю, бәлкем, язык,
Ятларныкын сөю — килешми!
Сугылдым мин синең утарыңа
Ераклардан кайтып килешли.

Синең биләмәләр... Гөлгә чумган бакча,
Бакча түрендәге ак келәт...
Ак болдырга чыгып басты бер кыз:
— Сакал абый, сиңа кем кирәк?

Биштәремне, салып, җиргә куйдым.
Изүемне ачып җибәрдем, —
Иркен утар бик тар иде миңа:
— Кемнәр яши монда, чибәрем?

— Ничек кемнәр?! Койрыклы җеннәр...
Әнкәй әле басу эшендә,
Аю Куышыннан ары китеп,
Чытыр Бүләк дигән төшендә...

Шулчак бар да эреп юкка чыкты, —
Кое сиртмәләре, ак келәт...
Үтеп кенә булмый үткәннәргә,
Көмеш тәңкәләрдән хак түләп.

— Йөз ел элек син дә анда идең.
— Мин бит күчтем бары җидегә, —
Ак болдырдан төшеп йөгерде ул, —
Юләррәк абый! — диде дә.

Карашлары гел синеке иде,
Йомры бит очлары — сипкелле.
Зөһрәдәй кызчык әйтеп качты:
— Бу... бу... биләмәләр — си-не-ке!..

Ят утарда ялгыз басып калдым,
Күрше-күлән күрер — килешми.
Сугылдым мин синең биләмәңә
Мәңгелектән кайтып килешли.

* * *

Туу — ул сәбәп кенә,
Яшәү дә — сәгать кенә!
Шаяртма, туган, «кү-кү...» —
Күкеле сәгать көлә.

* * *

Кем әйтте? —
«Дөньяда
Яшәүләре куркыныч...»

Әй, мәхзүн йөрәк! —
Бул тыныч!
Тыныч!
Тыныч!
Башыңның өстендә
Торса да сөңге-кылыч.

Ярсынма, талпынма —
Бул сабыр!

Сабыр!
Сабыр!
Күкрәгең югыйсә
Күмергә тик калыр.

Туктамый — яна ул...
Яныр!
Яныр!
Яныр!
Сүндерә алмый аны
Җил, яңгыр, буран, давыл.

...Тук та тук, тук та тук, —
Туктама, йөрәгем!
...Юллар түрендә — талир...

* * *

«И-и», — дисәң, башлар иелә, —
Кайчак шулай диелә.
Иелмә, башым: иелгән
Башка мунчак киелә.

* * *

Алмадым да... (аңладың ла!) —
Сөюгә нигә чылбыр?
Алтыннардан кадерле син,
Бу сөю, бәлкем, чындыр.

* * *

Бу өйдә күптәннән
Яшәми берәү дә:
Капкасы — йозаклы,
Коймасы — терәүдә.

Тик һәр иртә бу юллар
Себерелгән, көрәлгән булырлар.
Кешеләр ничектер елмаеп
Үтәләр аларның турыннан:

«Һай, үзе дә туксәндә, Гаптери
Кайчан бу эшеннән тыелыр;
Дөнья бит — кары да явылыр,
Канат та, яфрак та коелыр».

...Кемнәрдер: «Җүләрдер!» — диделәр.
Кемнәрдер: «Әҗере...» — диделәр.
«Җүләрме?», «Әҗереме?» — бер Хода беләдер,
Алар бит күршеләр иделәр.

* * *

Мело, мело по всей земле
Во все пределы.
Свеча горела на столе,

Свеча горела.

*Б.Пастернак*

Буран да буран... —
Күмелгән урам.
Шәм генә яна өстәлдә,
Шәм генә яна.

Утлы тәрәзгә сарылган
Черкиләр сыман,
Кар мамыкларын рамга
Җил йөри сылап.

Буран пыяла битенә
Ак кершән яга.
Шәм генә яна өстәлдә,
Шәм генә яна.

Мин карап ятам... Түшәмгә
Күләгә ятты, —
Аяк-куллар сурәте бу,
Язмыш сурәте.

Ике башмак, дөбердәп,
Идәнгә төште;
Күлмәккә тамды балавыз
Шәмнән — яшь төсле.

Аклыкка кереп күмелде
Тыкрык, урам...
Шәм генә яна өстәлдә,
Шәм генә яна.

Шәмгә җил үтте кагылып,
Ак болыт булып.
Ялкын телләре уйнады,
Тын бүлмә тулып.

Февраль. Буран. Ак көрткә
Күмелде урам.
Шәм генә яна өстәлдә,
Шәм генә яна.

*** * ***

Беләсеңме, Зөлфәт, Мәсеготнең*
Урыны гына калган үрләрдә...
Һәм истәлек булып ярлар калган
Билсәпитле зәңгәр төннәрдә.

Беткән авыл... Оясы
Таралган, җилгә очкан.
Сиртмәле кое һәм тупыл
Моңая Югарочта.

Җилләрсез, тыныч көннәрдә
Сиртмәле шушы кое
Арып талган карт ат кебек
Тын гына тора, оеп.

Чыкса җил, авыл өстеннән
Чиләге дулап-дулап
Әйләнә... Тимер чылбыры

Куя да авыр сулап...

Асылма чиләк сиртмәдә —
Бу авыл йөрәгедер!
Дидем: «Эчкән коеңны да
Онытма, кирәгер бер».

* * *

«Гел турыдан гына ярганнарның
Урау була кайтыр юллары...»
Поезд киткән, шлагбаум ябык, —
Бу юлы да җитешеп булмады.

Озатучым, каршы алучым да
Булмас, ахры, төнге вокзалда;
Диван почмагына башны салып,
Мин онтылып тордым беразга.

«Сөю-сөелүләр, имеш!.. Болар бары
Вакытлыча гына, ялган ич!
Нәҗагайлар юкса чикләвекнең
Төшкәйләрен күптән алган ич!

Нигә кирәк шундый мәҗүсилек,
Нигә кирәк шулай җан ату?!
Ярату ул китапларда була,
Фанилыкта булмый ярату!»

...Шлагбаум ачык... Казаныма дигән
Поезд килеп җитәр бераздан.
...Урау-урау юллар ялтырашып
Сузылып калды төнге вокзалдан.

* * *

Аһ, китәсе килми синнән, Казан, —
Мине алып китәр поездның
Уты да юк, номер-чутыры да,
«Проводнигы»на хәтле... мылтыклы.

Көпшә күзләреннән, үрелеп-үрелеп,
Озатып калды Ослан таулары.
«Авар!» дигәннәрдер...
Ауган чагымда да
Тотып калды Туфан «ау-у»лары:
«Һәрбер көпшә-ядрә атмый ла ул,
Чәчәкнең дә була көпшәсе;
Гөлләр әнә, гөлләр нишләр иде,
Бу көпшәләр өзелеп төшсәме?!»

Шушы көннән башлап, ахрысы, мин
Чәчәкләрне бигрәк үз күрдем.
...Кичер, Туфан абый, кичерәлсәң, —
Мин «анда» да чәчәк үстердем.

* * *

...Төлке уйный торган орлар бар.
*Халык җыры*

Чалгылар тагын чормага
Эленде. Кибәннәрнең
Итәген җилләр тарый.
Умартачы Мирхәйдәр карт
Шул якка карый-карый
Уйланып тора. Уены̧
Исәбе-хисабы юк:
«Төлкеләр уйный, ах, мут,
Күзләрендә — кызыл ут!
Димәк ки, еллар алга да
Киекле, кошлы булыр.
Чүнник эчендә тәпәннәр
Бал белән тулып торыр».

...Кибәннәр кипте. Мирхәйдәр
Инде күптән «тегендә».
Кызыл төлке уйнап йөри
Шәрә кырлар түрендә.

* * *

Атлар тугарылган. Кабык арба
«Зенитка»сын күккә төбәгән;
Йолдыз ярчыклары шыбыр-шыбыр
Коелдылар калай түбәгә.

Өйалдында йоклап яткан кызый
Рәтләп куйды мамык юрганын;
Һәм күкләрдән йолдыз атылуын
Бәхет килеренә юрады.

Таңнар аткач, тәртә каерылыр,
Сыеры савылыр, аты җигелер;
Мирхәйдәр карт кына тормый калды
Урын өскәендә, йөгенеп*.

* * *

Китүдән дә кайту авыррак
Бу дөньяның чиксезлегендә;
Яшәү белән Үлем арасында
Яши кеше — үз читлегендә.

Мәңгелеккә! диеп килгән идем,
Узсам узганмындыр бер саплам;
Сәхәрдә дә бер сүз, ахшамда да:
«Югалтырлык түгел, югалтмам».

Гомер җебе кыска — бер саплам.

* * *

Эскерт өстендәге Айның

Кыерчык кына чагы;
...Әле яңарак кына
Сүнде юлчы учагы.

Уянды төнге шәүлегән,
Шым гына чыктыауга;
Бер арба менеп килә
Төн ката — Калатауга.

Арбада — икәү. Арба ул
Теркелдәп кенә бара.
Атасы «кучер» улының
Башыннан сыйпап ала:

«Дилбегәңне, дим, катырак
Тот, улым, атың сизсен
Егетләр кулын». (Алда — тау,
Нишләрмен, әткәй, синсез?)

Эскерт өстендәге Айның
Тәгәрәп тулган чагы.
Арба. Юл. Әткәй һәм мин...
Бу — минем бала чагым.

* * *

Алиһәләр кунды кочакларда,
Соңгы сулышы булды: «Ү-ләм! Ү-ләм!»
Бер рәхәтнең мең газабы булып
Шытып чыга җиргә кеше-үлән.

* * *

Кичкә авышкан вакыт.
Явып үткән.
Табигатьнең үзгә бер мәле.
Җанландырды кинәт кыйгач нурлар
Шактый шыксыз, тынчу бүлмәмне.

Иркенәеп китте йортым эче
Тәрәзәдән төшкән нурлардан;
Икмәк исе керә — яшәү исе! —
Арыш серкәләнгән кырлардан.

Мин сокланып карап тордым шулай:
«Юк, бу дөнья башка, икенче, —
Йокысыннан әле яңа гына
Уянып килгән сабый шикелле
Саф һәм садә...
Яңгыр суы белән юылган».
Кыйгач нурлар сибелә җир өстенә
Очып үткән кошлар юлыннан.

...Һәм киереп ачам тәрәзәмне,
Якты нурлар күбрәк керсеннәр;
Дөнья — матур! Аның матурлыгын
Бүлмәм гөлләре дә күрсеннәр.

Киче хәтта таңга охшап тора, —
Табигатьнең үзгә бер мәле;
Почмакларга хәтле якты иңгән,
Мин танымый торам бүлмәмне.

Мин аңламый торам: кичкә каршы
Тирә-юнем нурга күмелде;
Кайчак бер ым, бер якты нур җитә
Эретергә безнең күңелне.

* * *

Алдыма өзелеп төшәләр
Саргайган
Парашют-яфраклар;
Көчкә асылып торганчы
Бу, бәлкем, яхшырак та.
...Алдыма өзелеп төшәләр.

Мең сере бардыр яшәүнең —
Кайчакта
Бик түзем булу кирәк;
Усак яфрагы күк җилферди
Җилсез дә — тузган йөрәк.
...Мең сере бардыр яшәүнең.

Ышанып йөргән буласың
Яктырак
Киләчәк җитәсенә;
Тибә дә язмыш-ат
Тормышның киртәсенә.
...Ышанып йөргән буласың.

Басасым килми — тередер! —
Кыштырдый —
Өзелгән яфракка.
Юл алам — бераз читкәрәк,
Аланга — яктыракка.
...Кыштырдый... Яфрак тередер!..

* * *

Бер эзгә басу кыендыр,
Мең кеше үткәннән соң;
Сөюнең булмый үткәне,
Ялганына хәтле... чын.

* * *

Эндәштеләр дә киттеләр:
«Ниләр, ни булды?!»
Кайтарып әйталмадым:
«Тулган... Ай... тулды!
Тулган... Ай... тулды!»
(Айга берни дә булмады,
Күңелем тулды.)

Шәрә ботак арасыннан
Сузылды мең кул.

Ялгыз кеше — ялгыз агач...
Төнге урман. Юл.

Үләннәр буйлап шуыша
Агачлар күләгәсе...
(Бер минут ташып туласың,
Ел буе түләнәсең.)

Әйләнеп кайтты авазың:
«Тулган... Ай... тулды...»
...Ертык болытлар күзендә
Йолдыз тотылды.

* * *

Әйләнеп карыйсың: тирәңдә —
Күбәләк, кырмыска, бөҗәк!
Аңлыйсың килсә дөньяны —
Барыбер бер Фабр* булу кирәк!

Аныңча —
Үләндә дә бар йөрәк.

* * *

Төн кундым Гаташның
Алмагач бакчасында.
Яшьлек язы... уртак юллар, —
Яңарттым барчасын да.

Алмагач тирәли Җир шарын
Урап үтте Ай бер төн;
Күршеләр яккан учактан
Күземә керә төтен.

Дидем: «Ялкыны сүнгән лә,
Бу бит соң бары төтен».
Дөньям ярылган урталай,
Тулган Ай гына бөтен.

...Күршеләр яккан...
Төтен...
Әле ярый Ай бөтен.

* * *

Янымда юк берәү, җанымда
Хис белән акыл тату;
Тәкмәрчек атып китимме? —
Аһ, дөнья нинди мату-у-у...
Мату-ур!

* * *

*Р.Ф-га*

Түмәр бүләк иттең:
— Алып кайт әле үзеңә,
Карама син кеше сүзенә,
Һәркем яши бары үзенчә.

Ташлап калдыралмыйм...
Бүләк ич бу!
«Сүгеп» кайтып киләм түрәмне, —
Түмәр түгел, яшәү бигрәк авыр,
«Түмәр басып тора түбәмне».

Кайтып киләм...
Колачларга сыймас
Мең яшәрлек түмәр иңсәмдә;
Егыласы килми, егыласы, —
Вакытлыча башым исәм дә.
Тагын нәрсә кирәк исәргә?! —
Хәлем бетсә, килеп утырам да
Колач җитмәс каен түмәргә...

Миңа авыр, сиңа да бик авыр,
Сиңа түгел — миңа бик авыр.
Түмәр кебек гомер басып тора,
Дөньялары бигрәк болгавыр.
Аһ, авыр!

## КҮТӘРЕЛИК КҮККӘ ПАРЛАШЫП

*(Җыр)*

Ашыкмый тор, дустым, хушлашырга,
Җаннарыңны юкка борчыма.
Кара: әнә тормыш дәвам итә, —
Киек кошлар бала очыра.

Бала кошлар оча уйнап-уйнап,
Күккә куеп җилләр иркенә.
Язлар җитсә, канатлана күңел,
Очар кошлар кебек җилкенә.

Төркеменнән аерылган коштай,
Кала күрмә ялгыз адашып:
Бир кулыңны — ике канат булып
Күтәрелик күккә парлашып.

* * *

Кырын-кырын гына сугылып үтә
Дусларыма килгән кайгылар.
Әйтәм:
— Сезнең кайгы — минем борчуларым!..
(Күкрәгемдә олуг кайгы бар...)

Көн-таң атса — Яшәү һәм Үлем бар,
Уянам да — Сезгә түгеләм!..
Яшәү агачыннан — шәҗәрәңнән! —
Бер «яфрак» та артык түгел лә...

* * *

Ераклардан килгән тавыш сыман
Уяна да хәтер... Бөтерелеп,
Бөтеренеп — кичерәеп алам;
Тоныгая истә калган төсең,
Кайчандыр үз, изге якын кешем! —
Син барыбер миңа сабый бала.
...Ераклардан килгән тавыш сыман.

Агачларны үлән кебек кенә
Ерып чыгарсың күк үткәннәрдән, —
Пәрәвезләр сарыр иңнәреңне.
Ташландык бер йортның каршысында
Бүкәннәргә утырып көткән мәлдә
Җилләр җилфердәтә җиңнәремне.
...Агачлар да үлән кебек кенә.

Бер көнен дә калдырмыйча яшәп
Уза гомер — ага гына, чәчрәп,
Улаклардан аккан су сыман.
Сөю — дәрья, ярларына тулмый,
Аккан суга кабат кереп булмый, —
Ярда калам... Бәхил шушыннан.
...Бер көнен дә калдырмыйча яшәп.

Әлсерәтте еллар, әлсерәтте...
Яшьлегемнең соңгы тәэссораты
Карап тора агач артыннан.
Мин әлегә туган туфрагымда;
Гомеремнең сыңар яфрагын да
Бирмәс идем көмеш-алтынга...
...Әлсерәтте еллар, әлсерәтте.

Тып-тып гына август җиле исә,
Ераклардан килгән тавыш сыман.

* * *

Бу юлларның чиге булыр микән?
«Юк!» дисәң дә, бәлкем, чигенмәм;
Каешланып беткән күлмәгем дә
Урман гөле белән чигелгән:
Ак күлмәген чиккән сатиннан!

Юлларыма чыксам, юлларымда
Юлчылардан калган эз булыр;
Бер гөнаһым булса, мине саклап
Изгеләрдән калган сүз торыр:

«Авыр булыр, ләкин сатылма!»

* * *

Сүнсә дә көннең күзләре,
Урманның бетми сүзе! —
Йокларга диеп ятсаң да,
Колакка керә үзе.

Сизеп ятасың... —
Күзеңне
Йомган булсаң да үзең!

Күзеңне йомган булсаң да,
Ишектәге ярыктан
Җил исе керә, гөл исе... —
Ачыл, күңел!.. Тарыкма!

* * *

Дәфтәреңнең соңгы битләрен дә
Ябып куйгач, тугры сүз калыр.
(Ләхетеңә якты бәхет булып
«Сөю» дигән изге Сүз тамыр.)

Ләкин болар... Ләкин болар әле
Соңгы сүзе булмас Ходайның;
Яшәү дәвам итәр... Ә барыбер
Бохарадан килмәс бодаең.

* * *

Юлымда ятып еладым... Дошманнар
Уйладылар: «Үлде!» — дип.
Терелеп кайткач әйттеләр:
«Юк, ул үзе түгел», — дип.

(Барабан кага-кага
Шатланышып көлештеләр:
«Бу егет кая таба!»)

Мин яшимен,
Ә үзләре
Нәкъ тере мәет кебек;
Денен вә кальбен югалткан
Мосафир сәет кебек.

...Алар юк инде, мин йөрим
Карадан кара көеп.

* * *

Бу юлдан — мин дә үткән,
Бу юлдан — син дә үткән.
(Туфрак шул ук, кешеләр —
Кешеләр генә бүтән.)
Туфанның* җыйдым баланын,
Арырак... түргә үтәм!

* * *

Ишекме?.. Ачык ич ул! —
Бикләдең, бикләмәдең ни,
Дусларың бәреп кererләр;
Телим шикләнмәвеңне...
Йөрәкме? —
Ачык ич ул!
«Киләсе» —
Сузылган кул!

* * *

Яңгыры үтте чылатып... —
Агачлар өсләреннән
Тама да тама тамчылар
Керфегем очларына.
(Очланып бетә бит инде
Керфекнең соңгы очы...)

Егет белән кыз шикелле,
Имәнне каен кочып
Утыра...
Кеше — бигрәк көнчел!

* * *

Морҗам ярык иде...
Һәр эзенә
Янык чыкты — диклоскопия;
Күкрәгем дә шулай — һәр ярадан
Көек кала — бер эз! — копия...

Уйлый идем: янган кирпеч кенә
Яна-яна түзә... ишелә;
Янган утка карап утырам да:
«Утын һәм ут үзенең эшендә!»
...Көле төшә ялан өстемә.

* * *

«Йоклама!» дигән шикелле,
Тавышлар өйгә керә;
Агач флейталарда
Урман моң-көйләр өрә.

Кушыла алар баздагы

Чикерткә зеңләвенә;
Кешеләр йоклый булырлар,
Бу көй бер бездә генә!..

* * *

Иртәсен ачылды пион,
Төнендә сүнде күзе;
Тамырга бәреп канаттым —
Яралы тезем...
Үзем
Тотындым чәчәкләргә лә —
Чәчәкләр сабагына;
Бу миңа авыр чагымда
Сулмаска сабак кына...

* * *

Үләр идем... Булмый! Сезнең өчен
Кереп ятар идем ләхеткә!..
Мине бары бирәү генә сөя,
Кагылмагыз минем Бәхеткә!..

Күзләрдән дә язлар эзләп йөргән
Чаклар —
Булса буладыр ул яшьлектә!
Мондый уйланулар — гаҗәпләнмә! —
Язылып калган хәтта «Тәүхит»кә...

* * *

Күкләреңне терәп торыр чакта
Ай-Кояшка җитәр кул булыр;
Исән чакта дусларыңны барла, —
Каберeңә парлак юл булыр.
Исән чакта!

Тузан күченә дә, вакытлыча
Күзне томалый да бер элпә;
Югыйсә бит хисләр барыбер шул ук, —
Йөрәк тибә, тибә дерелдәп.
Исән чакта!

Кемгә кирәк китеп югалгачтын,
Югалткачтын юлыңның очын, —
Үлә-үлә мин яраттым сезне,
Яшәү, ахры... югалту өчен.
Исән чакта!

Аккан суларны да туктатырлык
Кабилият иңгән чагында,
Син туктатма мине, туктатырлык
Көчең барда, сагын-сагынма...
Исән чакта!

Күзгә керер бер тузан да җитә, —
Томаланып кала бар дөнья!
Яна-яна урман сүнеп бара, —
Янган агачларга тотынма!
Исән чакта!

Кулларымны гына сузган идем,
Мәңгелеккә килеп бәйләндең;
Тоташ газап инде... гасабилы
Көнаралаш үткән бәйрәмем.
Исән чакта!

Юлларыма чыксам, юлларымда
Семафорлар яна — яшел ут!
Агач тамырлары абындыра,
Абынсам да, барыбер мин шул ук.
Исән чакта!

Килер бер көн — кемгә генә килмәс! —
Соңгы сүзе — кайчысы белән.
Килер алар — Яшәү... Үлем,
Мин калырмын кайсысы белән?
Исән чакта!

* * *

Авырдым көн буе, —
Чәчәкләр шиңмиләр;
Әйтерсең, терел, абый,
Без бергә, диделәр.

* * *

Йөзәсең — йөзәр чагыңда,
Түзәсең — түзәр чакта;
«Далада яшәмибез» лә,
Яшибез бер кочакта.

Бары — бар, югы буладыр, —
Юксынуы бигрәк күбрәк.
Ничек чыдасын йөрәгем,
Күкрәүләр тулы күкрәк.

Яусын да яңгыр яшенләп,
Күкрәп, яшен белән;
Җәй үтеп бара... июль —
Түләрмен яшем белән.

Кич иде... Киче июльнең.
Моннан бер илле еллап
Башланган сукмакның ахырын
Очыннан киләм очлап.
Кич инде!

* * *

Кем seберер бу юлларны,
Таушалсаң, тузан булсаң;
«Аһ!» дияргә өлгермисең,
Йөрәгең тузган була.

Юлым өсте — урман юлы,
Урманга чыгасым бар;
Нинди хуш дөнья!
Урманда
Каены, чаганы бер.
...Урманга чыгасым бар.

* * *

Тау тау инде... Тауларның
Күкрәгендә чишмә бар.
Кемнәр килеп сулар эчте? —
Килер юлы бигрәк тар.

Юл салыйм дисәң, сал икән
Тауларга илтсә генә...
Үләнгә абынып еларсың
Тауларның күкрәгендә!

Биектән тавыш иңә дә
Ерактан еракларга!
(Сулар ага сикерешеп
Улактан улакларга.)

Күк тулып ишелде дә, Көн
Энәдән-җептән үтеп
Чылатып китте... Җылытып
Бер болыт тора көтеп.

Мәңгелеккә дип килсәң дә,
Шул бер гомерең белән
Яшисең... Таулар өсләтеп
Йөгерә соргылт үлән.

* * *

Чигелде җилләр җилендә — күлмәгем яфраклары,
Кундылар инде иңемә — сафтан да сафраклары.

Таң гына ата югыйсә — ә инде кич, дисең;
Куркытма кош авазын — болында әрем исе!

* * *

Болыты белән төшәр дә
Яңгыры белән ишәр;
Түбәм тишек... Исәнме,
Күкрәүле яңгыр, исәр!

Күчәр дә болыт, теләгем,
Кабул бул иясенә;

Әйталмый калырмын юкса
«Рәхмәт!» диясемне.

Барыр юл озын булса да,
Әйтер сүз кыска, кыска;
Батышка карап китсәң дә,
Кайтасың көнчыгыштан.

Көнчыгыштан кайта кошлар
Таң алдыннан, төялеп.

Капка төбендә торадыр
Сөйкемлесе сөялеп.

* * *

Киләсең дә бер китәсең,
Яшәп каласы килә.
(Югыйсә, «аннан» кабаттан
Кайтыр юллар юк, диләр.)

Шуңа да кайчак сабыр мин,
Бер карасаң — гел юләр!

* * *

Бу сәгать йөри дә йөри,
Туктамастыр, ахры;
«Туктамас Мәхмүт түгел дә,
Чиге юк бу аклыкның».

Туа да таң, кошларның
Ак канат җилләреннән
Өн килә: «Ташламас ла
Дустыңнан, ишләреңнән!»

Урман бу!.. Җилләр тавышы
Капканы ача киереп;
Гайбәт сүз булса да, әйбәт дип
Үткәрә бел иелеп.

Сүнә яфрак, сүнәләр дә
Җилкән кебек җилкәмә!
...Мин китәрмен дә... ул калыр,
Аны да шулай иркәлә.

* * *

Иттифакый дуслар арасыннан
Аны сайлап алдым — белегез...
(Сез чибәр дә түгел... бигрәк,
Бигрәк моңсу иде күзегез.)

Кеше җаны — әгәр күзләр булса,
Сөйкемлесе сездә — иншалла!
Тәрәзәләр ачык... Ачып куйдым —

Таң җилләре керсен, машалла.

* * *

Кереп утыра идең: «Ни хәлең бар,
Нинди хәлләр хәзер авылда;
Кемнәрең бар, кемгә сыенасың
Күңелеңә авыр чагында?»

Өйләндең дә, әйе, җиңеләйдең,
Җиңел юлда авыр сизелми;
Тәрәзәңне ачасың да, бәлкем,
«Югалдылар болар» дисеңдер.

«Дию» җиңел, «пәри» авыр була, —
Өермәсе белән сугылса;
(Дусларга да бер кирәгең калмый,
Өермәләр өереп, сыгылсаң.)

Барысы әйбәт... Сиңа кирәк чакта
Сүз дә килеп, җил дә сугылмас;
Шартлап-шартлап имәннәр дә ава,
Озак яшәр агач егылмас.

* * *

«Килүең дә авыр булды, — дидең, —
Яшәвең дә җиңел түгелдер».
Һәр сулышын тоеп яшим, әнкәй,
Өлешемә тигән дәвернең.

Әвернәгә үргән сүс җепләрен
Күкрәгемә үреп яшәдем.
(Югалтулардан соң аңлашыла
Бар мәгънәсе Олуг яшәүнең.)

Әйтер сүзең тамар-таммас чакта,
Өзелер чакта әйтер сүзләрең
Бик якында идең... Ә мин
Ерак кырлар түрен күзләдем.

Кизләүләрдә сулар кипмәс барыбер,
Үзәннәрдә чыклар кипмәсә;
Сузылган кул булыр, әгәр инде
Вакытлыча барып җитмәсәм.

**АККОШ КҮЛЕНДӘ**

Исәнме, Йортым! Тордыңмы

Гел мине сагына, сагына...
Кайтардың мине, рәхмәт,
Туфанлы, әйе, Хәкимле
Борадәран чагыма.

Чыгып басам да болдырга
Күренмәсме дип алар,
Мөдәррис, Мансур... ерактарак
Равил Фәйзуллин да бар.

Арырак барып төртелсәң,
Ишеге бар — теле юк!
Монда булган Мостай, Нәҗми,
Сәйфи, Агиш —
Берсенең дә эзе юк.

Яшәгән диләр кайчандыр
Монда Нәби Дәүли дә...
(Гаепсезгә гаепледер
Бер мосафир-әүлия.)

Капканы ачып керәм дә,
Кырык яшәр чыршылар
Фәрукъ абый кулы белән
«Килдеңме?» дип каршылар.

Исәнме, Йортым! Тордыңмы
Мин килгәнче исән-сау?!
(Күлләргә төшәсең дә,
Менгән саен — тау да тау!)

* * *

Акчасы ни, бакчасы ни,
«Зөлфәтлек»не югалтсаң? —
Хәзинәңдә ни җыр калыр,
«Юкка!» төбәп ук атсаң?..

Кальбеңдәге сүз ирерме
Хәсән Туфан сүзе күк;
Сулар тип-тигез булса да,
Сурәтең күктә биек.

Болытлар төшәр ишелеп...
(Ишегең ачык булса да,
Ябып куй тәрәзәңне —
Черкиләр тулыр юкса.)

Иң биек болытлардан да
Өн килеп төшә кайчак;
Урманнан кайтып керер дә
Мөдәррис...
Бары шулчак

Хәлеңне сорашкан булыр,
Мең ел күрмәгән кебек.
(Югыйсә утырган идек бит
Уртак хәсрәтләр түгеп
Әле бит кичә генә...

Гел генә кайтып булмый шул
Бүгеннән — кичәгеңә.)
«Зөлфәтлек» керә урманнан,
Япсаң да йорт-кураңны...
Мөдәррис йөри яланөс,
Бикләп булмый урамны.

# ЭССЕ-ХИКӘЯЛӘР

## ӘТКӘЙ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

*(Әйтелгән васыять)*

«Вәгъдә — иман» диеләме әле Коръәндә?
Яшермим, бу язмамны язарга мине моннан егерме еллап элек булып узган бер вакыйга-сөйләшүдән күңелгә сеңеп калган хатирә-истәлекләр мәҗбүр итте.
Шагыйрь әйтмешли, без биш бала үстек (алтынчыбыз — Фәгыйль абый 18 яшендә вафат булды), һәм бишебез дә ел саен диярлек, аеруча җәйге-көзге айларда, күп вакытта гаиләләребез белән туган нигезгә җыела торган идек: өлкәнебез Наил абый — Мәскәүдән, апам Фәһимә белән сеңлем Фәндия — Чаллыдан, энем Рафис белән мин — Казаннан. Айлык ял вакытын бер вакытка туры китерү ничек кенә кыен булмасын, без барыбер, мең хәйләсен табып, чынын-ялганын бергә кушып, туган нигездә бергә җыелу ягын карый идек. Бу бер йолага әйләнгән иде. Инде һич югы, ял вакытын бергә туры китерә алмасак, аерым-аерым булса да туган туфракка ел саен баш орып килү гадәте безнең каннарга сеңгән иде.
Юк, туган авылыңа, атаң белән анаң янына кайту инде ул болай үзе бер дә батырлык та түгел, мактанырлык та эш түгел инде анысы, асылда исә барысы да гадирәк ләбаса — һәркем үзенең ата-анасына, туган йортына булган әҗерен үз вакытында түләргә тиеш ич! Әллә ничек безнең йорт эшле булды, әмма ашлы булды. Эше күп булганга, ашы мул булгандыр инде, мөгаен. Һи, ул авыл җирендәге эшне санап кына бетерерлекме соң? Бәрәңге утыртасы, утынын хәзерлисе, печәнен чабасы, малын карыйсы, чөгендер-бәрәңгесен алып базга урнаштырасы бар! Чираттан көтүгә йөрү үзе генә дә кара кайгыга сала. Мал асрамасаң, ачка үләрсең! Ә кулдан көч китә бара. Кыскасы, аңлашылса кирәк, туган нигез безгә моңарчы санаторий да, ял йортлары да иде, хезмәт һәм тәрбия дәресләре үткәрелә торган мәктәп хезмәтен дә үтәп килде.
Моңарчы, димен, чөнки, моннан нәкъ унбер ел элек әткәм Гыймран сиксән ике яшендә дөнья куйды. Алтмыш ел бергә гомер кичергән якынын югалту кайгысыннан әнкәйнең миенә кан сауды — ул кешеләр белән мөлдерәп торган карашлары аша гына аңлаша алды. Ни хәл итәсең, табигатькә каршы барып булмый, аның үз исәбе.
Хәер, мин читкәрәк киттем бугай. Мин сүземне бер вакыйга уңае белән алган сабак-вәгъдәдән башлап китәргә тиеш идем ләбаса.
Ул болайрак булды.
Әткәй безгә, хезмәт дәресләреннән тыш, һич тә көтелмәгән бер вакытта, «тәрбия» сәгатьләре дә үткәреп ала торган иде. Юк, көчләп яки ирексезләп тә түгел, үгет-нәсихәт белән дә түгел, асылда җиңелчә шаярту-кинаядән (улым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла!), киңәш-табыш итешүдән (киңәшле эш таркалмас), бер-береңне тиң күреп әңгәмә корудан (коега төкермә, суын эчәрсең!) гыйбарәт иде ул дәресләр. Хәтеремдә: без — ир-ат халкы — бәрәңге алып, төшке ашка кергәннән соң тирләп-пешеп тавык шулпасы сыпыртабыз, әнкәй исә газ плитәсе янындагы кечерәк өстәлдә коштабакка ит турый. Ә радиодан җыр агыла — сораулар буенча көндезге концерт бара. Әнкәйнең дә, башка аналар кебек үк, үзенең исемен радио аша ишетәсе, үзенә багышлап башкарылган җырны үз колаклары белән тыңлыйсы килгәндер, күрәсең, моңарчы бу ләззәтле дә вә яшерен дә серен күкрәк түрендә беркемгә дә чишмичә саклап килгәндер, әмма бүген ул түзеп тора алмады. Илһам Шакиров «...әниемнең җылы кочагы» дип җырын тәмамлауга, бераз тын гына стенадагы радиоалгычка карап торды да үзалдына сөйләгәндәй итеп:
— Минем малайлар да Казанда яшиләр ич! — дип куйды. — Бәлкем әле...
Күрсенү дә, киная дә юк иде бу сүзләрдә. Өмет бар иде. Кыен булып китте. «Йә, минем әнкәй кемнекеннән ким? Башка аналар кебек ул безне карап үстермәгәнме дә, ул иртә таңнан кичке караңгыга чаклы «эш-эш» диеп чапмаганмы? Әллә ул радиодан әйтелгән шул бер җылы сүзгә лаек түгелме?»
Читен хәлдән әткәй коткарып калды. Ул, гадәттәгечә, карашлары белән генә елмая төшеп (кәефе килеп, берәр мәгънәви вә хикмәтле сүз әйтергә җыенганда, әткәй гел шулай күзен кыса төшеп

елмайгандай итә иде):
— Һи, карчык! Исән кешегә нигә ясин чыгарга соң? — дип куйды. Аннары, әнкәйнең хәтере калмасын диптер инде, сүзен ул болайрак дәвам итте. Тавышы җитди иде: — Һи, синнән дә бәхетле кеше бармы соң, карчык? Кара син, кызларың-малайларың җыйнаулашып кайтып төшкәннәр. Чакырганны да көтмәгәннәр. Димәк, җыясы ризыклары бардыр, шөкер. Ә ярату, хөрмәтне аны урамга, миргә чәчеп йөрмиләр. Гайбәт түгел лә ул! Әнә аның малае бар, бердәнбер малае... — Әткәй ишегалдына караган тәрәзәгә табан баш кагып куйды. Сүзнең кем турында барганы билгеле иде, шулай да борылып карыйсы иттем — анда күршебез Таифә апа бакча артыннан җимерек такта лапаска таба — тауга каршы — бер капчык бәрәңге күтәреп менеп килә иде. — Егерме генә ел бардыр инде, кайтып та күргәне юк. Йөз чакрымнан. Ялгыз башы — салкын ашы!
Белмим, радиодан җыр башкаруларын сорап хат юллау ул — әле исән чагында ук әнкәйләрнең булмаган кабер ташына эпитафия язумы, ягъни, әткәй әйткәнчә, исән кешегә ясин чыгумы, һәм әхлакый яктан бу ничек акланадыр; бер уен бу, поза — шамакайлыкмы? Һәркемнең әнисе үзенчә матур, кадерле, сөйкемле лабаса! Шикләнүчеләр булса, Әмирхан Еникинең «Матурлык» хикәясен генә укып карасыннар. Әллә чын ярату, кадер-хөрмәт билгесеме, әйтә алмыйм, һәрхәлдә, маңкортлык һәм Хәтер югалтудан да хәтәррәк түгелдер. Әмма миңа шунысы ачык иде, мин ул көнне күңелемә яшерен бер уй беркетеп куйдым: «Аллаһы Тәгалә боерып, гомер бирсә, вакыты җиткәч, син әткәң-әнкәң рухына багышлап бер-ике кәлимә сүз әйтергә тиешсең!» — дидем үз-үземә. Бүген мин хәл кадәремчә шул әҗеремне үтәп маташам. Чөнки әткәйнең әлеге сүзләре миңа Әйтелгән Васыять булып яңгырадылар.

*** * ***

Мин әткәй арбасында үстем.
Туры мәгънәсендә дә, кыек-күчерелмә мәгънәсендә дә бу шулай булды. Туры мәгънәсендә дигәннән, әткәй гомере буена диярлек атлы эштә эшләде һәм, аңлашылса кирәк, басу капкасыннан да арырак башланган олы дөнья белән мин әткәйнең кабык төпле ат арбасында утырып йөргәндә таныштым. Хәтеремдә, биш-алты яшьләр булганда ул «Бүләк бул» колхозының төзүчеләр бригадасы бригадиры иде, ә мин — аның төп «ярдәмчесе» һәм «киңәшчесе» (шулай булмый ни: олылар инде олы, бәләкәйләр әле тумаган). Әткәй көнне белми, төнне белми — арба өстендә: әле урман кисүчеләр янына барып чыга, әле төзүчеләр янына килә, әле тугым сугу мастерскоена сугыла. Ә мин — чәче пәке белән кырылган — такыр, кабык башлы, юеш борынлы малай — юлда барганда тыңлаучы һәм киңәшче, тегендә йә монда туктап торган арада — кигәвен-черки куып торучы. Мин барысына да риза. Иртән иртүк торып йокым калганга да, сәгатьләр буе ат саклап торуга да риза, тик әткәй генә үзе белән алып йөрсен. Һи, ул якын-тирәдәге авыл-карьяләр белән беренче тапкыр танышып йөрүләрне (безнең авыл барыбер әйбәтрәк шул!), печән өсләре җиткәч, урман аланында таң аттыруларны, су тегермәне арыгыннан шаулап аккан төнге сулар тавышын сихерләнеп тыңлап торуларны нәрсә алыштыра ала соң?! Яки печән куышында, йә булмаса, такыр юлдан келтерәп кенә барган арба тавышына изрәп китеп йокыга талган минутларны нәрсә белән алыштырырга мөмкин? Ул балачакта авыз иткән балтырган, җир җиләге, каен җиләге, бөрлегән, шомыртларның тәме хәзер дә тел очында. Мин бәхетле идем.
Әйе, әткәй канаты астында үсүнең, өйдә, өстәл артында гына түгел, әлбәттә юлда, эштә, ял вакытларында бергә булуның үз өстенлекләре бар аның.
Картлар сүзен, ягъни халык арасында таралган гыйбарәләрне, кинаяле маҗараларны, халык мәкальләрен һәм әкиятләрен беренче тапкыр мин аның авызыннан, аның интерпретациясендә ишеттем. Китап кулга соңрак килеп керде.
— Берәүнең өч малае булган, — дип башлый иде ул сүзен еш кына (без дә өч малай лабаса). Һәм китә аннары сөйләп... Юк, ул үгет-нәсихәт белән, дусларың күп булсын, дип әйтми, бары авыл саен йорт салу турындагы кыйссаны гына сөйләп ала. Яки әңгәмәдәшенә «алдашма» йә «арттырма инде» дими, кыса торган күпер турында гына искәртеп куя.
Ә бу кыйссаның туу тарихы болайрак. Имеш, безнең авылның Миңнулла исемле бер егете флотта хезмәт итү срогын бетергәч, Пучыдан әткәй арбасына утырып кайтып килә икән. Билгеле инде, аңлашыла, моңарчы ындыр артыннан ерак китмәгән сала егете, арбага утыру белән борчак сиптерә башлаган, ди, мин фәлән-фәлән диңгезләрдә йөздем дә, фәлән-фәлән илләрне күрдем, янәсе. Әткәй моның шыттырганына түзеп-түзеп торган да, ярты юлны узгач, әйткән ди:

— Миңнулла, энем, бездә дә зур яңалык бар бит әле. Менә узган ел гына Ижаудан килеп, Мирзагофрәннәр янына алдашучыларны кыса торган күпер салып куйдылар. Хитрый күпер, чукынмыш! Аз гына ялган сүз сөйләвең була, тактасына аяк басуга ике яктан кыса да куя.
Бу сүзләрне ишетү белән Миңнулла-моряк авылга кадәр авызына су капкан кебек тын гына кайткан, ди.
Хәер, эткәй исеме белән бәйле мондый мәзәк хәлләр күп. Бәлки, шулай җор телле булганы өчен дә аны, Т.Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасы куелгач, авыл яшьләре «Әлдермеш карт» дип атап йөртә башлаганнардыр.
Эткәйгә ияреп йөрүнең өстенлеге тагын шуннан гыйбарәт — эшкә өйрәнәсең. Эткәй еш кына: «Ир-ат заты үзенә йорт салып керә алырга тиеш», — ди торган иде. Шуны истә тотыптыр, күрәсең, ул мине яшьтән юнышырга өйрәтте. Исемдә, бүрәнәнең аргы башына барып утырыр иде дә, эчкә керәсең, тышка чыгасың, дип, минем юнганны бәяләп-күрсәтеп торыр иде. Тире ничек иләнә, бау ничек ишелә, утыртма һәм яткырма читән ничек үрелә, көрәк яки балта ничек саплана, чалгы ничек чүкелә дә, ничек көйләнә, урманда агачны сөялдермичә ничек кисеп аударырга, печәнне кайсы баштан төшеп чабарга — патриархаль крәстиән тормышның тавык чүпләп бетерә алмаслык мең вә мең төрле эшләрен мин эткәйдән күреп, өйрәнеп үстем. Эткәй әйтмешли, эшләвем кеше өчен булса, өйрәнүем үзем өчен булды.
Кыскасы, мин эткәйнең тәрбия арбасында үстем. Барысы өчен дә рәхмәт аңа.

* * *

Эткәй миңа үз гомерендә ике мәртәбә кул күтәрде. Әгәр инде аларны кул күтәрү дип атасаң... Беренчесендә ул мине кирәк-кирәкмәгәнгә әнкәйләр итәгенә тагылып йөрмәскә, мөстәкыйль булырга өйрәтте.
Миңа ул чакта дүрт-биш яшьләр чамасы булгандыр. Уттай урак өсте — «халык ашыга, китә басуга». Төш вакыты. Әле уеннан башканы белмәгән авыл малае өчен иң күңелсез сәгатьләр: урамда этле җан да юк, иптәшләрнең кайсы кая таралышып беткән — кемдер әбисенә ияреп йә җиләккә киткәндер, йә абыйсы белән су керергә, йә ындыр табагына. Эткәй, утынлыктагы бер бүкәнгә чүгәләгән дә, ишегалды себеркесе бәйләп утыра. Әнкәй исә, каударланып, абзар-кура тирәсендә йөри. Һе, каударланмый кара, сугыштан соңгы еллар бит бу, чаң тавышы яңгырагач биш минут үтү белән ындыр табагы капкасын атлап кермәсәң, кара исемлеккә эләгәсеңне көт тә тор, ә аннары уполномоченный каршында, бригадир каршында җавап бир. Әнә, сискәндереп, чаң тавышы да яңгырады һәм янгын чыктымы, такта һәм читән җил капкалары бердәм ачылдылар да ябылдылар. Ул арада безнең капка төбеннән күрше Хәлимә апа да йөгерә-чаба үтеп китте:
— Мөсәвәрә, тизрәк бул, соңга калабыз, уполномочий килгән, ди!
Әнкәйне ай күрде, кояш алды: мин аны куып җиткәндә, ул урам коесы турында иде инде. Үзе алга таба тартыла, үзе яртылаш миңа таба борылган килеш:
— Улым, иртәгә алып барырмын, ияртмә инде бүгенгә, — ди.
Ә минем амбар алдына бик тә, бик тә барасым килә. Һи, андагы күңеллелекләр, могҗизалар, ыгы-зыгы турында сөйләп кенә бетерерлекме соң? Басудан яңа кайткан ашлык көшелендә тәгәрәшеп уйнауга нәрсә җитә ала соң? Җәннәтең бер якта торсын. Беләм ич, минем яшьтәшләрнең кайсы әнисенең итәгенә ябышып, кайсы капка асларыннан шуып үтеп, хәзер шул җәннәттә йөзәләр булыр.
Шул татлы уйларымнан эткәйнең кырку тавышы уятып җибәрде:
— Улым, кайт әле, бер әйбер бирәм... — Минем икеләнеп торуымны күргәч, тагын кабатлады: — Тизрәк бул инде.
Үзе урыныннан торып баскан да, кулы белән изәп, мине чакыра. Бирәм, дигәч, кайтмый хәлең юк, яланаякларым тыпырдатып эткәй каршына килеп тә бастым: нинди тәмле нәрсә бирергә тели икән миңа эткәй, янәсе. Ә ул берни булмагандай, себерке бәйләп утырган җиреннән кузгалмыйча гына:
— Улым, әнә теге чыбыкны гына алып бирче әле, — диде.
Алып бирдем һәм арт битемнең уттай кызышып алуын сизмичә дә калдым.
— Икенче ияргәссеңме? — диде ул ачуланмыйча гына.
— Иярмәм, — дидем үпкәләмичә генә.
— Иярмә, хатын-кызга ияреп йөрергә син нәрсә, ир кеше ич. Зур инде, — диде ул, кабатлап.
Мин дәшмәдем.
Бу минем беренче тапкыр ирләр тәрбиясе алуым иде.
Ләкин аңлап җиткермәгән булганмын икән. Бер-ике елдан эткәй тагын искә төшерде.

Беренче класста укый гына башлаган көннәр, төгәле — 1955 елның 5 сентябрь иртәсе иде. Хәтергә сеңеп калган бит, ә! Кече якта сәкегә яткан килеш дәрес әзерләп утырам. Кайдандыр әткәй кайтып керде. Мал-туар арасыннандыр инде, йә булмаса, идарә тирәсеннәндер. Кулларын юып чәй табынына утырган арада әйтеп куйды бу:
— Улым, Кара бияне генә алып кайт әле.
Ике минутлык эш инде бу бездәй авыл «егетләре»нә ат алып кайту, чыклы чирәмгә басмаска тырышып, әле кичәге җылысы сүрелеп җитмәгән тузанлы юлдан элдертәсең дә атыңны чаптырып кайтып та китәсең. Ә арба-сбруйлар өйдә, ишегалдында. Ишетеп ятам бит инде: бер әйтте әткәй, ике әйтте, ә мин һаман «Ал-ма, ал-ма!» — дип кабатлап ятам. «Аласым» булган икән: аркалык каеш белән «танышып алгач», чыгып йөгергәнемне дә сизмәдем.
Хәзер уйлыйм: әтисез үскән малайлар ничек тәрбия алганнардыр — әйтә алмыйм. Гомумән, педагогия күзлегеннән караганда, әткәй дөрес эшләгәндерме-юкмы — анысы да караңгы миңа, әмма ул мине юкка-барга үпкәләмәскә, үч сакламаска, олылар сүзен тыңларга, хөсетле булмаска, елак булмаска, балавыз сыкмаска өйрәтеп, сабак биреп калдырды кебек. Мондый характер-тәрбия белән «бүреләр» арасында яшәве дә җиңел түгелдер, бәлкем. Ләкин, кем әйтмешли, соң инде.

* * *

Кайсы гына малай-шалайның яшьтәшләре арасында үзенең әтисе белән горурланасы, бераз кәпрәеп аласы килми икән? Юктыр ул андыйлар. Бу җәһәттән, күрәсең, мин дә башкалардан аерылып тормаганмындыр инде. Шулай беркөнне Олы буада су кереп арыгач, «каз тәпие кимерә-кимерә тамаклар туйгач», малайлар арасында, сүз иярә сүз чыгып, үтә дә кызу бәхәс купты: кемнең атасы нинди эшкә маһир да, ниндирәк урыннарда эшләгән, янәсе. Китте чәкәләшү, китте мактанышу — түзеп кенә тор. Ә ир-ат халкының канына биләүдән үк сеңгән инде ул, бер мактаныша башласа — туктатырмын димә.
Беренче очкынны җор телле, күпертебрәк сөйләргә яратучы Марсель салды, әлбәттә.
— Бик беләсегез килсә, әткәй миңа пароход туктата торган ике җәпле пәке алып кайтты! — диде ул, яр буенда күккә карап кызынып яткан җиреннән бер дә исе китмәгән кыяфәттә.
Малайлар «аһ» итте, ике җәплесен түгел, алты җәплесен дә күргән бар ла ул пәкенең, ә менә пароход булып пароход туктата торган — бу инде безнең кабак башка сыймалы нәрсә түгел иде. Марсельгә нәрсә, аның үз җыруы җыру, сиптерә генә, калай колашага борчак чәчәмени.
— Ышанмасагыз, әнә Мирзагали абыйдан сорап карагыз. Ул да күргән. Әҗәкүл пристаненда ике катлы пароходны туктатып караганнар.
Пароход туктата торган пәкене түгел, без, пароходның үзен дә күрмәгән кыр ягы малайлары берсе дә, әлбәттә, аның сүзенә бер тамчы да ышанмадык. Марсельнең гадәтен беләбез ләбаса. Ләкин ышану-ышанмау — бер нәрсә, хакыйкать дигәнең — икенче нәрсә: мөшкә ачылган иде инде, сүз тегермәне туктаусыз тарта башлады.
— Тапкансың мактанырлык әйбер, — диде Роберт. — Аңа калса, минем абый сугышта герой булган.
— Минем әткәй берүзе йөз немецка каршы сугышкан, — дип бүлдерә аны икенчесе.
— Минем әткәйнең өч мидалы бар!
— Минекенең сандык тулы!
— Ә минем әткәйне, сугыштан кайткач, прсидәтел итеп куйганнар!
— Юк, минем әткәйне...
— Ә минем әткәй — лесник! Кирәк икән, әткәйгә әйтсәмме, берегезне дә кәшәкә алырга да урманга керттермәм әле!
— Һе, синнән сорап торырлар инде. Минем әткәй — умартачы! Бик кирәк ие синең кәшәкәң! Урман тулы.
Каравылчы, көтүче, ат караучы, балта остасы, тегермәнче малайлары эндәшми, үз уйларына бирелеп тыныч кына тыңлап яталар. Ничек эндәшсеннәр, мактанырлык нәрсәләре юк ич. Һи, сабый күңеле! Никадәр гөнаһсыз син!
Мин дә дәшмим. Дәшә алмыйм. Сүзләренә катнашасы килми. Әткәй өчен оят. Гәрчә ул, районның беренче шоферы, Хәсән күле һәм Фин сугышларында катнашса да, 1941 елның 23 июнь иртәсендә үк, районда иң беренчеләрдән булып, үзенең «полуторка»сы белән тагын фронтка чыгып китсә дә, Мәскәү янында барган бәрелешләрдә аягын югалта язып, сигез ай буена имгәк хәлендә госпитальдән госпитальгә өстерәлеп йөрсә дә, аның күкрәген орден-медальләр бизәми... Сугыштан кайткач та аны әнә, башкаларның аталары кебек, «грамоталы» булуына да

карамастан, прсидәтел итеп куймаганнар. Бүген дә менә урманга да, колхозның умарта бакчасына да хуҗа түгел ул — бар белгәне көрәк тә сәнәк, балта да пычкы; пароход туктата торган пәке сатып алу да аның кодрәтеннән килми...
Шундый күңелсез уйлар белән ындыр артлатып кына өйгә кайтып җиттем. Әткәй ишегалды уртасында чытыр арбаның (безнең якта салам-печән ташу өчен көйләнгән биек үрәчәле арбаны шулай атыйлар) күчәрен дегет белән майлый иде. Сәнәк-чалгылар, бастырык-баулар — арбада. Әнкәй коедан әле яңа гына алган салкын су белән әйрән ясап йөри. Апа да өйдән эчмәк-җәймәләр күтәреп килеп чыкты. Әһә, димәк, Усаккуакка печәнгә барачакбыз.
— Әле үзеңне эзли чыкмакчы идек... — дип каршы алды әткәй. — Ярый, кайтып әйбәт иттең. Бар, капкалап ал да, кузгалабыз...
Такыр басу юлыннан арба әкрен генә келтерәп бара. Әнкәй белән апа аркаларын аркага терәп, араталарыннан аякларын асылындырып арба артына утырганнар. Әткәй — уртада, ә иң алда — мин, дилбегә тотучы. Бу дөньяда аттан да акыллырак хайван заты юктыр, билләһи, дилбегәнең кем кулында икәнен шундук белә, бала-чага белән хатын-кызны санга да сукмый ул, йә юлдан буйлап кереп китә, йә селкәү сөягенә әйләнә. Барган җиреннән әледән-әле юл кырыендагы арыш башакларына үрелүенә үртәлеп булса кирәк, әткәй, төшеп, атны авызлыклап куйды:
— Җитте сиңа, баргач, иркенләп ашарсың... Әйдүк, малкай...
Ул, арбага менеп утыргач, бер генә сүз әйтте: — Катырак бул!
Бәлки, шушы «катырак бул» дигән сүздән соңдыр мин, батыраеп китеп, сорап куйдым:
— Әткәй, нигә син прсидәтел булмадың?
Ул авыр гына көрсенеп алды.
— И-и, улым, үсә төшкәч аңларсың әле. — Бераз тын баргач: — Сугыштан соң кешеләр болай да кан косып яши иде бит. Тагын аларга кандала булып ябышыргамы?! Юк, улым... Ярамый иде...
Дилбегә аның кулына күчте. Моны сизү белән атыбыз салмак кына юыртып та китте.

* * *

Бер тапкыр мин аның елаганын күрдем.
Җәй көне иде. Арышлар серкә очырган вакыт. Көтү чыга... Урамда — ыгы-зыгы: бәрәннәр бәэлдәшә, бозаулар сикерешеп уйный, сыер-сарыклар койма буйларындагы, канау-агач төпләрендәге берән-сәрән үләннәрне йолыккалап ялкау гына авыл башына табан агылалар. Көтүче Газизулла абзыйның еландай кара, озын каеш чыбыркысы буйлап алгач, алар бер-ике адым атлыйлар да борыннарын тагын чыклы үләнгә төртәләр. Апа-җиңгиләр, әби-бабайлар, кайсы тәпи баскан гына бәрәнен күкрәгенә кысып, кайсы качкын кәҗәсен каравыллап, көтүне авыл башына кадәр озата бара... Бу — үзе бер илаһи күренеш: мөгаен, элегрәк Бөек ефәк юллары буйлап сәфәргә чыккан кәрваннарны гына шулай озатып калганнардыр да, шулай каршы алганнардыр...
Урамда тузан да басылырга өлгермәде, әткәй чоланда эленеп торган капчыгын култык астына кыстырды да: «Йә, барып карыйм әле», — дип, колхоз амбарларына таба чыгып китте. Әнкәй бу вакытта, гадәттәгечә, күптән инде фермада иде, сыер савуда. Әбекәй аны (әткәйнең әнисе — Хәят исемле иде ул) каз куарга чыккан җиреннән нечкә башына кызыл чүпрәк бәйләнгән чыбыгына таянып озатып калды:
— Хәере белән булсын!..
Хәзер ничектер, элегрәк авылда эшсез кеше юк иде, бала-чагамы ул, карт-корымы — һәркемнең үз шөгыле, үзе генә башкара торган эше бар. Һәр гаиләдә диярлек шулай: эш бүленгән.
Минем дә үз вазифам бар: мин, үзебезне генә түгел, бөтен күрше-күләнне көнбагыш мае белән, шикәр-конфет белән туйдыручы. Атна саен диярлек сәпитемнең багажнигына ун литр керешле алюмин бидономны бәйләп куям да Бакалы ягына элдертәм. Мин инде моңа күнегеп беткән, ләкин башыма бернәрсә сыймый йөдәтә. Аларда — Башкортстанда — шикәре дә, мае да бар, каһәр суккыры, бездә генә юк. Нишләп юк ул, сигез генә чакрым ара бит югыйсә.
Менә бүген дә, әткәй артыннан ук, йомырка сатып җыелган атналык гаилә акчасын бәләкәй яктагы матча тишегеннән чалбар кесәмә шудырдым да сәфәргә кузгалдым.
Ничектер ул көнне юлым урау булып чыкты. Көнбагыш мае Яңа Әмәкәйдә дә, Яңа Әлмәт белән Яңа Әгъбәстә дә юк иде. Бакалы аша җитмеш-сиксән чакрым юл үтеп, авылга өйләдән соң гына кайтып төштем. Мин капканы ачып кергәндә әткәй белән амбарчы Фәхрулла абый Фәхруллин болдырда сөйләшеп утыралар иде. Аз гына чеметкәннәр, ахрысы, әллә шунда кояшта изрәп китеп оныткканнар, әткәйнең җигеп йөри торган аты тугарылмаган, гомердә булмаганны — алдына да салынмаган. Мине күргәч (күрәсең, шактый утырганнардыр инде, ә бәлки — бала-

чага алдында күп сөйләшеп тормыйк диптер), Фәхрулла абзый урыныннан кузгала төште.
— Ярар, Гыйммран, җан биргәнгә җүн бирер әле, бәлкем, яңа уңышка да җиткерерсең... — диде ул ниндидер бер эчке тавыш белән. — Быел игеннәр ару күренә, Ходай насыйп итсә, дөньясы гел болай бармас әле... Ә рәхмәтеңне миңа түгел, прсидәтелгә — Шәйхәйдаровка әйт, ул бирергә кушты, язып...
Аннары ул ак төстәге «солдатский» киндер фуражкасын кулына алды да: «Сау бул хәзергә», — дип, салмак-уйчан адымнар белән капкага таба китеп барды. Әткәй аның артыннан Теләнче урамына күмелгәнчегә кадәр озатып карап калды, күмелгәч:
— Шәп кеше, — дип куйды үзалдына. — Игелекле.
Мин өй почмагына сөяп куйган сәпитем янына китмәкче идем, — йөкне бушатырга кирәк ләбаса, — әткәй үз янына чакырып алды.
— Утыр әле, улым.
Инде миңа алты яшь түгел, үз эчемә бикләнә башлаган чагым, әткәйнең җитди сүз башларга җыенуын сизенеп, болдырның астагырак баскычына килеп чүгәләдем.
— Юк, өскәрәк менеп утыр.
Нишлисең, өскәрәк менеп утырдым.
— Менә шулай... — Ул җилкәмә авыр кытыршы кулларын салды. — Син бит инде хәзер үскән егет, ундүрт яшең тулып килә, кул арасына керә башладың... Аның тавышы дерелдәп куйгандай булды.
— Менә бер капчык он яздырып алып кайттым әле. Аллаһы боерса...
Мин шунда гына кабык арбадагы шактый ук тук ап-ак киндер капчыкны күреп алдым. Аның өстендәге печән як-якка кайтарылган иде, капчык авызы чишелгән. Димәк, ул аны чоландагы юкә он кисмәгенә кертеп бушатырга ашыкмаган, бәлки, сокланып та карап торгандыр әле шул капчыкка, яңа тарттырылган онны кулына алып җылысын тоеп торгандыр.
Мин әткәйгә күтәрелеп карадым. Аның күз төпләре яшьле иде. Сөенеч яшьләре идеме ул, әллә көенеч яшьләреме — хәзер бер Алла белә... Әмма сәбәпчесе шул бер капчык он иде.

*** * ***

Сугыштан соңгы елларда бөтен Рәсәй буйлап — һәрхәлдә, бу Татарстанда шулай иде — посадка утырту бер өмә төсен алып, киң җәелеп киткән иде. Кар ышыклау посадкалары, гадәттә, җир эрозиясенә каршы юнәлтелеп, җил-давыл иркен үтеп йөри торган урыннарга — тау башларына, юл буйларына, ике урман араларына каен-акацияләрдән, нараттан, сирәк-мирәк имән чаукалыкларыннан утыртылды. Шушы ук елларда урманнарны яңарту-сипләү, буш яткан урман аланлыкларына нарат посадкалары утырту да, кем әйтмешли, массакүләм төс алган иде.
Менә шулай, 1954 елда бугай, авылыбызның 10–15 бәхетлерәк, ә бәлки булдыклы-эшчәнрәк гаиләсенә Усаккуак дип аталган катнаш урман итәгеннән (башка кайберәүләргә «диләнкә» ерактанрак, Кара урман тирәсеннән тәтеде булса кирәк), буш яткан яссулыктан посадка утырту өчен җир бүлеп бирделәр. Бер якта — шомыртлы, баланлы уйдык-уйдык таллыклар тезелеп киткән; икенче якта — бөрлегәнле, җиләкле тар гына кишәрлек булып имән урманы үсеп утыра; ахыр чиктә болар барысы да төп урманга кушылып китәләр. Буе бер чакрым чамасы, иңе өч-дүрт йөз метрлар булган шушы ташландык җиргә без нарат посадкасын утыртып-тәрбияләп үстерергә тиеш икәнбез. Чыннан да, авылдан ике генә чакрымдагы алындык, Әмирхан Еники әйтмешли, әткәй белән әнкәйгә бик ошады; урман каравылчыларыннан, безнең яктагы тел белән әйтсәк — лесниктан фатиха алгач (шулай булмый мөмкин түгел, ул елларда урман хуҗалыгына алар хуҗа иде, ул хәзер генә урман хуҗасыз калды), без бөтен гаиләбез белән җиң сызганып эшкә тотындык. Без дигәнем — әткәй белән әнкәй, әткәйнең әнисе — безнең якын әбкәбез, беркайчан да алны-ялны белми торган инсафлы, бөтерчек хәтле, инде үз яшен дә оныткан Хәят карчык, апам Фәһимә һәм дә җиде-сигез яшьләрендәге мин үзем һәм дүрт-биш яшьләрдәге энем Рафис; абыйларым Наил белән Фагыйль ул вакытта инде төп йорттан очып чыгып «читкә» — ят җирләргә китеп барганнар иде булса кирәк, һәрхәлдә, урман утыртуның беренче өмәсендә алар өйдә-санда юклар иде. Эшкә тотындык дигәч тә, тотынуы алай бик ансат нәрсә түгел икән әле. Башта ат белән махсус җайланган сабаннар ярдәмендә бер метр чамасы ара калдырып алан кәсен сөреп-ярдырып аласың, аннары шул бураэнага ярты метр саен шөшле сыман утырту көрәге белән нарат үсентеләрен төртеп чыгасың. Монысын, төртеп чыгуны, әткәй ясаган ояга апа белән без дә башкара алабыз инде, ә «сыйфат карты» — Рафис энем йолкып ук булмаса да, үсентеләрнең якаларыннан тарткалап, абына-сөртенә арттан ияреп йөри. Өч-дүрт көн дигәндә без үзебезгә бүлеп бирелгән бер гектар-гектар ярым чамасы җиргә нарат

үсентеләре төртеп тә чыктык. Ә халыкның бу яңа гамәлгә дәррәү кубып тотынуы шуның белән аңлатыла: безнең авыл тирәсендә табигый печәнлек — болынлыклар булмау сәбәпле (урман эчендәгеләре лесник кулында), авыл халкы печәнгә күпмедер күләмдә мохтаҗлык кичерә иде — сорамыйча печән-утын түгел, сулыш та ала алмый торган еллар бит бу! Ә монда, посадкада — ызан араларында каерылып үскән печән ел да синеке, күтәрелеп килгән, буй җиткергән нарат урманы — дәүләтнеке. Ярый, еллар берсе артыннан берсе үтә торды, кадерләп, төпләре китмән белән йомшартылып үстерелгән наратлар саф-саф булып, «Чыңгыз гаскәрләре» кебек үсә торды һәм бүген алар өй салырлык бүрәнә агачына әйләнделәр...
...И-и, ул печәнгә төшкән көннәрнең хозурлыгы, ул мизгелләрнең рәхәтлеге — боларны сүз белән сөйләп, тел белән әйтеп кенә бетерерлек түгел.
Ул көнне, әйе, көтү иртәрәк куыла, казан аслары иртәрәк тергезелә, атлар иртәрәк җигелә. Беренче тапкыр печәнгә төшкән көн әле дә хәтеремдә: әткәй таңнан торып, кешеләрдән һәм силсәвиттән яшереп кенә сарык суйды, итнең бер өлешен урманда пешерергә диеп аерып алдылар да, калганын тозлап, агач кисмәк белән кар базына төшереп куйдылар: ул вакытларда авыл халкы ничектер бик тә сакчыл иде шул, бәлки, илгә түгел, үзенә генә таянганга шулай булгандыр ул! Аннары, олы вакыйгага тиң көннәргә генә хас булганча, җыйнаулашып бер өстәл артына утырып чәйләп алганнан соң, әткәй ат җигәргә чыгып китте, әбекәй белән әнкәй юл хәстәрен күрә башладылар — яңадан кар базына төшеп менелде, баз капкачы ачылып ябылды, сандык-сондык актарылды, төенчекләр төйнәлде. Ул арада әткәй үзе генә белгән урыннардан (кичтән үк көйләп, игәп, чүкеп, кайрап куелган) балта-пычкы, сәнәк-тырма ише эш коралларын булдыклы крәстиәннәрчә вәкарьлек белән арба төбенә урнаштырып чыкты, аның өстенә ефәктәй арыш саламын күпертеп җәеп куйды, ахырдан келәттә генә саклана торган торыпша-җәймәне алып чыкты да: «Яратмыйм шыгырдап, коелып йөргән арбаны», — дип үзалдына сөйләнә-сөйләнә тәртә бауларын барлады, тәгәрмәчләрне селкеткәләп карады (барысы да тәртиптәме, янәсе), аннары җигелеп куелган атның аркалыгын күтәреп куйды. Шуннан соң гына ул өйдәгеләргә дәште:
— Әй-й, сез анда буласызмы әле?
Аның тавышында хуҗаларча боеру да һәм шул ук вакытта ирләрчә кайгырту төсмере дә бар иде бугай. Озак та үтмәде, шуны гына көткәндәй, болдырда кулына мендәр чаклырак ашъяулык төенчек тоткан әнкәй күренде. Ул кайтарып бер сүз дә дәшмәде, күнегелгән гадәт буенча арба башына, саламга чокыр ясап, төенчеген җайлап урнаштырды да (чиләк-казан-мазар инде күптән арбага менеп кунаклаган иде) бер кырыйдарак бау төйнәп маташкан әткәйгә сүз катып:
— Булды бугай инде. Бернәрсәне дә онытмадык бугай. Хәерле сәгатьтә булсын, — дип куйды.
Юлга чыгар алдыннан гына була торган ыгы-зыгы басылып, ат капка төбенә килеп туктагач, берәм-берәм җәймә белән каплаулы салам өстенә чүмәштек. Ат дигәнең бик тә акыллы, сизгер җан иясе бит ул, (аннары әткәй, үзенең сөйләвенә караганда, Кара бияне күптән җигеп йөри, алар бер-берсен, кем әйтмешли, «ярты сүздән» аңлыйлар) капканы киереп ачуга бер пошкырып алды да — аның безгә «юлга кузгалдык, йоклап утырмагыз, тәгәрәп төшеп калырсыз» дип кисәтеп куюы булгандыр инде — дилбегә кагу белән дәртләнеп урыннан кузгалды. Вәкарь белән генә үзебезнең урамны үттек, авыл башын чыктык, зиярат та артта калды, басу юлына чыккач исә кара бия дәртле генә юыртып китте.
Авыл иртәсенең хозурлыгын, аның сихри тантанасын авылда туып, авылда үскән кеше генә җаны-тәне белән нечкәләп тоя аладыр шул: менә без агымсу өстедәй айкалып-чайкалып утырган арыш басуы эченә йөзеп килеп керәбез; талгын җил белән болынга арыш, үлән, тагын әллә нинди исерткеч тәмле исләр килеп бәрелә; һавада бертуктаусыз тургай сайрый — ул үзе һавада бер нокта гына кебек, ә үзе бөтен бер дөньяны тотырып тора, әйтерсең лә яңа көн, яңа вакыт агышының яңа бер мизгеле тууга ул да шулай шатлана, канатлана. Чыннан да, никадәр матур, тулы бу дөнья! Шулай сабыйларча «бөек», гасабилы уйларга чумып барган җиремнән, текердәп кенә тәгәрәп барган арба тәгәрмәче тавышына изрәп киткәнемне сизми дә калганмын. Менә без ел да туктала торган посадкага терәлеп үк торган урманның таныш аланлыгына килеп туктаганбыз. Беренче эш итеп йөк бушатылды, аннары ат туарылды, аны тышаулап, дилбегә белән арбага бәйләп куйдылар, шуннан соң учак тергезелде, ул арада якындагы сызадан күренер-күренмәс кенә булып агып яткан чишмәдән бар булган савыт-чиләк белән су алып менелде, учакка чәйнек, казан асылды, кыскасы, кырга чыккан «кыргый» кешеләр тормышы - башланды.
...Беренче покосны чыкканда, дөресрәге, чыгып җиткәндә, кояш инде баш түбәсен кыздыра башлаган иде. Ә посадкада печән чабуның үз хәйләсе бар, биредә болындагы кебек күкрәк киереп, алагаем селтәнеп чаба алмыйсың, печәнне бармак юанлыгы булып үсеп килүче нарат агачларын кистермичә, бер кырыйга янтаебрак кыркып барырга кирәк. Һәм, без бит үзебезне

белә-белгәннән бирле эш эшләп үскән авыл баласы ла, әткәй-әнкәйгә ияреп монысын гына апа белән без дә тиз үзләштердек. Шул рәвешле, үз алдына башта әткәй төшә, аннары әнкәй, соңыннан апа белән мин — кошлар кебек берсе артыннан берсе тезелешеп чалгычылар үткәннән соң рәт-рәт үскән агачлар арасына печән покослары сузылып ята; агачлар да, утырган бөркәвечтән арынгандай, берәм-берәм тураеп басалар. Энем Рафис исә, тизрәк һәм тигез кипшерсен өчен покосларны безнең арттан сәнәк белән аралап-әйләндереп бара.
Менә шулай берәр покос чыкканнан соң карт имән төбенә утырып мәтрүшкә чәе эчеп алабыз. Ә Казанда итле шулпа кайный: биредә әбекәй хуҗа — ул аш пешерү остасы, аны хәтта кунак-мазар җыйганда сый-нигъмәт хәзерләшергә күрше-күлән дә ярдәмгә дәшеп ала.
Бервакыт көтеп алган әбәт вакыты да җитә. Без, арып-талып, манма тиргә баткан килеш һаман да шул имән күләгәсенә килеп чүмәшәбез. Ул арада әбекәй белән әнкәй табын хәзерләргә керешәләр: кулдан сугылган ашъяулыкка табак-савыт тезеп куела; тегермән ташы чаклы булып күпереп пешкән бодай күмәчен кулына алгач, әткәйнең йөзенә елмаю йөгерә һәм:
— Кара әле син моны, бигрәк уңган, кояш кебек көлеп тора, — дип сөйләнгәләп ипи кисәргә керешә.
Чыннан да, шатланмаслыкмыни, олы бәйрәм, гаилә өмәсе ич бүген, мондый ак он күмәче бәйрәмнәрдә генә пешерелә, казан да елга бер генә асыла, ит пешсә, бит пешми дигәндәй, ипи-ит белән өйгә туклык керә шул. Әткәй күкрәгенә куеп ипи кискәндә, яисә коштабагын тотырып ит тураганда, беләм, ниндидер тынлык урнаша — тигез, тук тормыш итүнең бөек чагылышыдыр бу, мөгаен. Менә ул олы чүмече белән коштабакка ит сосып сала; әбекәй исә һәрберебезгә шулпа бүлеп чыга; ниһаять, без — бөтен гаиләбез белән ашъяулык тирәсенә кысылыбрак утырабыз да, агач кашыкларны эшкә җигәргә «команда» көтеп торабыз. Әткәй бисмилла урынын әйтә торган аш алды сүзләрен кабатларга көчкә өлгереп кала: «Әйдәгез әле, эшләгәндәге кебек итеп ашыйк, ашамый торып эшләп булмый ул», — дип әйтүгә бердәм рәвештә тын гына «урак урырга» керешәбез. Бергәләп тәгам җыюның ниндидер сихри көче бар, күрәсең, татарда бу бик борынгыдан килә торгандыр, берәү дә дәшми, һәркем җитди, бик изге эш эшләгәндәге кебек... Учакта пешкән ике-өч тәлинкә өреле шулпаны, симез-симез калҗаларны үлән чәе белән җепләп куйгач, кайсыбыз кая таралыша: әткәй ат-арба янында булыша; хатын-кыз җәмәгате, табынны җыештырып куйгач, урман эченә кереп югала — җиләкле, бөрлегәнле вакыт бит. Кем ничек шулай аш сеңдереп алганнан соң тагын чалгыларга тотынабыз. Печән чабу ул болай читтән карап торганда гына ансат, күңелле бер эш сыман тоелырга мөмкин, чынлыкта исә шактый авыр, күп көч сарыф итүне сорый торган хезмәт. Әнә көннең яртысы гына җиткән — кояш нәкъ баш очында эленеп тора! — ә инде беләк-кулларга, аяк-билләргә шактый ук ару-талчыгу шаукымы йөгергән. Ләкин эшкә килгәндә безнең нәселдә сынату гадәте юк ул, бу алгысарлык әткәй белән әнкәйдән балаларына да күчкән — өзелеп калсак калабыз, үзебез дигәнне эшләмичә торып туктап кала белмибез. Тик шулай да төштән соң туктап-туктап ял итеп алулар ешрак була бара, чалгылар да ешрак янап алына. Шуны сизеп алгандай, ерактагы покос башына чыккач, әткәй түземсезләнеп көткән хәбәрне җиткерә:
— Көне бигрәк кыздыра... бер-ике сәгатькә туктап, ял итеп алыйк булмаса. Безне куып килүче юк ла...
Һәм без, шуны гына көткәндәй, аллы-артлы тезелешеп, агачлар арасына су юлы кебек сузылып яткан покослар арасыннан казан аскан аланга табан юнәләбез. Нәкъ экияттәге кебек, башта әткәй, аннан әнкәй дигәндәй (ул беркайчан да әткәйдән узып сүз әйтмәс, аннан алда юл төшмәс), аннары без — тагын шул ук ашъяулык җәймә тирәсенә түгәрәкләнеп утырабыз. Ә әбекәйнең кулы җиңел аның, чәе дә, ашы да әзер, теләсәң, ачы катыгы да бар, хәтта бер тустаганга җиләк тә җыеп куелган. И-и, тулы-тигез гаиләң белән өмә ясап, иңгә-иң торып печән чабулары, аннан соң бергә-бергә ябып-пешеп ашап-эчеп утырулары экияттә бер төш кебек рәхәт тә, күңелле дә; болар бит теләсә кемгә тәтеми, белсә дә тигез, күп балалы гаиләләр генә беләдер моның хозурлыгын — Ходайга шөкер, үскәндә мондый татлы мизгелләрне без аз кичермәдек шикелле.
...Әткәйнең бер чаука төбенә чүгәләп чалгы чүкегән тавышы ничекләр тоныклана-тоныклана ерагая барып — ул инде бөтен урманны иңләп яңгырамый, чың-чың итеп зеңләүдән бигрәк быжан безелдәвенә охшый бара — бөтенләй ишетелмәс хәлгә килде. Һәм мин, арып-талып, чебен-черкидән качмакчы булып печән җәелгән арба астына килеп авам, авам да башым тию белән изрәп йокыга китәм... Йокы ястык теләми шул, белмим, күпме йоклаганбыздыр, энем белән мүкәйләп арба астыннан чыкканда кояш төшлектән авышкан иде инде. Эсселек бераз басыла төшкән, күк йөзендә берән-сәрән күчмә болытлар өере күренгәли. Бераз селкенгәч, тән язылып китте, беләк-бәдәннәргә тагын көч-куәт йөгерде, күңелне дәрт-дәрман биләп алды. Эшнең рәтен белеп эшләгәндә, сау-сәламәт чакта, җитмәсә, буыннар ныгып килгән бер мәлдә

син эштән түгел, эш синнән куркып тора лабаса. Чалгылар чаж да чож килә. Тәннән борчак-борчак тир ага; алда, ымсындырып, тагын яңа покос башы көтеп тора...
Ниһаять, җәйге озын-озак көн сүрелә барып, кояш кичкә авыша башлагач көнлек эшкә нәтиҗә ясалды, нокта куелды. Хатын-кыз җәмәгате, энемне ияртеп, авылга кайтып китте, ни генә дисәң дә, көтүне каршылыйсы, сыерны савып, кош-кортны ашатып, мал-туарны төнгелеккә ябып куясы да бар ич әле. Ә мин төнне әткәй белән бергә урманда уздырачакмын. Печән шалашында күңелле булыр. Беренче тапкыр гына түгел ләбаса. Башта бастырык чаклы усак киртәләр кисеп алып шалашның кысасын ясап куйдык, кысага читән юанлыгы ботак-санак тезеп чыктык та, шуның өстенә печән ташладык — менә сиңа шалаш әзер дә булды.
Тышауланган Кара бияне китереп бәйләгәч, әткәй тагын учак тергезеп җибәрде. Күз алдына китерегез: кич, урман... Агач башларына җитәрдәй булып, ялкын телләреннән яктылык сирпелә. Һәм без — ата белән малай — икәүдән-икәү калып, урман аланында төн ката учак каршында утырабыз. Картаеп килгән атам, учакка текәлгән дә сүзсез калган; ул бик сабыр, акыллы карт, төптән уй йөртә белә, бу минутларда ни уйлый ул, башыннан ниләр кичерә. Ә мин шул хакта уйлап утырам.
...Икәүдән-икәү калган вакытларда ул үзенең үткән гомере турында, гомумән, яшәү-яшәеш хакында бәйнә-бәйнә сөйли торган иде. Шуңа күрә мин ул үткән юлны яттан беләмдер төсле... Без ул көнне дә аның белән озак-озак итеп, тәмләп сөйләшеп утырдык. Сүзебез ахырында мин аннан, миңа шулай ышанганына бераз масаебрак китептер инде, мәктәп, район ярышларында алдынгы урыннарны алып килүемне исәпкә алып: «Җибәр, әткәй, мине, дөнья чемпионы булып кайтам», — дип ычкындырдым. Әткәй озак уйлап тормады, җавабы әзер булгандыр, күрәсең:
— Улым, миңа йөгерешче түгел, эшче кул кирәк, — диде. Бераздан болай дип өстәп куйды: — Моңарчы син минем ышанычлы терәгем булып килдең. Моннан соң да шулай булыр, иншалла. Хәзерге кебек эшне ярат, намуслы бул, кеше өлешенә кермә, беркайчан да тәкәбберләнмә, иманыңны сатма.
Шуннан соң без таң алдыннан гына шалашка кереп яттык. Соңрак исә аның әлеге үгет-нәсихәткә охшаш сүзләрен Коръәннән дә эзләп таптым. Дөресрәге, эзләгәнемне таптым...

*** * ***

Әткәй-Әлмәндәр карт — гыйбрәтле ич, Лев Николаевич Толстой үлгән елны туган һәм нәкъ аның яшендә якты дөньядан китеп барды. Безгә — балаларына — аның абруе Толстой абруеннан һич тә ким түгел иде.

Сизгер иде.
Ул бит үлән үскән
Тавышны да ишетеп яшәде.
Акыл җыйган саен — сабырланды,
Олыгайган саен — яшәрде.
Дуслар белән дусча аңлашты ул,
Кошлар белән кошлар телендә
Җаен тапмый калмас, Әҗәлне дә
Шаяртадыр әле... «тегендә».
Ходай бирмеш көннең һәрбер көнен
Яшәде ул сөеп, тын гына.
Фәрештә дә түгел... Җирдән килгән иде,
Җиргә китеп барды. Шул гына...

Урыны җәннәттәдер дип уйлыйм, амин!

*2003*

**МА-ТУ-У-У!!!**

*(Эссе)*

Нәрсә ул Яшәү?
Бу сорауга, әлбәттә, һәркем үзенчә җавап бирә алыр иде. Минемчә, Яшәү — ул минут-сәгатьләр, көн-еллар бәҗрасыннан хасил булган өзелмәс, тоташ Хатирәләр чылбыры. Хатирәләр икән, димәк, анда уй-кичерешләр, борчу-шатлыклар, яну-көюләр дә булырга тиеш. Баксаң, бар бит алар, бар: Туудан алып Соңгы чиккә кадәр Кеше гомеренең һәр көне сокланып туялмаслык, сөйләп сүз бетмәслек тылсымлы әкияткә тиң ләбаса. Ләкин гомер чылбырына тезелгән көннәр барыбер бердәй түгелләр; була шундый вакытлар, була шундый минутлар — алар синең бөтен җаныңны актарып ташлыйлар, барлык вөҗүдеңне биләп алалар, кайчак хәтта еллар агышын

кирегә дә борып җибәрергә мөмкиннәр. Хикмәт шунда ки: бер көн — ул Мәңгелекнең бер кыйпылчыгы гына. Ләкин Мәңгелек дигәнең үзе үк бер көнгә сыеп бетәргә мөмкин.
Ярый, сүзебезне башлыйк. Хәерле сәгатьтә булсын!
Ма-ту-у-у!!!

* * *

Казанга без таң алдыннан килеп төштек.
Машина бәллүендә йокымсырап барган җиремнән күзләремне ачсам, ни күрим: ул болын-кырлар, ул урман-үзәнлекләр — бар табигать алсу нурлар балкышына күмелгән иде; нәкъ Тукайдагыча «Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң» атып килә иде. Әйе, язлар үтеп, җәйләр җиткәч, печән өсте кергәч кенә була торган, анда да йөз елга бер генә тапкыр кабатлана алырдай үтә дә сәгадәтле вә хиссиятле бер иртә иде ул: Кояш әле агач биеклеге дә күтәрелергә өлгермәгән, дөнья-хәят инде сихри нурлар белән тулган. Офыклар — алсу, алсу; кая күз текәмә — яшеллек, яшеллек: урманнар — яшел, кырлар — яшел... Күктә исә — җәяүле болытлар төркеме, кошлар өне, кошлар моңы...
«Таң җиле куйды исеп, яфраклар аз-аз селкенә». Кыскасы, җиһанда уяну шатлыгы, яшәү хөрлеге! Әнә иртәнге таң нурларында балкып утырган Казан да күренде. Исәнме, иртә! Исәнме, Казан!

* * *

Шулай да Мөслим — Казан юлы безне шактый талчыктырган иде, «КамАЗ»ыбызны йөк алырга килгән склад каршына китереп туктаттык та, эш сәгате башланганчы бераз баш терәп алу зыян итмәс иде, дип, һәркайсыбыз үзенчә урын хәстәрләргә кереште. Шофер егет белән Рәйхан Хантимеров кабинада баш төртеп калдылар, ә мин, җаныма урын табалмыйча, машина әрҗәсенә үрмәләдем. Төнлә белән юлда безне узып киткән йөк машинасыннан төшеп калган берничә фанера кисәген алып салган идек һәм мин соңгы бер ел эчендә өстән төшмәгән фуфайкамны алдым да урман исе, туган як каены исе аңкытып торган ятагыма аудым. Ләкин кая ди ул йоклау! Уйлап кына кара син: әйткәнемчә, күз алдымда аллы-гөлле нурлар биешә, ә күңелдә — борчулар, борчулар...
Безнең ул чакта рәссам егет Рәйхан Хантимеров белән Мөслим районы үзәгендә туган якны өйрәнү музее оештыру нияте белән җенләнеп (мин башкача әйтә алмыйм) йөргән көннәребез иде. Казанга килүебез дә шул хаҗәттән иде: ясалма киез кирәк безгә, һәм бик күп кирәк. Табып булырмы аны, без теләгәнчә бирерләрме, буш кул белән кайтып китмәбезме? Гавәм каршында көлкегә калмабызмы? Зурдан куптык ла, хәерсез; җитмәсә, бу дөньяда сине аңлаучыдан битәр, алдаучылар күбрәк ич. Мөслимдә дә әнә, туган җиреңдә, күз күргән кешеләрең, моңа турыдан-туры «җаваплы иптәшләр» күпме тупсалар таптап йөреп тә музей ачу өчен яраклы бина табып бирә алмадылар. Һәм без череп беткән бер «тавык кетәге»нә кереп утырырга мәҗбүр булдык. Югыйсә, без уйлаганча, бу эшкә бөтен район җәмәгатьчелеге кубарылырга тиеш иде дә бит, юк шул, юк. Мөслимнең әле бу, әле теге почмагында шәхси «хан сарайлары» гөмбәдәй үсеп чыккан бер мәлдә, без — ике хәерче дивана! — үз дөньябызны онытып оешмадан-оешмага бусага таптап йөрдек: «Фәлән-Фәләнеч, ярдәм итегез инде, музей өчен бер-ике кило кадак» яки «бер-ике кубометр такта табып булмасмы», янәсе. Йә, хурлык түгел идемени бу? Әйтерсең лә музей дигәннәре безгә генә кирәк!..
Ярый, без бу хурлыкка түздек. Илшат та түзде (ул музейчылар командасының өченче әгъзасы иде). Безнең көндәлек сорауларга, әлбәттә, «тиешле иптәшләр» дә түзде. Чөнки, күп очракта, аларның колагы ишетми, күзләре күрми торган иде. Ә бит музей аларга да «кирәк» иде. Рухи хаҗәтләрен канәгатьләндерү, халык алдында, тарих алдында торган бурычларны үтәү өчен түгел, әлбәттә, югарыдан килгән рәсми кунаклар алдында: «Менә без дә тик ятмыйбыз, халык өчен яшибез», — дип шапырыну өчен кирәк иде музей аларга. Шулай булмаса, алар без бушка эшләп йөргәндә, әйтик, булган экспонатларны саклап калу ниятеннән музейга магистраль үткәргечтән җылылык кертү өчен күкрәгебез белән диярлек асфальт юл астыннан тоннель тишеп чыкканда: «Первый»ның рөхсәте юк», — дип, әрекмән астына качмаслар иде дә, ахыр чиктә, «Первый» өйдә юк чакта без эшкә керешкәч: «Юлны бозсагыз, үзегез җавап бирерсез», — дип бармак янамаслар иде. Хәер, андыйлардан ни сорыйсың, куркаклыклары өстенә, түргә иске чабата элеп куйсаң, музей була дип уйлый иде ич алар.
Ләкин монда бер яманаты чыккан партократияне генә гаепләү дөрес үк тә булып бетмәс иде. Әйтик, алар «по назначению» шулай сукырлык язмышына мәхрүм ителгән дә булсыннар ди, ә аларны сырып алган укымышлылар кайда иде? Аннары, бер уйласаң, аларны да гаепләп булмый

кебек: халкыңның миеннән гасырлар буена тарихи аң суырып алынгач, ни хәл итәсең; икенчедән, илдә гомуми буталыш барган бер мәлдә нигә әле үзеңне кайгыртып, калганына күз йомып яшәмәскә — җайлы ич!
Тарихи аң дигәннән, шундый бер хәл булып алды. Кичерәк кенә бер оешмада баш инженер булып эшләүче бер иптәш — замана зыялысы! — үтеп барышлый музейга сугылып чыккан иде. Менә шул түшәмгә асылынып куелган мамонт сөяген күреп алды да: «Бәй, бездә дә тарих булганмыни?» — дип гаҗәпкә калды.
Менә шулай, җәмәгать!
Сүз дә юк, «илдә бер дус булмаса да, ил бөтен дошман түгел» дигәндәй, музей төзелешенә дә ихлас күңелдән ярдәм итүчеләр аз булмады. Исемнәрен аерып атамастан, шуны гына әйтә алам: кылган игелекләре күләменчә халык исеменнән рәхмәтләр яусын аларга!
Ләкин музей ачылу көнен иң зарыгып көтүчеләр — балалар иде. Хәтердә ич, музей төзелә икән дигән хәбәр таралуга ук көн саен диярлек биш-алты укучы бала килә иде дә:
— Абыйлар, көне-төне шакылдыйсыз, сездә бик кызык диләр, карап кына чыгыйк инде, — дип, күз яшьләре белән генә ялвармыйлар иде.
Аннары әбиләр, бабайлар килә иде. Алар исә, яшьлекләрен исләренә төшереп, барлы-юклы экспонатлар белән танышып йөргәннән соң:
— И оланнар, бик тә рәхмәтле эш башлагансыз икән, Аллаһы Тәгалә ярдәменнән ташламасын, — дип, берсеннән-берсе матур теләкләр теләп, үсендереп чыгып китәләр иде. Ходай түгел, нәкъ менә алар һәм энтузиастлар, авыл мәктәпләрендә музей почмаклары оештырган фидакярләр үзләренең ярдәменнән ташламады безне. Аларның тырышлыгы белән чүплек башларында аунап яткан, йә булмаса, сандык төпләрендә, чорма-чоланнарда кадерләп саклаган халыкның күңел җәүһәрләре музей түрендә урын ала башлады. Шулай ул, шулай булырга да тиеш: музейны аны бер-ике кеше генә төземи, төзи дә алмый, аны халык үзе тудыра; көндәлек эше, яшәеше, көн итеше белән барлыкка китерә. Их, җәмәгать, төрледән төрле музейлары булган халык нинди бәхетле халык ул! Беркөнне радиодан ишетеп калдым: Германиядә ел саен йөзләгән музей ачыла икән. Ә безнең... авылларда түгел, Казаныбызда — башкалабызда! — тарихыбызны өйрәнүче музей юк. Адәм көлкесе. Милли музеебыз юк!..

* * *

Менә шундый уйлар белән йокыга китә алмыйча күпме изаланып ятканмындыр, бервакыт лаштыр-лоштыр атлап килгән берәүнең нәкъ безнең машина янында туктап калуы сискәндереп җибәрде — таң ката нишләп йөри бу бәндә? Мин теләр-теләмәс кенә урынымнан күтәрелергә мәҗбүр булдым. Карасам, өстенә аксыл төстәге таушалганрак плащ, башына ямьшәйгән кәпәч кигән берәү кулларын маңгаена куйган да, янтая төшеп, Күк йөзенә текәлгән. Ә Күктә... Күктә — тантана: Кояш инде шактый күтәрелергә өлгергән; гөмбәзи җиһан — биек, тирән, ачык; Көн туып килгән офыкның бер читенә «туктаганнар күрмәгә иртүк табигать күркене... аккошлардай ак күчмә болытлар төркеме».
Теге Диванам әнә шул биниһая тирәнлеккә кереп чумган да уйга талган. Ул Күк йөзен күзәтә, мин — аны. Һәм шул мәлдә миемне бер гасабилы уй көйдереп узып китте: «Йа Хода бәндәсе, тегеләйрәк түгелме соң син?»
Әйе, ул акылга җиңелрәк бер бәндә иде; көл төсле йончу йөзенә саран гына сирпелгән елмаюы да ничектер, гадәти кешеләргә хас булмаганча, үтә дә моңсу һәм газаплы иде шул аның.
«...Ни күрә икән ул тирән Күк чоңгылларында? Нинди уйлар бәргәләнә икән аның зәгыйфь аңында? Нинди көчләр сулкылдый икән аның йончыган, талчыккан, талкынган җанында?»
Чү! Тукта! Ни хакым бар соң әле минем аны шулай кимсетергә?! Каян беләсең, бәлки, рухы белән ул миннән мең мәртәбә сәламәтрәктер? Бәлки, бу дөньяның барышын миннән миллион тапкыр дөресрәк тә, тулырак та аңлый торгандыр? Бәлки, ул көндезен дә Күк гөмбәзенә сибелгән йолдызларны күрә алу кодрәтенә ия булган бер җан ияседер?..
Менә аның сүрән, моңсу күз карашлары кинәт яктырып китте, кипшергән иреннәренә, бүлтәеп торган бит очларына (әллә офыктан сирпелгән нурлар уйнаклавы гына идеме ул?) алсулык йөгерде, янтык-какча гәүдәсе тураеп, күкрәге киерелеп киткәндәй булды. Кыскасы, аны күз алдымда алыштырып куйдылармыни: әле генә боегып басып торган җан иясе бу минутларда барлык җаны-тәне белән, барлык вөҗүде белән көлә-шатлана, тантана итә иде; газаплы авырудан соң кинәт савыгып киткән кеше кебегрәк бер ләззәтле халәттә булса кирәк иде ул.
Талгын җил исеп куйды. Ул, кәпәчен кулына алды да, башын горуранә тоткан хәлдә, сакаурак күкрәк тавышы белән Күккә текәлеп бер сүз, бары бер сүз әйтте:

— Ма-ту-у-у-!..
Миңа ничектер уңайсыз булып китте, үземне ярамаган эш өстендә тотылган кешедәй хис иттем
— Ул бит берүзе, тулы бер Җиһан белән күзгә-күз калып сөйләшә иде ләбаса! Дөресрәге, ул мине шәйләмәгәндер дә әле, шушы тузанга баткан машиналар, акшары коелып беткән шыксыз йортлар, вак-төяк мәшәкатьләр каршында дер калтырап торган кешеләр — берсе дә, берсе дә юк иде аның өчен бу минутта! Ул бар да, Җиһан бар...
Аннары ул, шулай сәер генә көлемсерәп бераз басып торды да, әкрен генә, җирне авырттыра күрмим дигәндәй сак кына атлап, урыныннан кузгалды. Биш-алты адым киткәч, тагын Күк йөзенә күтәрелеп карады һәм тагын үзе генә аңлаган телдә әлеге сүзне кабатлады:
— Ма-ту-у-у!..
Ул китеп барды. Минем өчен гелгә, мәңгелеккә... Шул китүе белән мәңге чишелмәслек сорау да биреп калдырды: «Әй, кем идең син матурлыкны дөньядагы барлык адәми затлардан да ныграк тоя алган зәгыйфь акыллы изге җан иясе? Күктәге матурлыкка гына гашыйк-әсир идеңме син, әллә күңелеңдә изрәп яткан изге хисләрең кодрәти сүз булып оешып чыктымы?»
Мин тәмам гаҗиз идем. Бер атылуда машинадан сикереп төштем дә Рәйханны дер селкетә башладым.
— Син нәрсә, понимаешь, сәхәр вакытында төш күрә-күрә йокы симертәсең, җаны бар кешеләр әнә Җиһан белән сөйләшәләр...
Үзем шаяртмакчы булам, үземнең башта бөтенләй башка уйлар. Рәйхан да минем кебек юләррәк кеше: югыйсә тора салып буш кул белән музей төзүгә алынып идемени, булып узган вакыйга хакында бер-ике сүз әйтү белән чикләвекнең юкәдә икәнлегенә тиз төшенеп алды — машина яныннан бер-ике адым читкәрәк китте дә, Күк йөзенә текәлеп:
— Нигә, ма-ту-у-у... ич! — дип куйды.
— Чынлап та, ма-ту-у-у ич!
Бу юлы инде әлеге Илаһи сүзне без икебез беравыздан кабатладык.
Бу хәлләр әле кичә генә булып узган кебек иде, уйласаң, биш ел гомер узып та киткән икән. Гомер узгандыр анысы, уза инде ул, ә шул вакыт эчендә бик күп вакыйга-күренешләр күңелгә кагылмыйча да узып киткәндер, бәлкем, ләкин әлеге хикмәтле Сүз колак төбемдә һәрдаим яңгырап торды дисәм, валлаһи, гөнаһ булмастыр. Үләргә җитеп йөргән, иң бәхетсез көннәремдә дә, түбәм белән болытларга орынып үткән мизгелләрдә дә шул бер Сүз гел күкрәгемдә сулкылдап килде:
— Ма-ту-у-у!..
Моңарчы мин аны, Хозыр Ильястай таңда пәйда булган теге гөнаһсыз зат кебек, Алла белән сөйләшкәндәй, бары үзалдыма гына пышылдый идем. Юк, алай гына да түгел, ул җаным буйлап үз уңаена, эчтән тын гына ага бирә иде. Ләкин күңелгә кайчак шом да килә: «Нигә соң әле бу дөньяның ма-тур-лы-гын күбрәк күрә алган, тормышны матурайту сәләтенә ия булган кешеләргә яшәве торган саен ныграк кыенлаша бара? Нигә ишетмиләр аларның кодрәтле сүзләрен? Әллә бөтен гавәм чукракланып беттеме соң, каһәр суккыры! Каты күңелле «Акыллы»лар күбәйгән саен, нечкә күңелле «Исәрләр» азая барамы соң әллә?»...
Шуңа да минем менә бүген Күкләрне яңгыратырлык, Җиһанны иңрәтерлек итеп кычкырасым килә: җаны исәннәр — ишетерләр, теле барлар — кабатларлар, күзе барлар — күрерләр, иншалла!..
— Ма-ту-у-у-у!..
— Ма-ту-у-у-у!..
*1993*

**СӨЕМБИКӘ МАНАРАСЫНА АЙ КУЙГАН ЕГЕТ ТУРЫНДА ХИКӘЯТ**

Җае чыккан саен без аның белән озын-озын итеп сөйләшеп утыргалыйбыз. Юк, безнең беребез дә сүз тегермәнен тартырга оста, җор телле кешеләр түгел бугай, әмма ихлас күңелдән алып барылган әңгәмә, тәңгәллек, иптәшеңне аңлый һәм тыңлый белү һәртөрле ясалма «артистлар»ны алмаштыра ала икән — аның белән күрешсәк, сөйләшеп сүзебез бетми, коедан суыбыз китми... Бәлки, рухи якынлыкны сизгәнгә, бер-береңне баетып, тулыландырып яшәгәнгә шулайдыр ул? Мөгаен, шулайдыр! Кыскасы, ни генә булмасын, рәссам Илдар Әхмәдиев «алу»дан битәр, дусларын баетып яшәүче олы җанлы, киң күңелле, дусны дус итә белә торган кабатланмас-оригиналь бер шәхес ул! Аның белән аралашып яшәгәннәр миңа алдашырга ирек бирмәс...

...Менә бүген дә без, язгы кояшлы көннәрнең берендә, Казансуның аргы ягындагы Кремльгә йөз куйган хәлдә сәждә кылып утырабыз. Дөнья-хәят шундый тыныч, иркә, әйтерсең лә ул тымызык йокыга талган. Рәхәт тә, моңсу да... Моңсу да, рәхәт тә... Җанда табигатьтән күчкән тел белән әйтеп бирә алмаслык садә бер халәт...
— Һай, туганкаем, дөрес әйтәсең, — диде ул эчке бер яшерен дәрт белән (ничә тапкыр сынаганым бар, күңеле хушланганда ул үзеннән кечерәк яшьтәшләренә гел әнә шулай «туганкаем» дип олылап эндәшер), — һәр кешенең язмышында риваятькә тиң гыйбрәтле вакыйгалар була икән шул ул.
— Ә бәлкем, риватьләр нәкъ менә кеше язмышына бәйле рәвештә туа торганнардыр да әле?!
— Бик мөмкин.
Никадәрле генә кызу канлы, туры сүзле булмасын, Илдар Әхмәдине кабаландырырмын димә: әнә ул өстендәге кәгазь-каләм йөртә торган букчасын саклык белән генә ипләп куйгандай итте; авып китмәсен тагын, дип, «шифалы су» шешәсен гәрәбәдәй сап-сары комга утыртып куйды; шуннан соң гына ярты юлда өзелеп калган сүзен дәвам иттерде:
— Яшәү үзе үк риваять бит инде ул, дисең инде? — Һм! — Аның ирен читләренә хәйләкәр елмаю кунды. Ул кайчак шулай сабыйларча шуклана да белә. — Менә бит без дә Пушкиннар нәселеннән! Ышанмыйсызмы?
Аннары, нишләр микән бу дигәндәй, башын чөеп куйды (уйнама безнең белән, янәсе).
Мин ни әйтергә дә белмичә телсез-өнсез калдым: уйлап кына кара син — Пушкиннар нәселеннән, имеш. Ә югыйсә мин аның бөтен чыгыш юлын беләм дип уйлап йөри идем.
— Башы болайрак башлана, бик гади генә, — диде ул җавабымны да көтмичә. Бу минутларда мин аны бераз «Гайҗан бабай»га охшатып җибәрдем. — Бабамның бабасының бабасы, ягъни Әхмәди карт 1812 елгы гражданнар сугышында катнашкан бер каһарман була. Татар-башкорт атлы гаскәрендә хезмәт иткән ул. Менә шул Әхмәди карт, ук-җәя белән генә коралланган Әхмәди карт, Нарикс шәһәренә беренчеләрдән булып бәреп керә. Аңа шушы батырлыгы өчен, трофей рәвешендә, ике француз юыртагы һәм моркира, безнеңчә пушка була инде, бүләк итәләр. Көннәрдән бер көнне Әхмәди карт, Парижны алучы кыяфәтендә, элеккеге Лаеш өязенең Сиңгеле авылына кайтып төшә: бер француз атының иярендә үзе, икенчесендә — пушка. (Сиңа мәгълүмдер дип уйлыйм, элегрәк җиңел пушкаларны, аеруча тау-ташлы урыннарда, махсус көйләнгән атлар белән күчереп йөрткәннәр. Ярый, бусы сүз уңаенда гына.) Ә авыл халкын беләсең инде, ялгыш-молгыш бер генә адым атла, хәзер кушамат тагарга тора. Шулай итеп, пушка алып кайткан Әхмәди карт та «Пушкин» булып китә. Пушка белән Пушкин арасы ерак түгел лә ул... Йә, кем әйтә безне Пушкиннар нәселеннән түгел дип?!
— Ышанам, ышанам, анысы пушкинлык үзеңдә дә җитәрлек.
— Дөрес сүзгә җавап юк, мине хәзер дә «тәртипле бала» дип әйтеп булмый торгандыр, мөгаен. Хәер, бер уйласаң, рәссам булып китүем дә әнә шул гөнаһсыз шуклыклардан башланып китте бугай. Киров урамында үстем мин; хәзерге 56 нчы йортның ишегалды — Фукс йорты каршында гына ул — безнең ише почык борыннарның крепость-бастионы иде. Чыннан да, безнең ишегалды крепость-кальга кебек дүрт яктан да икешәр катлы йортлар белән әйләндереп алынган иде. Шул йортларның берсендә булачак скульптор Нәүфәл абый Адылов та яши. Ул бездән күпкә өлкәнрәк (ә сиксән белән туксан арасында гына аерма юк ул, сигез белән тугыз арасында җир белән күк арасы), җитмәсә, Нәүфәл абый ишегалдының мәшһүр рәссамы — ул сәнгать мәктәбендә укый иде булса кирәк. Менә Нәүфәл абый аупан-тәүпән килеп баскычтан төшәр, безнең яннан вәкарь белән генә үтеп китәр. Көнләшү дип әйтә алмыйм, сабыйларча бер этлек булгандыр инде, тотам да корым белән бөтен диварларны тутырып Нәүфәл абыйның капкорсаклы сурәтен төшереп куям бит. Үсмер чакта ук калынрак гәүдәле иде ул. Нәүфәл абый кайта, берни булмагандай сурәтләрне сөртеп-бетереп чыга. Ә икенче көнне — диварларда тагын аның сурәте. Шулай бер түзә бу, ике түзә һәм, түземе төкәнгәч, беркөнне мине тота да тукмый. Мин дә үҗәт — тагын корымга үреләм. Нәүфәл абый да бирешми — очраган саен «кәҗә мае» чыгарып китә. «Чаян» өчен ясалачак «картиналарым» Нәүфәл абый тырышлыгы белән үзебезнең ишегалды диварларында «мактаулы» урын алдылар.
— Илдар абый, бәлки, шулай яшьли «тормыш университетлары» үткәнгә Сез яшь талантларга игътибарлы булгансыздыр?
— Изгелек җирдә ятмый ул. Хет үтер, ятмый. Лотфулла Насыйров, Герман Огородников, Суфия Насыйрова һәм Виктор Бунь кебек дөньякүләм танылган рәссамнар, мактану булып аңлашылмасын, мине үзләренең остазы итеп саныйлар. Чынлап та, иҗатларының башлангыч чорында мин аларга хәл кадәренчә ярдәм итәргә тырыштым. Әле дә хәтеремдә, «Яшь ленинчы» газетасының, безнең телдә әйтсәк, «нолевой» санын мин ясадым. Шуннан соң көчләп диярлек үз теләгем белән дилбегәне таланты чәчрәп торган рәссам Герман Огородников куенына

тапшырдым. Югарыда исемнәре телгә алынган рәссамнарның кайсысы бүген Канадада яки Төркиядә, кайсысы Америка Кушма Штатларында, кайсы Болгариядә яки элеккеге Югославия илләрендә махсус заказлар алып эшлиләр. Димәк, чикләр киңәя...
Шунысы кызык, туганкаем, чит илләргә чыгу анысы бер мәсьәлә, менә бит алар кайда гына булсалар да, нинди генә заказ алсалар да, Казан мәктәбе традицияләрен дәвам итәләр, чукынчыклар. Әле күптән түгел генә кулыма Леонид Насыйровтан бер сөенечле хәбәр алдым. Ул Болгариядә балаларны урыс теленә өйрәтү өчен уку китабы чыгарган икән. Нишләтәсең инде аны, китап, кем әйтмешли, баштанаяк шул Казан мәктәбе традицияләренә нигезләнеп, татар-болгар рухында эшләнгән. Бик сөендем, сөенми мөмкин түгел. Шәхсән Леня өчен дә, татар мәдәниятенең торган саен киңрәк, олырак дөньяга чыгуы өчен дә сөендем. Ә мин генә Казанда... Казанымда...
Ул әсәренгән иде, ахры, «карт сөякләр бераз язылсын әле» дип, урыныннан торып басты да Казансу буена төшеп китте.
Үкенү сүзләре идеме бу? Юк! Бу хакта минем аның үзеннән дә сорап караганым булды. «Нигә?» — дигән сорауга ул, өздереп: «Ташлап киталмадым. Мин бит кендегем белән Казанга, татар мохитенә береккән», — дип җавап биргән иде.
Әйе, рәссам буларак, аның үкенерлек эшләре юк. Әйтик, ул — Татарстанда графика сәнгатенең иң абруйлы осталарыннан берсе. «Чаян», «Сөембикә», «Салават күпере» кебек журналларны Илдар Әхмәди иҗатыннан башка күз алдына китерүе дә кыен. Дөрес, сурәт төшерүчеләр күп ул, тик менә аның кебек рәсемгә җан өрүчеләр — бармак белән генә санарлык.
Аның остаханәсендә балалар өчен чыгарылган татар журналларын карап утырабыз. «Их, ясый да белмиләр инде балаларны, сабый урынына бабай йә әби сурәтен төшереп куялар. Андыйларның кулларын төясе килә, — дип карап-аптырап утырды ул. Ә берәр «матур» рәсем-сын күрсә, китап тоткан кулын өскәрәк күтәреп селкеп җибәрә дә авторны мактый башлый: «Вәт, маладис! Шәп! Балалар күңелен тоя, балаларча уйлый һәм уйлый белә, чукынчык», — дип, сөенечен яшерә алмыйча авызын ерып елмаеп җибәрә.
Җанны тоя алу, сүз яки сурәт аша яшәешнең асыл фәлсәфәсен ачу — әдәбият-сәнгатьнең төп бурычы шулардан гыйбарәт түгелме соң?
Хикмәти Хода, ә Илдар Әхмәди бу яктан бәхетле иҗаткяр: аның матур «кешеләре» исә чынлап та матурлар. Балалары сөйкемле, шук-шаян, иркә-нурлы; кызлары горур-чибәр, зифа вә сәгадәтле; ир-егетләре исә гайрәтле вә акыллы, мәһабәт вә солтанлы.
Шул чакта мин аның остаханәсенең диварлары буш булуга игътибар иткән идем. Югыйсә кайберәүләрнең остаханәсе эреле-ваклы картиналар белән тулган була ич.
— Моның сере бик тә гади, туганкаем, — диде ул бер дә исе китмичә генә. — Бердән, — мин майлы буяулар белән бик сирәк эш итәм; димәк, күләмле картиналарны аз язам. Минем эшләрем, нигездә, журнал-китапларда. «Азат хатын» журналына гына да унҗиде ел гомеремне бирдем. «Чаян» белән «Азат хатын» журналында басылган рәсемнәрне бергә җыйсаң, үзе бер күргәзмә булыр иде. Аннары, чын рәссамның эшләре музейларда яки шәхси коллекцияләрдә, журнал-китап битләрендә «сакланырга тиеш»; һәрхәлдә, әзер картинаның урынын остаханәдә түгел дип беләм.
Бүгенге көндә Илдар Әхмәди балалар өчен чыгарыла торган «Сабыйга» журналы белән «Мирас»ны шефлыкка алды. Ул татар ханнарының портретлар галереясын тудыру уе белән янып яши. Нәкъ менә янып яши. Борынгы темаларга мөрәҗәгать итүче кайбер (хәтта танылып өлгергән) рәссамнардан аермалы буларак, рәссам типажларын хәзерге заман кешеләре арасыннан эзли, эзли һәм таба. Шуңа күрә дә аның ханнары һич тә бер-берсенә охшамаганнар, алар җан-рух белән өретелгәннәр. Рәссамның үз сүзләре белән әйтсәк, Илдар Әхмәди иҗат иткән ханнар бер үк төсле «опереточный курчаклар» түгел, ә бәлки реаль җирлектә туган сәнгать әсәрләре. (Сер итеп кенә әйтим, бер «ролендә» мин дә сурәткә төштем.)
Ә «Майлы буяулар белән азрак эш итәм» дигән сүзләрдә беркадәр хаклык булса да, биредә моңа да бераз төзәтмә кертәсе килә. Беренчедән — Илдар Әхмәди акварель буяулар остасы, бу адым рәсем сәнгатендә иң мәкерле өлкәдән санала һәм ул әлеге мәкерле мәхәббәтенә хыянәт итмәскә тырыша. Дөресрәге, акварель сәнгате аны һәрдаим чабуыннан тартып тора. Икенчедән, майлы буяулар белән эшләнгән КамАЗ сериясен кая куясың? Ә Тукай темасы — Илдар Әхмәди иҗатында үзе бер олы дөньяны хәтерләтә. Аның «Тукае» башка берәүнекенә дә охшамаган, рәссам бутарик алымнардан кача. Бу уңайдан «Тәфтиләү» картинасына күз ташлау күп нәрсәгә аңлатма кертер сыман. Биредә кул белән түгел, җан белән, йөрәк белән сурәтләнгән мохит хөкем сөрә.
Әнә алгы планда, арбада — татар кызлары, алар артка карап утырганнар, башлары түбән иелгән. Ә алда: өметсезлек — каршыдагы кыйшаеп беткән кызыл кирпечле тәбәнәк кенә бистә йорты

шуның символы. Тукайның да башы түбән иелгән, әйтерсең лә ул «сөялгән дә чатта баганага» татар халкының кара язмышы турында борчылып уйга баткан. Никадәрле моң, сагыш, илаһият бар биредә.
Көлгән тавышка уянып киттем.
— Нәрсә, ялгыз байгыш кебек моңаеп утырасың, әллә бер кызык нәрсә турында сөйлимме үзеңә? — диде ул килә-килешкә. — Сөембикә манарасына карап тордым да, гөлт итеп исемә килеп төште. — Беренче булып ярым айны мин куйган идем бит аңа.
— ???
— Ашыкма, ул болай булды.
— «Азат хатын» журналында эшләгән чак. Тукайның тууына 90 ел тулу уңае белән журнал эчендә календарь эшләргә куштылар. Мин уйлыйм инде, анда Тукайның Казанга кайтуы сурәтләнергә тиеш, дим. Димәк, «Пар ат» мотивын үзәккә алырга кирәк. Тукай Казанга килсен дә ничек итеп инде Сөембикә манарасына күз атмасын! Ул чакта Сөембикә урысның көяз чиркәүләре арасында посып кына утыручы бер мескен манара иде. Туктале, мин әйтәм, бу мескенемә татар рухы иңдерим, дим, һәм аның очына кечкенә ай сурәте ясап куйдым. Редакциядә моңа берәү дә игътибар итмәде, әлбәттә, календарьлы журнал типографиягә төшеп китте, озакламый басылып та чыкты. Ул еллардагы гадәт буенча берничә көннән журнал өлкә комитетының идеология бүлегенә барып җитә. Менә бервакыт баш редактор Асия апа Хәсәнованы өлкә комитетына чакырып алалар да өстәл төеп яный башлыйлар:
— Сөембикә манарасының башына ник ай куйдың, милләтчелек белән шөгыльләнәсең, хәзер үк эшеңнән алабыз, — диләр.
Нишләсен, Асия Фәридовна обкомнан редакциягә шылтырата, чүт җыламый гына: «Илдар, аңлатып бир инде шуларга, нәрсә соң бу?» — ди.
Үз гомеремдә беренче һәм соңгы мәртәбә обкомнан кара «Волга» белән килеп алдылар. Бардым. Сөзәрдәй булып каршы алдылар. «Йә, аңлатып бир, нәрсә бу?» — диләр.
Җавабым әзер иде, билгеле:
— Ул бит манарада түгел, мин әйтәм, Күктәге Ай бит ул. Манарага беркетелмәгән бит ул. Ә бары тик мин ясаган ай.
Шунда берсе әйтеп куйды:
— Котылдың, төгәл логика белән аңлатып бирдең, — диде. — Вопрос исчерпан.
Ә кайсыдыр артымнан ысылдап калды:
— Ну ты, сволочь.
Ә хәзер, әнә, шөкрана кылыйк, Сөембикә манарасының нәкъ очында, болытларга терәлеп торырдай диярлек биеклектә, кыйблага карап ярым ай җемелди.
Күктә ай калыкты. Без дә урыныбыздан кузгалдык. Алтын айлы көләч манара безне күздән югалганчы озатып калды. Шул вакыт Илдар Әхмәди артына борылып карады да, күктәге ай белән манарадагы айның тәмам якынаеп, бердәй булуына ишарә ясап:
— Мин ясаганда да күктәге ай нәкъ шул турыда иде. Ул нәкъ Сөембикә манарасы очында иде, — дип кеткелдәп көлеп куйды.
Аның көлүеннән бөтен Казансу буе сискәнеп киткәндәй булды.

*1996*

## БЕР ЙОТЫМ СУ

*(Карт рәссам сөйләгәннәрдән)*

Бөтен ил буйлап Бөек Җиңүнең 50 еллыгын «лаеклы» каршыларга хәзерлек барган көннәр иде. Шау-шу, ыгы-зыгы. Купшы сүзләр, гомер бакый үти алмаслык вәгъдәләр елга булып агыла. Шәһәр саен диярлек иртәгә беркем дә аяк басмаячак Җиңү парклары ачыла. Сугыш ветераннарына целлофан пакетларда бер кабып йотарлык «имездек» таратыла. Гәзит-журналлар исә, ярыша-ярыша, Җиңүнең «әһәмиятен», совет солдатларының сугышта күрсәткән каһарманлыкларын тасвирлаучы материалларга конкурс-бәйге игълан итәрләр. Ул язмаларда, әлбәттә, элекке еллардагыча туплар атачак, миналар шартлаячак, дзот-биеклекләр алыначак, елгалар кичеләчәк, шәһәрләр азат ителәчәк... Ә безнең курку белмәс совет солдаты исән калачак, теләсә нинди авырлыкларны да «уңышлы» җиңеп чыгачак...
Без рәссам Илдар Әхмәдиевнең өендәге эш бүлмәсендә сөйләшеп утырабыз. Телевизорда да сугыш турында... Гәзит-журналларда да, радиода да.
— Ну малай, — дип куйды Илдар абый, гадәттәгечә башын артка чөя төшеп. — Туйдырды бит

инде бу ялган, күз буяу, күрәләтә халыкны алдау. Бер көнлек бәйрәм. Җиңелү бәйрәме... Ә, кстати, сөйлимме сиңа үзем белән булган бер вакыйга турында? Бәлки, кирәге чыгар, тарихи сабак буларак.
Бездә бит, әнә, күреп торасың, сугышны бер генә яклы итеп күрсәтәләр, — дип башлады ул үзенең хикәятен. — Сугыш икән, димәк, анда ким дигәндә ике каршы як чәкәләшә бит инде. Мин менә шул каршы як турында, ягъни немес әсирләре турында бер кыйсса сөйләмәкче булам. 1943 ел. Җәй. Чиллә вакыт. Чыдар әмәл юк. Ачлыкка ничек тә түзә адәм баласы, ә сусауга — юк. Кыскасы, мин Киров урамында (ул вакытта урам таш белән түшәлгән иде), Фукс йорты каршындагы өй почмагында су сатып утырам. Суым — графинда, стаканым да бар. Графиным бушау белән, өйгә йөгереп керәм дә, тагын урыныма килеп утырам. Бер сүз белән әйтсәк, үтеп-сүтеп баручыларны салкын саф су белән кинәндерәм генә. Әмма, уйлама, җиңел эш түгел иде ул. Көне буе кояшта утырсаң, шуңа вафлисыз ярты туңдырма алырга була. Аңлагансыңдыр, бик рәхәттән чыгып утырмыйсың бит инде, берәр ипилек эшләп булмасмы, дип уйлыйсың. Әти, Габделкаюм абзыең була, сугышта. Әни, Бәдриҗиһан исемле иде, дүрт бала белән торып калды. Казна эшендә эшли алмый, билгеле. Өйдә утырып шәл бәйли, парашют ефәгеннән яулык тегеп базарда сата. Шунысын да искәртим, әнкәй киң күңелле, бик тә тырыш кеше иде. Тагын бер шундый вакыйга истә калган. Утын ягып ятабыз. Кышка 10–12 кубометр утын китә. Бервакыт шулай Лаештан әткәйнең элекке авылдашлары ике-өч олау утын китерделәр. Әнкәй үзенең көмеш беләзеген сатып өлгергән иде инде, әҗергә әткәйнең «Омега» дигән сәгатен тәкъдим итте.
Тегеләр:
— Юк, юк, алмыйбыз, Габделкаюмның төсе итеп сакла, — диделәр. — Исән-имин генә әйләнеп кайта күрсен!..
Теләкләр хуш килде анысы, шөкер. Ходайның амин дигән чагына туры килде, ахры. Ләкин әтине без көчкә эзләп таптык. Әйе, әйе, эзләп таптык, Казан госпиталеннән, бер елдан соң. Контузия алган булган, адресны да, исемен дә хәтерләми. Менә шундый хәлләр.
Ярар, читкәрәк киттем бугай. Утырам шулай кычкырып: «Во-да! Вода! Свежая вода!» — дип. Минем яннан гына немес әсирләре сафы үтеп бара. Бу инде күнегелгән бер күренеш иде, аларны көн саен опера-балет театры төзелешенә йөртәләр иде. Алда — дүрт, биш рәт немес офицеры бара, арттарак — солдатлар. Киемнәре һәм кыяфәтләре күңелгә ничектер шом сала иде, шуңа соры саз төсен яратмыйм хәзер. Саф бара әкрен генә бер көйгә тирбәлеп. Аларга сакчыларның мылтыклары төбәлгән, читкә бер адым атла, хәзер атып егачаклар.
Иртәнге сәгать 8 ләр иде, ахры. Кинәт әсирләрнең берсе сафтан атылып чыкты да, күз ачып йомган арада алдымдагы сулы графинымны эләктереп, кире сафка кереп тә югалды. Ай күрде, кояш алды дигәндәй, мин аңыма да килә алмый калдым.
Еларга җитешеп өйгә кереп киттем.
Кич белән әни кайтып керде. «Улым, йә, күпме су саттың, — ди бу, — берәр ипи алырлык булмадымы?»
— И әнкәй, — дим мин, балавыз сыгып, — су гына түгел, графинымны да саттым... Графинымны немесләр алып калдылар.
Әнкәй алай артык орышмады.
Икенче көн дә туды. Тагын үз урыныма барып урнаштым. Тагын саф-саф булып немес әсирләре үтеп бара. Тагын шул ук немес әсире сафтан атылып чыкты да, алдыма графин китереп куйды. Һәм күз ачып йомганчы юк та булды. Карасам, ни күрим, әкияттәге кебек менә, графин тулы вак акча!
Хәзер кара акылым белән уйлап куям, конвойның да төрлесе була икән. Алар ник бер игътибар итсеннәр бу хәлгә, юкса күреп торалар бит инде, турыдан-туры устав кагыйдәләрен бозу бара. Болар безнең әсирләрне саклаучы ГУЛАГ конвойлары кебек кансыз булмаган, ахрысы. Әллә немес әсирләренең җаны кадерлерәк булганмы? Уйласаң, уйланырлык нәрсәләр бар биредә, туганкаем... Ә теге акчаларга килгәндә, алар безнең гаиләдәге өзелгән җаннарны бераз вакыт ялгап яшәргә ярдәм итте.
Шулай диде дә Илдар абый кухня ягына чыгып бер чынаяк су алып чыкты.
— Мә, эчеп җибәр, теге әсирләр рухына. Алар күптән вафаттыр инде, мөгаен. Солдатның ни гаебе бар, ул әмер генә үти ләбаса. Минем әткәй дә әнә, кирәк булгач, сугышка куып керткәч, кулына корал алырга мәҗбүр булды. Ә кайчагында кешене үлемнән йолып алып калу өчен бер йотым су да җитә ул. Бәлки, минем графинымдагы суым да теге чакта берничә немес әсирен үлемнән алып калгандыр? Кем белә... Ә бәлки, теге якта, минем кебек берәр немес малае да, җае туры килеп, безнең мескен әсирне бер йотым су белән сыйлагандыр һәм тормыш бүләк иткәндер? Дөнья бу... Ходай каршында һәркем бертигез.

Шушының белән су турындагы хикәят төгәлләнгән иде инде. Сүз бетсә дә уй дәвам итә бит ул. Шулчак бала вакыттагы бер хатирә искә төште.
Авыл клубы. Кино бара. Элегрәк халык кинога агылып йөри иде. Билгеле ки, безнең үше билетсыз тишек борыннарга урын калмый иде. Ә без аптырап тормыйбыз, сәхнәгә менәбез дә, ак бәздән тегелгән экран артына чыгып кунаклыйбыз. Алгы яктан карасаң да, арткы яктан карасаң да шул ук күренешләр ич. Аерма шунда гына: экран артында сурәтләр тоныграк була. Ә без зарланмыйбыз, идәнгә тезелешеп тын гына утырабыз, теге усал киномеханик агай гына куып чыгармасын да, кино карау ләззәтеннән мәхрүм итә күрмәсен. Ә кино кызык, мавыктыргыч — сугыш турында. Безнекеләр — батыр, акыллы, җиңә-җиңә алга баралар, үлмиләр, чукынмышлар. Ә нимесләр — куркаклар һәм юләрләр, шуңа да үләләр дә үләләр, кырылалар гына.
Их, без, беркатлы авыл малайлары, әтиләребез, сугыштан исән-сау әйләнеп кайтканнары өчен генә, әнкәйләребез мең михнәт-газапларга да бирешмичә, тугрылыклы Хатыннар — АНА булып калганнары өчен генә Ходай тарафыннан яшәү-туу дигән могҗизаи олуг бүләккә лаек булган сугыш арты яшьтәшләрем! — шул чакта без сугышта җиңүче дә, җиңелүче дә була алмавын аңлый алдык микән? Һәм хәзер дә аңлыйбызмы без? Сугыш — ул фаҗига, һәлакәт, үлем, гаделсезлек, хаксызлык символы лабаса. Монстр, җанвар. Ә фаҗига расаларга һәм кавемнәргә бүленми.
Әнә бүген дә ил буйлап тоташ КИНО бара. Махсус төшерелгән кино! Артистлары — сәясәтчеләр, массовкада катнашучылары — гади халык, хезмәт кешесе, Кешелекнең аз санлы булган өчен генә рәнҗетелгән тигез хокуклы вәкилләре; ә бу тамашаның башында — Мәскәү... Югыйсә, тулы бер халыкны, тулы бер халыкларны кыру сәясәте алып барылганда, шәһәрләр җир белән тигезләнгәндә хөрлек сөюче ватанпәрвәрләрне «сепаратист», «бандит» һәм башка шундый пычрак исемнәр белән атап булыр идемени? Такташ исән булса, бүген дә: «Чемберленның сатыйм анасын, тупка токкан Мәккә каласын», — дип оран салыр иде. Яки шул ук «җиңүче» солдатның — гади халыкның аңлы рәвештә кол дәрәҗәсенә төшерелүен ничек аңларга? Бу бит шул ук канлы кулларыңны халыкларның ак күлмәгенә сөртеп, җинаятеңне яшерергә омтылу түгелме соң?
«Кешеләр, — дип эндәшәсе килә олуг фикер иясенә ияреп, — уяу булыгыз! Без, әгәр чынлап та гуманистлар икәнбез, кайчак тарихи вакыйгаларга да «экранның арткы ягына» чыгып бәя бирергә өйрәнсәк иде. Сабак алыр өчен. Берьяклы караш ул һәрвакыт һәлакәткә илтә.
Су бирегез миңа! Бер йотым су! Авыр чакларда, тамакларыбыз кибеп корыганда бер йотым су бирешик без бер-беребезгә, Кешеләр!.. Бары бер йотым су...

*1996*

## БОЗ ӨСТЕНДӘ ЯЛГЫЗ МАЛАЙ

Безнең өй каршында ук буа бар. Дөресрәге, бар иде. Элегрәк, язын ташкыннар ташып үткәннән соң, урманнан төшкән кар сулары челтер-челтер йөгереп узгач, авыл халкы бердәй күтәрелеп, ат-арбалар белән кәс ташып, читән-чыбык катнаштырып күпер алдына җыйнак кына бер буа буып куяр иде. Без үскән йортның капкасы терәлеп диярлек ачылгангадыр инде, тора-бара «Гыймран буасы» дип аталган бу сулык, күз кердисә, авылның каз-үрдәктән ишлерәк эреле-ваклы бала-чагасы өчен чын мәгънәсендә «халык шугалагына» әверелә иде. Бу элегрәк шулай иде.
Мин хәзер атам-анам йортында кунак кына. Менә бүген дә, газета эшләре белән тирә-юнь авылларда йөреп арыганнан соң, туган нигезгә сугылып чыгарга булган идем: хәл-әхвәлләр хакында сөйләшеп, чәйләр эчеп хушлашкач, өйдә берәрсе юлга чыгар алдыннан гына була торган тынлык урнашты.
— Ничек инде, кунып та китмисеңмени? — дип, бер яктан икенче якка әнкәй чыгып йөри. — Ниләр генә җибәрим соң күчтәнәчкә, берниләр дә юк, ичмасам. Бигрәк тизгә икән! Һәм аннан тезеп китә: — Аягың бигрәк юка икән, юлга шулай чыгалармыни? Кая гына куйдым соң, сиңа дип атап бәйләп куйган чөлкәм бар иде бит югыйсә. Йон бияләй кирәк түгелме?
— Юк, юк, әнкәй, — дим мин, ничек тә аны тынычландырырга тырышып. — Берни кирәк түгел... Барысы да бар...
— Ал, ал, ни бирсәләр — шуны ал син, — дип сүзгә кушыла әткәй, ишегалдына караган тәрәзә яктысына күтәргән «Авыл утлары»ннан аерылмыйча гына уенын-чынын бергә кушып. — Сандык ачылганда алып кал.

Үзем картларны тыңлыйм, үзем урам як тәрәзә аша буаны күзәтәм. Буа дисәң, хәтерең калыр — аның бер исеме генә инде. Аны быел буып та тормаганнар. Ләм, сырганаклар басып бетергән төбендә, аның да урта бер төшендә аяк чылатырлык уентык су боз булып каткан. Шул боз уртасында бер малай басып тора. Безнең күрше егете Ильяс ул.
Егет булмый ни. Ильяс өченчеме, дүртенчеме класста укый ич инде: Индус белән Фәниянең икенче малайлары, зурысы хәрби хезмәттә. Менә ботинкалы конькие белән талпынып китә дә колач киңлеге шугалагының икенче башына барып төртелә. Тагын икенче якка борылып талпынып китә. Бер-ике адым атлау белән аргы башка барып җиткәч, «бетте дәмени әле» дигәндәй аптырап, күзлеген борыны өстенә күтәреп куя. Күтәреп куя да беркавым яр буендагы корып ауган өянкеләргә, ялан-кырлар ягына карап уйланып тора. Ни уйлый ул? Икеләнми әйтә алам: «менә шушы ярлар боз белән тулып торсын иде» дип күз алдына китерәдер бу минутларда Ильяс. Аның да телевизор-кинолардан күргән үз тиңнәре кебек очынып-очынып шуып китәсе, хоккей уйныйсы киләдер бу минутларда.
Мин түзмәдем, киртләч-киртләч катканаклы урамны бер-ике генә сикереп үттем дә, чалбар балакларына сырганаклар ябышмасын диебрәк, тар гына сукмак кебек җирдән күрше егете янына төшеп киттем.
— Нихәл, Ильяс, шуып буламы соң? — дим булдырган хәтле дустанә тавыш белән.
— Өйрәнеп кенә киләм әле. Күнекмәгәч, аяклар арый.
— Ничава, болай булса, күнегер.
— Бозы бәләкәйрәк шул.
Бөтенләй үк «юк» дими Ильяс, күрәсең, ул моннан да зуррагын өмет тә итми.
— Иптәшләрең дә күренми нишләптер?
— ...абый килермен дигән иде дә, күренми шул әле.
Ильяс кем турында әйтергә теләгәндер, исемен ишетми калдым. Шулай да сорап куйдым:
— Зурмы соң әле ул?
— Сигезенчедә укый инде. Башка кеше юк ич.
Аннары Ильясның күзләре нурланып китте.
— Ну, килсә, уйнар идек инде... — Соңгы сүзен ул сузып әйтте: — Кә-шә-кә-ле. Былтыр килгән иде югыйсә.
Бу сүзләре белән ул мине тетрәндереп җибәрде. «Их, сабый күңеле, — дип уйлап куйдым мин шулчак үзалдыма. — Никадәрле беркатлы һәм ышанучан әле син. Синең өмет йолдызың нинди якты әле. Синең бик тә, бик тә бәхетле булуың өчен конькида шуарлык уч төбе хәтле боз кисәге һәм бер иптәш тә җитә ләбаса. Сиңа шунысы да җитә, сиңа артыгы кирәк түгел. Әмма ялгызлык, тәгәрәшеп уйнарлык җан дустың булмау синең күңелеңә авыр таш булып ятмас микән? Ятмасын иде».
Һәм мин үзебезнең балачакны искә төшердем. Беләсеңме син, Ильяс, без менә шушы буа бозында егерме-утыз бала-чага, гөж килеп, агач тамырыннан үзебез юнып эшләгән шарны үзебез урманнан алып кайткан кәшәкәләр белән куып уйный идек. Аягыбызда олтанлы киез итек иде, синеке кебек конькилар төшкә дә кермәле түгел иде. Әмма без синнән бәхетлерәк булганбыз икән. Чөнки без егерме-утыз идек, күп идек. Кызык иде безгә. Ә син юк бозында килмәгән (?) абыеңны көтеп йөрисең. Оят булса да синең белән кәшәкәле уйнар идем мин, бәләкәч күршем. Тик икебез сыярлык шугалак бозы да юк икән шул син яшәгән туган авылда. Ильяс, олы кайгыңны дөньяга чәчүем өчен гафу ит, син аңларсың мине. Бу минем дә олы кайгым иде. Ышан, нәни дустым!
*2000*

**АВЫРТА!..**

Сөю-мәхәббәт минем җаныма язгы сулар белән бергә бәреп керде. 1964 елның 26 марты иде. Җомга көн. Табигатьнең кышкы йокыдан соң тәмам уянып килгән бер мәле. Күк гөмбәзе — зәп-зәңгәр, чиксез, тирән; һавада — «кошлар өне», язгы кар исе; кыскасы, бөтен хәят нурлы, шашкын дәрт белән тулган бер чак. Әнә әле кичә генә чана юлларында оеп яткан сулар бердәм телгә килгәннәр дә, шатлыкларына тыела алмыйча, урам киңлекләренә җәелгәннәр. Әйе, озак тормас, ерак кырлар түреннән көч-дәрт алган гөрләвекләр, иштәшләре белән гөр-гөр сөйләшә-сөйләшә, үзәнлекләрдә бергә кушылып, көчле вә тыеп булгысыз ташкынга әверелерләр; әверелерләр дә... Бүләк белән Үрәзмәт авыллары арасындагы Аркылы Тал үзәнлеген тутырып ага башларлар. Бу әле, мөгаен, бераздан булыр. Ә бүген?..

Бүген мин үзем дә әнә шул кузгалырга торган ташкын-ду хәлендәмен. Алда җәйрәп яткан көрт өемнәрен сикереп үтәр өчен бер якты нур, бер җылы тамчы да җитәр кебек. Чөнки күңелгә очкын төшкән инде. Хәер, аңлатыбрак сөйлим әле. Моннан нәкъ бер атна элек булды бу хәл. Барысы да Аның кулларын ялгыш кына авырттырудан башланды. Кичкырын иде. Чаңгыларымны мәктәп бинасы янындагы коймага сөяп куйдым да физкультура укытучысы янына кереп киттем. Бераздан әйләнеп чыксам, ни күрим: Ул минем саклап-кадерләп кенә тоткан ярыш чаңгыларым белән берни булмагандай каткан кытыршы кар өстеннән тау шуып ята! Җитмәсә, Такташ әйтмешли, үзе көлә, үзе сөйкемле... Гомумән, чая, шаян, телгә оста иде Ул. Мин Аны ишек төбендә куып җиттем һәм, аны-моны уйлап тормастан, йөгереп килгән уңайга коридорның урам капкасы хәтле ишегенә аягымны терәдем: туктале, җәзасыз гына котылмый тор әле, янәсе, шайтан кызый! Чү, ни булды? Ул кинәт кенә көлүеннән туктап калды, менә-менә елмаерга-үртәргә торган иреннәре дерелдәп куйгандай булды. Шунда гына аңлап алдым: Аның ачарга үрелгән уң кулы ишеккә кысылып калган икән бит! Мин инде Аны менә хәзер бөтен дөньяны бетереп җылап җибәрер дип уйлаган идем, ә Ул сабыйларча самими карашлары белән күзләремә текәлде дә моңсу гына:
— Башка уйнамам... — диде.
Каушап калдым, юк, эсселе-суыклы булып киттем, бәлки, шуңадыр Аның соңгы сүзләрен аңышмыйча да калдым һәм (унҗиде яшьлек «карт юләр» димә инде, мин Аннан өч яшькә өлкәнрәк идем) үзем гафу үтенәсе урынга:
— Алайса, үскәнем, бу бармакларың, дөньяда минем барлыкны белгертеп, гомер буе сызлап торсыннар, — дидем дә тышка атылдым.
Әйе, шушы минутта миңа нәрсәдер булды, бәгыремнән нәрсәдер өзелеп төште, җанымны басып торган салкын карлар эреп юкка чыкты, күкрәгемә ташкын тулды. Йа Хода, уйларга да куркыныч, бу бер гөнаһлы эштер: мин әсир идем, мин аптырашта идем — мин беренче мәртәбә кыз-кыркын затына икенче күзләр белән карый башлаган идем.
Тагын бер атнадан соң мәктәптә әдәби кичә булды. Шигырь кичәсе. Ул чакта, танылып килгән шагыйрь Рәдиф Гатауллин безгә әдәбият укытучысы булып килгәч, Үрәзмәт урта мәктәбе «шигъри бунт» кичереп яшәде. Әнә Зөлфәт олыларча, кулларын болгый-болгый, авызыннан энҗеләр чәчә; Фәрит Гыйльми яңа хикәясен төгәлләгән икән. Шушы кичәдә мин дә беренче шигырьләремне «халык алдына» чыгып укырга җөрьәт иттем. Алар, әлбәттә, туган авылыма һәм Аңа багышланганнар иде.
Кичәдән соң, ул еллардагы гадәт буенча, вальс әйләндек. Беренче мәртәбә мин Аның нәфис кулларын учларыма алдым һәм дулкынлануымны яшерергә тырышып (юк, чын хисләрне яшереп буламы соң аны! Ул да барын да аңлаган иде инде):
— Кулың авыртмыймы? — дип сорый алдым.
— Авырта! диде Ул, ирен чите белән генә мәгънәле көлемсерәп.
Әйе, «Авырта!» — диде Ул. Сөю «авыртмыйча» гына, «авырттырмыйча» гына булмыйдыр шул инде, мөгаен... Һәм без, ике сабый бала, — Абый белән Сеңел — өч ел дәвамында курку-гайбәтләрдән өстен булып, садә һәм гөнаһсыз хисләр кичереп, бер үк сукмаклардан атлап бардык. Ходай шаһит!
*1994*

**БӘХЕТ ОРЛЫКЛАРЫ**

Таң атты исә — яңгыр да болыт; кич җитте исә — болыт та яңгыр...
Шыксыз, караңгы, томанлы көзгә иртә... Таланган бишмәт шикелле асылынган-салынган күгелҗем-кара болытлар күк йөзен томалап алганнар, әйтерсең лә басу-кырларны гына түгел, күкне дә сөреп, актарып ташлаганнар — кайда күк башлана да, кайда кыр бетә, белмәссең, күз алдында тоташ бер караңгылык. Нарат Асты урманнары да, Ык, Мәллә елгалары, таллык, болынлыклар да шул караңгылык артында күмелеп калганнар.
Атна буе, ай буе менә шулай инде. Зәһәрләнә табигать. Табигать зәһәрләнгән саен, кешеләр дә үҗәтләнә бара. Авылда сизәсең ипинең тир түгеп табылганын: тездән пычрак, юеш, салкын, кешеләр җитди, җилкенүле, юлларда машиналар үкерә, басуларда тракторлар гүелди — соңгы ыргым, быелгы урып-җыюның соңгы көрәше бара. Чөгендер өчен көрәш.
Шундый киеренке көннәрнең берендә очраштык без аның белән.
Председательнең эш бүлмәсе. Хуҗа кеше тәрәзәдән тышка текәлгән. Тәбәнәгрәк буй, аякта — кирза итекләр, өстә — сырган фуфайка. Эш кешесе икәне әллә каян күренеп тора.
— Бер дә мактанырлык эшләр юк бит әле, туган. — Ул миңа табан борылып басты. Тавышы

бераз карлыккан икән, әмма эчке рухи ныклык, ихтыяр көче сизелеп тора аңарда. — Чөгендерне бетерми торып җан тынычланырлык түгел әле. Менә хәзер дә шунда чыгып чабарга кирәк.
Без тагын тынып калабыз. Сизеп торам, Дусил Гаязовичның кәефләре бик үк шәп түгел; ә бит югыйсә сөйләсәң сөйләрлек эшләр бар хуҗалыкта. «Кызыл Октябрь» — Мөслим районында иң алдынгы колхозларның берсе. Дәүләткә терлекчелек продуктлары сатуның бишьеллык планын ул әллә кайчан, районда беренчеләрдән булып үтәгән. Терлекчелектән генә дә 185 мең сум саф табыш алынган. Әнә шулар хакында сөйләтәсе килә председательдән.
— Анысы шулай... — Ул тамагын кырып куя. — Шулай... Ләкин, әйтик, безнең сөйләрлек уңышлар булсын да ди, ләкин алар үткәннеке инде. Тагын яшисе бардыр бит әле, алда, кем әйтмешли, яңа үрләр тора. Киләчәк белән яшәргә кирәк. Ә киләчәк белән яшим дисәң, үткәннәр белән мактану килешми инде. Менә, мәсәлән, безнең Мөслим яклары гомергә ипиле як булып макталып килде. Бу чыннан да шулай иде. Тик менә соңгы елларда әллә ни алдыра алган юк ич.
— Нигә соң?
— Мин дә шул хакта баш ватам. Үземне өлкәннәр рәтенә куймасам да, хуҗалык җитәкчесе булып эшләүдә азрак мая туплаган кеше дип исәплим. Ышанасызмы, бер-икесеннән башка, игенче өчен әйбәт килгән елны хәтерләмим. Нишләтәсең аны, игеннәргә менә бүген-иртәгә яңгыр кирәк, юкса эшләр харап — юк, корылык; ә урып-җыю җитте исә — яңгыр да яңгыр. Табигатькә каршы барырга ярамый. Табигатьнең хакиме буласың килсә, аңа буйсынырга кирәк: колы булырга кирәк дигән сүз түгел бу, ә бәлки табигатьнең табигатен тирәнрәк аңларга кирәк дигән сүз. Яраклашырга кирәк аңа... Кеше, илаһи көчкә ия булса да, барыбер табигать баласы ул.
Боз урыныннан кузгалды. Хуҗа фуфайкасын салып, чөйгә элеп куйды, бухгалтерия ягына чыгып нидер әйтеп керде, аннары каршыдагы урындыкка килеп утырды.
— Дусил Гаязович, менә сез: «Табигать үзгәрә, ә аның белән без дә үзгәрергә тиеш», — дип әйтәсез. Конкрет очракта, ягъни мәсәлән, сезнең колхоз мисалында бу үзгәреш нидән гыйбарәт? Әйтик, мөмкинме ул?
— Әлбәттә... Беренче чиратта, корылыкка да түзә торган, давыллы яңгырда да аумый торган сортлар кирәк. — Ул, минем тагын сорау бирергә җыенуымны күреп, кулын күтәрде. — Ашыкмагыз... Менә шулай, быелгы кебек иза чиккән көннәрнең берендә Неттевич Энгель Данилович дигән галимнең «Сорт, тормыш һәм үсеш» дигән китабын кулга төшердем мин. Танылган селекционер, фән докторы. Ул менә нәкъ шундый чыдам, югары уңыш бирә торган бодай чыгаруы турында яза. Гомумән, галимнең үсемлекләрнең үсеш эволюциясенә, селекция мәсьәләләренә караган фикерләре минем җанның бөтенләй астын өскә китерде — шикләнүләр, икеләнүләр җилгә очты, иңнәргә канат үсеп чыккандай булды. Ул туп-туры әйтә, элита орлыклар белән һәр хуҗалык үзен-үзе тәэмин итәргә тиеш, ди. Нигә дип әле безгә дә үз бәхетебезне сынап карамаска?
Кешегә идея генә бир син — шул җиткән. Урып-җыю төгәлләнүгә баш агроном Җәмил Сәлахов белән экономист Фәрит Гыйздәтовны чакырып керттем дә әйттем: «Егетләр, ничек итсәгез итәсез, Неттевич дигән галим бер яңа сорт бодай чыгарган, шуны хет бер гөрәнкә булса да алып кайтасыз. Буш кул белән колхоз ихатасында күренәсе булмагыз», — дидем.
...Көтәм егетләрне, бер көн көтәм, ике көн көтәм — юк, күренмиләр... «Булмады, ахры», — дип торганда кайтып төште болар. Авызлар ерык, кулда ике янчык; янчыкларда — 10 килограмм «Родина», 20 килограмм «ЗОН х 70» сортлы бодай орлыклары. Бәхет кошы тоткан кешеләр кебек йөрдек без ул чакта!
Җитте яз. Чәчкечнең клапаннарын ябып, рәт араларын 45 сантиметр киңлектә калдырып чәчтек без бу орлыкларны. Рәттән «Мироновская яровая», «Харьков-46» бодайларын урнаштырдык. Тикшереп, чагыштырып карау өчен. Ә чагыштырып карау өчен быелгыдан да кулайрак ел булмагандыр, җәй буена бер тамчы яңгыр яумады бит, урып-җыю башлануга — болыты белән төшеп утырды. Ә безнең тәҗрибә бодайлары нишләде дисез?! Башаклар эре, бөртекләр тук, сабаклар кыска, юан — егылуның нәрсә икәнен дә белмәделәр.
Җәйге чиллә уртасында Неттевичның килеп төшүе үзе бер күктән төшкән бәхет булды. Яшермим, тәҗрибә участогыннан канәгать булып калды ул, ләззәтләнеп карап йөрде, киңәшләрен бирде һәм нәтиҗәләрне хәбәр итеп торуны үтенде.
Бераз тын торганнан соң, Дусил Гаязович елмаеп куйды.
— Онытып торам икән әле, — дип дәвам итте ул. — Аларны җыеп алу үзенә күрә бер бәйрәмгә әйләнде. Комбайн белән урып булмый бит инде аларны, ни дисәң дә тәҗрибә бодайлары ич. Бер генә бөртек тә чит сорт катнашырга тиеш түгел аларга. Өлкән гвардияне ярдәмгә чакырдык — урак белән урдык, көлтәләргә бәйләп куйдык.
«Һи, рәхмәт инде бу тәҗрибә бодайларына. Яшь чаклар искә төшеп китте, валлаһи», — дип сөенештеләр картлар, самавырлар акканчы юкә балы белән чәй эчкән арада.

Шундый сорау туарга мөмкин: кайберәүләр уйлаганча, үзен аклармы соң бу кыланулар? Икеләнмичә әйтә алам — берсүзсез. Игенчедән нәрсә сорала? Икмәк үстерү, илгә, халыкка икмәк бирү. Яңа, көчле сортларны сынап карау, тарату ул инде өстәмә көшелләр дигән сүз. Утыз кило бөртек тагын ике елдан бөтен колхоз басуына чәчәргә җитәрлек хәзинәгә әйләнәчәк.
Планнар, хыяллар, киләчәк хакында озак гәпләшеп утырдык. Ә планнар һәрвакыт зур, хыяллар матур инде ул: күңелдәге болытларның сүрелүен сизми дә калганбыз. Гаҗәп, дөнья да яктырып киткән ләбаса: тәрәзәгә күз салсак, ни күрик, иләмсез зур болыт ертыгыннан кояшның бер «колагы» күренеп тора. Каршы яктагы болытлар исә, кояшлы кучмә утраулар сыман, салмак кына урыннарыннан кузгалып, таралыша башлаганнар. Председательнең Дусил Гаязович Шәкүровның йөзе яктырып китте:
— Аязырга гына булса ярар иде.

*1980*

**МӘКАЛӘЛӘР**

## ЮЛЧЫ ЮЛДА СЫНАЛА

Татарстан китап нәшрияты яңа шигырь җыентыгы чыгарды. Исеме — «Юл башы». Аңа дүрт яшь шагыйрьнең соңгы елларда иҗат иткән шигырьләре тупланган. Бу иптәшләрнең кайсылары поэзиянең олы юлыннан атлап китәр, кайсылары юл башында калыр — анысы вакыт эше. Ә бүгенге сүз аларның юл башлары турында.
Әлеге дүрт шагыйрьнең берсе — Кадыйр Сибгатуллин. Ул әдәбият мәйданына артык шауламыйча, тыйнак кына килеп кергән иде. Аннан җайлап кына тизлек җыйды. Ә хәзер, ерак арага йөгерүче йөгерешче кебек, аның тыны тәмам ачылып җитте. Кадыйр Сибгатуллинның узган ел «Казан утлары» журналының махсус бүләгенә лаек булуы да әнә шул хакта сөйли. Шунысы куанычлы, Кадыйр Сибгатуллинда халык күңелен сизәрлек, халык күңелендәге теләк-омтылышларны сиземләрлек нечкә йөрәк бар. Ул үзенең бу өлкәдәге мөмкинлекләрен «Өч йөрәк» дигән кыска поэмасында шактый тулы ача алган. Шагыйрь сугыш җәрәхәтләренең халык күңелендә әле дә төзәлеп җитмәвен күрсәтә бу әсәрендә. Менә авылның соңгы өч егете сугышка китә:

Печәннәре чәбәләнеп калды,
Чабылып бетми калды өч алан.
Чалгыларны онытып
Калдырдылар
Покосларга кадап очларын.

Бу өч егетнең сугыштан исән-имин әйләнеп кайтачагына ышаныч шулкадәр зур, алар хәтта чалгыларын да онытып кына калдырганнар. Әмма ел арты еллар уза. Ә егетләр кайтмый. Алар чабып үткән аланнарга тагын яшелләнеп куе үләннәр үсә, өч егетне озатып калган өч кыз тагын болыннарга чыга. Кызларның шушы чактагы эчке кичерешләре турында түбәндәге юллар ачык сөйли:

Әллә кайчан вәгъдәләшкән кебек
Сыенышып үскән үләннәр.
Аермагыз, без — бер дигән сыман
Кыякларны бергә үргәннәр.

Еллар үтә дә үтә. Ә кызлар һаман «унсигездә шиңгән чәчәкләрен яулык почмагына күчерә-күчерә» егетләрен көтәләр.

Илле яшьлек кызлар яулык чигә,
Дулкынлана яулык читләре.
Ишекләр дә ачык,
Егетләре
Бүген тагын кайтып җитмәде.

Кызлар күңелендә өмет уты һаман сүнеп җитмәгән. Егетләре бүген кайтмаса, иртәгә кайтыр, иртәгә булмаса — берсекөнгә. Әмма барыбер бер кайтыр. Шигырь әнә шулай эчтәлеге ягыннан да, тасвирлау чаралары ягыннан да ифрат тәэсирле чыккан...
К.Сибгатуллин еш кына буыннар арасындагы үзара мөнәсәбәт мәсьәләсен күтәрә, шуның аша заманның четерекле проблемаларын хәл итәргә омтыла. Ул үзен изге көрәш кырларында ятып калган буыннарның турыдан-туры дәвамчысы дип атый. Әмма шунда ук кисәтеп тә куя: әле заман давыллы, «хәтәр җилләр яшь кошчыкка канат чыкканны» көтеп тормыйлар, ояны күтәреп атарга гына торалар. Шуңа да замана әтиләр юлын дәвам итәрдәй ирләрнең тууын һәр

мизгелдә көтеп тора. «Өлкәннәр» шигыре башка шигырьләрдә әйтелгән әнә шул фикерләрнең дәвамы кебегрәк яңгырый. Автор биредә өлкәннәрне юлга чыгарга, яшь буынга юл күрсәтеп барырга чакыра. Без аларга:

Ут бирик.
Учак ягарга
Бер шырпы җитә бит ул.
Бу дөнья бер шырпы сызсаң да
Ялт итеп китә бит ул, —

ди шагыйрь.

Бармаклар да тигез булмаган кебек, Кадыйрның да җыентыкка кергән шигырьләре бер дәрәҗәдә түгелләр. Гражданлык мотивы белән сугарылган әнә шундый шигырьләр арасында йомшаграк эшләнгәннәре дә очрый. Аннары җыентыкка кергән шигырьләрне оештыручы үзәк булмавы да күзгә ташлана.

Әдәбият кырында тагын бер буын борын төртеп килә. Ф.Сафин — шул буынның бер вәкиле. Аның җыентыктагы шигырьләрен укуга күзгә ташланган нәрсә шул: Фәннур эзләнә, үз-үзенә таләпчән карый. Ул аңлый: менә шулай эшләгәндә генә аңа үз юлын табарга, тагын да югарырак баскычка күтәрелергә мөмкин булачак.

Сүз хәнҗәрен ал кыныннан,
Тик ятмасын, —

дигән юллар аның иҗат программасы. Ф.Сафин шигырьләрендәге лирик геройның үз йөзе бар. Ул яшь, яшьлекнең үзе кебек саф, ярсу, ул ярата, шуның утында яна. Лирик герой күп вакыт сөйгәнен күз алдына китерә, аны төрле хәлләргә куеп уйлап карый, хыялында аның сурәтен ясый.

Нурга чумган күзләреңә
Ай сокланып карыйдыр,
Тәрәзәң чиртеп йолдызлар
Дәшәләр гүя: «Ярыйдыр».

Күз алдына китерегез: тәрәзә каршында кыз. Аның йөзенә, күзләренә ай нуры сирпелгән, шунлыктан алар нурланып, яктырып киткәннәр. Бу нурлар, шигырьне укыганнан соң, безнең күңелне дә яктыртып, балкытып җибәрәләр кебек. Ф.Сафинның мондый шигырьләре шактый. Ул шигырьдә шактый кыю хәрәкәт итә. Сыгылмалы формалар табарга омтыла, вакыт-вакыт матур чагыштырулары, образлы сурәтләүләре ялтырап китә. Шигырь тукымасына халык иҗатыннан килгән мотивлар килеп керә. Кайчагында шигырьнең буеннан-буена бер фикерне үстереп килә дә, соңгы строфада «ә чынында мәсьәлә менә болайрак бит ул» дигән кебек баштагы фикерне кире кагып, көтелмәгән нәтиҗә ясап куярга ярата. Сүз дә юк, болар эзләнү җимешләре. Әмма Ф.Сафинга бер нәрсәне истән чыгармаска кирәктер, шигырь ул бизәк кенә түгел, ә бәлки көрәшү чарасы да. Ә тулаем алганда, автор бу җыентыктагы шигырьләре белән «Беренче карлыгачлар»дан алга бер адым ясаган.

Рифкат Закировның исеме матбугат битләрендә моннан берничә ел элек күренгән иде. Аның шигырьләре «Казан утлары» журналында, «Беренче карлыгачлар»да басылды. Һәм матур гына тәэсир калдырган иде. Эчкерсезлек, туган як табигате турында кызыклы гына уйланулары бар иде. Менә шуннан соң Р.Закиров ничектер ялкынланып янып китә алмады, бер биеклектәрәк кала бирде. Бу җыентыкта да ул шул биеклектәрәк. Рифкатнең бер җитди кимчелеге бар. Ул да булса, образлар ярдәмендә уйлый белмәү, фикерне шул образлар аша поэтик буяуларга төреп бирә алмау. Шуңа күрә шигырьдә фотографиячелек, сөйләп чыгу өстенлек ала. Бу уңайдан «Татарстан — Урал» циклына кергән шигырьләрне карап үтү урынлы булыр. Урал диюгә, ул безнең күз алдыбызга шаулы, кайнар табигатьле, киң сулышлы кешеләре белән, «челем тартып утыручы» завод-фабрикалары белән килеп баса. Аның шундый сурәтен Хәсән ага Туфан биргән иде. Ә Р.Закиров шигырьләрендә без бүгенге Уралның панорамасын, андагы үзгәрешләрне күрмибез, сулышны тоймыйбыз. Чөнки циклда Уралның җанлы сурәте юк.

Табигатьтә шигърият өчен иксез-чиксез серләр яшеренгән. Аларны күрергә, бал корты чәчәкләрдән ширбәт җыйган кебек, ул серләрнең согын сыгып ала белергә генә кирәк. Моның өчен «үткен күз» кирәк. Әнә шул нечкәлекләрне тотып ала алганда гына табигать турында яхшы шигырь язарга мөмкин. «Нәҗәгайлар уйный» шигыре — моның ачык мисалы. Шигырьдә кайбер детальләр санап кителгән, әмма образлы сурәт тудырылмаган. Шуңа күрә дә шигырь бездә бернинди фикер уятмый, ләззәт тә бирми. Дөрес, Р.Закировның да матур гына язылган шигырьләре бар. Әмма алар менә шушындый җитди кимчелекләр фонында югалып калалар.

Ф.Гыйззәтуллина соңгы елларда актив эшләде. Матур-матур гына шигырьләр дә бирде. Бу җыентыкта да бар алар. «Чаптар атлар кире кайтмады», «Балта чабу нигә», «Бәйлим... сүтәм»,

«Тау» шигырьләре әнә шундыйлардан. Күренеп тора, Ф.Гыйззәтуллина шигырьләрне бирелеп язарга, бөтен барлыгын шигырьгә күчерергә омтыла. Ләкин шул вакытта аз гына чаманы да югалта бугай. Күңелдә туган ялкын шигырьгә күчкәнче янып та бетә, шигырьгә аның рифмага әйләнгән шәүләсе төшә.
«Юл башы» — яшь шагыйрьләр җыентыгы, тулаем алганда, әйбәт кенә җыентык. Әмма бу җыентыкның авторлары яшь шагыйрьләр булсалар да, яшел түгелләр инде. Кыскасы, аларның олы уйлар, олы эшләр белән янар вакытлары. К.Сибгатуллинның үз сүзләре белән әйтсәк:

Әрәм итәр чаклар түгел инде,
Әләм итәр чаклар гомерне.

*«Казан утлары», июль, 1973*

## ТӘЛГӘШЛӘРДӘ СУСЫЛ ҖИМЕШЛӘР

Зиннур Насыйбуллин иҗаты белән татар укучысы беренче мәртәбә 1969 елда танышкан иде. «Казан утлары» журналының җиденче санында аның шигырьләре басылып чыкты. Кереш сүздә Зиннур: «...Хәзер Башкортстанның Чакмагыш районы газетасында эшлим. Көрәк-сәнәк, балта-пычкы, гайка ачкычы кебек эш коралларын каләмгә алыштырганчы шактый вакыт узды. Армиядән соң читтән торып урта мәктәпне бетердем. Башкорт дәүләт университетында укуны читтән торып дәвам итәм... Казан күңелне тарта», — дип язган иде.
Бу аның кыскача тормыш юлы. Күренгәнчә, шигърияткә ул, Уфа университеты белән бергә, «тормыш университетларын» да бетереп килгән кеше. Ә «Казан күңелне тарта» дигән сүзләре чыннан да хак булган икән, озак та тормады, Зиннур Насыйбуллин Казанга күчеп килде һәм менә аның беренче җыентыгы да дөнья күрде*.
Зиннурның иҗаты турында уйланганда, ирексездән миләш агачы күз алдына килә. Башка җимешләр ширбәткә туенганда, миләш әле әче була, авызны бөрештерә... Миләш шулай соңрак, башка җимешләр коелып яки кибеп беткәндә, көзге салкыннар башлангач кына өлгерә. Әмма бер өлгергәч, кышкы салкында да үз төсен, үз тәмен югалтмый.
Зиннур Насыйбуллин да шулай, миләш кебек, «соңга калыбрак» өлгергән шагыйрь. Тик соң өлгерсә дә, аның «Тәлгәш»ендәге җимешләр сусыл, һәркайсының үз яме, үз тәме бар, аларның нигезенә авторның тормыш тәҗрибәсе һәм дөньяга олыларча карашы салынган. Моның шулай икәненә тәлгәштәге җимешләрне авыз итеп карау белән үк ышанасың.
Авыз итеп караганчы, тагын бер генә сүз. Берәүгә дә сер түгел, җыентык төзи белү үзе бер осталык ул. Автор бу осталыкка да ия икән. Һәр тәлгәшкә тематик яктан бертөсле шигырьләр тупланган, һәм автор әйтергә теләгән фикер шигырьдән шигырьгә үсә, тулылана, камилләшә бара. Бу инде укучы күңеленә ышанычлы күпер салу дигән сүз.
Беренче тәлгәштән аңлашылган төп фикер шул: тормышның, яшәүнең асылы, кешенең кешелеге нидә? Шагыйрь әледән-әле шушы сорауны куя һәм аңа төрле ноктадан торып җавап бирергә омтыла. Тормышта яшәве авырмы? Авыр, әгәр:

...йөрәксезләр өчен йөрәк булсаң,
...кулсызларның сыңар кулы булсаң,
...аяксызга терәк-таяк булсаң,
...яманлыкка үчле-тешле булсаң.

Әйе, «җиңел түгел яшәү. Кеше булсаң». Юк, бу тормыштан зарлану, авырлыктан качарга өндәү түгел, бәлки мәгънәле яшәүгә, кешенең олылыгына мәдхия. Моны түбәндәге юллар да раслый:

Ләкин кеше башын салса салыр,
Кешелеген барыбер саклап калыр.

«Кешелекне саклап калу» берәүгә дә җиңел бирелми, «күкрәк киереп сынны туры тоту» кайчак авырга да туры килә, хәтта ныклык символы булган имәннәрне дә җил тегеләй дә, болай да бөгә. Ләкин кеше, киресенчә, «җилнең каршысына авыштыра үзенең гәүдәсен». Янып, ялкынланып, тормышын сөеп яши алучы кеше генә әнә шулай давылларга бирешми. Менә аның тормыш фәлсәфәсе:

Язгы ташкын булып, ташып, тулып,
Яшәү көче кайный күңелдә:
Аңым, җаным, эшем — яшәү өчен,
Тәнем генә калыр үлемгә.

З.Насыйбуллинның шигырьләре иң элек тормышчан булулары белән игътибарны җәлеп итәләр. Ул шигъри бизәкләрне күктән дә чүпләми, бармак очыннан да суырып чыгармый, ә тормыштан

ала. Аның илһамчысы — тормыш үзе.
Менә аеруча характерлы бер мисал. Һәр яшь кеше өлкән буыннан «тормыш йөген» кабул итеп алырга һәм аны гомере буена — киләчәк буынга тапшырганчы намус белән иңендә күтәреп барырга тиешле. Бу — шәхеснең кешелек каршындагы изге бурычы, — бу яшәү диалектикасы. Зиннур Насыйбуллин менә шушы гади тормыш күренешендә дә шигърият күрә.

Җиде диңгез кичкән чая ирләр
Кайтмас юлга китәр алдыннан
Бу дөньяның бөтен мәшәкатен
Мирас итеп безгә калдырган.

...Тик курыкмый йөкнең зурлыгыннан
Ата улы булган беркем дә —
Йөк төялгән көймә — тотырыклы,
Ә буш көймә — дулкын иркендә.

Шушы берничә юлда да шагыйрь тормыш дөреслеген, чор сулышын, яшь буынның уй-хыялларын бирә алган. Һәм, гомумән, бүгенге көн сулышын күрсәтергә омтылу Зиннур өчен хас төп сыйфат. Ул:

Хиросима,
Син үткәне микән,
Киләчәге микән дөньяның, —

кебек бөтен кешелекне борчып торган проблемаларны күтәрә һәм аңа кискен җавап та бирә:

Мин ышанам:
Төтәп яткан бикфорд шнурларын
Безнең тешләр өзә алырлар.

Болар аның шагыйрь буларак кына түгел, шәхес буларак та өлгергәнен күрсәтәләр инде. Икенче тәлгәштә төп урынны Бөек Ватан сугышына караган шигырьләр алып тора. Сугыш... Аның яралары әле дә төзәлеп җитмәгән. Алар шагыйрьнең күкрәгендә «җөйсез яра» булып әрниләр, алар «шагыйрь күңелендә әнисенең иңбашыннан шуып төшкән», ничәмә еллар инде «сөйрәлеп барган кара шәл сыйфатында уяналар»*. Ләкин совет кешесе дошман алдында тез чүкмәде, азатлык өчен көрәштә батырлык үрнәге күрсәтте. Аның бу сыйфаты «Исем турында баллада»да бик дөрес һәм дулкынландыргыч итеп күрсәтелгән.

...Көтте палач
Кискән агач кебек
Корбанының авып төшкәнен,
Ләкин кеше ерткыч йөзгә төбәп
Төкерде тик сынган тешләрен.
...Түзде кеше.
Газап авазына
Нәфрәтенә төенеп, үченә,
Авызындагы каны белән бергә
Исемен дә йотты эченә...

«Безнең көнгә карый Спартак», «Яшьтәшләрең китә армиягә», «Җөйсез яра», «Юк, билгесез түгел» кебек шигырьләрдә дә җиңелмәс көрәшче образы гәүдәләнә. Һәм Зиннур бу шигырьләре аша:

Баш июне белмәгәне өчен
Баш исән дә ярый кешегә, —

дигән фикер үткәрә,
Бу идеягә автор өченче тәлгәштә дә турылыклы булып калган. Мәхәббәттә аның өчен барысыннан да бигрәк сафлык, турылык һәм тигезлек кадерле. Шушы фикерләрне яклап, ул:

Барысын да уртаклашып, безгә
Гомер юлын бергә үтәргә.
Тимер юлда рельслар да шулай
Бөтен йөкне уртак күтәрә, —

ди.
Әмма кулдагы бармаклар тигез булмаган кебек, тәлгәштәге җимешләр дә тигез пешмәгән әле. Андагы кайбер шигырьләр (мәсәлән, «Кешенең бит табигате шундый», «...Тынычлан, дим йөрәгемә», «...Шундый чаклар була», «...Качар идем кайчак дусларымның» кебек шигырьләр) образлы сурәтләүгә түгел, ә бәлки нинди дә булса фикерне шигъри калыпка салып сөйләп чыгуга корылганнар. Һәм, һичшиксез, мондый шигырьләрнең күпчелегенә «дип», «диләр» кебек артык сүзләр килеп керә, ә шигъри тукыманы булдыруда аларның бернинди әһәмияте булмый. Әйбәт кенә язылган «Колларга һәйкәл» шигырендә дә бу кимчелектән котыла алмаган шагыйрь:

Пирамидаларны төзегәндә
Каннан, диләр, измә изелгән.

Биредә «диләр» ник кирәкте икән? Билгеле инде, буш урынны тутыру өчен. Ә шушы урынсыз кулланылган бер сүз күзгә кергән чүп кебек (бу урында Зиннурның үз сүзләрен иске төшерик: «Күзләрем бөтен дөньяны болганчык күргән иде, ә бит күземә нибары чүп кенә кергән иде...») күңелне тырнап, шигырьнең эмоциональлеген киметеп тора.

Тынычлан, дим йөрәгемә,
Ярсыма, дим, ярсыма:
Барыбер, дим, син дигәнчә
Булып бетми барсы да.

Бу юллардагы «дим-димнәр» дә түтәлдә үскән әрем кебек.
Зиннурның бик шәп әйтелгән сүзләре бар:

Сандал белән чүкеч арасында
Кылыч туа. ...

Күренгәнчә, шигърияттә үткен кылыч булып җитәр өчен Зиннурның тагын да чүкеләсе бар әле. Шагыйрь үз сүзләрен онытмас дип ышаныйк.
*«Казан утлары», октябрь, 1973*

## ГӨРЛӘВЕКЛӘР ЯЗ АЛЫП КИЛӘ

Алдымда Гәрәй Рәхимнең «Гөрләвек» җыентыгы*.
Соңгы битен яптым да, шундагы шигырьләрнең фикер очын эзләп, уйга калдым. Хыялымда балачакның матур бер хатирәсе яңарды.
...Безнең авыл кырыннан ук ялан башланып китә. Яз җиткәч, малайлар җыелып шунда чыгабыз да уйнаклап-уйнаклап аккан гөрләвекләрдә көймә узыштырабыз. Дәфтәр битеннән ясалган кәгазь көймәләр куыша-куыша ындыр артларыннан үтәләр дә, кызыл тасмадан ясалган флагларын җилфердәтеп, күздән югалалар. Шул көймәләр белән бергә уйлар да еракларга китә:
— Безнең көймәләрне агызып киткән гөрләвекләр кайларга барып җитте икән? Башта Сөнгә кушылганнардыр инде, аннан Агыйделгә, Агыйделдән Иделгә...
Бер уйласаң, язучылар иҗаты да шулай — алар да башта бәләкәй гөрләвек кенә булып башлыйлар да бормалы-бормалы тормыш юллары аша Иделгә — мең еллык тарихы булган татар әдәбиятына килеп кушылалар.
Г.Рәхим — шундый «гөрләвек»ләрнең берсе. Аның шигъри гөрләвеге билгесез чоңгылларга ташланмый, мәһабәт Иделгә килеп тоташа.
Гәрәй Рәхим — әйбәт мәгънәдә виртуоз шагыйрь, аның стихиясе — сүзләр. Ул бер өлге ала да сүзләрдән «челтәр бәйли», аңа халык орнаментларыннан матур-матур бизәкләр төшерә, җитмәсә, алар Гәрәйгә генә хас шаянлык белән дә өртелгән булалар. Шуңа күрә бу бизәкләр социаль мәсьәләләрне күтәргән шигырьләрдә дә үз төсләрен югалтмыйлар.
«Неон яктысында уйлану» шигырен алып карыйк. Техник прогресс гаять киң колач алган дәвердә кешелекне нинди язмыш көтә? Әсәрдә сүз әнә шул турыда бара.

Ә бомбаны бирмәгәндер сиңа,
Бу тик ялгышыдыр дөньяның.
Куян ясыйм диеп бомба чыкса?!
Зыяны бармыни куянның?..

Сизеп торам, куян дигәч, синдә
Потенциаль аучы уяна.
Нәсле корсын, халыкара бер ау
Игълан итик бомба-куянга.

Күрәсез, шигырь җитди темага багышланган. Ләкин мондый темага караган байтак шигырьләрдән аермалы буларак, әсәрдә лирик җылылык бар, шаяру аша әйтелгән җитди фикер бар. «Соус» белән бирелгәч, шигырь җанга да ятышлы, фикерләр дә үтемле булып чыккан.
Г.Рәхим сүзләрдән челтәр бәйли, дигән идек. Төптәнрәк уйлап карасаң, бу — шагыйрьнең дөньяны күрү формасы да икән әле. Берничә чигештә шул нәрсә бик ачык күренә.

...Яңгыратып кызлар көлә,
Кызлар көлә — ямансу.
Тып-тын гына кызлар елый,
Кызлар елый — ямансу.

Сызылып кына таңнар ата,
Таң атуы — ямансу.
Сызылып кына кояш бата,
Кичләр бигрәк ямансу...

Яки:

— Һай, ямьсездән дә ямьсез,
Ямьсездән дә ни ямьсез?
— Ямьсездән дә ямьсез шулдыр —
Илен каккан ир ямьсез...

Күрәсез, күз явын алырлык образлар да юк (бер яктан, бу — Г.Рәхимнең кимчелеге дә булып тора), шаккаттырырлык чагыштырулар да очрамый, әмма бу юллар битараф калдырмый. Биредә шагыйрь безне сүзләр хәрәкәте белән сихерли, ул фикер-хисләрен шул хәрәкәт аша белдерергә омтыла. Кыскасы, бу — ритм патшалыгы, биредә сүзләр стихиясе хакимлек итә. «...Үткән гомер — кара күмер», «...Кемдер квартир сорый», «...Сызланма дип, сыкранма дип» кебек шигырьләр дә шул юнәлештә иҗат ителгән.

Г.Рәхимнең тавышы интонацияләргә бай. Менә ул тыйнак, мәгънәле; менә ул уйчан, борчулы; икенче карасаң — чәнечкеле. Димәк, без шигырьләрдә шагыйрьнең рухи дөньясын да күрәбез. Чыннан да, әгәр шагыйрь укучысын үз хисләренең сафлыгына һәм хаклыгына ышандыра алмаса, ничек итеп аның рухына үтеп керә алсын ди?! Ә укучы, бигрәк тә бүгенге укучы, сизгер. Ул кемнең чын утта янганын, кемнең пыскып кына ятканын, кемнең җырында фальшь ноталар яңгыравын шундук сизеп ала һәм бер алданганнан соң синең китабыңны кулына алып та карамаячак инде.

Г.Рәхим — бу яктан бәхетле шагыйрь. Аны яратып укыйлар. Күп кенә әсәрләре шигырь сөючеләр телендә. Моңа шагыйрь үзе сәбәпче. Чөнки аның лирикасы — эчкерсез лирика. Сүзебез җирдә егылып калмасын, бер шигырьне карап үтик:

Урамнар артында яшел болын,
Аранны кимерә яшь колын.
Аранда тилмерә яшь колын!
«Урамнар артында яшел болын...

Урамнар артында яшел болын...»
...Тибенә, әйтергә теле юк.
Аранны кимерә яшь колын.
Нишләсен, әйтергә теле юк:
«Урамнар артында яшел болын,
Урамнар артында яшел болын...»

Урамнар артында гына яшел болын, чыгарып җибәрәсе иде аны шунда, уйнасын иде иркенлектә, хозурлансын иде гүзәл җәйнең матурлыгы белән. Юк шул. Чалгы чүкегән агайларның да, июньдәй көләч кызларның да, чирәмдә кояшка йөз тотып нур җыючы чал чәчле бабайның да яшь колын хакында уйларга вакытлары юк. Колын аранда тилмерә... Ай-һай, бер колын турында гына микән бу шигырь?!

Ә «Көз-патша» шигыре? «Көзге Урман», «Миләш төбендә», «Хыялый төбәктә», «Көтмәгәндә», «Болыннарны атлар табырлаган» шигырьләре... Аларның һәммәсе дә хыялларга киңлек, фикерләргә тирәнлек бирердәй шигырьләр.

Шушы уңай белән тагын бер генә сүз. Хәзер I класс баласын да проблемалы укытабыз, ягъни уйланырга мәҗбүр итәбез. Шигърият тә үз укучысын шушы юнәлештә тәрбияләргә тиеш. Ул да, укучы алдына җитди мәсьәләләр куеп, аны уйландырсын, аңа әдәби «ачышлар ясарга» ярдәм итсен. Дөрес, бу өлкәдә уңышларыбыз да юк түгел. Әмма теләк шул — алар тагын да баетылсын, тирәнәйтелсен. Моны заман таләп итә.

Китапта мәхәббәт турында да әйбәт шигырьләр бар. Ләкин «Юл уңаенда» шигыре үзенчә шәп. Һ.Такташның «Урман кызы» интонацияләре яңгырап киткән бу шигырь романтик буяуларның куелыгы белән үзенә җәлеп итә.

...Лирик герой ике юл чатында басып тора. Кайчандыр шушы урында сөйгәне аңа шашып-шашып сөюе хакында сөйләгән. Еллар үткән, алар аерылышканнар. Хәзер менә ул үзе, үткәннәрне искә төшереп, чал тарихтан килгән мосафирдай сөю хакында фикер йөртә. Никадәр тормышчан, никадәр кешелекле һәм гыйбрәтле аның фәлсәфәсе:

...Һәм шушында, гөлләр арасында,
Бер имән йорт саласым килә.
Анда булыр су һәм кара икмәк
(Мосафирлар кереп ашасын).
Һәм ишеккә һәркем күрсен өчен

Килә шундый язу кагасым:
«Мәхәббәттә һәйкәл, сарайлардан,
Хәтфәләрдән ерак кач, адәм!
Җир кешесе булып кер, кунак бул,
Бу ишекне киереп ач, адәм!»

Без хәзергә кадәр җитди Гәрәй турында гына сүз алып бардык. Ә икенче кырыйда юмористик Гәрәй елмаеп басып тора. Аның юмористик шигырьләренең максаты көлдерү генә түгел. Алар — чәнечкеле, алар — әйбәт тормыш, әйбәт шигырь таләп итүче «нәни» көрәшчеләр. Каләмдәш дусларына язылган пародияләре дә, кыска шигырьләре дә шул таләпчәнлек белән сугарылганнар. Бер шигырендә Гәрәй болай ди:

Түзеп тормам,
Тагын тик бер тапкыр
Купшы сүзләр белән ялтыра —
Пычак кебек үткен шигырь белән
Мин суярмын сине, халтура.

Бу юллар югарыда әйтелгәннәргә ачык дәлил булып торалар. Һәм икеләнмичә әйтергә мөмкин, алар үз адресатларын бик тиз табачаклар.
...Гөрләвекләр җиргә яз алып килә. Алар йөгереп үткән кырларда күкрәп игеннәр үсә, болыннар яшел хәтфәгә төренә.
Шигъри «гөрләвек»ләр дә күпләрнең күңеленә яз, шатлык алып килер. Ул сугарган күңелләрдәге «матурлык» дигән изге шытымнар чәчкәгә бөреләнер.
*«Казан утлары», июль, 1974*

## БӘХЕТЛЕ БУЛУ КЫЕНМЫ?

Чордашым Роберт Миңнуллин иҗаты турында бер-ике сүз әйтим дип кулыма каләм алган идем, каршылыклы хисләр өермәсе эчендә торып калдым. Бер яктан күңелгә яшьтәшем өчен ихлас шатлану дулкыны килеп кагыла, ә икенче яктан нәрсәгәдер борчылу, нииндидер канәгатьсезлек тойгысы үзен сиздереп куя. Мондый икеләнүле халәт нилектән туа соң? Яшь шагыйрьнең күптән түгел дөнья күргән беренче китабы — «Бәхетле булыгыз!» — безгә бу сорауны ачыкларга шактый ярдәм итә кебек.
...Робертның шигъри почмагында тыйнаклык, әдәплелек, ихтирамлылык хөкем сөрә, тәрәзәләрендә кояш уйный. Җылы, рәхәт, хәвефсез, ипле, салмак тормыш биредә, олыдан кубып лаф ору да, артык ваем да юк.

Бөтен дөнья бәйрәм белән тулы,
Бөтен дөнья — якты нур гына.
Йөрәкләрдә,
Җирдә,
Урамнарда
Бәйрәм ташый, бәйрәм ургыла.

Шагыйрьнең көне аяз, күгендә ни болыт, ни җил-давыл:

Чалт аяз көн.
Баш очында гына
Алтын кояш тора эленеп, —
Гел өлгергән әнис алмасыдай, —
Төшәр төсле учка өзелеп.

Шагыйрь кешеләргә дә әнә шундый бәхетле, аяз көн тели, — нияте изге:

Сезгә дигән теләгем бар:
Бәхетле булыгыз.
Һәммәгез дә минем шушы
Теләктән уңыгыз!
Бәхетле булыгыз!

Ә «Тайлар» дип исемләнгән шигырьдә бүгенге яшьлекне характерлаучы бик матур һәм көчле образ табылган. Тай яшьлек, кайнарлык, шашып, яшьнәп яшәү символына әверелгән:

Күккә ыргый берсе әнә,
Кояшны тешләмәкче!
Ялан гына җитми, ахры, —
Биектә кешнәмәкче!

Ләкин шигырь моның белән генә чикләнмәгән, аның нигезендә тормыш, яшәү диалектикасы, катлаулы, каршылыклы мөнәсәбәтләр ята:

Карт ат кына
Гаҗәпләнеп
Карап тора тайларга.

Кем әйтмешли, комментарийлар артык биредә: һәркем үзенең фантазиясе мөмкинлек биргәнчә уйлансын, хыяллансын, фикерләсен.
Чыпчык борыны кадәрле генә «Мәхәббәт» шигырендә дә тормыш үзенең кырыс дөреслеге, фәлсәфи тирәнлеге белән тасвирлана:

Әрнеттең дә ничә кабат,
Юаттың үзең озак.
Газаптан торган шатлык син,
Шатлыктан торган газап.

Робертның үзе кичергән, үз хисләрен җырлаган шигырьләрендә ясалмалык югала, андый шигырьләрнең артында нинди шәхес торуы, аның нинди хисләр белән януы ачык төсмерләнә. Алар ихлас хисләр — шуңа күрә безне дә ышандыралар. Һәм гаҗәп тә түгел, андый әсәрләрдә коры, буш сүзләр юк, ә образлар, образлы тасвирлаулар өстенлек итә. Тагын бер генә шигырьгә тукталып үтик. Ул «Көз» дип атала.
Аның беренче строфасында хисләр өермәсе әле күтәрелеп кенә килә һәм «учак булып янган усак» образы аша беренче ноталар яңгырый:
Сагынуга иң мул чак.
Ялкынлана көзге урман.
Һәрбер усак — бер учак.

Икенче строфада исә хисләр тирәнәя төшә: «сагыну», «кайгы»га әверелә, автор «ялгызым» дигән бер сүз әйтмәсә дә, бу төшенчә ассоциатив сурәт аша күңелгә кереп утыра:

Җанымда кайгым барга,
Эч серләремне сөйләдем
Игезәк каеннарга.

Соңгы строфа — соңгы аккорд. Биредә «усак» бөтенләй төшеп калган инде, ә бу исә шигырьнең тәэсир көчен, күчерелмә мәгънәсен арттыра гына:

Сагышларым бер кочак.
Синең яулыгың шикелле
Җилфердәп калды учак.

Хәтердә, студентларның тулай торагында үткәрелгән әдәби кичәләрдә Робертның шигырьләрен кызлар яратып тыңлый иде. Мәхәббәт лирикасындагы юмор белән үрелгән садәлек, кызлар күңеледәй самимилек җәлеп итә иде бугай аларны:

Төшләремдә кызлар күреп,
И оялып уянам.
Ә синнән, сылу кызыкай,
Оялырга... оялам...

Кемгә ничектер, әлеге шигырьләрдә мин Робертның йөрәк пульсын ачыграк тоям, тавышын, аһәңен ачыграк ишетәм — үз дөньясын күрәм. Тик кызганыч, беренче китапта андый шигырьләр азрак... Барыбыз да беләбез: көндәлек тормышта адәм баласына яхшысы белән дә, яманы белән дә күзгә-күз очрашырга, көләргә дә, бүтәннәргә сиздермичә генә еларга да туры килә, ул бер янып, бер көеп яши. Тик менә кайбер шагыйрьләрнең иҗатында тормышның кояшлы, нурлы ягы бик күп чагыла, ә пәрдә артындагы күләгәләр читтә кала бирә. Нәрсә җитми? Кыюлыкмы?! Әллә ихласлыкмы?!
Ихласлык дигәнбез икән — инде аңа үзебез дә турылыклы булыйк: Робертның күп кенә шигырьләрендә тормышны беркадәр бәйрәмчәрәк, аның эчке агымнарына үтеп кермичәрәк сурәтләү төсмерләнә, дөреслекнең күзенә туры карап әйтү җитми (гәрчә матур ялганга караганда ачы хакыйкатьне тасвирлау мең мәртәбә гуманлырак булса да), аның «шигъри өендә» берәүне дә рәнҗетмиләр, ваемсызламыйлар, яшь шагыйрьнең мөкатдәс, чын хисләре ниндидер бер тышкы кабык астында кала. Ягъни андый тип шигырьләрендә Робертның үз шигъри күңеле күренми — җаны, иманы, мәсләге сизелми. Ә моның, безнеңчә, берничә хәтәр ягы бар. Һәрхәлдә, Роберт иҗатында ул шулай чагыла.
Беренчесе. Шагыйрьнең үз дөньясы, «үзе уйлап» чыгарган, шунда җенләнеп яшәгән мохите булмадымы, бербөтен рух белән сугарылган, диалектик бөтенлеккә ирешкән Иҗат булмас, икенче төрле итеп әйткәндә, Иҗаттагы һәр шигырь, тормышның бер читеннән умырып алынган кыйпылчык буларак, аерым-аерым яшәр, аларны бергә бәйләп торучы идея-фәлсәфи җепләр булмас, тормышны катып калган хәлдә, статик тасвирлау өстенлек алыр, җанлы сурәтләрне

коры сүзләр алыштырып килер.
Мисаллар ярдәмендә шәрехләп китик.
«Татар хатыннары» шигыре болай башланып китә:

Хөрмәт итәм татар хатыннарын,
Ихтирамым олы йөрәктә.

«Бал» дию белән генә авызда бал тәме килмәгән кебек «хөрмәт итәм» дию белән генә хөрмәт хисен белдереп булмыйдыр. Булмыйдыр, чөнки безнең аңыбызга «хөрмәт итү» дигән төшенчәнең билгеле бер калыбы инде бик күптән салынган, «таушалып» беткән, ул безнең тойгыларда статик хәлдә яши бирә. Аны бары тик яңа ассоциатив сурәт кенә терелтә ала, җан өрә ала. Ләкин шагыйрьдә андый сурәт юк. Икенчедән, сүз татар хатыннары турында бара икән, шагыйрь инде нәкъ менә аларга хас сыйфатларны эзләргә, табарга, сурәтләргә тиеш иде. Кызганычка каршы, бу да юк.

Ничек инде хөрмәт итмисең ди
Алиһәдәй шундый хатынны!
...Табигате белән тыйнак алар,
Табигате белән акыллы, —

дигән «характеристика»ны теләсә кайсы милләт вәкиленә карата әйтергә мөмкин булыр иде. Керпе дә үз баласына «йомшагым» дип әйткән шикелле, җир йөзендәге һәр милләт шагыйре хатын-кызга карата шушындый ук гомуми фикерләрне әйтә алмыймыни?!
Яки булмаса, «Комиссарлар», «Икмәккә мәдхия», «Кылыч», «Ветераннар» кебек шигырьләрне алып карыйк. Аларда да тормыш хәрәкәттәге вулкан кебек түгел, катып калган лава шикеллерәк сурәтләнә. Сәбәп?! Сәбәп шунда ки, ул шигырьләрдә автор юк, алар шагыйрь күкрәгеннән, аның хис, борчу, янулары белән укмашып, вулкан булып атылмаганнар, бәлки читтән торып күзәтү формасында гына иҗат ителгәннәр. Бу — без әйтергә теләгән икенче хәтәр як инде — шигырьнең үзәгендә Кеше булмау, аның нигезенә Кешенең хис-борчулары, яну-талпынулары ятмау.
Менә «Кылыч» шигыре:

Тоткач чыңлап тора кылыч.
Бер карасаң, гади корыч.
Нинди тыныч — кында чакта,
Тик куркыныч — кулда чакта.

Булмас иде һич куркыныч,
Кем кулында бит ул кылыч.

Хәзер шушы шигырьдән аерылыйк та Лермонтовның «Кинжал» шигырен искә төшерик. Тема бер үк — тимер турында, кинжал, кылыч турында, ә эчтәлектә нинди аерма!
Сизеп торам, кайберәүләр әйтер, таптың чагыштырыр кешеләр, дияр. Дөрес, Роберт яшь шагыйрь, ә Лермонтов дөньякүләм танылган шагыйрь. Ләкин эш анда түгел. «Кинжал» шигыре җылылык, гуманлык белән өртелгән — салкын тимер хәтта кеше дәрәҗәсенә күтәрелгән, ул шигырь — Лермонтовның җаны (нәкъ менә җаны, башкача әйтеп тә булмый кебек), күңеленең бер почмагы, биографиясенең бер бите.
Ә «Кылыч» шигырендә исә Робертның җаны да, күңел дөньясы да күренми. Юк ул. «Кылыч» — шигъри информация, фикер һәм хис синтезына әверелмәгән шигырьгә хас булганча, яфраклары коелган агач кебек, шәрә. Күңел сискәнеп, уянып китәрлек сурәтләрнең булмавы, коры нәсихәт бирүгә әйләнеп калуы да шуннан килә, безнеңчә.
Шулай, шигъри дөньяңны булдыру, тышкы дөньяны трансформацияләп яшәү белән бергә, Кеше күңелен җырлау, ихлас бакчачыдай, Кеше күңелендә «казыну», Кеше күңеле туфрагына изге орлыклар чәчү дә дигән сүз. Бу нәүбәттән бер рус язучысының сүзләре аеруча актуаль яңгырый: «Миңа әдәбиятта һәм сәнгатьтә художникларның кеше күңелен өйрәнүгә сарыф иткән тырышлыклары аеруча заманча булып тоела. Биредә ясалмалылыкка бөтенләй диярлек урын юк, чөнки кеше күңелен өйрәнүне имитацияләүче хезмәт кешеләргә кирәк түгеллеге белән үзен шунда ук фаш итәчәк. Мәсәлән, Есенин шигырьләрендәге моң, сагыш, сафлыкны ничек ясыйсың!»
Юк, ясап булмый! Тукай, Дәрдмәнд, Бабич, Такташ, Җәлил, Туфан, Хәким шигырьләрендәге хис, настроениеләрне дә ясап булмый — алар чын, йөрәктән чыккан хисләр. Гомер бакыена шулай күңелдәге чын хисләрне җырлау гына шагыйрьләрне шагыйрь иткән, чын хисләр генә шагыйрьләр үткән тормыш сукмакларында «серле йомгак» булып сузылып калган. Кешеләр шагыйрьнең шигъри дөньясына шул йомгакны сүтә-сүтә килеп керәләр, шатлык-әрнүләр, моң-сагыш, хакыйкать өчен көрәш, өмет, яшәүгә мәхәббәт алып керә аларны.

Шуңа күрә дә:

Без кемнән ким әле дөньяда?
Бер дигән бит әле хәлебез.
Кайгырмыйк кайгыга үч итеп,
Юкка да борчылмыйк әле без.

Зарланмыйк әле без дөньядан,
Шатлансаң — шатлыклар табыла, —

дигән юллар күңелгә шом салалар. Кем фәлсәфәсе бу?! Көрәштән-тормыштан качарга, сукыр тычкандай посып яшәргә өндәүме?! Шушымы безнең яшәү идеалы?!

Болары — Роберт Миңнуллин поэзиясенең күңелне әрнеткән ягы.

...Роберт татар поэзиясе офыгында күренеп килүче яңа дулкынның өметле бер тамчысы, бу дулкын әле көч җыеп кына килә, олы әдәбият диңгезенә чыгарга гына әзерләнә. Аның куәте, үзеннән алдагы дулкыннарны куып җитәргә омтылып, ургылып-шашып кубарылуы күпләгән тамчыларның — Фәннур Сафин, Марсель Галиев, Зиннур Мансуровларның һәм башка бик күпләрнең бердәм аваз көченә бәйләнгән.

Шагыйрьнең шигъри аһәңе автор үзе укыганда ачыграк сизелә, диләр. Бәхәссез, дөрес фикер. Робертның шигъри авазы да минем күңелгә үз укуында, бигрәк тә «Кызлар елый» шигырен укыганда колакка сеңеп калган. Робертның сөйләменә хас яңгыраш, төгәлләнгән ритмлы сөйләм, бетте дигәндә генә калкып чыккан «элмәкләр» бу шигырьдә аеруча ачык күренә:

Кызлар елый,
Якыннары
Яудан кайтмый
Ятып калса еракларда.
Соңгы куанычы булган
Мәхәббәтен югалтканда,
Үкси-үкси кызлар елый.
Сагынса да кызлар елый.

Танылган чех язучысы һәм художнигы А.Гофмейстер болай ди:

— Әдәбият елга шикелле, күкләрне, ярларны, күперләрне, көймәләрне һәм балыкчыларны үзендә чагылдырып, тормыш кыры буйлап ага бирә. Диккенс ул — Темза, Толстой — Идел, Шолохов — Дон, Фолкнер — Миссисипи.

Ә Роберт Миңнуллин, безнеңчә — Сөн елгасы.

Җир йөзендәге башка бик күп елгалар кебек, Сөннең дә үз матурлыгы, үз йөзе бар, Роберт Миңнуллинның поэзиясендә Сөн өстендәге күкләрнең, яр буйларындагы таллык-тугайларның, күпер-көймәләр, балыкчыларның тагын да тулырак, рельефлырак чагылуын күрәсе килә. Шул вакытта ул, Сөн ярларын калдырып, Агыйделгә күчәр, шул вакытта шигъри почмагы да киңәер, дөньяга әйләнер. Ышанам.

*«Идел», 1977, № 8*

**БӘХЕТКӘ ЮЛ — ГЕЛ АЛДА**

Тормышның үзеннән килгән! Без бу сүзләрне Мөсәгыйть Хәбибуллинга карата әйтәбез икән, хакыйкатькә хилафлык китермәбездер. Чөнки ул әдәбиятка чын мәгънәсендә тормышның озын һәм катлаулы борылмаларын үтеп, аның кояшлы утрауларын да, күләгәле почмакларын да, җил-яңгырын, карын-бозын да күреп-тоеп килгән язучы. Ил биографиясендәге олы вакыйгалар аның да күңеленә эз салып үткәннәр.

М.Хәбибуллинның яшьлеге сугыш елларына туры килә. 1941 елның дәһшәтле 22 июнь таңы атканда аңа әле ундүрт яшь тә тулып җитмәгән була. Афәт кешене бик иртә җитлектерә шул — башка бик күп авыл малайлары кебек ул да колхоз эшенә муеннан кереп чума: җир сөрә, язгы чәчүдә катнаша, лобогрейкада ашлык ура, хәтта суктыргыч машинаны эшләтә. Ләкин озак та үтми, аңа үзенең туган якларын — Оренбург далаларын ташлап китәргә туры килә — ул бу өлкәнең Абдуллин районы Габдрахман авылында туып үсә — язмыш җиле аны Урал якларына, Магнитогорск шәһәренә китерә. Колхозда көрәк-сәнәк кенә тотып эшләгән малай биредә токарь һөнәрен үзләштерә. Заводта эшли башлый.

Бераздан техникумга укырга керә һәм аны тәмамлагач, Башкортстанның Октябрьск шәһәренә күчеп килеп, бораулау конторасында мастер булып эшли. Күп вакыт та узмый, еллар һәм юллар аны яңадан туган авылына алып кайталар. Ул колхозда инженер-механик булып эшкә урнаша. 1959 елда булачак язучыбыз Татарстанга килә. Баулыда башта шофер булып, аннары «Байрак»

исемле район газетасының промышленность бүлегендә эшли. Читтән торып Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. 1970 елда Татарстан Язучылар союзы чакыруы буенча Казанга килә һәм союз идарәсенең секретаре итеп билгеләнә.
Тормыш анкетасыннан алынган шушы саран мәгълүматлар да аның шактый кызыклы биографиясе булуы турында искәртәләр. Ләкин язучының хезмәте үткән тормыш юллары белән генә түгел, барыннан да элек күңел җимешләре — китаплары белән билгеләнә. Аның төп язмышы — язган әсәрләре, әдәби мирасы. Сүз шулар хакында.
Мөсәгыйть Хәбибуллинның күләмле беренче әсәре «Унсигезенче яз» повесте булды. Унсигезенче язын каршылаучы яшүсмер кызның тормышның асылы, яшәүнең мәгънәсе турында уйлануларын, гомумән аның, үз язмышына хуҗа булып, хәятка беренче мөстәкыйль адым ясаган чактагы кичерешләрен чагылдырган әсәр иде ул.
Әгәр биектән, бик биектән күз ташласаң, кешеләрнең яшәеше дә ниндидер кырмыскалар чабышуы кебегрәк буталчык хәрәкәтне хәтерләтер иде, диләр. Әйе, мөгаен, шулайдыр, әмма бу беренче карашка гына. Чөнки нәкъ шул буталчык булып күренгән хәрәкәтләрнең асыл нигезендә билгеле бер закончалыклар, бетмәс-төкәнмәс эчке һәм тышкы бәйләнештә безгә билгеле һәм билгесез бихисап серләр ята.
Тормыш бусагасын әле атлап кына кергән яшүсмер өчен хәят та шул кырмыска оясы сыман серле бер нәрсә ич. Тагы да төгәлрәк әйтсәк, ул, кырмыска оясына карап: «Кая чаба бу мәхлуклар», —дип сөрән салган бәндә хәлендә генә. Бу дөньяда аңа шактый нәрсә таныш кебек һәм шул ук вакытта әле бик күп нәрсәләр таныш та түгел. Тормышка аяк атлаган һәр кеше алдында тылсымлы һәм могҗизаи олы дөнья киңлеге ачыла. Ул андагы күренешләрнең серен ачарга, аңа үзенчә бәя бирергә, анализларга тиеш. Повестьның төп герое яшүсмер кыз Әнрүсә әнә шундый олы һәм катлаулы дөньяга килеп керә. Юк, бу дөнья Әнрүсәне үзенең серлелеге белән куркытмый, кеше, табигатенә хас танып белергә омтылучанлык аны тормыш эченә бөтереп алып кереп китә, алга җилкендерә. Ул эзли, таба, югалта, тагын таба. Һәм Әнрүсә безгә үзенең әнә шул югалту-табышлары хакында сабыйларча беркатлылык белән бәйнә-бәйнә сөйләп бирә.
...Әнрүсәнең эшләре шәптән түгел әле, җырчы булу теләге челпәрәмә килде, үтә алмады. Нишләргә? Кая барып төртелергә? Кай тарафка карап юл тотарга? Әй, күрсәтүче булсын иде: нинди юллар илтә икән бәхеткә табан? Ни генә булмасын, кешеләр арасына ашыгырга кирәк — аның карары шундый. Һәм менә ул нефть чыгару конторасына лаборант ярдәмчесе булып эшкә килә. Эшкә, кешеләр белән якыннан аралашуга сусаган яшь күңел тиз арада үсенеп, канатланып китә. Биредә ул үзенә чын дуслар, турылыклы юлдашлар таба, шуларның берсе, иң якыны — Вәсил. Ул тормышны Әнрүсәгә караганда күбрәк күргән, тормышта аның үз принциплары, кыйбласы бар: туры сүзлелек, гомуми эш өчен чын күңелдән яну, максатка ирешү юлында авырлыклар алдында туктап калмау хас аңа. Вәсил Әнрүсәдә дә шундый характер тәрбияләргә омтыла. «Ә син бирешмә, тагын бер сынап кара. Үз-үзеңне сына! Нигә сәләтле син: яшьлек хыялың буш куык кынамы, әллә булса киләчәк өметеңме? Әйтик, синнән опера артисткасы чыкмасын да ди. Шуннан ни? Шуның белән барысы да җимерелергә тиешме? Юк, тагын бер тапкыр юк. Ә нигә, әйтик, бу хыялыңны тормышка ашыру өчен үзешчән сәнгать түгәрәгенә йөрмәскә. Хезмәтен түбәннән башлаган кешенең эше уң була, диләр. Берәүләр сине тыңлаудан ләззәт алыр, икенчеләренә синең җырың көч-куәт бирер, ә сиңа моннан ышаныч килер. Тормыш итү ул — көрәш, беләсең килсә».
Вәсил белән танышканнан соң, Әнрүсәнең сәлперәя башлаган канатлары кабат ныгый башлый. Авыр булыр, әмма ул барыбер үзенең максатына — бәхет вәгъдә иткән аргы ярга җитәр. Ул хәзер үзендә көч тә, ышаныч та сизә.
Кешеләрне якыннанрак белгән саен, Әнрүсә үз күңелендә торган саен күбрәк ачышлар ясый. Тормыш берәүне дә иркәләп, якты, җылы нурлары белән назлап кына тормый икән ләбаса. Ул кешене һәр адымында сынап тора икән. Менә, кара инде, ул лаборатория мөдире Ләйсән Хафизовнаны нинди бәхетле кеше дип йөри иде. Айхәл абый белән пар күгәрченнәрдәй яшиләр кебек иде бит югыйсә. Баксаң...
«— Сез, сез, — дидем мин, беравык уңайсызланып торсам да, — Айхәл абыйны яратмыйсызмыни?..
— Мин ансыз — канатсыз кош. Күргәнең бармы, очып китмәсеннәр дип зоопарктагы очар кошларның канатларын кисәләр. Кызганыч аларга каравы. Алар, башларын кырын сала-сала, зәп- зәңгәр һавага карыйлар. Аннан очып үткән кошларны күрәләр һәм, кайгылы-сагышлы аваз салып, каңгырып, канатларын җилпеп алалар. Тик күтәрелеп кенә китә алмыйлар. Менә мин дә шул канаты киселгән кош сыман дөнья көтәм, семья хакы дип яши бирәм...»
Әнрүсә әнә шулай тормышның эчке каршылыкларын тирәнрәк аңлый бара. Яшәүнең асылы

нидән гыйбарәт?! — Һич көтмәгәндә, уйламаганда җавап таба ул бу сорауга, тормыш үзе җавап бирә. ...Әнрүсә үзешчән сәнгать түгәрәгенә йөри башлый. Казанга смотрга киләләр. Анда Мөнирә апасы белән очраша, күзгә-күз карап сөйләшәләр. Бөтенләй башка сыймаслык хәл ич — Мөнирә апасы аның үз әнисе икән, аңа бөтенләй башка, ят кеше күңел җылысын биргән икән. Юк, юк, аның әнисе бер генә — ул вафат инде. Әни дә, әти дә бер генә бу дөньяда, бер генә була ала! Мөнирә апасы (әйе, ул апа гына!) аны ташлап киткән — сабый чакта, бернәрсә дә белмәгән вакытта, сәнгатькә хезмәт итәм, үсәм дип. Бердәнбер юлмы бу?! Нигә соң әтисе ташлап китмәгән, ул да бит үсәргә тиешле, талантлы кеше булган?!
Өермәдәй булып узган шушы вакыйга Әнрүсәнең күңелен бөтенләй актарып ташлый. Йә, кайсы бәхетсезрәк аларның: Мөнирә апасымы, әтисеме? Юк, кайсы бәхетлерәк?.. Гомумән, бәхетсезме алар әтисе белән?! Әнрүсә смотрда җиңеп кайтты, җырларга Мәскәүгә барачак. Ул максатына ирешә, ул җырлый, җырчы булачак.
«...Әти миңа карый да бөтен уй-кайгыларын онытып көлеп җибәрә. Ул шат һәм бәхетле. Мин дә».
Әйе, вафат булган әнисеннән дә сөйкемлерәк, көннәр буе сөйләшмичә, үз эченә бикләнеп, уйланып йөрүче әтисеннән дә кадерлерәк кеше юк бу дөньяда Әнрүсә өчен. Ярата аны әтисе.
Яшь кыз Әнрүсәнең рухындагы төп үсеш этаплары, рухи ачышлары менә шушылардан гыйбарәт. Ул хәзер шуңа инана: тормыш, яшәү компасы һәрвакыт бәхеткә табан юл күрсәтеп тора. Югалтулар да булыр, әмма кеше кеше булып калган очракта чын бәхет барыбер килер! Әсәрнең шушындый якты идея белән сугарылуы аны укучылар күңеленә якынайта — җәмәгатьчелек повестьны чыннан да шактый җылы каршылады. Ләкин шул ук вакытта бу повестьта яшь авторның кайбер кимчелекләре дә төсмерләнеп калды. Дөресен әйтик, язманың башында без кырмыскалар оясы турында юкка гына бәхәс куертмадык. Безнеңчә, Мөсәгыйть Хәбибуллин бу әсәрендә тормышны чын художник буларак күзәтеп җиткерә алмады әле. Психологик мотивлаштыруның йомшаграк булуы, хис-кичерешләрне вакыйга-картиналар аша сурәтлисе урынга, күп урында аларны сөйләп кенә чыгу, билгеле ки, әсәрнең ритм-динамикасын, тәэсир-тылсым көчен беркадәр киметә төште. Шулай ук Мөнирә белән Галимнең рухи дөньялары, аларның «эчке механизмын» хәрәкәткә китерүче идеяләрнең зәгыйфьрәк тасвирлануы да (юкса Галим эчә дә «кунак» җыя, аннары тагын көннәр буе авызына су кабып утыра: бу «йомыкый»ның эчендә ниләр бар — укучылар аны күрми дә диярлек) әсәрнең бөтенлегенә зыян китерә.
Французлар: «Исем әле җисем түгел», — диләр диюен, ләкин М.Хәбибуллинның «Икмәк кадере» повестена салынган төп идея аның исеменнән үк башлана дисәк тә ялгыш булмас. Әсәрдә нәкъ менә «икмәк кадере» турында сүз бара һәм икмәккә — ипекәйгә мөнәсәбәттә геройларның мораль һәм рухи дөньялары ачыла.
Повестьның сюжеты гади: скважинада авария булу сәбәпле колхозның уҗым басуына нефть ага — төп вакыйга шуннан гыйбарәт. Гаепләүче, билгеле, колхоз председателе Сәхаб Кадыйров, гаепләнүче — нефть чыгару идарәсе начальнигы Вәкил Ходайбирдин, тикшерүче — район партия бюросы һәм район партия комитетында яңа гына эшли башлаган беренче секретарь Бакир Галиев.
Биредә бер сорау туа: ни өчен соң әле уҗым басуына нефть агу вакыйгасы шулкадәре җәнҗал төсен ала? Әмма эш аның белән генә чикләнми; асылда, бер-берсенә капма-каршы булган ике төрле фәлсәфә, ипигә, җиргә, ахыр чиктә тормышка, яшәүгә карата булган ике төрле мөнәсәбәт бәрелешкә керә монда. Бит бер дә юкка гына Сәхаб Кадыйровның да, Вәкил Ходайбирдинның да үткән тормыш юлларын, яшәү принципларын, дөньяга карашларын тәфсилләп сөйләп бирми автор, ул аларның җаны һәм рухы белән идарә итүче эчке импульсларның нинди учактан очкын алуларын киңрәк тасвирларга омтыла.
Сәхаб — җир кешесе, гомере буе җиргә бил бөккән, җиргә баш игән игенче. Аның «кендеге җиргә береккән». Туендыручы һәм киендерүче җирдән дә кадерлерәк, тереклек чыганагы ипекәйдән дә изгерәк нәрсә юк аның өчен. Шуңа күрә дә Сәхаб нефтьчеләрнең җирне теткәләп, пычратып бетерүләрен тыныч кына кичерә алмый.
«— Карагыз, нишләткәнсез җирне! Монда кайчан икмәк үсәчәк? Бу җир кайчан чәчәргә яраклы булыр? Беләсезме сез шуны, юкмы?! — дип, сафура бураннары чыгарып орыша иде». Ләкин соңгы ЧП аны бөтенләй чыгырыннан чыгара. Нефтькә баткан иген кырын күрүгә ул, йөрәге әрнеп, идарә начальнигына элдерә. Ходайбирдинның күн диванга күмелеп тыныч кына тәмәке тартып утыруын күргәч, бөтенләй кабынып китә:
«— Скважинагыз шартлаган!.. Бөтен басуны нефть баса, ә сез тәмәке тартып тынычланып утырасыз... Оят түгелме?!»
Ходайбирдин исә бөтенләй икенче төрле фикер йөртә: «...Без аларга бу җирләрне пычраткан өчен дөнья чаклы акча түлибез. Нәрсә оттыралар алар?! Икмәк бәясе нефть бәясе түгел! Без

нефтьне алтынга сатабыз!..»
Икмәк бәясе нефть бәясе түгел, имеш. Хәер, Ходайбирдинның болай әйтүендә бер дә гаҗәпләнерлек нәрсә дә юк югын. Иман дигән кыйбласының үз кучәреннән тайпылуы белән ул моңа инде күптән әзер иде. Институтны тәмамлап чыкмас борын ул, аны-моны исәпкә-санга сукмыйча, тизрәк начальник булырга, креслога менеп кунакларга ашыга. Һәм теләгенә дә ирешә. Бораулау конторасында баш инженер булып эшли башлый. Тик башбаштак характеры аның үз юлына киртә булып ята — беренче адымыннан ук ул кирегә каера башлый. Ул бөтен нәрсәне акчага гына кайтарып исәпли, ә мораль җаваплылык сизми. «— Беләсезме сез электр линиясен бер сәгатькә өзү күпмегә төшә? — диде Вәкил һаман тынычлана алмыйча сукранып торган бригадирга. — Сәгате ничәмә йөз сумга. Ә бодай җиренең бәясе аның ярты хакына да тормый...»
Аннары, поши белән булган мәләкә, кыздырырга дип алып кайткан тере балыкларны ваннага җибәрү мәсьәләсендә кыз белән ата арасындагы бәрелеш! Кечкенә генә детальләр, әмма алар Вәкилнең характер сыйфатларын ачарга ярдәм итә.
Вакыйгаларның логик үсеше нигезендә Сәхаб белән Вәкил арасындагы конфликт иртәме-соңмы чишелергә тиеш иде. Һәм шулай була да: райком бюросы утырышында алар бөтенләй икесе ике якка китеп баралар. Сәхабның райком өстәле өстенә пешкән ипи куеп сөйләгән сүзләре ышандыргыч, көчле яңгырый. «— Кем таптый ала шушы икмәкне? Кем?! Ә менә болар таптыйлар, ике аяклап менеп таптыйлар!..»
Вәкилнең астыртын көлүдән башка дәлиле юк: «— Иптәш Кадыйров, ипиегезне алып китегез, монда ач кешеләр юк». Бу сүзләр Вәкилнең үз өстенә гаепләү акты булып әйләнеп кайталар — күккә таш атсаң, үз башыңа төшүе мөмкин шул.
Әсәрдә башка сюжет сызыклары да бар, әмма бу очракта аларга тукталып торуның хаҗәте юк кебек. «Икмәк кадере» әсәренең идея максаты ачык: халык хәтере, халык күңеле, халык иманы булган икмәк образы аша кешеләр күңелендәге изге тойгыларны уяту, каткан күңеллелеккә каршы бер нәфрәт сүзе әйтү.
Ибраһим Гази бер чыгышында болай дип сөйләгән: «Икмәк кадере» повестен зур канәгатьләнү белән укып чыктым. Әсәр тормышны тирәнтен белеп язылган. Авторның әдәбиятка зур тормыш тәҗрибәсе белән килүе әсәреннән үк күренеп тора. Язучы өчен тормыш тәҗрибәсе бик зур сыйфат. Әсәрдә аеруча колхоз председателе һәм нефть идарәләре оешмаларының җитәкчеләре яхшы сурәтләнгән». Мөсәгыйть Хәбибуллинның аннан соң иҗат ителгән әсәрләре дә тормышны яхшы белеп язылган. КамАЗ төзүче шоферларга багышланган «Тау белән тау очрашмаса да...» повесте һәм авыл тормышын чагылдырган «Чоңгыллар» романы турында да шушы ук сүзләрне әйтергә мөмкин. Бу әсәрләрендә дә автор хезмәт поэтикасын, хезмәт романтикасын тасвирларга омтыла.
...М.Хәбибуллин үзе байтак еллар шофер булып эшләгән кеше. «Тау белән тау очрашмаса да...» повестенда без шушы авыр һәм катлаулы профессия кешеләренең тормышын, аларның кыен юлларда, иң җаваплы һәм авыр вакытларда да үзара ярдәмләшүен күрсәткән байтак уңышлы сәхифәләрне очратабыз. Аның геройлары юлны, машинаны һәм шулай ук тизлекне күңелләре белән тоялар...
Анысы шулай, әмма автор кайчак дуганы артыграк бөгеп җибәрмиме дигән шик тә туа. Кайсы гына әсәрне алма — авария, интрига. «Тау белән тау очрашмаса да...» повестенда да шулай. Дөрес, дөнья булгач барысы да булырга мөмкин, ләкин язучы хәл-вакыйгаларның кайдан, ни сәбәпле килеп чыгуын, аларның социаль нигезләрен укучыларына дәлилләп аңлатырга, ышандырырлык итеп мотивлаштырырга тиеш. «...Зөлфәт үз машинасының моторы тартмаганын да, шул мотор белән тауга менәсе барын да яхшы белә, шулай булса да, балластны нормадан уздырып салдыра. Бу очракта безгә автор нияте генә аңлашыла: аңа тау менгәндә киеренке ситуация тудырырга кирәк. Ә менә аның герое нәрсә уйлый икән? Күңеленнән нинди хисләр, кичерешләр үтеп китә? Шуларга психологик нигезле, дәлилле җаваплар тапканда гына без геройларның сәер эш-хәрәкәтләрен кабул итә алабыз», — дип әйтүе белән Фәрит Хатипов хаклы. Психологик анализ булмадымы, әсәрнең кеше күңелен өйрәнүдән производство, технология мәсьәләләрен тикшерүгә кайтып каласын көт тә тор инде. Кызганычка каршы, соңгы еллар татар прозасына хас мондый кимчелекләр Мөсәгыйть Хәбибуллин иҗатында да төсмерләнә. Бу бәладән «Чоңгыллар» романы да тулысынча азат түгел әле.
Сүз дә юк, Мөсәгыйть Хәбибуллинның әдәби осталыгы үскәннән-үсә бара, моны берничек тә инкарь итеп булмый, ләкин әдәбият та язучы алдына торган саен зуррак бурычлар куя тора бит...
...Мөсәгыйть Хәбибуллинның әдәбият мәйданына килеп керүенә әле күп түгел. Шулай да инде ул берничә повесть, хикәяләр һәм роман авторы. Татар прозасында актив эшләп килүчеләрнең берсе. Акыл утырткан, тормыш тәҗрибәсе туплаган илле яшьлек ир-егет. Шулай икән, аның,

артка әйләнеп карап, үткән юлына, кылган эшләренә карата нәтиҗә ясарлык, шулардан чыгып киләчәккә юл сызарлык хатирәләре дә бардыр. Язучы буларак, Мөсәгыйть Хәбибуллин алдында бер зур баскыч тора — производство-технология мәсьәләләрен полемик рәвештә алгы планга чыгарып иҗат ителгән әсәрләрдән югарырак күтәрелеп, кеше күңеленең бетмәс-төкәнмәс байлыкларын, мәңге кипмәс чишмәләрен зурлап җырлаган, чынбарлыкны художникларча фәлсәфи тасвирлаган әдәбият мәйданында тагы да алга үтәсе бар аның. Язучыны ачылмаган яңа әдәби катламнар — бәхетле мизгелләр көтә. Бәхеткә юл — гел алда.

*«Казан утлары», декабрь, 1977*

**УЧАК ҖЫЛЫСЫ**

Ул учак ягарга ярата. Көне буе бакчада әвәрә килеп йөргәннән соң, дача өе каршында ут тергезеп җибәрә... Якты көздә үк урманнан коры-сары җыештырып чыга, бакчадагы чыбык-чабыкны да бер урынга җыештырып бара, аннары, күз бәйләнә башлагач, арып-талып учак урыны каршындагы утын кискәсенә килеп утыра. Ашыкмыйча гына, ниндидер бер пөхтәлек белән дигәндәй, чыбык-чабыкларны кисеп өеп куя да ут ягып җибәрә. Учак терелеп, ялкын телләре дәртләнеп сикерешә башлагач, иркен сулап куйгандай була — тәмәкесен кабыза, күкрәген тутырып бер суыра, кулына берәр чыбык алып, учакны ара-тирә рәтләштереп ала.
Инде караңгы да төшә.
Ялкын телләре, җилдә тузгыган ат ялыдай, лепер-лепер килеп сикерешәләр дә, учак тамырыннан өзелеп, караңгылыкта эреп югалалар, алар урынына тагын яңалары терелеп чыга. Ул әнә шуларга карап уйланып утыра. Йөзендә ялкын шәүләләре уйный — чырае бер яктырып, бер караңгыланып китә, әйтерсең лә тарих үзе чагыла аңарда.
Ут һәм Кеше... Әнә шулай учак ягып утыруда бер мәгънә бар сыман. Бәлки, мәгарәләрдә беренче тапкыр ыру учагын тергезеп җибәргән ерак бабалар җаны-рухының безнең тамырларда тилпенеп, сулкылдап куюыдыр ул?! Әйе, әйе, мөгаен, шулайдыр...
Учак тере булганда җанга җылы, тәнгә рәхәт, күңелгә хәвефсез шул. Кешеләргә генә түгел!..
Җылы барын сизенеп, әнә Шарик та аның аяк астына килеп елышкан. Хуҗасы:
— Ай инде, ай инде! Бигрәк тәти инде үзе, — дип, башыннан сыйпауга, ул аяк астына тагын да сыенарак төшә. Мондый чакта Шарик нишләргә белми: иркәләнә, назлана, тутырып хуҗасына карап ала — сөенеч, бәхет тулы күзләре менә-менә җиргә тамып төшәрләр төсле тоела. Учак җылысыннан бигрәк, күңел җылысын тоеп иркәләнә бугай ул.
Бар шундый кешеләр — алар, кичке караңгылыкта өмет булып кабынган учаклар шикелле, үзен чолгап алган мохиткә җылылык, яктылык биреп торалар. Алар янына, җылы эзләп, кешеләр килә — яшьләр дә, өлкәннәр дә, танышлар да, таныш түгелләр дә. Без аның белән менә дүртенче ел инде бер бүлмәдә утырып эшлибез, менә дүртенче ел инде мин үзем шул учакның җылысын тоеп яшим. Хәер, бер мин генә микән?!
Аның янына еш кына әдәбиятыбыз аксакалы Сибгат ага Хәким кереп утыра. Сүз, әлбәттә инде, әдәбият турында, иҗатлары бөреләнеп килүче яшь көчләр — алмаш турында бара. Теге яки бу яшь әдипнең егәр көче ничегрәк, ут тамыры тирәннән киләме, бер җил исеп кую белән сүнеп китмәсме — әңгәмә әнә шулар хакында. Күреп, сизеп торам — Язучылар союзына кабул итү комиссиясендә бергә эшләгәннәре өчен генә түгел, әле болай, кеше буларак, милли әдәбиятның бер вәкиле буларак, кабынып килүче яңа учакка утын-сары ташларга әзер торалар алар.
Язмышлар турында чын күңелдән кайгырта алган кешеләр бәхетле алар. Андый кешеләр күңелендә Кешене ярату дигән сүнмәс учак яна. Шундый кешеләрнең берсе ул Рәис абый.
Бер генә әдәбият та бөекләрдән генә тормый. Бөекләр, Атлант кебек, әдәбият күге гөмбәзен иңнәрендә тотып торсалар, бөекләрне үз җилкәләрендә бик күп «әдәбият хадимнәре» күтәреп тора.
Рәис абый әнә шул бөекләрне үз җилкәсендә күтәреп торучыларның бер вәкиле, татар әдәбиятының намуслы, тырыш «хадиме». Дөрес, ул шагыйрь дә, прозаик та түгел, пьесалары да сәхнәдә уйналмый, «башкаларның әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә». Бу сүзләрне юри куш җәяләр эченә алдым әле. Ни өчен дисәң, беренчедән, тәрҗемә эшен «икенче сортлы» иҗат итеп караучылар да очраштыргалый бит (гәрчә алай булмаса да), икенчедән, «әдәбият хадиме» дию белән гомумән теге яки бу язучының әдәбиятка карата булган мөнәсәбәте турында бер-ике сүз әйтәсе килә. Тирән ышануымча, Рәис абый үз-үзенә пешәр-пешмәс, урта кул повесть-мазар язарга рөхсәт итмәс иде. Чөнки ул әдәбиятны артык нык ярата, күңеле авыртыр дәрәҗәдә аңлый, хөрмәт итә. Бар ич шундый категория кешеләр — урта кул булып калмас өчен, әдәбиятка хыянәт итү ихтималыннан шикләнеп, «язучы» булмый калучылар. Аларның бу батырлыкларын

аклап булмаса да, аңлап була. Әдәбият дигән изге йортка аяк салмый керүчеләргә караганда аларның бу адымнары, мөгаен, мең мәртәбә гуманлырактыр да әле. Ләкин Рәис абыйның, алардан аермалы буларак, татар әдәбиятында үз урыны, үзе генә терелткән учаклары бар. Ул баш-аягы белән әдәбиятка кереп чумган, ул әдәбият дөньясында яши, һәр күзәнәге әдәбият һавасы белән сулый.
Һәрбер агымсу үз үзәнен таба, ди. Ул юлында нинди генә борылмалар ясамасын, тау-ташларга очрамасын, барыбер үз диңгезенә барып коя. Рәис Даутовның андый диңгезе — әдәбият, әдәбиятның да тәрҗемә өлкәсе. Аның бер анкетага биргән җавапларында мондый гыйбрәтле юллар бар, озынрак булса да шуларны күчереп үтәсе килә: «Мин чын мәгънәсендә китап культы яшәгән гаиләдә үстем. Безнең гаиләдә һәммә кешегә, шул җөмләдән эти-әнигә дә, китап җене кагылган иде. Мәрхүм әнием Тукай шигырьләренең барысын диярлек күңелдән белә һәм яшьрәк чагында үзе дә шигырьләр язгалый иде. Табигый, әдәбият сөюче һәр яшүсмер кебек, минем үземдә дә иҗат дәрте уянды, һәм ул елларда, үзем өчен генә дигәндәй, шигырьләр, хикәяләр язарга да азапланып маташтым. Әмма ул балалык, яшьлек чорында мине иң дәртләндергән нәрсә — ул да булса үзем укыган дөнья әдәбияты җәүһәрләрен татар телендә күрү теләге иде. Шул эчке теләк-дәрт, ихтимал, минем әдәбиятның тәрҗемә жанрында тукталып калуыма сәбәп булгандыр. Хәтеремдә, шул мәктәп елларында ук мин Микеланджелоның берничә сонетын һәм Ронсарның үземә бик ошаган шигырьләрен, рус теле аша, татарчага тәрҗемә иткән идем».
Менә шулай «уйнап» башланган эш аның гомерлек шөгыленә әйләнеп китә. Бүгенге көндә татар укучылары М.Твенның «Янки король Артур сараенда», Д.Фенимор Куперның «Соңгы могикан», Ф.Достоевскийның «Җинаять һәм җәза», А.Купринның «Атышу» әсәрләрен, Э.Хемингуэй «Хикәяләр»ен Рәис Даутов тәрҗемәсендә укыйлар. Ләкин хикмәт санда гына түгел бит әле... Әйтик, татар әдәбиятында тәрҗемә үсешенең төп өч этабын күрсәтергә мөмкин. Октябрьгә кадәр һәм аннан соңгы беренче унъеллыкта «ирекле тәрҗемә» методы өстенлек иткән. Ә 30 нчы еллар башыннан 50 нче еллар ахырларына кадәр нигездә «механик тәрҗемә» дип яманаты чыккан юнәлеш канат җәя. Бу юнәлешләрнең һәр икесе җитешсезлекләрдән азат түгел иде. Беренче юнәлеш оригиналдан читкә алып китте, икенчесе җаны-рухы суырылган төссез, хиссез тәрҗемәләрнең күбәюенә китерде.
60 нчы еллар башында, әлеге «механик тәрҗемәгә» каршы реакция сыйфатындарак, яшь тәрҗемәчеләр арасыннан яңа бер дулкын күтәрелде. Бу агым елдан-ел көч җыя барып, хәзерге көндә үзен тәмам танытып өлгерде. Шулай итеп, татар теленә тәрҗемә итү эшенең фәнни теоретик принциплары эшләнде — «иҗади тәрҗемә» барлыкка килде.
Конкрет алганда, Рәис Даутов нинди принципларга таянып эш итә соң? Бу сорауга ул бая искә алып үткән анкетага җавапларында бик ачык әйтеп үтә: «Тәрҗемәчеләрнең иң изге вазифасы — теге яки бу әдәби әсәрне эчтәлек, стиль, образлылык хасиятләренә хилафлык китермичә, икенче бер телдә мөмкин кадәр адекват, тәңгәл гәүдәләндерергә омтылу. Мин монда нәкъ менә «гәүдәләндерү» сүзенең асыл мәгънәсенә ишарәлим. Шул асыл мәгънәсендә тәрҗемәченең эшен актер хезмәте белән чагыштырырга мөмкин булыр иде. Актер да бит образ-персонажның эчке дөньясына тирәнтен кереп, сәхнәдә аны автор тасвирлаган яки күз алдында торган эмоциональ югарылыкта гәүдәләндерергә тырыша. Тәрҗемәче дә шулай: бүтән телдә язучы әдипнең рухи дөньясын, фикерләү формаларын, әсәрендәге фикри-әдәби хасиятләрне йөрәге аша үткәреп, ул үз ана телендә бу әсәрне яңабаштан корып, гәүдәләндереп бирергә бурычлы».
Практикада Рәис Даутов шушы бурыч-принциптан читкә тайпылмаска омтыла һәм шуңа күрә язу стиле, фикерләү формалары белән үзенә якынрак торган язучыларның әсәрләрен тәрҗемә итә.
Сәхнәдә уйналган һәрбер рольдә оста актерның индивидуаль сыйфатлары ачык сиземләнгән кебек, тәрҗемә әсәрендә дә, табигый, тәрҗемәченең үз стиль үзенчәлекләре, язу манерасы чагылмый калмый. Ләкин, тәрҗемәче үзе оста стилист булганда, андый «югалтулар» оригиналның гомуми эмоциональ яңгырашына сизелерлек зыян китермиләр, аерым очракларда исә аны баетып кына җибәрәләр.
«Җинаять һәм җәза» романының татарча яңгыравы моңа ачык мисал булып тора ала. Бу тәрҗемәдә Ф.Достоевский рухы тулысынча сакланган хәлдә, татар тел үзенчәлегенең халыктан, Тукайлар, Ибраһимовлардан килә торган байлыклары, хасиятләре дә аеруча калку чагылды. Менә шуңа күрә дә бу әсәрнең татарчага тәрҗемә ителүе бөтен татар әдәбиятының тәрҗемә өлкәсендәге казанышларыннан берсе булды.
Искә төшерергә тырышып уйлап утырдым, ләкин аның бер генә эшне дә аннан-моннан гына, ашык-пошык башкарганын хәтерли алмадым. Өйдә, эштә, бакчада — һәркайда һәрнәрсәне җиренә җиткереп һәм, әйтергә кирәк, анализлап, бөртекләп эшләргә тырыша ул. Коры

рационализм гына түгел бу (аңарда иҗат фантазиясе дә җитәрлек), ә бәлки табигатьтән бирелгән байлык — эчке рухи культураның югары булуы турында сөйли торган бер дәлил. Бу сыйфат, бер яктан, озак еллар Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшләү дәверендә камилләшкәндер, икенче яктан, характерына хас шушы төсмерләр аны әйбәт редактор иткәндер.
Рәис Даутов үз гомерендә өч йөзгә якын китапка фатиха биргән — халык күңеленә мәгърифәт кошлары очырган кеше. Өч йөзләп китапка аның күңел җылысы салынган. Үзенең «мин чын мәгънәсендә китап культы яшәгән гаиләдә үстем» дигән сүзләрен искә алсак, әлеге саннарның асыл мәгънәсенә төшенү кыен булмас. Китапны ул кешеләрне яраткан кебек ярата, китапка карата аның күңелендә ниндидер бер аерым җылылык, хөрмәт яши.
Китап тудыру җиңел хезмәт түгел, фәлән генә битле җыентыкка да дистәләгән кешенең акыл һәм физик көче кергән була. Ләкин нәшриятта аның чын хуҗасы — редактор.
Менә ул сигнальный экземплярны карап утыра. Беркемне дә күрми, ишетми — китапка чумган. Ничек басылган, буяулары әйбәт төшкәнме, төпләнеше ничек, формат сакланганмы? — барысын-барысын тикшерә. Өстәлгә бастырып куя да еракка китеп карап тора — читтән ничек күренә икән? Әгәр китап тулаем күңеленә хуш килсә, йөзе яктырып, нурланып китә. Әйбәт редактор булу өчен чыннан да автор белән кулга-кул тотышып эшли алу, әдәби зәвык, эрудиция генә җитмидер, ә бәлки китапны аңлау, ярату хисе дә зарурдыр.
Хәзер Рәис Даутов татар әдәбияты классикларының әсәрләрен редакцияләү буенча специальләште — Тукай, Ибраһимов томнары аның редакциясендә дөнья күрде.

...Ул учак ягарга ярата.
Аның учагы һәрвакыт тере, учак урыны һәрвакыт җылы. Чөнки учагын ул кешеләр, халык күңеленнән сирпелгән очкыннардан кабызып җибәргән.

*«Казан утлары», март, 1978*

## ЙӨРӘК ШАГЫЙРЕ

Хәсән ага Туфан иҗатына мин яшьлегем хатирәләре аша карыйм. Үсмер чакның иң якты бер истәлеге, матур бер сәхифәсе итеп искә алам мин аның белән (ягъни шигырьләре белән) беренче очрашуымны.
Әйе, тормышта шундый вакыйгалар була бит: алар, кинәт кузгалган давыл кебек, күңел капкаларын каерып ачып керәләр дә барлык дөньяны актарып-туздырып ташлыйлар. Хәсән аганың китабын кулга алып укый башлагач та мин шундыйрак бер рухи сискәнү, хәтта, әйтергә мөмкин, тетрәнү кичергән идем.
Күз алдына китерик: Татарстанның тыныч бер төбәгенә кереп оялаган бәләкәйрәк кенә татар авылы. Биредә дә кешеләр иген игәләр, терлек асрыйлар, шатланалар, борчылалар — кыскасы, яшиләр... һәм китап укыйлар. Әйе, әйе, ул чорда авылда китапханәгә йөреп китап укыйлар иде әле. Әйтергә кирәк, шушы кечкенә генә Бүләк дигән авылның шактый бай китапханәсе бар иде һәм, билгеле, авыл кешесенең, бигрәк тә үсмер егетләрнең — безнең яратып йөри торган бер урыныбыз иде ул. Шулай көннәрнең берендә — 1964 елның җәеме, әллә көземе иде — китапханә мөдире Мирфәез абый Галиев кулыма яшел тышлы бер китап тоттырды да, гадәтенчә сынаулы караш ташлап: «Мә, укып карале», — диде.
Хәзер ничектер, без үскәндә авыл баласының бер гадәте бар иде: әнисе кибеткә прәннек-конфет ише тәм-том алырга җибәрдеме, ул кайтышлый аннан авыз итми калмый торган иде — чоры шундый иде. Шуның кебек мин дә, китапханәдән чыгып бераз китү белән, култык астымдагы «нигъмәттән» авыз итми кала алмадым, билгеле. Кирәк бит шулай: бу бер бәхет эшедер, китапны алуга ук соңыннан шагыйрь иҗатындагы иң яраткан шигырьгә әйләнеп киткәненә — чын җәүһәргә тап булганмын лабаса. «Агыла да болыт агыла...» Йә, инде ниндидер билгесез, яшерен утлар белән яна башлаган, авылның басу түреннән соң да дөнья барлыгын чамалап өлгергән күңелне кузгатып җибәрү өчен күпме кирәк?! Күп кирәктер. Ләкин бер Туфан да җитә икән.
Туфан дөньясы... Бу бөтенләй ят, үзгә, сихри дөнья иде: мәктәп дәреслекләре кысасына сыеп бетми торган күңел, йөрәк дөньясы иде ул. Тукайның бөеклеген аңлау (бәлки, аңларга тырышудыр) соңрак, акыл утыргачрак булгандыр. Әмма Туфан дигән шагыйрьнең үзенчәлекле җанын, моң-сагышка, сөю-мәхәббәткә тулы күңелен бала-чага акылы белән дә тоймый калу, алай гынамы соң, — аңа сокланмау, алдында баш имәү мөмкин түгел иде. (Яшермим, зинһар, тыйнаксызлык дип санамагыз, мин мәктәптә укыган елларымда Туфан белән тәмам җенләнеп

йөрдем, һәр шигырен диярлек укып-ятлап бардым һәм кичләрен бердәнбер тыңлаучыма күңелдән сөйли дә торган идем.) Хәзер беләм: Туфанның олуг җаны, гыйбрәтле язмышы, какшамас рухы белән очрашкан бик күп кешеләр менә шундыйрак рухи сискәнү, тетрәнү кичергәннәр икән. Бу сүзләрнең хаклыгына шик белдерүчеләр булса, 1989 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән Туфан ага турындагы «Ак чәчәк атар иде...» (төзүчесе Харрас Әюпов) дигән истәлекләр китабына тагын бер мәртәбә күз салсын, күз салып кына калмасын — игътибар белән укып чыксын. Һәм ул күрер: биредәге истәлекләр, әдәбият-сәнгать әһелләренең тормышы һәм иҗатына багышлап язылган бик күп хатирәләрдән аермалы буларак, үзләренең эчкерсезлеге, җылы һәм ихтирамлы булулары белән аерылып торалар. Сүз дә юк, ул истәлекләр белән танышканнан соң безнең алга катлаулы тормыш юлы үткән олы шәхес килеп баса. Ирексезләп уйлап куясың: «чын шагыйрь үзе үлгәч яши башлый» дигән сүзләрдә әллә, чынлап та, хаклык бармы соң?! Мин моңа ышанам, минем моңа ышанасым килә, моның шулай икәнлеген халыкның бөек улларына булган мөнәсәбәте аша дәлиллисе килә. Хәер, Хәсән Туфанның әле быел гына басылып чыккан «Гүзәл гамь» җыентыгы үзе үк алда әйтелгәннәргә ачык дәлил ләбаса. Ниһаять, «Моңарчы басылмаган шигырьләре» белән танышу, бер яктан, бик күркәм күренеш булса, икенче яктан, өстә генә яткан учак кузларын — юксыну хисен терелтеп җибәрделәр.
Шигырьләр, шигырьләр... Әйе, эчтәлеге белән билгесез булган, әмма рухы белән бик тә, бик тә якын, бик тә таныш Туфан шигырьләре. Һәр олы шагыйрьнең үзенә генә хас тавышы, яраткан сөйләме, образлар өлгесе — шигъри дөньясы булган кебек, әлеге шигырьләргә күз ташлау белән үк Туфанның һичкемнеке белән дә бутамаслык сулышын тоясың. Менә аның китапка кереш итеп бирелгән шигъри юллары:

«Нәрсәгә лә тормыш?
Нигә лә?» — дип
Йөдәтмә лә, йөрәк,
урынсыз.
Нәрсә өчен, нигә кирәк
булсын —
Кеше өчен кирәк бу
тормыш.

«Лә» кисәкчәсе белән ясалган элмәкләр, йөрәк образының килеп керүе, сөйләме, гомуми рухы — барысы да Туфанча, соңгы чор, олуг Туфанча, соңгы рәвешле, шигырьдән шигырьгә шагыйрьнең һәр чор иҗатына яңа билгеләр, яңа төсмерләр өстәлә тора, өстәлә тора: ахыр килеп, алар синең шагыйрь иҗатына карата булган фикри офыкларыңны киңәйтә төшәләр, тулыландыралар һәм уйланырга мәҗбүр итәләр: Туфан — бөтен җаны-тәне белән, иҗаты һәм яшәеше белән бербөтен шәхес. Менә ул без моңарчы белгәнчә усал-кинаяле («Гөрзине, әйтик, ничек кулланырга — Мөнкирчәме, Мөсәгыйтьчәме?», «Ярашырга өйрәтмәкче мине — татар баласын...»), менә ул сагышлы-моңсу, гаделсезлектән гаҗиз җан иясе:

Яралар авыр минем.
Иңемдә — канлы кием.
Кайда син? Өйдәме син?
Әй, кил, әй ялгыз ярым, —
Ахыргы минут минем...

Шигырьне сүзләр белән аңлату файдасыз эш. Шуңа да шигырьләрнең үзләренә — шагыйрь кичерешләренең җанлы шаһитларына мөрәҗәгать итик: никадәр фаҗига, тирән сагыш һәм өмет, сүнмәс өмет чагыла аларда:

Йолдызлар сүнә. Учак та.
Мин — һаман янам әле.
Хушыгыз, соңгы
тӧтеннәр,
Мин монда калам әле.

Кыскасы, татар китабы авырлык кичергән бер чорда зәвык белән эшләнгән бу җыентыкта (төзүчеләре Мәсгуд Гайнетдинов, Фәиз Зөлкарнәев, рәссамы Ильяс Субаев) мин ап-ак чәчле, башын кыңгыр салып торган Хәсән ага Туфанның кабат үзен күргәндәй, тонык, ипле тавышын ишеткәндәй булдым. Бу китаптан ул безгә — меңләгән укучыларына — «Хәлегез ничек, туганнар?» дигәндәй, уйчан күзе белән багып тора сыман.
Шаять, «билгесез». Туфан белән бу күрешү соңгысы булмас. Китапка бирелгән аңлатмада әйтелгәнчә, әле аның тагын «хәзерге укучыга таныш булмаган бик күп шигырьләре, әдәби

тәнкыйть, эссеистика, публицистика, хатлары» белән танышасыбыз бар икән. Бирсен Хода! Шагыйрь гомерен халык рухына барып ирешкән әсәрләре озынайта, аны китаплары яшәтә ләбаса.
Ә син яшисең, Хәсән ага! Укучыларыңның күңелендә, йөрәгендә яшисең. Син бит йөрәк шагыйре.

*«Шәһри Казан», октябрь, 1990*

**БАШНЫ САЛЛАРГА САЛЫП...**

Равил Габдрахман улы Фәйзуллин 1943 елның 4 августында Татарстан Республикасының Балык Бистәсе районы Балтач (Юлсубино) авылында туа.
Котлы Бөкәш авылы урта мәктәбен, 1965 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый; Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында аспирантурада укый.
Р.Фәйзуллин — 1966 елдан Язучылар берлеге әгъзасы.
1968–1972 елларда Р.Фәйзуллин — Татарстан язучыларының Әлмәт оешмасы җитәкчесе. 1973 елдан 1977 елга чаклы — Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы сәркатибе.
Р.Фәйзуллин — яшь шагыйрьләрнең, Мәскәүдә ВЛКСМ ҮК оештырган Бөтенсоюз фестивале премиясе (1966), «Дружба народов» журналы премиясе (1973), «Мәрмәр» исемле китабы өчен Татарстан комсомолының М.Җәлил исемендәге премиясе (1970) һәм, ниһаять, «Шигырьләр һәм поэмалар» китабы өчен Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.
Р.Фәйзуллинның аерым әсәрләре рус, башкорт, кыргыз, әзәрбайҗан, чуаш, литва, эстон, грузин һ. б. халыклар телләрендә һәм шулай ук итальян, немец, поляк, француз, гарәп кебек чит ил телләрендә дә дөнья күрде.
1989 елдан «Казан утлары» журналының баш мөхәррире. Татарстан халык депутаты.

Шигъри дөньялар эзлим!..
Моннан байтак еллар элек, шигъриятнең асылы турында уйлана башлаган гына бер чорда, беренче (һәм әлегә соңгы) мәртәбә Шигырь турында сүз әйтү өчен Тукай клубындагы трибуна артына чыгып баскач, яшьлеккә хас кайнарлык белән әнә шулай дип әйтеп ташлаган идем. Аз да түгел, күп тә түгел: дөньялар эзлим... Ә эзләгән кеше таба инде ул, кем әйтмешли, һич югы, табарга тиеш. Мин дә үземнең рухани эзләнүләрем, күңел җегәрем мөмкинлек биргәнчә яңа кыйтгалар ачканмындыр, ачканмындыр да гомер юлымда кайберләрен инде югалтырга да өлгергәнмендер (тапканны гына, бар булганны гына югалтып була лабаса); әмма кай тарафка китеп баш орсаң да, Шигърият диңгезенең чиксез киңлекләрендә серле дөнья булып балкып торган, юлыңның азимутын дөрес билгеләргә ярдәм итә алган Казык йолдызлары бар ул, бар.
Ни гаҗәп: мине беренче тапкыр тетрәндергән шагыйрь Тукай, Дәрдмәндләр дә, Пушкин, Лермонтовлар да түгел (күрәсең, безгә — күзе ачылып кына килгән сала малайларына — Шигърият серләре иң беренче булып китаптан битәр Табигать аша ачылган булгандыр) Хәсән ага Туфан булды кебек. Сәбәбе? Сәбәбе шуннан гыйбарәт иде: минем беренче рухи уянуым, егетлеккә атлаган көннәрем, әйләнә-тирәдәге олы дөньяга гыйшкый күзләр белән карый башлавым Хәсән аганың көндәлек мәшәкатьләрне бар нәрсәдән дә өстен күреп, өстән җибәрелгән җәзалардан тәмам гаҗиз булып яшәп яткан татар мохитенә кабаттан әйләнеп кайткан көннәренә туры килде. Хәтерлим: яз, апрель һәм мин — заманның һәрбер җиленә киереп ачылучан, күндәм, шыгырдавык авыл капкасыннан соң да дөнья барлыгын аңлый башлаган иләсрәк күңелле үсмер — төз лапас түбәсенә өелгән сары арыш саламына күмелә идем дә, моңарчы исеме дә таныш булмаган шагыйрьнең уй дөньясы белән хозурланып, каршылыклы да, газаплы да хыялларга чума идем. Аның һәр сүзе минем өчен яңача: серле дә, моңлы да, хәсрәтле дә иде. «Тышта яз, һавада кошлар өне» генә әле югыйсә, табигатьтә дә, күңелдә дә тормыш-яшәү уянып кына килә ләбаса, ә ул инде — китапның титул битеннән җаныңа керердәй булып текәлеп карап торган чал чәчле, какчарак сөякле шагыйрь агай: «Тагын бер яз саубуллашып үтте, ядкяр итеп чәчәкләр биреп», — дип җаныңны сискәндереп куя.
Икенче тапкыр чын-чынлап шигырь алдында югалып калуым Равил Фәйзуллин исеме белән бәйле.
Менә шундый сәгадәтле моң, билгесез ашкынулар белән тилереп яшәгән гомер иртәсендә язмыш дигән хакыйкать иясе безне — Үрәзмәт урта мәктәбе укучыларын, шул исәптән мин фәкыйрегезне дә, һич уйламаганда, чын шагыйрьләрнең берсе белән дә таныштырды: әдәбият дәресләрен Рәдиф Гаташ алып бара башлады. Дөреслекне танырга кирәк: авылдашым Дәүфит

Раянов әйтмешли, «Үрәдмәт малайлары» Шигырь турында беренче олуг сүзне нәкъ менә аның авызыннан ишеттеләр, яңа исем-атаулар белән аның аша таныштылар. Ул беренче көннәреннән үк һәр дәрес саен социалистик реализм кануннарын өйрәнүгә багышланган ун-унбиш минутлык мәҗбүрияттән соң «ирекле» темага күчә торган иде һәм бу ирекле темага үткәрелгән дәресләр еш кына өй эше итеп тә бирелә иде. Кыскасы, без дөнья әдәбияты үрнәкләрен тәүге тапкыр аның ярдәме аша авыз иттек. Казанның үсеп килүче яшь шагыйрьләре иҗаты белән дә безне нәкъ менә ул — Рәдиф Гаташ таныштырды.
Шәхсән минем үземне, Равил Фәйзуллинның иҗат дөньясына Рәдиф Гаташ җитәкләп алып керде. Бу хәл болайрак булды.
1965 елның җәе иде, безне — Үрәзмәт урта мәктәбенең шигъри күңелле алты малаен (алар арасында Зөлфәт белән Фәрит Гыйльми дә бар иде) — хәлфәбез Рәдиф Гаташ республика туристлар слетына (асылда, уйла, шәһри Казанның әдәби мохите белән таныштырырга) җыеп алып килгән иде. Пароходтан төшү белән, ул безне шәриктәше Равил Фәйзуллин хозурына ияртеп алып китте. Әмәт тавы итәгендә алма бакчасына төренеп утырган җыйнак кына бер йорт. Тәрәзәсе урамга караган тар гына бүлмә. Күп булса без анда ике-өч сәгать сөйләшеп утырганбыздыр, әмма ничек иркенәеп чыгып киттек без аннан. Ике «яшь авантюрист» илләр, шәхесләр хакында гәп корып утыралар, бер селтәнүдә авторитетларны тетеп аталар, юкка чыгаралар, йә булмаса гавамга бөтенләй билгеле булмаган яшел авызларны күккә чөеп мактыйлар, ә без — математика дәфтәренең арткы битенә кешеләрдән яшереп кенә шигырь сырлаучылар — журнал-газеталар актарып утырабыз. Ә аларда — шигырьләр, шигырьләр... Әллә нинди, беркемнекенә дә охшамаган, көч-акыл ташып торган, неоннар балкышы, кыйтгаларны тоташтырырлык фәлсәфә, гамәли уй-гамь белән сугарылган Равил Фәйзуллин шигырьләре...
Ләкин, барыннан да бигрәк, гадәти булмаган сүз-гыйбарәләрнең, фикер-төшенчәләрнең һич уйламаганда шигырь тукымасына кереп китүе, саллы-салмак музыканың кинәт зеңләп өзелүе, метафора-образларның «аҗагандай» ялтырап-ялтырап алуы — кыскасы, яңача шигъри сөйләм, яңа дөнья (!) әсир дә иткән, бераз аптырашта да калдырган иде бугай безне ул чакта. Билгеле, әдәби терминнар телгә соңрак килеп кергәндер, гомумән, шагыйрь үзе дә, аның турындагы карашларым да тулаем соңрак формалашкандыр, әмма әлеге очрашудан соң мин Равил Фәйзуллинны урылмаган кишәрлек башында аякларын киң итеп басып торучы Җир хуҗасына, ягъни атасы нигезеннән «башка» чыккан яшь йорт хуҗасына охшатып калган идем. Әйе, беренче карашка ул, бәлкем, бераз һавалырак тадыр, исәп-хисаплыдыр, тик ул — кодрәтле, ул — зирәк акыллы, ул — үз көченә ышанучан.
Гаҗәп тә түгел: аннан соңгы иҗат юлында шагыйрь моны исбатлады да. «Нюанслар иле» матбугатта басылып чыккан көннәрдә — әдәби җәмәгатьчелек умарта күче кебек гөжләгән бер мәлдә булган әлеге очрашу вакытында Равил Фәйзуллин тамагын каты гына кырып куеп: «Юк, мин барыбер үземнең хаклы икәнлегемне исбат итәчәкмен. Татар шигъриятендә такмаклардан тыш башка төрле шигърият тә яшәргә тиеш!» — дигән иде.

Пәйгамбәрләр —
ничек кирәк таба —
шулай иңдерәләр вәхине!
...Җирдәгеләр, әйдә, теләсәләр,
хорга басып, хорей белән
кабул итеп,
дога кылсыннар.

Һәм, әйтергә кирәк, вакыты-вакыты белән аңа нинди генә уклар яудырылмасын, аны нинди генә гөнаһларда (кичерешләр шагыйрен — салкынлыкта; ирекле киңлекләргә ашкынуын — формализм чире белән авыруда) гаепләмәсеннәр, ул беренче адымнарыннан ук үзенең кем булып тууын, алдында нинди максат торуын аңлап эшкә керештe; аның җиңе һәрвакыт сызганулы, биле буулы булды. Беренче эшен ул максатка ярашлы «эш кораллары» булдырудан — сүз белән осталарча эш йөртергә өйрәнүдән, яңача ритмика, рифма, образлар системасы тудырудан башлады (җир казыйм дисәң — көрәге, өй салыйм дисәң балтасы кирәк ләбаса); беразга, ориентирлар тәмам ачыкланганчы, тормыш тәҗрибәсе тупланганчыга кадәр, фикерне хисләренә башлык итеп куйды да, акыл «минаэзләгечләре» ярдәмендә дөнья агышын күзәтергә керештe. Иҗатының башлангыч чорындагы сәер шигырьләре — кыйтгалар һәм халыклар язмышын «телефон аша» хәл итү, кеше күңелен онытып торып, глобаль галәми уй белән артык мавыгып алу менә шулай дөньяга килде бугай инде. Ләкин болар, безнеңчә, вакытлы күренеш, һәр талантлы яшь кешегә хас булганча берникадәр салулап алу буларак кына, һәм шул чор контекстында, «яңа» әдәбият туу процессында кабул ителергә тиеш иде. Хәер, яшьлек авыруы

ул тиз үтүчән була һәм шулай булды да. «Кеше җаны, Кеше күңеле — үзе бер галәм, Шигъриятнең төп вазифасы шул галәмне өйрәнү» дигән төшенчәне тирәнрәк аңлый барган саен, Равил Фәйзуллинның иҗаты да яңадан-яңа төсмерләр алып байый төште, тирәнәйде, ягъни «суы аска китте», ялган пафослар, билгесез көрәшкә чакыру урынына Кешелеклелек, Туган җир, халык язмышы турында уйлану мотивлары алгы планга чыкты. Миңа калса, 70 нче еллар азагы, 80 нче еллар башында шагыйрь чын мәгънәсендә гуманистик идеяләр белән сугарылган фәлсәфи-лирик әсәрләр тудыру осталыгына иреште, нәкъ менә шушы чорда ул макродөнья белән микродөньяны бердәй күкрәгенә сыйдыра алырлык, аларның гармоник уртаклыгын тоеп яшәрлек шәхес булып өлгерде. Ул утыз яшәр ир-егет иде...

* * *

Хәер, алгарак киттем бугай, «уй йомгагын» киредән сүтә башлыйм әле. Мин бит сүземне «шигъри дөньялар эзлим» дип башлаган идем ләбаса. Бу дөньяда һәрбер адәм баласына рухи терәк кирәк, һәрбер адәми затның бу тормышта үз кыйбласы булырга тиеш. Кемдер аны — Ходайга сыгынудан, кемдер — сөю-сөелүдән, кемдер — мал җыюдан, кемдер башка бер нәрсәдән табадыр. Кемдер... шигъряттән! Шөкер, бездәй «юләрләргә» хәзергә хәтле шигърият гел терәк була килде. Дөнья бит бу: гомер узган саен әшьяларның җете төсе уңа төшүе дә бик табигый, «башны салларга салып» агып китәсе килгән көннәр дә булмый калмагандыр, әмма хәятта тормыш юлының иң текә үткелләрен, хәтәр борылмаларын кичкән чагында да сине һәлакәттән йолып кала алырлык, сүнәм-сүнәм дигәндә дә күкрәгеңне утлы күмер кебек яндырып-өтеп торырлык бер Бөек көч барлыгын тоеп-аңлап яшәү үзе бер чиксез бәхет икән лә ул! Шуңа да гомеремдә җан азыгы булырлык бер генә кәлимә сүз әйтә алган һәркем каршында башымныияргә дә әзермен — төчелек булып аңлашылмасын тагын. Бу нәүбәттән, Равил Фәйзуллин шигърияте минем өчен җанга ныклык, иманга нур өсти торган шигърият булды дип әйтер идем. Ләкин бу урында шунысын да искәртеп үтү артык булмас, ахры: Шигырь — изге җан ул! Шулай булгач, аны аңлату миңа кайчак бер-бер гөнаһлы эштер сыман тоела башлый. Бәлки, аны аңларга гына омтылырга кирәктер. Алланы аңларга тырышкан кебек.

Әгәр дә мин фәкыйрегез Шигырь турында, чорыбызның күренекле шагыйрьләреннән берсе булган Равил Фәйзуллин турында сөйләргә дип кулыма каләм алырга җөрьәт иткән икәнмен икән, моны «аңлатырга омтылу» дип түгел, «аңларга тырышу» дип кабул итәргә кирәктер. Мәгълүм ки, олуг шигърият шагыйрьнең чынбарлыкка үз мөнәсәбәтен белдерү җирлегендә генә туа ала, һәрбер олуг иҗат — ул шагыйрь җанының, аның уй-кичерешләренең, яшәү рәвешенең, фәлсәфи һәм рухи эзләнүләренең ак кәгазьгә күчкән моделе, сүз-образлар ярдәмендә ясалган ихлас сурәте. Ләкин чын шигърият реаль чынбарлыкны да, җанга үзгәреп күчкән, хыялый тирәнлекләрдә яшәүче чынбарлыкны да чагылдырырга тиеш. Н.Гумилев сүзләре белән әйтсәк, реаль чынбарлык ул — Күк, ә шагыйрь күңеле шул Күкне чагылдыручы Күл өсте. Бу чагылышның соңгы нәтиҗәсе, — ягъни Шигърият, — бер үк вакытта күктәге сурәтләрнең байлыгына да (анда нинди кошлар оча, аның болытлары нинди төстә, яр өстеннән ниндирәк агачлар карап тора), Күлнең күзе ниндирәк билгеләргә (суы чистамы аның, тирәнлеге, су өстендәге дулкыннар ничегрәк һ. б.) ия булуга да бәйле. Йә, без тормыш бизәкләрен төрлебез төрлечә күрмибез дә, аларга һәркайсыбыз үзенчә бәя бирмибезмени?

Шушыңа нисбәтән рәвештә, шагыйрьләрне шартлы рәвештә ике төркемгә — «шигъри дөнья»ларын тудыра алганнарга һәм, киресенчә, тудыра алмаганнарга бүлеп карарга мөмкин булыр иде. Була шундый шагыйрьләр: аларның иҗатында чынбарлык ничек бар шулай чагылыш таба, андый шигырьләр сине сискәндерми дә, сихерләми дә һәм, табигый буларак, андый иҗат тора-бара мае бетә башлаган шәм кебек әкренләп сүнә, тоныклана бара. Заман-чор төсмерләрен тоюдан мәхрүм ителгән «күрә караучы», ягъни күз алдындагы проблемаларны да абайлый алмаучы шагыйрьләр шушындый җирлектә туа. Шагыйрь өчен, «дальтоник» булуга караганда, «күрә карау» чире белән авыру хәтәррәк, безнеңчә.

Була икенче төрле шагыйрьләр — алар чынбарлыкны бөтенләй башкача, үзләренчә, әмма бөтен тулылыгында, каршылыклар бердәмлегендә кабул итәләр; андыйларның һәр әсәре, үзенчәлекле аһәңгә ия булу өстенә, тегеләйме-болаймы, алдагы иҗат үрнәкләре белән органик тоташалар, төп идея-мотивларны үстерә төшәләр, аңа яңа төсмерләр өстиләр. Шул рәвешле һәр шигырь аерым ояда гомер кичерсә дә, ахыр чиктә композицион яктан гомуми бер кәрәзгә берләшә һәм шушы нигездә, безнеңчә, шагыйрьнең Шигъри дөньясы барлыкка килә.

Болай дигәндә, танылган литва шагыйре Эдуардас Межелайтисның мәгълүм сүзләре хәтергә килә. «Әдип үз дөньясын тудырырга тиеш, — дигән иде ул. — Бу бер дә реаль чынбарлыктан

качу дигән сүз түгел. Киресенчә, анда башкалар күрмәгәнне күрә белү һәм чагылдыра алу дигән сүз. Шагыйрь өчен үз иҗат омтылышларыңның дөреслегенә фанатикларча ышанудан да әһәмиятлерәк нәрсә юк. Алай булмаса, берни дә барып чыкмаячак. Үз идеяләренә инанмаган яки үз идеяләре бөтенләй дә булмаган әһле шагыйрьләр кеше таптап, изеп бетергән урам ташларына охшап калалар».
Равил Фәйзуллин исә, нәкъ менә шагыйрь әйткәнчә, «үз иҗат омтылышларының дөреслегенә фанатикларча ышанып» яшәде. Әйе, ул — татар шигъриятендә беркемнекенә дә охшамаган үз дөньясын тудырган, тудыра алган бәхетле шагыйрь. Бу дөньяның Күге — биек, тирән; Күленең суы — чиста, тонык; төсләр спектры — бизәкле, бай; нигез ташлары — ныклы, тотрыклы. Хәзер без моны Олы Иҗат биеклегеннән карап, утыз биш еллык иҗади үткәннәргә бәя биреп әйтәбез һәм аны табигый бер нәрсә, тормыш тарафыннан расланган, алдан ук тәкъдир тактасына язып куелган билгеле язмыш итеп кабул итәбез. Хәлбуки, берәүнең дә гомер юлы энҗе-асылташтан гына түшәлмәгәнен аңлаган хәлдә, шуны да икърар итик: безне болай уйларга озак еллар буена шагыйрь үзе күнектереп килде түгелме соң? Яшәү рәвеше, әдәбиятта яулаган биеклекләре, иҗаттагы һәм көндәлек тормыштагы тынгысызлыгы, яши белүе һәм яшәүне ярата белүе белән күнектерде бугай ул безне моңа. Хәзерге исән шагыйрьләрдән, һәрхәлдә, илле бусагасына аяк баскан иҗат әһелләреннән үзен-үзе кабаттан тудыру, формалаштыру, үстерү өчен, — ягъни, ахыр чиктә, олуг максатына ирешү, шагыйрьлеген һәрдаим һәм һәркайда исбатлап тору, исем-имиджының сафлыгын саклау һәм аклау өчен Равил Фәйзуллиннан да газаплырак рухи эзләнүләр алып барган, ихтыяри һәм физик җегәр сарыф иткән, шул ук вакытта өлгерлек һәм зирәклек күрсәткән башка берәүне хәтерләмим мин. Әйе, әйе, ул хәтәр борылмаларны кирәгенчә, үз вакытында әйләнеп үтә белде, кайчак гел кирәкмәгән урында компромисска да баргалады бугай, эндәшергә-чаң сугарга кирәк чагында юл читендә калган чаклары да булмады түгел, әмма ул хәрәм уеннарда катнашмады, кеше язмышы белән уйнамады. Кыскасы, ул үз эшен белде — әдәбиятка җиңүче булып килеп керде, тикшеренүче-эзләнүче булып, иманын раслап яшәде һәм яши. Гомумән, ул — актив тормыш алып бара торган, һәр яңалыкка һәвәс, мавыгучан шәхес. Бәлки, шуңадыр ул, текә генә басып йөрүче, үтә дә сак кайбер агайлардан аермалы буларак, вакыты-вакыты белән (тегеләр күзлегеннән караганда, әлбәттә) малайчарак адымнар да ясап куйгалый. Әнә ул бервакыт ерак араларга йөзү белән мавыгып китте, хәтта берме-икеме тапкыр, мөмкинлекләрен сынап карау өчен, Компрессорныйның күпереннән Киров дамбасына кадәр, ун чакрымлап арага үзенә-үзе йөзү ярышы да оештырды. Билгеле, тамашачысыз нинди ярыш инде ул — һәм билдән югары суга керергә дә чирканып торган шагыйрьләр, әдәбият-сәнгать әһелләре, аны, көймәләргә төялеп, һау-һаулап финишка кадәр озата бардылар. Шулай, җәй җитсә, Равил Фәйзуллин, бер генә сәгать буш вакыты булса да, су буена төшеп китә, теннис уйный, кышын исә ачы буранда да чаңгы юлыннан кайтып керми. Әйе, ул «вакыт эчендәге вакытны» таба белә.

Яшәү — кыска. Аҗагандай!
Үтә гомер цейтнотта!

Бөтен өмет, бөтен ышаныч —
Үзем өчен үзем генә белгән
Вакыт эчендәге Вакытта!

Дөрес, читтән караганда, Равил Фәйзуллин су өстендәге күбектәй тормышта җәй гына тирбәлеп яшәде кебек, ләкин аның «су төбенә» китеп торган чаклары да булмады түгел (озын сәфәргә бергә чыккан дусларны югалтулар, сөйгәнең белән ара салкынаюлар, «җаваплы эштән» үз теләгең белән китеп торып, хөрлеккә омтылулар — азмы алар каныңа тоз салып торырдай хатирәләр кеше күңелендә!). Ләкин:

Суыр көн дә коллыгыңны!
Җаныңнан чыгар чөйләп!
Иреген тоеп суласаң,
исемең — Кеше димәк.

Менә шулай, үзенең «кыен» хәлен дә шагыйрь файдага әйләндерә белде — асылда, ул, гавам күзеннән югалып торып, акыл туплап ятты, йомшак кәнәфидән сикереп төште дә, «диңгез төбе гауваслары» арасына чумып, энҗе-мәрҗән эзләде һәм эшләде дә эшләде...

Сәясәттән ераклашкан саен —
Табигатькә ныграк елышам.

...Тәгәрәде кызыл кыргый алма
Елан үтеп киткән юл аша.

Дөрес, мондый адымнар ясау шагыйрьдән күпмедер күләмдә егетлек һәм фидакарьлек тә таләп иткәндер. Шулай икән, бу инде аз түгел. Шагыйрьнең ике томлыгы басылып чыгу моның ачык дәлиле булса кирәк. (Җәяләр эчендә генә әйтеп үтик, үзе исән чагында ике томлык шигырьләр җыентыгын Сибгат ага Хәким генә чыгара алган иде.) «Эш агачы юмарт китерер җимеш» дигәндәй, икенче томның корректурасын укып тапшыргач, ул: «Ярый әле үз вакытында бераз эшләнеп калынган», — дигән иде рухи бер канәгатьләнү белән. Тирәнтен ышанып әйтергә мөмкин, Равил Фәйзуллин яшәеш-тормышның бик тә гади, әмма бик тә авыр бер канунын үзләштергән шәхес булырга тиеш. Кеше булу ул барыннан да элек, Кеше булып калу өчен туктаусыз көрәш алып бару дигән сүз. Бу табигый халәт түгел, шуңа да шәхес булу ул өзлексез эзләнү, үсештә генә иҗат ителә ала һәм, алда әйткәнемчә, бик күп көч сарыф итүне таләп итә. Кызык, Равил Фәйзуллин яшь иҗат әһелләре, сәләтле егетләр белән аралашып-дуслашып яши. Бу, бер яктан, яшьлектә калырга тырышу кебек табигый бер халәт булып аңлашылса, икенче яктан, яңа буыннарның уй-теләкләрен, идеал-омтылышларын тоеп-күзәтеп яшәү дип бәяләнергә тиештер, мөгаен. Ә, бәлкем, шигъри балачактан, шигъриятнең мәңге дә яшь, мәңге дә яшел, хәрәмсез иленнән аерылырга теләмәүдер бу? Ни генә булмасын:

Бүтәннәр юри уйныйлар,
Мин, юләр, чынлап уйныйм.
Ихлас ышанып уйныйм.
Барсын беләсе килә.
Кайчак көләсе килә.
Уендашлар шаркылдыйлар,
Миңа күз яше килә.

Шушы хакыйкатьне истә тотып микән, Равил Фәйзуллин, гадәттә, үзеннән яшьрәкләр белән күрешкәндә, күзгә карап:
— Исәнме, егет? — дип эндәшергә ярата.
Бу сүзләргә ул, миңа калса, гадәти исәнлек-саулык сорашудан бигрәк, фәлсәфи-этик мәгънә төсмере сала кебек: «Ир-егетме син, янәсе».
Чынлап та, ир-егетме син? Ир-егетләрме без?
Моңа һәркем намусы каршында үзенчә җавап бирер, әлбәттә, ләкин «ир-егет»лек көннән-көн ныграк девальвацияләнә барган бер мәлдә, ил-халык язмышы турында уйланып кына калмыйча, гамәли эш күрсәтү аеруча актуаль зарурият булып күз алдына килеп баскан бер чорда, бу гыйбарә һәркем өчен риторик сорау булудан битәр, иман-кыйблага юл күрсәтүче маяк хезмәтен үтәргә тиештер.
Равил Фәйзуллинга килсәк, аның алдында мондый дилемма тормады кебек. Ул — шәхси омтылышларында гына түгел, социаль яктан да үтә дә актив шәхес; әйе, үзен дә онытмаган хәлдә, ул шигырьләре белән һәрдаим туган халкына хезмәт итеп килде, иманына тугры булып калды. Аның көче дә, бәхете дә шунда, шушы ике башлангычны — ике өйрәтелмәгән тайны — бер мичәүгә җигә алуында. Шигырьләре һәм иҗтимагый эшчәнлеге — моның ачык мисалы. Ә шагыйрьнең эчке җанын аңламый торып, иҗатын аңлау мөмкин түгел.
*** * ***

Равил Фәйзуллин — шагыйрь буларак та, кеше буларак та иртә җитлеккән шәхес. Тормышта балалык, иҗатында өйрәнчеклек чоры булды микән аның? Шикләнәм. Чөнки ул егерме яшендә хәзерге илле яшьлек Фәйзуллиннан җитдирәк, хәтта прагматиграк булып тоела миңа. Ул — үргә каршы аккан агымсу кебек; кешеләр, гадәттә, үткәннәрдән киләчәккә — яшьлектән картлыкка таба үтеп баралар, ә ул, киресенчә, киләчәктән үткәннәргә — картлыктан яшьлеккә таба хәрәкәт итә сыман. Аңлата алдым микән, һәрхәлдә, илле яшендә ул, тыштан караганда, егерме яшендәгедән яшьрәк, хыялыйрак, җилбәзәгрәк сыман.

Алай үтелгән Вакыт...
Болай үтелгән Вакыт...
Яшәп үтелгән Вакыт...
Яшьнәп үтелгән Вакыт —
Бүтәннәр бәхете өчен
сарыф ителгән Вакыт!

Гайре табигый түгелмени: унбиш яшьлек малай шагыйрь, ата-ана оясыннан чыгып борын асты кибәргә дә өлгермәгән үсмер, үткән гомерләр турында уйлана?! Юк, гайре табигый түгел! Чөнки бу «үткән гомер». Үткәнгә түгел, ә бәлки, программ идея-максат сыйфатында Киләчәккә төбәлгән... Искә төшерик әле: йә, кайсыбыз соң көннәрдән бер көнне, үсмер чакларда, һичбер сәбәпсез моңсу гына ерак кырлар түренә күз текәп, киләчәкнең гүзәл сарай-атауларын

күңелебездә торгызмады икән дә, яшәүнең асыл мәгънәсе турында уйланып бер генә мизгелгә олыгаеп алмады икән? Равил Фәйзуллин кебек уйланучан һәм күзәтүчән сизгер күңелле җан ияләрендә бу тойгы, мөгаен, аеруча иртә уяна торгандыр... Уяна торгандыр да мәңге сүнмәслек гамь-учакка әвереләдер! Чөнки:

«Сөям» дип сөйрәлә сөйрәлчек,
«Килдем» дип кинәнә килмешәк.
Тапмаслык таралган туганнар.
Үзәккә үткәзеп бар үтен
Үтә Вакыт...

Аның иҗатында Вакыт төшенчәсенең тоташ бер агым булып кабатланып килүен, шагыйрьнең әледән-әле Яшәү турында гасабилы тойгы-кичерешләргә бирелеп алуын шуның белән генә аңлатырга мөмкин. Әйе, «кошлар оча-оча югала» шул:

Менгән саен, күтәрелгән саен
ачыла һаман — офык-киңлекләр!..
Ә күзләрне
әкеренләп
томан сара.
Кими бара —
җетелекләр,
үткенлекләр,
мөмкинлекләр...

Ә күзәтүчән дигәннән, Гете мең мәртәбә хаклы: «Хәят шулкадәрле киң һәм бай, тормыш шулкадәрле күп бизәкле ки, шуңа да шигърият бервакытта да сюжетка кытлык кичермәячәк. Әйдә, шигърият чынбарлыкны өйрәнергә тиеш түгел дип юкка сафсата сатмасыннар; шагыйрьнең таланты гап-гади күренешнең нинди дә булса кызыклы ягын тасвирлый белүендә ачыла да инде».
Равил Фәйзуллин исә беренче иҗат тәҗрибәләреннән ук үзен нәкъ менә чынбарлыкның кеше күзенә бер дә ташланмаган якларын (Айның «караңгы» ягын) күрә алучы шагыйрь-рәссам итеп танытты, аның шигърияте шуның белән кызыклы да инде. Менә аның унҗиде яшендә язган бер шигыре:

Кара карга оясы —
ап-ак кар бүрке.
Яшел чыршы ышыгында
кызыл төлке.

Беренче карашка биредә искитәрлек бернәрсә дә юк кебек: нәрсә, гадәти бер кышкы урман күренеше тасвирланган инде, дияргә дә мөмкин булыр иде, ләкин соңгы юлны укуга барысы да үз урынына баса — төсләр антитезасына корылган сурәт (яшел чыршы ышыгында уттай кызыл төлкенең чагылып китүе) изрәп яткан урманны кинәт гөлт итеп кабызып җибәрә дә күңелләрне сагаерга мәҗбүр итә: чү, бөтен очракта да идиллиягә ышанып бетәргә ярый микән соң әле?
Дөрес, шагыйрьнең кош теле хәтле генә бу шигырендә гомумиләштерүләр, анализ, нәтиҗә чыгару кебек шигъри атрибутлар да юк (алары киләчәктә булыр), ләкин иҗатының башлангыч чорында ук ул бер деталь, образ ассоциациясе аша да гомумкешелек алдында торган проблемалар киңлегенә чыгарга сәләтле сүз остасы икәнлеген сиздереп куйды. 1962 елда иҗат ителгән «Кадак» шигыре аның шушы юнәлештә эзләнүләренең беренче өлгесе булды дисәк тә хата булмастыр, мөгаен. Әйе, дөнья бер кадактан тора, ул югалдымы, тормышның рәте-чираты китә: әнә тимерчелектә кадак булмау сәбәпле дага төшеп калган, дагасыз атның аягы сынган; ат баралмагач, командир яраланган; командир үлгәч, солдатлар качкан; солдатлар качкач, халкы кырылган... Дөрес, бу образ, композицион алым аңа инглиз халык иҗатыннан күчкән, әмма Равил Фәйзуллин, дөньяны танып белүгә сусаган, тынгысыз җанлы шагыйрь буларак, бер тапкан ачкычны югалтмый инде, аны кирәк булган саен яңадан-яңа конструкцияләрдә куллана килә. Бу яктан «Яңгыр» шигыре аеруча гыйбрәтле.
Дөньяга хәвеф килгән: коргаксыган Җир яңгыр көтеп ята, гөлләр көтә, Кеше көтә аны, һәм тәннәр чымырдап китә — хәтта кырда чалкан яткан тырма да, тимер бармакларын сузып, зарыгып яңгыр көтә икән бит. Ләкин «яңгыр» һәркемгә дә тигез яумый ул: «болыт күл өстенә килеп койды орып, койды оеп... Кырда эсселектән кызган тимер тырма күккә табынып кулларын сузып калды...» Җитәр, «яңгырсызлык» афәтен — бәлки, рухи яңгырсызлыктыр ул! — моннан да үтемлерәк итеп әйтеп бирү мөмкин түгелдер, тырма тешләре бәгырьләргә үтеп керде ләбаса.
Деталь аша — гомумиләштерүгә! Җитмешенче еллар башында шагыйрь, тормышның кайсы гына почмагына күз салса да, шушы девизга тугрылыклы булып кала. Ул татар шигъриятенә

моңарчы әдәби кулланылышта булмаган, хәтта, әйтергә мөмкин, башка да сыймаслык башбаштаклык булып тоелган бик күп сүз-гыйбарәләр һәм деталь-образларны алып керде, башкалар күзе күрмәгән тормыш күренешләрен шигъриятнең өйрәнү объектына әверелдерде. Ләкин хыял канатларында, тормышны чиксез ярату җирлегендә туган мондый лирик детальнең фотографик, натуралистик, «тормышчан» деталь белән бернинди дә уртаклыгы юк иде, чөнки сискәндергеч өлге табу шагыйрь өчен үзмаксат түгел, ә бәлки һәрдаим үзгәреп торучан чынбарлыкны өйрәнү чарасы иде. Бу нәүбәттән «Метаморфоза» (1963) шигыре аеруча характерлы. Шагыйрь биредә бер деталь, бер кинаяле образ аша тулы бер халык язмышын, ул кичергән трагизмны сурәтли алган. Сарайда аунап яткан иске, тутыккан колун балта образы — ул («түтәсе иңгән — күп сугудан, йөзе тонган — тутыгудан») кулда көч-власть бар вакытта ярты дөньяны тетрәтеп торган («бар иде колунның ялтыраган чагы, — йөзәр яшьлек имәннәрнең калтыраган чагы»), хәзер инде, картайгач, хакыйкать каршында җавап бирер вакыт җиткәч, үлеме белән тартышып ятучы теге еллар (һәм бүгенге көннәр!) героеның — димәк, тулы бер эпоханың — фаҗигале күләгәсе. Ләкин нинди күләгә ул? Тулаем татар халкының фаҗигале язмышымы, әллә Сталин хакимияте җимешеме, йә булмаса бүгенге Рәсәй чынбарлыгымы? Уйла, нәтиҗә яса...

Инкяр итмим, бу төр шигырьләр, бәлки, шагыйрьнең киң колачлы иҗат дөньясында үзәк урынны да алып тормыйлардыр, ләкин нәкъ менә шушы чорда ук (минемчә, шагыйрьнең эволюцион үсешенең беренче этабы 1958–1966 елларга туры килә) шушындый кискен антитезага, контраст буяуларга, образ-метафораларга бай, гуманистик идеяләр белән сугарылган әсәрләрендә шагыйрьнең һәм рухи кыйбласы, һәм форма-өслүб өлкәсендәге эзләнүләре, һәм фәлсәфи инанулары, һәм фикри-җисми ориентирлары һәм, гомумән, ПОЭТИКА турындагы карашлары ачык төсмерләнде кебек.

Схема рәвешендә генә әйтсәк, ул түбәндәгеләрдән гыйбарәт булыр иде. Равил Фәйзуллинның бер төр шигырьләрендә еш кына хисләр фикерне түгел, ә бәлки фикер хисләрне тудыра һәм бу фикер аның җанын шулкадәрле биләп ала ки, алар, ахыр чиктә, аңны яктыртып җибәрерлек хискә әвереләләр. Шагыйрь әледән-әле, тасвирлаудан битәр, сөйләү алымына күчеп куйса да (бу бигрәк тә «Күмәч пешерүчеләр», «Гадиләргә гимн», «Көрәшчеләр» кебек күләмле әсәрләрдә сиземләнә), афористик фикер, көтелмәгән әйләнмәләр укучыны ахырга кадәр киеренкелектә тотарга ярдәм итә. Планетар идеяләр нигез булып яткан бераз салкынчарак әсәрләр белән бергә («Шагыйрь өчен тиран нәрсә ул», «Кояшка атылган ядрәгә», «Парикмахерскаяда», «Төштә»), үтә дә кешелекле, халыкчан-яңача, садә аһәңле «Кер чайкыйлар кызлар», «Аҗаган», «Җилфердәүче керләр җыры», «Башны салларга салып...» кебек әсәрләре дә шушы чорда иҗат ителә. Моның белән без шуны әйтергә телибез: санап киткән әлеге әсәрләрендә шагыйрь, ниһаять, Шигъриятнең алтын баганасы булган образ һәм ул тудырган хис бердәмлегенә — гармоник ассоциациягә ирешә. Мәгълүм ич, әсәрдә Образның үзеннән бигрәк ул тудырган хис-эмоция зуррак әһәмияткә ия. Әгәр хис-эмоция чынлап та илаһи кыйммәткә ия икән, образ да шул ук югарылыкка күтәреләчәк. Шушы берлектә генә хисләр поэтик яктан камил, чиста була ала, чөнки алар, имитация, чагыштырулардан аермалы буларак, күңелнең иң тирән чоңгылларында бөреләнәләр.

Башны салларга салып,
Китәсе иде агып.

Дәшәрләр иде әле дулкыннар
бер шагыйрь җанны танып...

Күренә ки, биредә көтелмәгән чагыштырулар да, искитәрерлек метафора-эпитетлар да юк, ә шигырь тәэсир итә. Аның көче нәрсәдә соң? Образ-сурәт тудырган хисләрнең тасвирый ассоциациясендә: шагыйрь турыдан-туры берни әйтмәсә дә, кинаяле белән генә кеше гомеренең, аның җанының тулы бер сурәтен, фаҗигасен, кичерешләр гаммасын җанландырып бирә алган лабаса. Бу яктан караганда, Равил Фәйзуллинның кыска формаларга бик теләп мөрәҗәгать итүе, алай гына да түгел, аны билгеле бер иҗат принцибына әверелдерүе аеруча тәкъдир ителергә хаклы. Бу төр шигырьләрендә ул үзен чын мәгънәсендә сурәтләр остасы итеп танытты, татар шигъриятенең афористик фикерләү чикләрен киңәйтте. Шул рәвешле шигырь-афоризмнар, шигырь-метафоралар дөньяга килде.

Җил бик тиз актарды әкият китабын...
*(«Балачак»)*

яки:

Кыны тулы кан. Тышында чәчәк сурәте,
*(«Тарих»)*

яки:

Торналар китеп бара.
Кош канатлары орынгач,
Болытларның күңеле тулды, —
*(«Көзге яңгыр»)*

дигән бер, ике, өч юллык шигырьләрне, кем әйтмешли, шәрехләп торуның кирәге юк, һәркем үзенең фантазиясе мөмкинлек биргәнчә фикер йөртсен, нәтиҗә чыгарсын — шагыйрь укучыларын Капу мәйданына чыгарып куя, калган юлларын алар үзләренчә, мөстәкыйль рәвештә дәвам итәргә тиешләр.

Кызык кына килеп чыга түгелме соң: бер яктан, Равил Фәйзуллин (һәрхәлдә, иҗатының башлангыч чорында) сөйләм-санау алымыннан да бөтенләй баш тартмый, икенче яктан, кыскалыкка, «сүзләргә кысан булса да, фикерләр иркенлегенә» омтыла. Ләкин биредә бернинди дә каршылык юк. Бу метаморфозаның нигезендә гади генә бер закончалык ята: Равил Фәйзуллин — катлаулы, «күп сыйдырышлы» шәхес; аның җанында кулга өйрәтелмәгән кыргый аю да, гөл күзенә кунган нәзберек күбәләк тә янәшә яши, ә киң колачлы, беркемнекенә дә охшамаган бай иҗатны шундый затлар гына тудыра ала.

«Ташларны барлар вакыт!» — Равил Фәйзуллинның иҗаттагы төп мәсләге менә шушыннан гыйбарәт иде. Кайбер шагыйрьләребез юл өстендәге шомарып беткән, сайландыктан калган ташларны җыеп йөргән арада, ул, шигърияттә киң колачлы, иркен сулышлы, күптөсле мозаик панносын тудыру өчен, тормышның җил-давылына карамыйча, киртләч-киртләч үткелле мәрмәр кыялар иленә сәфәргә кузгалды.

Җилме син?
Бәр! Бәр!
Бозмы син?
Бәр! Бәр!
Без — Мәрмәр!

Җилкәбездә тоеп, юк, барлык вөҗүдебез белән аңлап яшибез ләса, тиңдәшсез көрәштә арып егылмау өчен, рухи һәм гамәли дошманы каршында тез чүкмәү өчен татар халкыннан, аның шагыйрьләреннән икеләтә ныклык сорала. Ә мәрмәр — беләбез, ныклык, чыдамлылык билгесе ул! Шушы мәгънәдә Равил Фәйзуллин гади генә төшенчәләрне (мәрмәр образы йөздән бере генә) заманның төп билгеләрен тасвирлый алырлык биеклеккә күтәрде... һәм алар белән бергә үзе дә күтәрелде.

* * *

Һәр олы шагыйрьнең иҗатында алтын хәзинәгә тиң бер дәвер була. Равил Фәйзуллин да кичерде андый дәверне. 1969–1972 еллар арасында, аеруча 1971 елда үтә дә рухланып, яшәү шатлыгыннан исереп дигәндәй иҗат итте һәм ул эволюцион үсешендә текә борылыш ясады. Шагыйрьнең үз сүзләре белән әйтсәк, моңарчы аның иҗатында әлегә нindiдер үсмерлек чаткылары сизелә иде: буй җитүгә дә карамастан, «терсәкләр» тырпаебрак торалар, «җилкә-күкрәкләр» дә ир-егетләрнекечә тыгыз, камил мускулга төренеп өлгермәгәннәр. Җитмешенче еллар ахырында исә тулышу чоры төгәлләнде, нәкъ менә шушы чорда аның шигъриятенә тагын бер көчле вә дәртле агым — мәхәббәт лирикасы килеп кушылды. Дөрес, шагыйрь Мәхәббәт турында һәм, гомумән, лирик шигырьләрне элек тә язмады түгел, язды, ләкин алар шул дәвер иҗатының кыйбласын билгеләрлек дәрәҗәдә үзәк урынны алып тормыйлар иде. Ә инде бераздан, «кеше күңеленең моңарчы җырланмаган» бизәкләрен табарга омтыла башлау белән, Равил Фәйзуллин шигырьләрендә лирик башлангыч та көчәя төште. Бу нәүбәттән аның «мәхәббәт эволюциясен» күзәтү шактый гыйбрәтле.

Мәхәббәт дигән изге хис, әлбәттә, билгесез өметләрдән, икеләнү-ашкынулардан башлана инде ул.

Бәлки, син минем җырланмас
иң гүзәл җырымдыр?
Бәлки, син — минем чыгалмас
иң данлы юлымдыр.

Күренә ки, бу әле хиснең үзе түгел, ул якында гына, шагыйрь шул хакта уйлана.

Бу сөю — бөек мәгънә —
бәхетнең үзе икән.
Аңа таба онытылып
гел чап, оч һәм йөз икән.

Ләкин Равил Фәйзуллин салон шагыйре түгел, ул мәхәббәт турында җырлаганда да үзенең

шагыйрь, димәк, фикер иясе икәнлеген онытмый, яшәү аның бөтен күкрәге аша тулып ага. Бу төр шигырьләрнең үзәгендә — Кеше! Ул сөя, сөелә; ул көя, көенә; аның өчен сөю — илаһи сәгадәт.

Янарга да, батарга да риза
эштә, өйдә, идеалларда...
Барыбер килә,
күзләр аша килә олыгаю,
күзләр аша, — авыр аларга...
...Бер бөтерелеп без дә яшәп алдык!
Героинялар көтте урамда.
Онытылып сөйдек, сөелдек бер!
Йә, тагын соң ни бар дөньяда?..

Тора-бара гомуми мотивлар конкретлаша төшә, шуңа бәрабәр рәвештә лирик геройның хыялый сурәте дә ачыклана башлый. Мәхәббәтнең татлы агуын эчкән һәр кешегә хас булганча, ул шатлана, борчыла, газаплана, шаша, ләкин горурлыгын, кешелеклелеген югалтмый, хисләре каршында алдаша белми, «дөресен» сөйли. «Мәхәббәт күзсез була, ди...», «Беренче дә, иң соңгы да түгел...», «Бар күк булган сабырлыгымны...», «Көнләшү ирләр эшеме?..», «Җавап», «Көндезен — кеше күзендә...», «Син — теләп алган сагышым...», «Яшьлегеңне, гомереңне...» һ.б. шундый бик күп шигырьләрдә сөенечле дә, газаплы да мәхәббәткә дан җырлана; аларда кичерешләр реаль эчтәлекле, конкрет сурәтле.

Мәхәббәт күзсез була, ди,
ярату сүзсез була.
...Безнең мең күзле булды,
гайбәтле-сүзле булды.

Тагын бер нәрсәне искәртеп үтик: Равил Фәйзуллинның мәхәббәт лирикасында кичерешләр палитрасы шулкадәр бай ки, аларда баш болытка тигәнче ашкынулар да, өзгәләнү-үпкәләшүләр дә — барсы да, барсы да җитәрлек, ләкин үкенү, гаеп ташлау кебек хөсетле уйлар аның өчен бөтенләй ят нәрсә. Бу — сәгадәтле, рәхмәтле, ихтирамлы сөю. Чөнки:

Син — теләп алган сагышым,
Син — теләп алган ярам.

Гомумән, лирик шигырьләрендә шагыйрьнең хисләре ачык, сагышлы, фаҗигале; ритмик яктан алар ярсулы, тыгыз тәнле, камил, аһәңле. Бәлки, «Аккошлар», «Сагыш», «Элегия», «Тимим күңелемә» кебек шигырьләрнең көйгә салынуы, «миниатюрадагы лирик симфония» булып китүе шуның белән аңлатыладыр да. Ләкин вакытлар узу белән төсләр уңа, чәчәкләр шиңә, «сәгатьләр» югала... мәхәббәт тә уала. Мәхәббәткә рәхмәтле булып калган хәлдә, утыз яшьлек ир-егет «көн уртасында» башкачарак уй-хисләр белән дә яна:

Хәзер эшкә! Онытылып!
Бар ләззәтен тоеп хезмәтнең! Әйтер
Вакыт — асылың турында.
...Җиңел түгел үзеңә лаек булу
Кояш астындагы урыныңда.

* * *

Җәмгыятьтә шагыйрьнең урыны кайда булырга тиеш? Бу сорауга һәр заман, һәр халык үзенчә җавап бирә, һәр шагыйрь үзенчә җавап эзли һәм аңа иң кыска туры юлны табарга омтыла. Берәүләрнең, әйтик, шагыйрьләрне гел яу кырында, көрәшнең алгы сафында, баррикадаларда, митинг-трибуналарда күрәсе килә. Икенче төрле караш та бар (бу очракта Зөлфәт белән килешми мөмкин түгел).
«Орышка керер алдыннан бер бөек хан мондый фәрман бирә торган булган:
— Шагыйрьләрне һәм ишәкләрне уртада калдырыгыз! Алар сугыштан соң кирәк булачак!» («Татарстан», 1993, № 10).
Яшьрәк чагында, планетар идеяләрне байрак итеп күтәреп, риторик чаралар ярдәмендә гуманизм өчен көрәш алып барган дәверендә, Равил Фәйзуллин да беренче караштарак торды - бугай:

Бөтен
планета
буйлап
вакансия!
Көрәшчеләр кирәк!

Әйе, шагыйрь әле яшь иде, уй-хыялларында — максималист, хис-кичерешләрендә ярсу-самими иде. Җитмәсә, дөньяда яңарыш бара — тираннар бәреп төшерелә, колонияләр иркен сулыш ала, империяләр җимерелә. Мондый эволюцион үзгәрешләр поэзиягә дә йогынты ясамый калмый, әлбәттә. Яшьләрнең яңа кыйтгалар ачкан вакыты бу.
Аңлашылса кирәк, Равил Фәйзуллинның — яшь буын татар шагыйрьләре лидерының — үз урынын мәйданнарда күрүе, яшәүнең асыл мәгънәсен, Җәмгыять һәм Шәхес арасындагы мөнәсәбәтләрне тасвирый чаралар ярдәмендә бөтен катлаулылыгында сурәтлисе урынга, беркавым оран салу, чакыру-өндәү, үзе язганча, «гимн җырлау» белән мавыгып алуы бер дә гаҗәп түгел иде. Аннары, «президент булырлык ат караучыларга, философ каравылчыларга, полководец күмәч пешерүчеләргә, мәгърифәтче кер юучыларга» «авазлардан үлмәс һәйкәл, таштан — җыр» кую, никадәрле генә гуманистик акт булып яңгырамасын, «иң кешелекле» тоталитар режимның, күзгә төтен җибәреп, аңнарны томалаган чагында ук шагыйранә сүзгә үтә дә сизгер һәм таләпчән укучылар тарафыннан (шагыйрьнең новаторлыгын һәм осталыгын һич тә инкяр итмәгән хәлдә!) «изге теләк», бер мавыгу буларак кына кабул ителделәр. Шул ук вакытта шагыйрь иҗатында кешелекле, сәламәт рухлы, тирән, көчле агымны күрми калу мөмкин түгел иде. Чын шагыйрь дилетанттан шул ягы белән аерыла да инде: ул тормышны төрле ноктадан торып күзәтә, ул бер генә халәттә яши алмый, аңа «тоннель комплексы» хас түгел. «Дөнья буйлап киләм. Байлыгым, тәҗрибәм юк, риям, мәкерем юк, тик гаҗәпләнә беләм!» (1966) дигән шагыйрь икенче бер урында, язучылык миссиясе турында уйланып, менә болайрак фикер йөртә (1968):

Үлеп күрсәттеләр безнекеләр!
Гомерләре булды, һай, кыска.
Ә бит үлеп үлемсезлек яулау —
Бердәнбер юл түгел тормышта...

Дөрес, бердәнбер юл түгел! Шагыйрьнең үлемсезлеге — шигырьләрендә. Шигырьләрендә «үлә алса» гына, аңа бөтен җанын бирә алса гына шагыйрьнең иҗаты ышандыра, тылсымлый һәм үзе артыннан гавамны ияртеп барырлык көчкә әйләнә. Равил Фәйзуллин белән дә шулайрак булды. Күп кенә шагыйрьләрдән озак еллар буена аның йогынтысыннан котыла алмыйча азапланыуы хакында ишеткәнем бар. Бер шагыйрь хәтта болайрак дип тә шаярткан иде: «Безне чытырманлыкка алып кереп адаштырды да, үзе аннан тиз генә чыгып качты». Монда, күрәсең, бер нәрсәне искәртеп үтәргә кирәктер: Шигърият Равил Фәйзуллин өчен сүз уйнату яки акыл сату чарасы гына түгел, ул шигырьләрендә үзенең эчке рухи халәтен аңларга һәм аның тышкы дөнья белән бәйләнешләрен ачыкларга омтылып газаплана, шушы өзлексез борчу аны дөньяны энә күзеннән дә, телескоп аша да өйрәнергә этәрә. Әгәр, чынлап та, шигырьләрендә үлеп терелә алган кеше генә шагыйрь икән, димәк, Туудан Соңгы чиккә кадәр сузылган мистик юлын алдашмыйча сөйләп бирә алу гына — ПОЭЗИЯ. Поль Элюар сүзләре белән әйтсәк, «без беләбез, поэтик даһи шагыйрь алдашмаган очракта гына туарга мөмкин. Ә алдашмау ул — менә бүген хәрәкәт итү дигән сүз. Шигърият йогынты ясау чарасы, алга хәрәкәт итү чарасы булырга тиеш, чөнки ул бөтен ачык тәрәзәләр аша һәм һәр дүрт тарафка таратып хакыйкатькә мәдхия укый, вөҗданга дан җырлый, ялганга нәгърә ора».
Бу нәүбәттән Равил Фәйзуллин иҗаты аерым өйрәнүгә лаек: аның шигырьләре шулхәтле автобиографик ки, шагыйрь белән бөтенләй таныш түгел кеше дә, аларны укып, авторның холык-фигылен, дөньяга карашын, кичерешләр гаммасын тәгаен ачыклый алган булыр иде. Равил Фәйзуллинның лирик герое каршылыклы, күпкырлы, катлаулы характерга ия; ләкин ул нинди генә шартларда да горур, ихлас, уйчан, борчулы, эзләнүчән һәм «зәмһәрир кыш уртасында яланаяк басып торам» дигән «сабый» да. Ә бит, әйткәнебезчә, шунысы мәгълүм: катлаулы шәхесләр генә катлаулы, димәк, сәнгатьчә камил әсәрләр тудыруга сәләтлеләр. Дин — гавамга, шигырь шәхескә төбәлгән, диләр. Әгәр шулай икән, бу тулысынча Равил Фәйзуллин иҗатына да карый: шагыйрь, аеруча җитмешенче еллар ахырыннан башлап, иң гавами дип аталырлык шигырьләрендә дә барыбер нинди дә булса шәхесне күз алдында тота; аның «тыңлаучысы»... шагыйрь үзе дә булырга мөмкин. Темадан темага, бер алымнан икенчесенә шагыйрь иркен күчә, ләкин һәр әсәрнең диярлек үзәгендә гамьле шәхес тора.
Менә болар барысы бергә, Шагыйрьнең һәм Шигырьнең миссиясе бозылып аңлатылган һәм бозылып аңлашылган «ябык ишекләр» дәверендә Равил Фәйзуллинны күп кенә бәлаләрдән коткарып калды да инде. Шигырьләре аша ул икейөзлелеккә, битарафлыкка, маңкортлыкка каршы көрәш уты ачты.
Күз алдында булды ич, шигъриятькә бөтенләй ят функцияләр йөкләнде, ул идеологик сугыш

коралына әверелде. Шигырьләр имгәтелде, шагыйрьләр гариплләтелде. Мондый хирургик операциянең нәтиҗәсе дә озак көттермәде: ничә гасырлар дәвамында зинданга ябылып тотылган мәхбүс хәлендә яшәгәндә дә исән калган татар шигърияте соңгы җитмеш биш ел эчендә нинди генә хурлыклар кичермәде, еш кына шагыйрьләр башка тавыш белән җырларга мәҗбүр ителделәр, көнлекчеләр исә идеология ялчысына әйләнделәр.

Җырчы шагыйрьләр аз яши.
Тираннар — озак.

Шулай итеп, әдәбият сәхнәсенә, асылда, үсешне тоткарлый торган «гражданлык», «солдат», «эшче» поэзиясе дигән төшенчәләр күтәрелде. Билгеле, монда терминнарның бер гаебе дә юк, ләкин хикмәт шунда: күз буяучылар, һөнәрчеләр шушы терминнарны калкан итеп, Шигърият дигән асыл затның канын суырып яттылар; идеологик басым көчәйгән саен, ясалма рәвештә үстерелгән әрекмән астында черек мәшкәләр дә күбәйделәр.
Хәзер язучылар арасында: «Мин теге елларда Ленин турында, партия турында язмадым», — дигән сүзләрне ишетергә туры килгәли. Бу нәрсә, тагын икейөзлеләнү, кылган эшләреңнән, кичәге көнеңнән куркакларча ваз кичүме? Андый акланучыларга Равил Фәйзуллинның моннан чирек гасыр элек әйткән сүзләрен исләренә төшерәсем килә, бәлки, сабак булыр.

Җаныңныңваклыгын
Сылтама заманга.
Куркырга, өркергә
Җай бар ул һаман да.
Асылыңны яшереп,
Кыланма ни генә, —
Буыннар хәтерендә
Бары да чигелә.

Фикеребезне дәвам итик. Бервакыт татар әдәбиятында «нефть» темасы белән мавыгып алу, хәтта, әйтергә мөмкин, мактанышу модага кергән иде: без нинди бай, бездә фәлән хәтле «кара алтын» чыга, янәсе. Дөрес, бу темага Равил Фәйзуллин да язды, ләкин ничек язды!

Артык данлыйсың түгелме
Илнең гади каласын?
Тәнендә ул як җирләрнең
Кырык меңләп ярасы.

Менә шулай, шагыйрь очсызлы коткыларга бирелмәскә, узгынчы темалардан, идеологик хорафатлардан өстен торырга тиеш. Вакытны узып алдан күрә белү, мәсьәлә-проблеманың асылына төшенү — аның изге миссиясе! Равил Фәйзуллинның бу яктан хафаланырлыгы юк: аның намусы чиста, күңеле пакь. Вакланмауның үз өстенлеге бар шул, соңыннан акланып торасы булмый.
Бүген илдә сәяси атмосфера башкачарак. Халык, бер таңда уянып, урам-мәйданнарга чыкты, аның теле чишелде. Шушы шартларда шигырь, лозунг вазифаларын үтәүдән азат ителеп, үз ярларына кайтып төшәргә тиеш иде кебек. Чөнки шигырь эстетик категорияләр белән эш итә, шуңа күрә дә ул, сөңге яки ук очына манылган зәһәр агу булудан битәр, агукайтаргыч булып тора. Һәрхәлдә, шулай булырга тиеш.
Кем ничектер, кайбер шигъри митинглардан мин икеләнүле хисләр белән кайтып китәм. Андый җирләрдә, гадәттә, сөңгесе агуга манылган яңгыравык-купшы, ярым әдәби, ярым сәяси шигырьләр укыла. Юк, шигъриятнең милли аңны тәрбияләүдәге, үстерүдәге ролен һич тә киметергә теләмим мин, киресенчә, шигърият ул халыкның рухи көзгесе булырга тиеш. Ләкин әдәбият хәзинәләрен кысрыклап, терсәк белән төрткәләп алгы рәтләргә, трибуналарга һөнәрче-кәсепчеләр үрмәләвен күрә торып дәшми калыргамы? Һәм моңа каршы ничек көрәшергә? Утка каршы ут ягыпмы? «Борынгылар тын гына эшләп-язып яткан шагыйрьләрне бала табарга җыенган Ананы саклаган кебек саклаганнар... Ниһаять, бала тудыргандагы газаплар белән шигырь дөньяга килә. Әгәр шагыйрь шигырь туганда сәнгатьнең табигатенә хас булмаган уй-ниятләр коткысына бирелмәсә, мең рәхмәтләр яусын аңа». Ә бездә киресенчә: кемнең тавышы калынрак, шул яд ителә.

Аһ, тау юклыклар!
Кыя юклыклар!
Күз тегәмә кая —
үзән, калкулыклар.

Заман җилләре исеп, тарих комнары күчә барган саен кемнең чынлап та «тау», кемнең «калкулык» икәнлеге тәгаен ачыкланыр, шәт. «Калкулыклар»ны ком күмеп китәр, «таулар»ның исә нигезләре ачыла барыр һәм алар тарих тирәнлегеннән тагын да биегрәк булып калкып

чыгарлар.
Ышанам, Равил Фәйзуллинны бөркетләр оялаган таулар язмышы көтә булыр...
*Казан утлары, май-июнь, 1993*

**ҖӘЯҮЛЕ КҮБӘЛӘК**

Шигырь ялкыны кайчак очраклы бер очкыннан кабынып киткән кебек, шагыйрь җанын аңлау өчен дә ул тудырган берәр образның мәгънәсенә төшенү җитә икән. Роберт Әхмәтҗанов турында бер-ике сүз әйтим дип кулыма каләм алгач та, дөресрәге, сүземне нидән башлыйм дип аптырап утырганда, кылт итеп исемә килеп төште: «Җәяүле күбәләк». «Шигырь китапханәсе» сериясендә басылып чыккан китабына шулай дип исем кушкан иде бит ул!
Җәяүле күбәләк!..
Роберт Әхмәтҗановның күңел дөньясын, аның иҗади принципларын, рухи эзләнүләрен, эстетик карашларын, ахыр чиктә, поэтик идеалларын шушы метафорик образдан да төгәлрәк әйтеп бирергә мөмкинме соң? Дөрес, аны күпләр җилбәзәклектә гаепләргә ашыктылар, әмма бу тыштан караганда гына «дөрес» бәяләмә. Асылда исә ул бөтен җаны, омтылыш-ышанычлары, бөтен вөҗүде белән шагыйрь; өрфия күбәләктәй самими, сабый җанны нишләтәсең инде аны...
Ләкин онытмыйк: көндәлек ваклык-интригалар бәрелешендә баштан ук җиңелергә дучар ителгән шушы күбәләк җанга — Җәяүле күбәләккә — табигать үзе үк тулаем сыя ала, чөнки аның җаны шигырьдән тора. Ул — үзе бер шигъри дәүләт!

Ятам ярда. Тыныч дәүләт сыман.
Баш очымда шаулый тупыллар.
Баш очымда Идел әкият сөйли.
Йөрәгемне юа дулкыннар.

Якты. Тыныч. Иркен. Әйтерсең лә
Дөньяның бу кыл бер уртасы.
Кочагыңа ал да эрет мине,
Җил һәм Кояш Республикасы.

Кеше — Җәяүле күбәләк!..
Бу хакта ул үзе болай ди:
— Эзләнүләр — Иҗатның гомерлек юлдашы. Мин әлеге шигырьләр китабын «Җәяүле күбәләк» дип исемләдем. Ни эзли соң ул җәяүле күбәләк? Нәрсә хакында сөйли ул безгә?
Туган җирне, газиз табигатьне кошлар юлыннан карасаң, тагын да якынрак, сагынулар яңа мәгънә ала: туган җирнең гади күбәләге дә бөек киңлекләр аша, җил-давылларны җиңеп, туган төбәкләргә ашкынып, җилфердәп кайта икән.
Бервакытны миңа яшел киңлекләр, Идел өстеннән җилфер-җилфер очкан күбәләкләрне иллюминатор аша күрергә туры килде. Кайларга оча, кайларга кайта алар шулай? Беркадәр мистик Җәяүле күбәләк образы Мәхәббәт, Табигатькә һәм кешеләр язмышына багышланган шигырьләрдә безнең уртак юлдашыбыз булса икән!
Шикләнми әйтергә мөмкин: Роберт Әхмәтҗановның шигырьләре күпләр өчен юлдаш булды. Чөнки ул гомере буе Матурлык турында җырлап килде. Ә матурлык кешелекнең аерылмас юлдашы инде ул. Йә, уйлап карасаң, исәннәрдән күпме татар шагыйре үзенең иҗатында, Туган як турында («Каенстан! Урман башыннан ук күренәсең — йөрәгемә матур утырган! Әнә синең яңгыр басмаларың — минем Нотр-Дам»), «дөрләп янган усаклар», «күгәрчен очынып туймас көн», «орчык җыры», киңлек буйлап очучы пәрәвезләр («шундый көз бу, шундый киңлек бүген, — пәрәвезләр оча әдрәнгә») хакында, гомумән безне чолгап алган тирәлек, туган җир, Табигать хакында Роберт Әхмәтҗанов кебек үзенчәлекле итеп, дәртләнеп, очынып, талпынып, ихлас күңелдән, күтәренке рух белән кем җырлый алды икән?
Андыйлар бармак белән генә санарлык.
Ул — күбәләк, ә без — җир кешеләре. Биектәнрәк оча шул ул. Бәлки, шуңа да аны «күреп», зурлыгын бәяләп җиткерә алмыйбыздыр? Шагыйрьгә бүген 60 түгел, 6 гына яшь тулгандыр кебек. Мөгаен, нәкъ менә шушы холык-фигыле, сабыйлыгы өчен дә санлап бетермибездер. Шигырьдә шоңкар булып та, тормышта Җәяүле күбәләк булганы өчен...
Шулай дидем дә, «Вокруг света» журналында бер натуралистның (фәнни телдә күбәләкләрне өйрәнүче, бәлкем, башкача аталадыр, бу очракта анысы әһәмиятле түгел) язмасын искә төшердем. «Моннан күп еллар элек Амазонка бассейнына сирәк очрый торган экзотик (исемен хәтерләмим) күбәләк эзләп (ә ул фәндә бик кыйммәт бәяләнә икән), сәяхәткә чыккан идем, — дип яза ул. — Баксаң, ул безнең урта полосаларда да очрый икән. Берничә ел элек мин шуңа тап булдым».
Әдәбиятта да шушыңа охшашрак вакыйга-хәлләр була. Еш кына «экзотик күбәләкләр» эзләп

ерак-чит киңлекләргә күз атабыз түгелме без? Бәлкем, бу бер яктан дөрестер дә, офыкларны киңәйтү ягыннан. Ләкин, икенче яктан, шундый сорау туа: үзебезнең җирлектәге сирәк очрый торган «күбәләкләр»не вакытында танып алып, «исемле гербарийлар»га теркәп куя беләбезме? Яки фән өчен кыйммәте нульгә тигез булган бер көнлек күбәләкләрне, яза белгәннәре өчен түгел, яши белгәннәре өчен алтын тартмаларда сакламыйбызмы? Сораулар күп, әлбәттә.
Ә шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов — татар шигъриятенең сәер холыклы Җәяүле күбәләге — әдәбият киңлекләрендә бернигә дә карамыйча җилфер-җилфер оча да оча бирә. Очсын гына. Бәлкем, дөнья агышын «иллюминатор»дан күзәтеп торучы «натуралистлар»ның берәрсе аның да барлыгын күреп алыр әле. Татар акылы төштән соң дигәндәй, тик соңга калмаска иде.

*«Казан утлары», апрель, 1995*

## КОЯШЛЫ ТАУГА КҮТӘРЕЛҮ

Сынчы-рәссам Фәһим Фәсхетдиновның остаханәсендә колачка сыймаслык бер мәһабәт имән (әллә нараттанмы соң?) бүкән бар. Күпне күргән, күпне ишеткән, күпләрне «үз күзе» белән танып белгән тарихи бүкән ул. Тарихи, дим, чөнки аның янына еш кына атаклы шәхесләр — Фәһимнең дуслары — рәссамнар, сәнгать белгечләре, галимнәр, язучылар, артистлар һәм, гомумән, остаханә хуҗасын якын иткән кешеләр түгәрәкләнеп җыелып утыралар да эч серләрен сөйлиләр. Сүз, әлбәттә, тормыш-яшәешнең асыл мәгънәсе, әдәбият-сәнгать яңалыклары хакында бара. Кыскасы, әлеге Бүкән — эчкерсез әңгәмәләрнең, кызу-кызу бәхәсләрнең дә, аһ-зарларның да шаһиты ул. Шуңа да аның бу язмага үзәк «персонаж»ның берсе булып кереп китүе гаҗәп тоелмасын.
Шулай бервакыт, Бүкән янында җай гына гәп корып утырганда, арадан берәү:
— Иҗат кешесе ялгызы гына тау түбәсенә күтәрелүче альпинистны хәтерләтә, — дип әйтеп куйган иде.
Без — бүкәндәшләр сагаеп калдык: йә, ни өчен ялгыз альпинист, көттермә, тел төбеңдә ни ятканын аңлатып бир, янәсе.
Әңгәмәдәшебез сүзен болайрак дәвам итте:
— Шуңа ялгыз альпинист дим, Иҗат күмәкләшеп тауга күтәрелүне күтәрә алмый. Бу мөмкин түгел. Безнең кыска гына гомердә дә моңа мисаллар күп булды инде. Бер бәйдәгеләр, иртәме-соңмы, күр дә тор, киеренке ситуация тудымы, страховкасын өзә дә кача. Ә ялгыз альпинист исә нинди тауга күтәреләчәген дә, маршрутын да, кирәк-ярагын да үзе сайлый, үзе хәл итә. Кыскасы, Иҗат — индивидуаль хезмәт ул. Ә инде нинди биеклектәге Тауга күтәрелә аласың, монысы талант һәм бәхет эше. Миңа ышанмасагыз, әнә Фәһимнән сорап карагыз.
Фәһим — ялгыз альпинист?! Үзен сырып алган дус-ишләре булыптамы?
Бу чагыштыруның хаклыгына мин Фәһимнең тормыш юлы һәм иҗаты белән тирәннәнрәк танышкач төшенеп җиттем кебек. Чөнки Фәһим Фәсхетдинов, — нәкъ менә берьялгызы озын һәм хәвефле сәфәргә кузгалган альпинист кебек, һичбер тормыш ваклыкларына бирешмичә, михнәт-авырлыкларга баш имичә түбәннән, авыл клубында рәссам булудан башланган хезмәт юлын дәвам итеп, үр артыннан үрләр, үткел артыннан үткелләр яулаган, хәзер инде сынлы сәнгатьнең «Альп болынлыклары» итәгенә күтәрелеп җиткән шәхес. Әйе, ул «таулар»ны түбәннән күтәрелеп яулады. Фидакарь хезмәте белән. Чын альпинистларча.
Бүкән янында журналист һәм язучы Эльс Гаделнең Фәһим иҗатына багышланган бер язмасын укып чыккач, хәтердә мондыйрак юллар уелып калган. Озынрак булса да, автор рөхсәте белән шуннан бер өзек китереп үтәсем килә. Чөнки биредә, безнеңчә, Фәһимнең холык-фигыле бик тә ачык чагыла кебек.
— Миңа Фәһим белән бу Бүкән артында бик күп тапкырлар киңәш-табыш итешеп утырырга насыйп булды. Исемдә калганнардан бер-ике генә хатирәгә тукталып үтим әле. «Сәнгатькә юлың кайдан башланды», — дигәч: «Озынрак һәм әйләнчегрәк юл булды шул ул», — дип искә ала Фәһим. Мәгълүм булганча, булачак сынчы 1944 елда Апас районының Аюкәйдергән авылында туа. Шулай, язмыштан узмыш юк, ди, һөнәр училищесын тәмамлап, авылга кайткач, аны тракторга утырталар. Уттай урак өсте. Көннәрдән бер көнне, «Сталинец» комбайнын тарттырып йөргән вакытта, тракторы Аюкәйдергән елгасына батып эштән чыккач, «синнән механизатор чыкмас, ахры, клубта эшләп кара әле» дип, мөдир итеп куялар. Хрущев вакыты, коммунизмга барып җитәргә 20 генә ел калып бара. Җан башына йомырка-йон җитештерү буенча АКШны куып җитеп, узып китәбез дип, Фәһим авылдагы бөтен телеграф баганаларын, иске калай кисәкләренә язып, плакатлар белән тутыра.
Армия хәлләре үзе бер кыйссага тиң. Танк батальонында Фәһим — тупчы һәм Ленин бүлмәсендә

— бизәүче-рәссам. Беренче көннәрне үк, дневальный швабра белән Ильич башын сугып төшергәч, тегене каталажкага озаталар, ә Фәһимгә приказ — бер тәүлек эчендә Ленин бюстын җыеп-ямап куярга! Шулай итеп, авыл малае гомерендә беренче тапкыр скульптура һәм гипс белән таныша.
Хезмәте бетеп килгәндә генә, төннәрнең берендә 22 танк янып киткәч, командирларны рәшәткәле машинага утыртып алып китәләр, «старик»ларны янган танклар белән бергә танк ремонтлый торган заводка төяп җибәрәләр. Шул заводта Фәһим тимердән кою серләренә төшенә.
Армиядән кайткач күп җирләрдә каңгырып йөргәннән соң, энекәше Фаризны ияртә дә, Алабуга мәдәният-мәгърифәт училищесына юл тота. Аннары ул — Апас каласының «баш рәссамы». Шунда колхоздан колхозга йөреп, урам-клубларны бизәп яткан көннәрнең берендә Казаннан килгән скульпторлар белән таныша бу: тегеләр сугышта һәлак булганнарга таштан һәйкәл куярга тиешләр икән.
«Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына» дигәндәй, Фәһим моны Алла бүләге дип кабул итә. Асылда бит әле аның бер генә профессиональ сынчы белән дә танышканы булмый, ә күңел шул дөньяга тартыла.
Һәм Фәһим «коллегаларын» инде үзе бизәп бетереп килә торган мәдәният сараена «кунакка» чакыра. Эшләве дә, яшәве дә дигәндәй, шушында Фәһимнең бу көннәрдә: әнә почмакта караваты, әнә электр плитәсе өстендә чәйнеге, ятагында рәсемнәр, эскиз-планшетлары аунап ята. Ә сәхнәдә, яшел сукнолы «президиум» өстәлендә, бүген кунаклар өчен бәйрәм табыны әзерләнеп куелган. Үзенең эшләре белән кунакларны таныштырып чыккач, Фәһим аларны шунда чакыра.
— Ягез әле, — ди Фәһим, — почетлы каравыл астында гына бер сөйләшеп утырыйк әле. Әнә уң ягыбыздан безгә Владимир Ильич, сул ягыбыздан Леонид Ильич карап тора. Мәҗлесебез түгәрәк шикелле...
— Ә болар безгә карамыйлар ич, читкә борылганнар, әнә залга карыйлар, алар халык белән, — дип, бер кунак шунда хихылдап куя.
— Ә без аларны үзебезгә барыбер каратабыз, — ди Фәһим. — Үзебез ясадык, үзебезгә барыбер каратабыз аларны, — ди дә көлеш эчендә сәхнәнең ике канатындагы ике бюстны өстәлгә таба борып куя.
— Тормышта да шулай гына борылсаң иде ул. Торсыннар әйдә торганча, — дип кушылып китә өлкән скульптор. — Алар күзгә карап торганда, нишләптер тамактан ризык узмый, оялта... Куй, Фәһим, урыннарына. Кстати, кем эше алар?
— Үземнеке инде...
— Чынлапмы? Карале, малай... — дип сузып куя кунак. — Яхшы гына эшләр бит болар! Нишләп син монда ятасың әле болай? Әйдә, энекәш, Казанга кил син. Ятма монда. Сәнгать фондына үзем эшкә урнаштырам. Сиңа тирәнрәк чумарга вакыт җиткән. Авыл крәстиянгә калсын. Осталар белән аралашу, тәҗрибә, белем туплау кирәк сиңа. Зур сәнгать ипиен авыз итеп кара әле бер. Аннан үзеңә карарсың...
Ә «зур сәнгать ипиен бер авыз итеп караган» кеше, көнкүрмешендә ачлы-туклы яшәсә яшәр, сайлап алган язмышыннан ваз кичмәс. Фәһим исә шундый фидакарьләрнең берсе. Менә иҗат биографиясеннән кайбер сәхифәләр.
Шулай итеп, 1973 елдан Сәнгать фондының Татарстан иҗади-производство комбинатында эшли башлый, һәм 1974 елдан башлап Бөтенсоюз, республика, «Зур Идел» зональ күргәзмәләрендә катнаша. 1979 елда плакатчы рәссамнарның Бөтенсоюз конкурсы лауреаты. 1980 елда аның «эшләре» Совет — Польша хезмәттәшлеге уңае белән үткәрелгән конкурста катнаша. 1980 һәм 1994 елларда Казан шәһәрендә аның шәхси күргәзмәләре үткәрелде.
Останың осталыгын кимсетү булып яңгырамасын берүк, ләкин Фәһим әйбәт мәгънәдә «эш аты» (эше юкның ашы юк лабаса). Фондта 25 елга якын эшләү дәверендә ул республиканың төрле шәһәр-авылларында театр һәм башка биналарның интерьерларын бизәде. Болары, кем әйтмешли, эш арасында эшләнгән эшләр. Асылда, ул үзенең иман-кыйбласыннан тайпылмады, бер-бер артлы киртләч-киртләч кыяларны үтә-үтә яңа иҗади биеклекләргә үрмәләде.
Тарихилык — бу илаһи кичереш аның җанында һәрдаим сулкылдап торды. Ул Г.Тукай, М.Җәлил, Һ.Такташ, Ф.Кәрим кебек олуг шәхесләребезнең скульптур-портретларын иҗат итте һәм, ниһаять, 1994 елның 15 ноябре килеп җитте.
Республика милли китапханәсенең фойе-заллары, баскыч-коридорлары халык белән шыгрым тулы. Җанлылык. Хәрәкәт. Рухи күтәренкелек. Бүген биредә рәссамның китапханә диварларына куелган сыннарын тәкъдир итү бара. Тарихи мизгел...
Беренче сүз, әлбәттә, татарның төп «китапчысы» академик Әбрар Кәримуллинга бирелә.

— Китапка мәдхия бит бу, егетләр, — дип башлый ул сүзен, гадәтенчә, җан кайнарлыгы белән. — Аңлыйсызмы сез моның тарихи әһәмиятен? Элек без Кол Галинең дә, Сәйф Сараиның да, Курсавиның да төс-кыяфәтләрен күз алдына китерә алмый идек. Фәһим Фәсхетдинов татар әдәбияты вәкилләренең галереясын булдырган лабаса. Минем Молдавиядә булганым бар. Кишинев шәһәренең иң гүзәл бакчасында борынгыдан алып бүгенгә кадәр яшәгән әдипләрнең сыннары тора. Гаҗәп бит... Кешеләр бу сыннар яныннан ничектер бер инсафлык һәм горурлык белән үтеп китәләр. Алла боерса, безнең шәхесләребезнең галереясы да китапханәләрдән урам, бакчаларга чыгар әле. Рәхмәт сиңа, Фәһим туган! Рәхмәт сиңа да, Разил Вәлиев әфәнде!
Шамил Закиров, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры:
— Ташкентта, урамда, бөек үзбәк артистларының сыннар галереясы бар. Ышанам, Фәһим, татар театры каршындагы мәйдан да буш тормас.
Фәрит Якупов, рәссам:
— Бу — фидакарьлек! Ни өчен дигәндә, борынгы бабаларыбызның төс-кыяфәтләре сакланмаганлыгы һәркемгә мәгълүм, ә Фәһимнең сыннары ышандыра. Алар нәкъ менә шулай булгандыр кебек тоела. Тоем — сәнгатьтә зур нәрсә шул ул. Шушы уңайдан минем бер-ике тарихи чагыштыру китереп үтәсем килә. Беренчесе. Илья Репинның Иван Грозныйга багышланган картинасы бар бит әле. Атаклы антрополог Герасимов, Явыз Иванның баш сөяген тикшереп караганнан соң, шундый нәтиҗәгә килә: әйе, ди ул, картинадагы Иван тормышта да нәкъ шулай булган. Икенчесе. Әллә кая ерак китәсе юк. Юбилей уңае белән рәссам Байназар Әльменовка Каюм Насыйриның портретын язарга әмер бирәләр. Яза рәссам һәм әдипне исән чагында күреп белгән кешеләргә портретын күрсәтә, тегеләр исә: әйе, нәкъ үзе, диләр. Шуның кебек, Фәһимнең сыннарын карагач та: нәкъ үзләре кебек, дип әйтәсе килә. Ләкин бу әле башы гына, минемчә.
Нинди сыннар соң алар? Һәм сәнгати яктан нинди әһәмияткә ия булып торалар? Гомумән, Фәһим Фәсхетдиновның иҗаты кай ягы белән үзенчәлекле? Әйдәгез, шушындый сорауга җавап эзләп, сәнгать белгече Розалина Шаһиевага сүз бирик.
— Бу иҗат хакимият диварларында шытып чыккан рәсми тенденцияләрне яки агымнарны гәүдәләндергән иҗат түгел. Фәһим тудырган милли пластика — рельефлар, бюстлар, тулай сыннар, балчыктан әвәләнеп эшләнгән садә-нәфис савыт-сабалар — һәммәсе дә борын-борыннан килгән мөселман сәнгатенең дәвамы. Аларда сабырлык һәм тын илаһият, иман вә инсафлык бар; рухи биеклекләргә ашу, камиллеккә омтылу кебек эчке әсәрләнүләр тышкы яктан саран, тотнаклы чаралар аша гамәлгә җиткерелгәннәр. Сүз, аңлашылгандыр, сынчы тудырган татар мәдәнияте һәм фикри каһарманнарының асыл тезмәсе турында бара. Бу галерея эч пошудан яисә ниндидер формаль максатларны күздә тотып, тарихи иллюстративлыкка омтылудан туган хезмәт түгел. Рәссамның йөрәгендә Бакый ага Урманче колачлылыгы, аның киң сулышы, куәт-җегәре, тарихи киң күңеллелеге төсмерләнә.
Сүз дә юк, олуг затларның сыннарын тергезү иҗаткяр остаһның изге нияте — борынгыны барлау, андагы көрәш, мәдәният, мәгърифәтчелек орлыкларын җыеп, бүгенге уңдырышлы туфракка күчереп утырту нәтиҗәсендә пәйда булганнар. Ягъни татарның акыл бакчасы гөрләп торсын, тәрәккый итсен, аның нигезе, тамыры корымасын...
Дөрес, мондый асыл затларның сурәтләрен торгызу юнәлешендә узган чор рәссам, сынчылары көч куеп карамады түгел. Ләкин алар еш кына Тукай, Җәлил, Такташ, Мәрҗани, Насыйри исемнәре тирәсендә генә бөтерелеп, анда да бары тик үзләре яшәп килгән чор, система һәм идеология ихтыяҗларыннан чыгып кына эш иттеләр, нәтиҗәдә «геройлар»ның четерекле күләмлелеген, моңын һәм каршылыклы эчке дөньяларын, бәргәләшү-өзгәләнүләрен, фаҗигаләрен ачып бирә алмадылар. Курыктылар... Фәһим академияләр дә бетермәгән, ләкин ул үз табигатеннән, рухыннан чыгып эш итә. Ул — бозылмаган, азмаган, шайтанга сатылмаган. Аның рухы — милли, иманы — камил! Шунлыктан ул татар әдипләренең рухын барлык вөҗүде белән тоя алган, аларны җанлы итеп гәүдәләндергән.
Гади генә соры тактага беркетелгән сыек-зәңгәрсу, ком төсле, фил сөяге төсендәге рельефлар, бюстлар үзләренең композицион элементлары — алга чыгып торган якалары, кул-әгъзалары, чәч-түбәтәйләре ярдәмендә тирәлеккә бәйләнгәннәр. Әйтерсең лә аларга тарих җиле кагылган, хәрәкәтчәнлек биргән.
Моннан күп еллар элек Яңарыш чоры сынчысы һәм дивар бизәүчесе Микеланджело Ватикан бинасының түшәменә Инҗил эчтәлегенә караган фрескалар иҗат иткән. Шуларның берсе Саваоф-демург атабыз Адәмгә җан сала... Фресканың фоторепродукциясенә генә игътибар итсәң дә шуны тоясың: әнә битараф халәттәге ир затының гәүдәсендә ниндидер хәрәкәтчәнлек билгеләре, чатнау-ярылу сызыклары пәйда була... Әнә, әгъзалар бер-береннән аерылып, кан тамырлары ярылып чыга... Менә ул хәзер торып басар да тәпиләп китәр сыман...

Фәһимнең әһелләре дә шулай: «җан керә башлаган», тоташ җанлы массив итеп сурәтләнгәннәр. Калкулы башлар, өмет тулы киереп ачылган күзләр, ничектер дивардан алга, тирәлеккә ыргылган гәүдәләр, җан кергән тарих, милли-драматик эпос булып күзаллананалар. Әллә соң бу инкыйразга каршы протестмы?.. Әллә башы-аягы киселгән милләтнең, тереклек суы эчеп, бербөтен булып оешуымы?
Әйе, Фәһим — татар җанлы, авыр тормыш юлы үтеп, үз-үзен тәрбияләгән, рәссам итеп үстергән корычтай ир-егет. Аның карашлары киң. Белеме тирән. Моңы, җыры бар. Шушы сыйфатлар аны, югары сәнгати профессиональ белем алмый торып та, рәссам итеп танытты. Әйткәнебезчә, иҗатында Урманче эзләре ярылып ята. Димәк, рухы көчле. «Мәктәп» (школа) — дөньяга карашка бәйле нәрсә ул. Бу — түбәнрәк баскыч. Иҗаткяр өчен рух, күңел — беренчел. Фәһим исә бу сыйфатка ия зат.
Фәһимнең утташ (шамот) материалыннан ясалган әсәрләрен минем мәчет-мәдрәсә эчләрендә, милли мәдәният храмнарында, зур-зур китапханә диварларында күпләп күз алдыма китерәсем килә. Чөнки алар бу биналарның алмаз терәге булырлык.
Керамикасы бармак эзләрен, җил улауларын, башак чайкалуларын сеңдергән... Табигать белән берләшкән мәҗүсилек бар аларда. Архаик сыйфатлар ярылып ята. Орнаменты соклану һәм ихтирам уята. Шәкеле буенча гади татар йортындагы табаларны, тәлинкә-касәләрне хәтерләтә. Җылылык бар. Татар сәнгатендә яңа агым бу.
Алма агачыннан ерак төшми, диләр.
Бу сүзләрне Фәһим Фәсхетдинов гаиләсенә карата да кулланып булыр иде. Аның күз алмасыдай кадерле, чая кызы Луиза да сәнгать юлын сайлады: ул татар халкының борын-борыннан килеп тә соңгы дәвердә онытылып бара торган милли традициясен тергезде — Луиза бәрхет җирлектә ука белән чигү чигә. Аның турында еш кына: «Татар сәнгатенең алтын киләчәге», — диләр. Бу сүзләрдә символик мәгънә бар. Беренчедән, бу Луизаның алтын җепләр белән чигү чигүенә ишарә булып яңгыраса, икенчедән, Луиза чын мәгънәсендә алтын куллы сәнгать остасы. Эшләре шул хакта сөйли.
Луиза 1988 елда Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлый. 1991 елда исә Бохара шәһәренең Ука белән чигү фабрикасында эшләп тәҗрибә туплый: ул әлеге һөнәрнең классик үрнәкләре белән таныша һәм дистәләгән чигү технологиясен үзләштерә. Һәм Казанга кайткач, «җиң сызганып» эшкә тотына. Ул чиккән калфаклар, түбәтәйләр, шәмаилләр, намазлыклар, гомумән, халык чигү промыселы үрнәкләре күз явын алырлык нәзакәтлелек һәм осталык белән иҗат ителгәннәр.
Әйе, нәкъ менә иҗат ителгәннәр, чөнки алар иш-үрнәкләре булмаган сәнгать әсәрләре булып торалар. Луиза чиккән көнкүреш әйберләре, Төркия, Венгрия, Алмания илләрендә үткәрелгән халыкара күргәзмәләрдә катнашып, югары бәя алдылар. Ул чиккән түбәтәй, калфаклар менә шул рәвешле татар халкының илчесе сыйфатында дөнья буйлап сәяхәт итеп йөри башлады. Әйе, чын сәнгать әсәре географик чикләрне белми, ул гомумкешелек тудырган байлыкка әверелә.
Менә шулай, Фәһим белән Луиза Фәсхетдиновлар — ата белән кыз — халык рухы белән сугарылган хәзинәне иңнәренә салып, һәрберсе үз юлыннан кояш нурлары яктырткан тауга күтәрелеп баралар.
*«Казан утлары», ноябрь, 1995*

## ЕРАКТАН КИЛГӘН — ЕРАККА КИТӘР...

Мөдәррис урманда яши. Хәсән ага Туфаннар, Сибгат ага Хәкимнәр рухы сеңеп калган Аккош күленең шигъри урманында. Ул алар эзе сеңеп калган сукмаклардан атлап йөри. Башкалар килеп кенә китә, ә ул анда даими яши, шунда таң аттыра, якты көнне озатып кала, агачлар белән сөйләшә, кошлар җырын тыңлый һәм... бертуктаусыз шигырьләр яза.

Калды ярлар, вакыт барлар.
Кайтулар юк анда кире...
...Һич булмаса, җырда барсын
Киләчәккә Аккош күле.

Сибгат ага Хәким рухына багышланган шигырь бу. Әйе, Аккош күле — әлеге исемнең үзендә үк символик мәгънә бар лабаса, — Хәсән Туфан, Сибгат ага Хәким киләчәккә алып бардылар, алар урынына хәзер Мөдәррис калды.
Мин еш кына, рухи азык, терәк эзләп, яңа шигырь тыңлыйсым килгәндә, бер-берәңә шигырь уку гадәте тәмам бетеп баргангадыр, бәлки, Мөдәррис дустым янына барып егылам. Һәм автобустан төшеп, урман юлына аяк басу белән, хөрмәтле әдибебез Мәхмүт ага Хәсәновның «Язгы аҗаган»

романындагы әлеге юлларны эчтән генә тәкрарлыйм (467 бит): «Шунда бер адәм, явыз кешеләр тарафыннан кыерсытылудан туеп, кара урманга кереп китә. Шунда, кыргый табигать кочагында яши башлагач кына җанына урын таба».
Әйе, Мөдәррис тә, минемчә, Аккош күле урманында шигъри җанына тынычлык табып яшидер кебек, һәрхәлдә, тыштан караганда бу шулай тоела. Ә көндәлек мәшәкатьләрнең, тәртипсез һәм «неустроенный» тормышының, ялгызлыкның ачы газапларын белсә дә бер үзе генә беләдер.

Айкала-чайкала барам ничә еллар,
Чорлар аша атлап барам, эзләп терәк.
Дөнья, Вакыт, Гавам төшенчәсе белән
Бергә яши алганда да терәк кирәк.

Бер карасаң, шәһәрнең кысан фатирында, ыгы-зыгылы дөньясында, бәлкем, ул кочак-кочак шигырьләр яза да алмаган булыр иде. Урманда ул шигырь белән күзгә-күз карашып, дустанә кочаклашып яши. Икенчедән, шагыйрьнең үзе әйтмешли, ерактан торып караганда, төсләр җетерәк, чын кыйммәтләр төгәлрәк тәгаенләнә, тормыш картинасының асыл сыйфаты ачыграк күзаллана. Ни генә булмасын, Мөдәррис — шигырьнең мәңгелек корбаны, аның иреклe һәм хыянәтсез каены.

Үз халкымның киләчәген,
Үткәнен, бүгенгесен,
Кайгысының, шатлыгының
Зурлыгын белер өчен
Еракка китеп кара син,
Еракка китеп кара!

Мөдәррис — әйбәт мәгънәдә иреклe, сукбай, дәрвиш, сәях шагыйрь. Ул үзе исән чагында ук легендага әверелде. Бәлки, шуңа күрәдер дә аның исеме тирәсендә, кораб тәненә ябышып үскән суүсемнәр кебек, төрле имеш-мимешләр йөри. Ә хәл болайрак тора безнеңчә: уйдырмаларның чыны да, ялганы да (кызганычка каршы, ялганы) бигрәк тә шәхесне кимсетә торганнары билгеле бер максатлардан чыгып «сарык» тиресе ябынган «бүреләр» тарафыннан да иҗат ителәләр. Биредә көнләшү һәм хөсетлек дигән төшенчәләр дә катнашмый микән әле? Бу урында аның, башка уңай белән язылса да, «Әйтте Тукай» дигән шигыреннән түбәндәге юллар хәтергә килә: «Мине чит иттегез, тәгәрәшеп миннән көлдегез...»
Икенче яктан, ни хәл итәсең, монысын да инкарь итеп булмый, уйдырма-риваятьләр туугa Мөдәррис үзе дә «гаепле», яшәү рәвеше, җәмәгатьчелек каршында үз-үзен тотышы, озын һәм ачы теллелеге белән ул кирәк-кирәкмәгәндә дә гавамга авыз чайкарга азык-җим биреп тора. Аны, шыттыра, диләр. Бәхәссез, шыттыра, ләкин бу бит иҗади процессның, иҗади фантазиянең дәвамы гына. Эчтән ничектер (ә, юк, минем аның бик тә моңсу чакларын да күргәнем бар лабаса), тыштан Мөдәрриснең моңа артык исе дә китми кебек, инде бик ачуы килә икән, яраткан «тавыгыгыз, чебешегез...» гыйбарәсен әйтә дә китә дә бара. Чөнки белә булыр, неординарный кешеләр турында гына уйдырма-риваятьләр тудыралар ич. Болай дигәндә, борынгы бер канатлы гыйбарәне искәртеп үтү дә зыян итмәс: «Гади кешеләрнең барысы да даһилар, ә талант ияләре гомуми кагыйдәдән чыгарылма булып торалар». Аннары, исбат итеп тә торасы юк, шәхес гомуми «көтүдән» никадәр алгарак, ераграк китеп карый белә, никадәр үзгәрәк тормыш алып бара, ул никадәр төркемчелек философиясеннән арыныбрак, гомуми кагыйдәләргә буйсынмыйчарак гомер кичерә, көтүне ташлап киткәнен гафу итә алмаганга күрә, көтүдәшләре аны шулкадәр күбрәк күрә алмый башлыйлар. Яшертен генә берләшеп алган ыспай киемле, уклаудай төз сынлы, шома, «дөрес» агайлар агу телле, бил бирмәс («Бирмә биленңне!.. Бирмә!..») Мөдәррисне әллә өнәп бетерәләр дисезме? Алар үлсәләр дә аны үз араларына алмаячаклар. Хәер, Мөдәррис үзе дә алар арасына керергә ашкынып тормый. Ул үҗәтләрчә үз кишәрлеген армый-талмый сөрә бирә («Мин табышмак чишәм нәселемә»), үз инануларын канунлаштыра («Сүз җибәрдем... Гаебем зур. Яратмыйм болгатуны. Күлне — балык, илне халык болгатачак. Мин — ил улы»). Ә көтүнең беркайчан да уртак, олуг идеясе була алмый, чөнки ул «көтүче» ихтыярына буйсынып яшәргә мәҗбүр ителгән кавем.
Андыйлардан аермалы буларак, Мөдәррис үзенә-үзе хуҗа, ул үзенең бу якты дөньяга ни өчен килгәнлеген, үзенең миссиясен җаны-тәне белән, барлык вөҗүде белән аермачык тоеп яши. Ул тулаем шигырьдән тора, аның кан юллары буйлап кан түгел, ә шигырь агадыр кебек. Шушы мәгънәдә ул эволюция кичермәгән шагыйрь, шигырь аның җанына болыты белән төшкән. Мөдәррис өйрәнчеклек чорын кичермәде, ул беренче адымнарыннан ук җитлеккән, буын нығыткан шагыйрь иде. Халык күңеленнән шытып чыккан шагыйрь. Дөрес, күп кенә шагыйрьләр үзләренең әсәрләрендә «халкым» дип халыкка мөрәҗәгать итәргә яраталар һәм бу, нәкъ менә мөрәҗәгать кенә булганлыктан, шигырь тукымасына ясалма рәвештә генә

кертелгәнлектән, көлке яңгырый. Халык шагыйре булу өчен бу гына җитми шул. Мөдәррискә килсәк, халык төшенчәсе аның шигырьләренең бер кисәк-өлеше, матур бизәге генә түгел, ә бәлки гомуми иҗатның юнәлешен билгеләүче гамь, моң. Бу шуннан килә: халык рухы аның канына, җанына ана сөте белән кергән. Яшьли ятим калса да... Тукай кебек... Кайчакта, шаяртыбрак булса да, Мөдәррисне «бүгенге көн Тукае» дип атап йөртүебез әнә шулардан килми микән әле? Чынлап та, шушы тәбәнәк буйлы, какча бәдәнле, орчык кына хәтле, кыяфәте белән үсмерне хәтерләткән «нәни гигант» ничәмә-ничә еллар буе халыкның рухи йөген үзенең юка гына җилкәсендә сыгылмыйча күтәреп бара! Мөдәррис һәм халык җаны — болар янәшә төшенчәләр. Аның сәбәбе ачык:

Җырны чикләмәгән вакыт,
Ә гомерне чикләгән.
Рәнҗеп туктамасын
Синә
Халкың тапшырган каләм!

Һәрдаим менә шушындый олуг хис белән янып яшәү, мөгаен, аңа рухи көч, дәрт-дәрман бирәдер, авыр булган чакларында да тураеп басып торырга ярдәм итәдер. Мөгаен, мөгаен... Ник дисәң, яшерен-батырын түгел ич, аның һәйбәтләп җиһазланган, иркен, якты фатирларда яшәгәне, кешечә кадер-хөрмәт күргәне дә юк бугай. Игътибар үзәгендә булуга да карамастан. Хәер, аны алтын хан сарайларына бикләп куеп, хур кызлары кочагына көчләп салсаң да, ул барыбер, Дерсу Узала кебек, сакчыларны алдап, үзенең табигатьтәге куышына качып китәр иде. Сере шунда түгел микән: авыр чаклары да бар ич, ләкин ул зарлана белми, һәрхәлдә, аһлар орып, бетеренеп бәргәләнгәнен хәтерләмим. Юкса ул да бит шатлана да, кайгыра да белә торган адәм баласы.

Зарланма әле, болай да
Көч-хәлгә тыңлап торам:
Беребез дә азат түгел
Дөньяның кайгысыннан.

Мөдәррис миңа кайчак бик борынгы кешедер кебек тоела. Бәлки, шигырьләренең тарихилыгыннан, халыкчанлыгыннан, «Тукайдан хатлар»дан, «Акмулла арбасы»ннан киләдер бу?

Шундый бер хис туа бу киңлектән,
Әйтерсең лә инде менә күптән
Бер яфрак булып йөзгәнбез дә...
Ул Җир дигән ярга килеп җиткән —
Кузгалган да ерак чиксезлектә.

Шушы шагыйрьгә бүген 50 яшь тулган, диләр. Ышанасы килми.
Бу аның мәңгелектән килеп, чиксезлеккә китеп бару сәфәрендәге бер тукталыш кына!
*«Шәһри Казан», 11 октябрь, 1996*

## КАЕННАР ЯКТЫСЫНДА

Азнакайның каен урманнарында булганыгыз бармы сезнең? Булырга туры килмәсә, мондый мөмкинлекне кулыгыздан ычкындырмаска тырышыгыз! Чөнки, Такташ әйтмешли, «бер җирдә юк андый ак каеннар»... Шушы сүзләрнең асыл мәгънәсенә төшенергә тырышып, шушы табигать ясаган картинаның сурәтен күзалларга омтылып хәтер төенчекләрендә актарына башлыйм да Азнакай каеннарына кереп югалам.
Менә минем алда тоташ каенлык урманы. Үләннәре хәтфәдәй ямь-яшел, куак-чытырманлыкта, ауган-корыган агачлар да юк анда, яшь-төз, шәмдәй зифа, озын буйлы, ап-ак тәнле каеннар, каеннар гына тезелеп киткән. Ул каеннарның кәүсәләрендә ник бер җыерчык, ботак-санак күренсен, бары уңган авыл карты бәйләгән себерке хәтле генә җыйнак-пөхтә ябалдашы күк гөмбәзен терәп, күтәреп тора сыман.
Табигать белгечләре, Татарстанда 200 дән артык төрдәге каен агачы үсә, диләр. Әмма мондый каеннарны Азнакай урманнарында гына очратырга мөмкиндер, мөгаен.
Марсель Галиев, Аяз Гыйләҗев һәм Нур Әхмәдиевләр әнә шундый якты, сәгадәтле «урманнан чыккан» шагыйрьләр.
Һәр иҗат кешесенең «визит карточкасы»на тиң, аның җанын ачып бирердәй әсәрләре була. Нур Әхмәдиев диденме, җырдагы гади генә, җанга якын моңы белән бергә үрелеп, түбәндәге юллар хәтергә килә:

Каенкайлар, күңелемне

Һәрвакыт аңладыгыз;
Нигә инде бу юлы да
Җибәрми калмадыгыз?!

Нигә җибәрсеннәр, ул бит әнә журналыбызда урнаштырылган фотосурәттәге кебек туган ягы каеннарына сарылып үскән шагыйрь, ләбаса. Нәкъ менә «Каенкаем — бәгырькәем» шигырендәге кебек:

Йөгерә-йөгерә каршы чыгалар да,
Үр җитәрәк туктап калалар.
Үзебезнең якта каеннарым
Мине шулай каршы алалар.

Дөрес, заманында Нур Әхмәдиев «башка урманнарда» — узгынчы темалар урманында да адашып йөргәләде. Ләкин соңгы дәвер иҗатында да ул каеннар яктылыгына чыга алды, бу бәладән аны хис һәм фикер шигърияте коткарды. Ул шигъриятә ил язмышын кайгырта алучы ир-егет булып җитлекте.

Ил язмышы — ир язмышы булган,
Күпме башка казык кагылган.
Антлар гына түгел,
Тарих үзе
Ирләр каны белән язылган.

Ә көндәлек тормышта ул яшьтән үк җитди, кеше хәленә керә белүчән эшлекле егет иде. Шушы сыйфат-холкын искә алыптыр, бәлкем, аны Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлекчәсенә җитәкче итеп сайлап куйдылар. Ул әле өлкән язучыларның өйләренә барып, аларның хәл-әхвәлләрен белеп кайта яки язучылар үзләре аның янына кереп утыралар. Гариф Ахунов, Әдип Маликов, Равил Фәйзуллиннар «эстафетасын» кулыннан төшермичә, ул Әлмәт язучылары мәнфәгатен кайгыртып яшәде. Боларына мин үзем дә шаһит. Мөслимдә яшәгән чорымда мин еш кына Әлмәт бүлекчәсенә барып чыга идем. Шундый көннәрнең берендә ул, Язучылар берлегендә әгъза булмавыма бик тә гаҗәпсенеп: «Ничек була инде ул? Мин бит сине күптән язучы-әгъза дип белә идем. Хәзер машина тәгәрмәчен хутка җибәрәбез аны», — диде дә җиң сызганып эшкә кереште һәм үзе юллама язып, мин бер ай- ай ярым дигәндә секция утырышында «язучылыкка» тәкъдим ителдем.
Боларны шуңа гына әйтәм: Нур Әхмәдиев — кешелекле кеше. Соңгы вакытта ул чордашы һәм хезмәттәше Фәрит Гыйльмине күз карасыдай саклады... Тик адәм баласын күкрәк кесәсенә салып йөртеп булмый шул: Фәрит дустыбыз вакытыннан алда арабыздан китеп барды. Урыны җәннәттә булсын!
Шулай шул, кызык бу тормыш: әле кайчан гына безнең буын 50 яшьлек агай-апаларга астан өскә карап йөри иде. Баксаң, үзебез дә шул биеклеккә менеп җиткәнбез икән. Әнә ич, ай саен диярлек кырык алты, кырык җиденчеләрнең юбилейлары үтеп һәм көтеп тора. Югыйсә алар авыл саен бармак белән генә санарлык булсалар да. Ләкин:

Туган еллар безнең — кырык алты.
Сугыш күрмәгәнбез дисәк тә.
Авыл саен без бит ничәү генә,
Тарихта без аерым исәптә.

...Җаваплылык шуңа башкалардан
Күбрәк төшә безгә дөньяда.

Рәсемдә ак каенга сөялеп-кочаклашып бер ир-егет басып тора. Илле яшәр Нур Әхмәдиев гел шушы сурәттә минем күз алдыма килеп баса. Уйчан һәм моңсу булып.

*«Казан утлары», декабрь, 1996*

**ЯШЬЛЕК ХАТИРӘСЕ**

Шагыйрь кайда һәм ничек туа? Ягъни кайчан ул, фани дөньяның гади кешесе булудан битәр, Ходай биргән иҗади сурәтен гавам көзгесенә төшерә башлап, соңрак үзе дә Илаһи затка әверелә? Бу сораулар мине гел җилкендереп, алгысытып тора. Зөлфәт турында уйлый башладым исә, тоташ калын урман күз алдыма килә дә баса...
Бу очракта мин башкалардан күпкә бәхетлерәк. Чөнки заманнарыбызның танылган шагыйре Зөлфәт белән без очраклы рәвештә генә, бер үк елны дөньяга килгән яшьтәш-чордашлар түгел, ә бәлки якташлар һәм, шәрикләр, фикердәшләр дә. Без икебез дә галиҗәнап сүз мохитенә бер

оядан очып чыктык — Мөслим районының Үрәзмәт мәктәбен тәмамладык, бергә кызлар артыннан чаптык, бергә сөйләшеп йөреп, йокысыз үткәргән төннәр дә булды һәм бер үк чорда Казанга килдек...
Кыскасы, хәзер без аның белән «борынгыдан» килгән аерылмас дуслар инде. Шуңа күрә микән, җан-кесәләребездә дуслыкка хокук бирүче рәсми мандат йөргәнгәме, малай чакларны искә төшереп, кайчак үртәшеп тә алгалыйбыз. Билгеле инде, һәр тартай үз түмгәген мактый.
Зөлфәтнең туган авылы, ягъни Яңа Сәет, исеменнән үк күренгәнчә, чагыштырмача яңа авыл. Заманында Иске Сәеттән аерылып башка чыккан һәм, һәр яңа авылга хас булганча, табигатьнең ифрат та гүзәл җиренә урнашкан — аның ындыр артыннан ук катнаш «кара урман» башланып китә; болын-сулары да хозуранә матурлыкка ия. Зөлфәткә шигъри орлык, имезлек биргән җир бу.
Ә минем дөньядагы иң матур туган авылым — газиз Бүләгем хәзер мае беткән шәм кебек сүнеп бара. Кем әйтмешли, авылда да кеше язмышлары. Кичерсеннәр мине авылдашларым, алар гаепле түгел ич! — картайган урамнарның берәм-берәм теше төшеп бара — ике-өч йортны үтүгә, койма биеклеге алабута-кычыткан баскан ихаталар сөрәеп утыра; кайчандыр челтерәп агып яткан инеш буйларында «мамонт өянкеләр» аунап ята; Үткән белән Бүгенге арасындагы чикне билгеләп, авыл башына ук — ерак-еракка — йөзләрен тут баскан коры ябалдашлы карт тупыллар чыгып баскан; әле моннан 80–90 еллар элек кенә авылга терәлеп торган урман да, куркынып, 7–8 чакрымга чигенгән: бүләкледәрнең ике күзе әнә шул «Олы урман»нан бүленеп калган якындагы үтә күренмәле «Имәнлек»кә текәлгән...
(Кызганыч ки, Зөлфәтнең беренче сөйгән яры Гөлнәзирә яшәгән Мәсегөт авылы инде бөтенләй дә дөньяда юк. Ул үзе дә юк... Бу югалтуны Зөлфәт кенә түгел, Зөлфәтнең хатыны Фирая ханым да бик авыр кичерде кебек...)
Кыскасы, авылларыбыз турында сүз чыктымы, Зөлфәт үзенең Яңа Сәет урманы белән мактана башлый. Гәрчә авылларыбыз арасы шул ук 7–8 чакрым гына булса да.
— И, син бит кыр ягы малае ла, мин белгәндә салам ягып яшәдегез, — ди, горуранә рәвештә башын артка чөя төшеп. Каян килсен инде сиңа урман җанын аңлау?
Гәрчә әткәйнең ат арбасында үсеп, төннәрен бөтен якын-тирә урманнарны «айкап» чыккан малай булсам да, дөрес әйтә бит чукынчык — дәүләт дигән «бояр урманыннан» рөхсәтсез бер кура-үлән дә өзеп алырга ярамаган бер заманда «уфалла»дан башка терәге булмаган ятим-җилпе саламын да, тиресен дә якты шул авылыбызда. Иле белән шулай иде.
— Алабутага да налог керсә...
— Тәүбә, диген!
— Ничек яшәп булыр берьялгыз...
— Әйтмә инде...
— Кайчан бер көн килер?
— Нишләп кенә җиргә туганбыз?
Ләкин беркөнне, һич тә көтмәгәндә, әлеге төрле моназара җиңел генә чишелде дә куйды. Малайлангач тәмам малайланырга кирәк бит инде, алдан төзеп куелган «стратегик план» буенча сак кына һөҗүмгә күчтем:
— «Олы урман» сезнең «Яңа Сәет урманы» белән тоташамы әле ул, Зөлфәт? — дим.
— Бәхәссез, — ди бу бер дә исе китмәгәндәй. — Әле алай гына да түгел, бормалана-бормалана «Завод урманы» белән кушылып, Бакалы ягына, Урал буйларына ук чыгып китәләр алар.
— Ә менә шул «Олы урман» безнеке бит инде!
— Анысы шулай, — диде Зөлфәт, әмма бераз сагая төште.
— Син, әйтик, шигырең саен диярлек «чытырманлык» дисең, «Коргылды», «Коргылды» дисең, алар бит безнең теге «Олы урман» итәгендә «Чытыр Бүләк» чытырманлыгыннан башланып китә ләбаса. Так что ... безнең гомер елгалары бер үзәннән агып бара.
Шулай итеп, ике арада солых-килешү төзелде.

Исемең — чайяр! Әйтерсең лә анда
Кем каядыр ярсып ыргылды!
И Коргылды!
Минем өчен бит син
Керсез яшәтердәй сер булдың.
Әнкәемнең үзе бит син ләса...
Син карыйсың һаман мөлдерәп.
Күкрәгемә кулым куям —
Бушлык —
Синдә калган бугай бу йөрәк.

Менә шулай, урман ешлыкларыннан, «Коргылды»лардан моң алган Зөлфәт бүген татар

шигъриятендә мең тавышлы урман кебек гүләп яши: аның ухылдап эндәшкән йөрәк тавышы күптән инде ерак киңлекләргә сибелгән бөтен татар халкы күңелендә яңгыраш тапты. Юк, бу матур сүз уйнату гына түгел, бәлки Зөлфәт шигъриятенең асыл сыйфатын ачыклаучы символик сурәт, хакыйкый чынбарлык. Ышанмаучылар булса, Зөлфәт шигырьләрен кабаттан укып карасыннар. Шагыйрь әллә юкка гынамы шигырь турындагы иң саф, иң эчкерсез хисләрен, күз яше белән сугарылган иманга тиң уйлануларын «Чытырманда былбыл сайрый» дип атаган?! Әллә юкка гынамы аның иҗатын иң әтрафлы чагылдырган китабы «Ике урман арасы» дип исемләнгән?! «Юкка түгел, юкка түгелдер...» Нинди генә төрдәге агач-үләннәр үсми анда, нинди генә кош-корт, җанварлар яшәми... Анда — бу Галәми киңлектә — кемнәр генә фидаи гомер кичерми... Ике урман арасы — ике Чик арасы ул!

Яудым йолдыз яңгырлары булып
Татар җанына мин киң күктән —
Һәр иҗегем, һәр сулышым канлы,
Җәрәхәтле килеш мин китәм...

Әйе, Зөлфәт иҗатында — шагыйрь, философ, табигать баласы иҗатында дөньялыкның һәр күзәнәге, һәр сулышы халык язмышына барып тоташа. «Татар теленең каргышы», «циркtagы уен», үлемгә мәхрүм ителгән «сазлык» ыңгырашуы, «кайнар кәлтә эзе», «Йодрык һәм ат турындагы балладалар», «өн» һәм «нигез»ләр һәм башка, һәм башка меңнәрчә төрле төс-сурәтләр аша барып тоташа ул. Илаһият аша! Язмышлар аша!
Шагыйрьне тыңлыйк: «Империя үзе кадәр үк зур әдәбият бирә алмый. Бер чикләвек куагында күп дигәндә егермеләп сабак үсә. Артканы яңа куакка аерыла. Артык ишәйгән куак чикләвек бирә алмый. Милләтләр — әнкәбез Табигатьнең төрле агачлары, аерым куаклары. Моны бернинди Мичурин дә үзгәртә алмый. Сак усак лепердәп утыра. Юкә гашыйклар сыман назлы иттереп, шыпырт кына сөйләшә. Имән тарихның үзе сыман тирәннән, җир күкрәгеннән гүли». Болай дип, безнеңчә, урман — халык язмышын тирәнтен аңлый алган, күзәтүчән һәм уйчан фикер иясе генә әйтә ала.
Шушы «җир күкрәгеннән гүләгән имән» тавышын беренче булып сак сизгер колаклы Рәдиф Гаташ ишетеп алды. 1964 ел. Һаман да шул Үрәзмәт мәктәбе, һәр укучы бала, укытучы абыйсына охшарга тырышып, дөресрәге, аның тылсымына буйсынып, исәрләнә-исәрләнә, әсәрләнә-әсәрләнә шигырь яза. Мәктәп тоташ шигъри ялкын эчендә.
Һәм кинәт кышкы салкын көннәрнең берендә, бөтен мәктәпне сискәндереп, шомлы хәбәр таралды:
— Зөлфәтнең әнисе үлгән!..
Белмим, иҗатка мондый рухи тетрәнү ничек һәм ни рәвешле йогынты ясый торгандыр, әмма шушы фаҗигадән соң Зөлфәт кинәт олыгаеп, олпатланып китте. Бу хәл-үзгәреш аның шигырь тукымасында да чагылыш тапты. Шуграк малайларга атап көлкеле-чәнечкеле шигырьләр чыгарып йөргән «Исәр Мәләк»тән ул бер кичтә (һәрхәлдә, читтән караганда бу шулай тоелды, ләкин аның чишмәсе тирәннән дым тартып килгән булган икән) Дөлфәт Маликов дигән шагыйрьгә әверелде дә куйды.
Бу хәл Бүләк авылында булды. Агач клуб. Тын беленерлек салкын. Шигъри кичә бара. Зөлфәт шигырь укый. Бөдрә чәч, зифа буй, баш югары чөелгән, уң кулы кош канатыдай җилпенеп-җилпенеп ала, әмма тавышы уйчан, моңсу.

Елга буйлары талдыр.
Агызма —
Тик яшьлегемне калдыр.

Шигырь тәмамлануга, иске клуб сулкылдап куйгандай булды... Шигырь «җене» кагылырга өлгергән безнең якын авыл апа-агайлары бер тын белән шигырь тыңлыйлар. Алар нәкъ менә шушы минутларда яңа шагыйрь тууын эчтән генә чамалап алганнардыр (халык сизгер ул!): уен эшмени, әле яңарак кына әнисен югалткан егет «тик яшьлегемне калдыр» ди бит! Олыларча итеп, үзәккә үткәреп, үксетеп.
Бу — триумф инде. Сәхнә артына чыккач, Рәдиф Гаташ, шатлыгын яшереп тормастан, шәкертенең иңеннән кочып алды да яраткан сүзен шәрран ярып кычкырып җибәрде:
— Афәрин, күсәк!
Икенче елны ул ике «күсәген» — Дөлфәт белән Фәрит Гыйльмине ияртеп (авыр туфрагың җиңел, урының җәннәттә булсын, дустым!), күкрәгендә булачак «Гөлләр су сорый» китабының җылысын тойган хәлдә, Казанга юл алды. Казанны яуларга.
«Дөлфәт белән Фәрит университетка кереп кайтканнар икән!» — бу хәбәр мәктәптә яшен тизлегендә таралды.
...Менә мин әле камыл җылысы да сүрелеп җитмәгән арыш саламы өемендә ялгызым күккә

карап ятам. Сентябрь төне. Күзгә төртсәң, берни күренерлек түгел. Ә йолдызлар шундый яктылар, шундый якыннар — менә-менә күзгә тамып төшәрләр сыман. Таныш тавыш ишетелүен көтеп ятам. Көзге тымызык, тыныч кичләрдә шалт иткән дә әллә кайдан ишетелә бит ул: әнә, көткән юлчым таудан күтәрелә башлады булса кирәк — сәпит чылбыры авыр сулап ыңгырашып куя иде. Ә ыңгырашу тәмам якынайгач, алдан сөйләшенгән буенча, «тычкан күзен» — кытай фонарен өч мәртәбә яндырып алдым. Хәер, шартлы билгесез дә туктаган булыр иде ул, чөнки без аның белән нәкъ менә шушы урында, Мәсегөт — Үрәзмәт — Бүләк юллары кисешкән «Бермуд өчпочмагында», җәенә-кышына карамыйча, көн саен диярлек күрешә идек. Саф вә сәгадәтле, хиссиятле вә гөнаһсыз беренче мәхәббәт утрауларыннан исән-имин илгә кайтып барышлый. Сәяхәттән кайтучы диңгез кораблары кебек.

— Гаепләмә, озак көттердем бугай, — диде ул көрсенеп һәм туктар-туктамас ук сәпитеннән сикереп төште дә салам күбәсенә йөзтүбән капланды. — Иртәгә китәм бит, малай.

Аның белән аерылышу, күрәсең, шушыдыр инде.

Башка вакытларда без Зөлфәт белән шушы урында очрашкан саен, бер-беребезне көтеп алышып, эч серләребез белән уртаклаша идек, яңа «шедеврлар»ыбызны укый идек, киләчәк турында хыяллана идек, бүген менә эндәшми-тынмый гына һәркайсыбыз үз уена батып ята. Кузгалып киткәндә дә ул авыр сулап бары:

— Югалма, икенче елга сине Казан көтә, — дия алды.

Без ул көнне шигырьле, мәхәббәтле, хыялый уртак мәктәп елларын хәтер буразналарына күмеп хушлаштык. Тагын бер елдан, университетның тулай торагында очрашканда, ул инде Казанның шигырь казанында Дөлфәт Маликовтан «Зөлфәт»кә әверелгән шагыйрь иде. Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Нури Арсланнардан фатиха алган, алар учагында җылынырга өлгергән шагыйрь. Шулай итеп, йөзләрчә авылдан килгән йөзләрчә яшьтәшләре белән бергә Зөлфәт Казанның казан астында үз учагын кабызып җибәрде. Хәзер бу учак иң яктылардан да яктырак инде.

Һичберкем дә түгел, үзем бу.
Яшь чагымда әйткән сүзем бу.
«Күз нурларым күкне уяр күк,
Күкрәгемә дөнья сыяр күк —
Үз-үземне кайчак аңламыйм,
Әллә кеше, әллә Алла мин».

Шулай, Шигырьдә Алла була алган шагыйрь генә үз исеме белән туа. Кирәк икән, ата-баба кушкан исемне үзгәртеп булса да. Дөрес, бу тышкы атрибут кына, әмма Иҗат исемдә дә кабатлануларны яратмый. Шигырьдә ике Тукай, ике Дәрдмәнд, ике Такташ, ике Туфан була алмаган кебек, мин ул бишеккә ике Зөлфәт сыеша алуын да күз алдына китерә алмыйм. Исем ул — шагыйрьнең шәхси паспорты, иҗади таныклыгы, гавам көзгесенә төшкән җан сурәте. Бөек шәхесләр арасында югалып калмасын өчен Ходай кодрәте белән иңдерелгән язмыш тактасы. Ниһаять, үзеңнең кем икәнлегеңне таныту билгесе. Шагыйрь шуңа күрә бераз нахалрак та булырга мөмкин, аерым очракларда бу хәтта мәҗбүри дә. Әлбәттә, «вето салдым барлык мескенлеккә» дип әйтерлек хәлдә, чөнки «шагыйранә ялгансыз» иҗат булмый, була да алмый. Әнә бит Зөлфәт ничек ди (ә моңа ышанмый мөмкин түгел): «Туганлыкның кан тибеше — шигырь. Лев Толстой янындагы агачтан коелган яфракларны Мөслимнең Яңа Сәет авылы янында ага торган тын ерганакка — Коргылдыга алып кайтып агыздым. Калганнарын Тукай каберенә илтеп салдым. Лермонтов туфрагын әнкәй каберенә сиптем. Коперникның туган йорты нигезенә Тукай туфрагын куштым. Үземнең шушы мәҗүсилектән күңелем хушланды». Туганлык! Коргылды инеше, Сәет урманнары егете Бөекләр хозурына килеп кушылды түгелме соң? Мин шушы җан авазларын тыңлыйм да кайчак югалып та калгалыйм — Бүләк авылы башына чыгып баскан ялгыз тупыл кебек хис итәм үземне һәм ирексездән Галәми киңлекләр түрендәге Олы урманнар ягына үрелеп карыйм. Алар арасында минем яшьтәшем, дустым да бар лабаса. Мин шуның белән бәхетлемен дә: менә утыз еллап инде без, хәлфәбез шагыйрь Рәдиф Гаташка кат-кат рәхмәтләр әйтә-әйтә, бер-беребезне югалтышмыйча, шәһри Казан казанында кайныйбыз. Ә мин үзем әдәбият-шигърият учагына «салам ягып» яшәргә дә риза: «салам»ың гына юеш булмасын да төтенең генә туры чыксын!

*«Ватаным Татарстан», 10 гыйнвар, 1997*

**ИХ, ЖИДЕНЬ!..**

Тыйнак вә сәер, хыялый вә прагматик, беркатлы вә фәйләсүф кеше иде ул Фәрит дустыбыз. Гариф абый Ахунов әйтмешли, «чуднойрак» шәхес иде. Хәер, әдәбият-сәнгать әһелләренең

күбесе нинди дә булса берәр сәеррәк сыйфатка ия була инде ул. Фәрит эчтән яна торган кеше иде. Елмайганда да зәңгәрсу күзләреннән ниндидер яшерен моң, садә борчылу китми иде; күрешкәндә исә, бермәл сынагандай тутырып карап торыр иде дә карашларын читкә борыр иде — менә ул кыбырсына башлый, гаепле кешедәй ояла, пошкырына, бер урында таптана; кирәкле сүзен эзләгәндәй, читкә, күккә карап-карап куя, чукмардай йодрык арты белән итлеч-калын иреннәрен сөртеп ала... Аннары гына, тамагын мәгънәле кырып куйганнан соң, сүзен башлый. Әлбәттә, еmegaктан, серле итеп. Әңгәмәгә бөтенләй дә кагылышы булмаган җирдән.
Менә ул бервакыт Әлмәттән Казанга килеп төштә. Аның батырма торбалар заводында эшләгән чагы иде. Мәскәүгә командировкага китеп барышы икән.
— Малай, бит, кхм-кхм, ни, бер ни... бар бит әле, — диде ул бераз тотлыгып торганнан соң. — Косыгинның (ул чакта СССР Министрлар Советы рәисе. — *Н.Г.*) бүлмәсен карап кайтасы ие бит әле. К-хм! Ы-һым!
Ул, ишетеп тормыйлар микән дигән кебек, тирә-ягына алан-ялан каранып алды да күрәк кулларына урын таба алмыйча дәвам итте:
— Ни бит, роман башлаган ием... Сугыш елларында анда Сталин утырган, диләр. Күрәсе ие... Минтимер абыкай ярдәм итсә генә инде... Әнкәй ягыннан туганнар ич без (Минтимер Шәймиев ул вакытта мелиорация һәм су хуҗалыгы министры булып эшли иде. — *Н.Г.*)...
Көлемсерәмәдем дә, шаккатмадым да, мин аның гадәт-кыланышларын мәктәп елларыннан ук беләм ләбаса. Фантазер, фаталист иде дип әйтимме? Кыскасы, бу дөнья кешесе түгел иде ул.
...Университетта укый башлаган еллар. Кояшлы җәйге иртә. Тулай торак бүлмәсе.
Фәрит кара трусикларын җилфердәтеп тимер челтәрле караватыннан торып баса да озак кына тәрәзәгә карап уйланып тора, аннан, кулларын кош канатлары кебек як-якка җәеп, сөрән сала:
— Их, жидень...
Нәрсә әйтергә теләде икән ул моның белән? Көрсенде микән, әллә сөенде микән? Бәлки, садә балачагына, туган авылына, тәгәрәп үскән кырларына (хыялында гына булса да!) кайтып килгәндер ул бу минутларда, бәлки, ач студент тормышын каһәрләгәндер? Бәлки...
Ни генә булмасын, күңел түреннән бәргәләнеп, искәрмәстән генә очып чыккан шушы «сүз-чыпчык» Фәриткә ябышты да куйды. Менә хәзер еллар аша аның язмышы турында, аның белән бәйләнешле вакыйгалар турында уйланып утырам да, ирексездән: «Их, жидень», — дип куям. Шундый гадәти булмаган сыйфатларга ия, гомергә сагынып сөйләрлек хатирәләр бүләк итәрлек шәхес булган икән шул Фәрит дустыбыз!
— Каләм тибрәтә башлаган һәр яшь кешенең кумиры, остазы була. Әнә Мөдәррис Әгъләм Хәсән ага Туфан белән Сибгат ага Хәким яныннан кайтып керми. «Туфанда булдым әле», — дип кенә җиффәрә. Фәритнең дә яшерен сере бар: кич җиттеме, шыпан-шыпан гына Аяз абый Гыйләҗев янына шыла.
«Килеп керде бу берзаман, — дип яза Аяз абый. — Өс-башы әллә кем булмагандыр, аларын хәтерләмим. Әмма Фәритнең алагаем дәү ике якка җәелеп, изелеп төшкән тишек ботинкалары исемдә. Явымлы көн булгандыр инде, атлый Фәрит, идәндә дәү-дәү эзләре кала. Мин егеткә «Җилкәнсезләр»дәге Зәйнетдин кебек итеп: «Әй, парин, синең каталар протестка чыккан икән!» — дип көлемсерәдем. Зарланмады егет, мин ыргыткан җимгә үрелмәде. Егетнең кысылган иреннәренә карап, мин аның ныклы бер карар белән ишегемне шакуын аңладым. Хикәяләр алып килгән икән! Зәңгәр тышлы дәфтәрен куеныннан чыгарды һәм миңа тапшырырга ашыкмады, кадерләп ике куллап кысып урындыкка утырды.
Сөйләшә башладык. Егет сүзгә саран вә сак иде...
...Без бер чакта да артык якынаймадык, еш очрашмадык, әмма мин дөньяда Фәрит Гыйльметдинов барлыгын, аның сабыр күз карашын бер чакта да хәтеремнән чыгармадым. Егетнең тәүге әдәби адымнары авылны, крәстияннең җанын тирәнтен аңлавы, телебезне камил белүе күңелемне җылытып килде. Күрешкән мәлләрдә мин аны дәртләндерергә тырыштым. Әкренлеген читкә куеп, ешрак, күбрәк язуын теләдем. Ул Әлмәттә яши башлады. Шунда төпләнде, ныгыды. Мул һәм иркен яшәмәгәндер, ахрысы. Казанга килер иде, кайтырга еш кына акчасы калмас. Юк, акча туздырып, теләсә ничек исраф итеп йөргәндер дип уйламыйм, артык гади, юаш иде Фәрит. Әҗәтен дә өзеп-өзеп, ваклап кайтаруларыннан чыгып, мин аның тормыш-көнкүреше җиңел булмагандыр дип уйлыйм. Мәгәр ул бер чакта да авыз ачып зарланмады. Тышындагысы эчендә иде егетнең. Мин һаман көттем, берөзлексез өметләндем. Чиста күңелле каләмдәш дустым, алай әйтергә яраса, шәкертем, үз күкрәгендә салмак кына дөрләгән утны дөньяга чыгарыр дип уйладым.
Ни аяныч! Тыйнак дустыбыз бу дөньядан ашыгып китеп барды».
Өлкән әдибебезнең күңел түреннән саркылып чыккан шушы сүзләрен укыгач, Фәритнең тере сыны күз алдыма килеп баскандай булды. Моңсу да, үкенечле дә булып китте. Әйе, әйе. Фәрит

Гыйльми әнә шулай сәер, моңсу, сабыйларча фәйләсуф булып күңелгә кереп калган, һәм, әлбәттә, сәер кыланмышлары белән. Андыйлар гадәттә тигез урында да абынып егыла... Юк җирдән дә көлкегә кала... Могҗиза эзли... Олыгайгач та Том Сойер булып кала белә. Гөнаһсыз бәндәләр!
Әнә Фәрит турында сабакташы Зөлфәт болай дип искә ала.
— Сөйгән яр яныннан кайтышлый Иске Үрәзмәткә кереп, Фәритнең бәләкәч кенә бүлмә тәрәзәсен чиртәм. Тәрәзә ачыла. Таң атканчы кызлар, әдәбият, дөнья хакында акрын гына сөйләшеп ятабыз. Ул төнге әңгәмәләр хакында аерым бер сөйлисе бар әле. Ә бүген менә син мәрхүм Фәритнең сәер холкы хакында сүз кузгаттың... Сәерлек кенә түгел иде бугай бу. Мистика, ырым-шырымны хәтерләтә иде аның кыланышлары. Нәфис, чиста, хыялый кеше иде ул. Аның Әлмәттә төпләнгән чагы. Командировкага барып төштем. Язучылар берлегенең Әлмәт бүлекчәсе башлыгы — Нур Әхмәди. Ярдәмчесе — Фәрит Гыйльми. Күрештек. Өйгә кунакка йөрергә яратмаганлыктан, Фәритне үзем яшәгән кунакханә номерына әйдәкләдем. Ике ятаклы бүлмә алган идем. Шактый гына сыйланып алганнан соң, икебез ике ятакка сузылдык.
Фәрит сүз башлады:
— Минем гел шул булыр инде... Кеше шикелле генә булмас. Менә бер роман сюжеты башка килде әле. Кызыл галстуклы Мөслим пионерлары Ык елгасы төбеннән өр-яңа бер танк табып алалар... Фәрит, язылася романын шушы урында туктатып, башын селкеп куясы итте. Аның башына чорналган пәрдә гардины-ние белән дөбер-шатыр кубарылды да аска ишелде. Фәрит тәмам каушап урыныннан сикереп торды.
— Минем гел шул булыр инде... Кая, калдымы әле безнең анда?
Калмаган иде.
Сынчы-скульптор Әхсән Фәсхетдиннең энесендә генә өмет. Умарта тота ул. Әчегән бал булса да — шунда гына! Адресын Фәрит кенә белә.
Ул юлга җыенганда әйтеп калдым:
— Маҗарага юлыкма тагын! Әйбәт кенә алып кайтып җиткерә күр!
...Ярты сәгатьләр узуга Фәрит урап кайтты. Кыяфәте — коточкыч! Корсагына кысып өч литрлы банка кочаклаган. Бүрегеннән алып аягына кадәр лычма бал! Чәчләрем үрә торды.
— Минем гел шулай булыр инде, — диде дә Фәрит банка төбендәге балны чөмереп куйды. — Синең ишеккә килеп җитүгә банка атты, каһәр! Үләм дип торам! Ярар, чукынмасмы... Шуннан теге кызыл галстуклы малайлар Ык төбеннән өр-яңа танк табып алалар бит...
Төне буе сөйләде Фәрит бу язылася романны.
Тик ул романга язылып бетү насыйп булмаган икән.
Һәм Фәрит миңа теге дөньядан уңайсызланып елмая сыман тоела:
— Минем гел шулай булыр инде...
Аның күңеле салават күпере иде.
Фәрит Гыйльми күләме ягыннан тыйнак, әмма рухы белән садә, якты, бай мирас калдырып китте. Ә әйтелмәгән күпме хисләрен үзе белән алып китте икән? Тормышта гел шулай.
— Их, жидень!..
*«Мәдәни җомга», 18 апрель, 1997*

## УЛ ТОРМЫШНЫ ЯРАТА ИДЕ

Үсеш динамикасы ягыннан язучыларны ике төркемгә бүләргә мөмкин.
Була шундый иҗат әһелләре, алар башлангыч чорларында ук зур тизлек белән «кала тавын» яулап алалар да, соңрак бер урында таптана башлыйлар яки бөтенләй үк түбән таба тәгәриләр. Була тагын шундыйлары, алары исә тау түбәсенә әкренләп, әмма ышанычлы адымнар белән үрмәлиләр һәм ахыр чиктә иҗатларының «йөзек кашы» булырлык әсәрләр иҗат итәләр. Мәхмүт Хәсәновны, мөгаен, икенче төр язучылар рәтенә кертеп карарга кирәктер. Ул «беренче адымнарын» тыйнак кына башлады, гомеренең уртасында да уртакулрак әсәрләр иҗат итте, әмма әсәрдән әсәргә осталыгын чарлый барып, соңгы дәвердә берсеннән берсе уңышлырак эшләнгән роман, повестьлар тудырды. Әйе, әдип түбәннән югарыга күтәрелде, югарыдан түбәнгә мәтәлеп төшмәде — бу юл катлаулы вә четерекле, әмма гыйбрәтле булды.
Мәхмүт Мәкъсут улы Хәсәнов 1927 елның 21 декабрендә Татарстан Республикасының Саба районы Югары Кибәхуҗа авылында туа. 1937 елда алар гаиләләре белән Зеленодол шәһәренә күченеп киләләр. Әдәбиятка һәм театр сәнгатенә бала чактан ук гашыйк егет 1944 елда — димәк, унҗиде яшендә — Мәскәүнең А.В.Луначарский исемендәге Дәүләт театр сәнгате институтына (ГИТИСка) укырга керә. Биш елдан соң, ягъни институтның актерлык факультетын тәмамлап, Казанга кайта һәм Яшь тамашачылар театрында актер булып эшли

башлый. Тагын бер елдан соң аны Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында уйнарга чакыралар. Шушы чорда, дөресрәге, 1949–1951 елларда, беренче хикәя, очерклары вакытлы матбугатта күренә башлый. 1954–1956 елларда Татарстанның беренче нефтьче-разведчиклары тормышына багышланган «Яңа горизонт» повесте, эшчеләр тормышыннан алып язылган «Урман шаулый», «Кыюлар юлы» дигән повестьлары басылып чыга. Бу әсәрләр, әдәбиятта заман темасын яктыртудагы өлгерлек үрнәкләре буларак, әдәби тәнкыйтьтә дә уңай яктан бәяләнәләр. Кыскасы, Мәхмүт Хәсәнов алдында яңа гаризонтлар ачылган чор бу.
«...Әмма Бөгелмәдә миңа озак эшләргә туры килмәде. Нәкъ шул елларда Мәскәүдә М.Горький исемендәге әдәбият институты каршында язучылар өчен Югары әдәбият курслары ачылган икән дигән хәбәр таралды. Кабул итү шартлары каты: иң беренче шарты — СССР Язучылар әгъзасы булу. Икенчесе — һәрбер республикадан нибары бер генә кеше кабул ителәчәк. Шул сәбәпле конкурс игълан ителгән. Татарстаннан биш-алты кешенең гариза бирүенә дә карамастан, мин дә бәхетемне сынап карарга булдым. Җавап озак көттермәде. Конкурска җибәрелгән әсәрләребез белән танышканнан соң, бары бер мине генә кабул иткәннәре билгеле булды.
Бу 1955 елның җәе иде.
Шулай итеп, мин яңадан студент. Яңадан Мәскәүдә. Аерма тик шунда, сугыш елларында ачлы-туклы яшәгән чаклар бик еракларда, томан артында калган... Югары курсларда исә һәр туган көн бәйрәмгә тиң иде дисәм, һич тә хаклыкка хилафлык кылу булмас. Анда илебезнең төрле почмакларыннан җыелган төрле милләт әдипләре. Җәмгысы кырыклап кеше. Кем әйтмешли, җитмеш җирдән җыелган булсак та, бер гаиләдәй тату яши идек.
...Сәбәбе нилектән булгандыр, мине аеруча яраталар, үз итәләр иде. Әрмәннәр «Хасанян» дип дәшсә, грузин Вано Цховребов «Махмудашвили» дип кенә җибәрә. Дусларча шаяруның, уен-көлкенең һич тә иге-чиге юк иде».

Әйе, Мәхмүт ага тормышны, кешеләрне ярата иде һәм кешеләр дә аңа (күп чакта!) шундый ук хисләр белән җавап кайтаралар иде. Аңлашыла ки, шушы ярату, тормышны тирәнрәк аңларга омтылу хисе аның тулаем иҗатына да уңай йогынты ясады. Аның иҗади яшьлеге, әйткәнебезчә, Татарстанда нефть ятмаларын эшкәртә башлау чорына туры килде, һәм гаҗәп тә түгел, Югары әдәби курсларны тәмамлап кайтканнан соң, ул нефтьчеләр тормышын якыннанрак өйрәнү максатыннан (дөресрәге, мәҗбүриләп) Азнакайга күченеп китә (ул анда егерме елдан артык яши), һәм бер-бер артлы хикәя, повесть, романнар иҗат итә. Шушы елларда ул «Саф җилләр» (1961–1963) нефть төбәгендә автострадада эшләүчеләр тормышын яктырткан «Юллар, юллар...» (1964), КамАЗ төзелешенә багышланган «Кама таңнары» һәм «Инженерлар», тарихи-революцион темага «Саумы, кояш» (1973), колхоз тормышыннан алынган «Хәдичә», нефтьчеләргә багышланган «Шөгеровлар» кебек киң полотнолы әсәрләрен тудыра.
Әмма бу юл, текәгә күтәрелү, аңа җиңел генә бирелми. Гел шат, гөрелдәп көлеп йөрүче, батыр йөрәкле, алыптай бәдәнле Мәхмүт агабыз менә нәрсә ди. «Истәлекләр»дән үзен тыңлап карыйк.
«...Казаннан киткәч, күп нәрсәгә күзем ачылды. Чын, турылыклы дус дип йөргән каләмдәшләремнең чын йөзен күрдем. Кайберләре ачыктан-ачык хыянәт иттеләр. Шундый чакларда Казаннан китүемә чынлап торып үкенә башлый идем».
Шулай да, тоннель артында кайчан да булса яктылык күренәчәк дигәндәй, аны шул коткаручы яктылыкка әйдәп чыгучылар Хәсән ага Туфан белән Сибгат ага Хәким булалар.
«...Шулай тома ялгыз, шөбһә белән өмет арасында каңгыраеп яшәгәндә, көтмәгәндә-уйламаганда, тугрылыклы якын дустым Сибгат ага килеп чыкты... Мәкерле, икейөзле «дуслар»дан чак кына зарланып алдым булса кирәк.
— Зарланма!.. — диде Сибгат ага, гадәтенчә тыныч, сабыр гына...
...Көчең бар, дәрт-дәрман да җитәрлек... Кулга тотарлык зур әсәр, чын әсәр кирәк. Телгә керерлек, укучылар күтәреп кабул итәрлек әсәр кирәк. Синең кулдан килә торган эш бу. «Хокук якларга» ташланмый торган, бомба шартлагандай тәэсир итәрлек әсәр кирәк. Масштаблы фикер йөртә беләсең... Сюжет һәм композицияне төзи беләсең. Бу сыйфатың һәрбер әсәреңдә диярлек чагыла...
...Азнакай яклары безнең аксакалларыбызны да яңа әсәрләр иҗат итәргә илһамландырды, дәрт бирде. Әсәрләребез өчен материалны да бергәләп тупладык. Күрше-күлән авылларда да күп булдык, ферма терлекчеләре белән дә очраштык. Әле дә булса хәтеремдә, Хәсән ага, ферманың буеннан-буена йөреп, сыерларның исем-кушаматларын язып йөргән иде. Аның бу шөгыле миңа чак кына сәер тоелган иде.
Сибгат ага исә, гомерләре буена фермада эшләгән өлкән яшьтәге савымчылар, көтүчеләр белән гәп сатарга ярата иде.

Әгәр дә мин хәзер, «Саф җилләр» романымны иҗат итәргә Сибгат Хәким белән Хәсән Туфан көч-дәрт, илһам бирделәр, кулымнан диярлек тотып яздырдылар» дисәм, бик күпләрне гаҗәпләндерер иде, мөгаен. Әмма бу шулай иде...
...«Саф җилләр» матбугатта да уңай бәяләнде. Кемнең кем булуы белән исәпләшеп тормаучан, сәнгать әсәрләренә карата ифрат та таләпчән... Ибраһим ага Гази Хәдичә образы турында болай дип язган иде: «Шунысы гаҗәп: башта Хәдичәдән җирәнгән булсам, ахырда мин аны яраттым. Әйе, Хәдичә үзен яраттыра. Бу исә авторга да, безгә дә сабак».
Гомумән, Мәхмүт Хәсәновның иҗат лабораториясен, күңел тирбәнешләрен аңлау, ул чактагы, ул еллардагы гомуми әдәби процессны чамалау җәһәтеннән әлеге истәлекләр уникаль документ булып торалар. Кызганыч ки, кеше китә... һәм үзе белән бик күп әйтелмәгән серләрне дә алып китә. Башка бик күп язучылардан аермалы буларак, Мәхмүт ага үзенең йөрәген ачып салудан курыкмаган. Бу да бит олы әдәбиятның дәвамы.
«...Чак кына чигенеш ясап, ул еллардагы тормышым, иҗади эшчәнлегем турында бер-ике авыз сүз әйтәсем килә. Тормышым түгәрәкләнде, менә дигән, теләсә кем кызыгырлык гаилә корып җибәрдем. Иҗади эшем дә, кем әйтмешли, үкереп алга бара. Дәртләндереп, илһам биреп торучым, тугрылыклы дустым-остазым Сибгат ага да янымда. Шундук Хәсән Туфан. Иң хикмәтлесе шунда: икесе дә миңа зур ышаныч белән, олуг өметләр баглап карыйлар...»

Бу юллар Мәхмүт Хәсәновның архивында сакланып калган «Дустым да, остазым да иде» дигән истәлекләреннән алынды. Әлеге әсәрдән алга таба да өзекләр китерелер. Чөнки язучының асыл кичерешләрен, эчке дөньясын, иҗат лабораториясен тулырак аңлау өчен аның үзеннән дә төгәлрәк әйтеп бирү мөмкин түгел. — *(Н.Г.)*

...Ул вакытта инде ил өстеннән чын мәгънәсендә шифалы, саф җилләр исә башлаган иде. Минем әсәрләрем өчен дә... юл ачылды. Баштарак (чак кына кыскартылып булса да) «Шөгеровлар», бераздан «Хәдичә» дөнья күрде. Икесе дә искиткеч матур рецензияләр белән каршыланды. «Хәдичә» турында группачылардан курыкмыйча уңай фикер әйткән кеше, талант иясе Хәсән Сарьян булды. ...Хәсән Сарьян үзенең «Бүгенге авыл һәм аның кешеләре» («Казан утлары» журналының 1975 ел 1–6 саннарында чыккан роман һәм повестьлар турында) дип аталган докладында Хәдичә образын күкләргә чөеп мактады. ... Хәдичә образына туктап ул болай диде: «Инде әсәр турында гомуми нәтиҗә ясап шуны әйтәсем килә: Мәхмүт Хәсәновның бу әсәрендә бик нык эшләнгән бер образ бар, ул — Хәдичә. Автор аны бик тә яратып, хатын-кызның нечкә хисләрен белеп язган. Хәдичәне мин үзем нәфис күңелле хатын буларак та, көчле натура буларак та яратып кабул иттем. Шуның өстенә ул бөтен эш, бөтен җаваплылык үзе өстенә төшкән, колхоз производствосын әйдәп баручы заман герое буларак та үрнәк ителерлек шәхес. Хәдичә — Мәхмүт Хәсәновның әдәби уңышы: кешелекле дә бу, эшчән дә бу, мәхәббәтле дә бу».
Мәхмүт Хәсәнов чын мәгънәсендә тынгысыз җанлы әдип иде. Сәяхәтче иде. Ул заман сулышын тоеп яшәде. Аның өчен бервакытта тема кытлыгы булмады. Кайда яңалык — ул шунда иде.
«...Уңышлар белән канатланып яңа әсәр язарга керештем. Роман гадәти түгел. Чорыбызның бөек төзелеше КамАЗ автомобиль гигантын төзүчеләр турында. Әсәр бик катлаулы булыр сыман иде. Хикмәт, дөньяда тиңдәше булмаган төзелеш булуында гына түгел, аның татар җирлегендә барлыкка килүе, аның татар халкы тормышына, гасырлар буе тупланып килгән гореф-гадәтләренә дә, милләт буларак рухи үзенчәлекләренә дә күпмедер дәрәҗәдә йогынты ясаячагы турында иде.
Әлеге тиңдәшсез төзелештә мин ялгыз түгел, һаман да шул гел хәрәкәттә, гел ил гаме белән яшәүче тынгы белмәс Сибгат ага Хәким белән. ...Мин романымны «Кама таңнары» дип атадым. Тора-бара хәтта икенче китабын — «Инженерлар» дип исемләнгән дәвамын да яздым».
Бүген бу юлларын укыйсың да хәйран каласың: Сибгат ага белән Хәсән ага Мәхмүт Хәсәнов өчен чын мәгънәсендә юл күрсәтүче, киңәшче булганнар икән. Хәзер бар микән ул андый олуг шәхесләр, «кече энекәшләренә» һәрдаим ярдәм итәргә әзер торучы аксакаллар? Әллә соң заман башка, җен башкамы?
«...Инде сабыр канатларым сына дип кенә торганда, зарыгып, интизарлар булып көткән хәбәр килеп төште. Очар өчен канат кирәк булган кебек, иҗади юлыңда да Сибгат Хәким, Хәсән Туфан ише олы җанлы, игелекле-шәфкатьле, әүлияларга тиң кешеләр очратасың икән!» — дип яза Мәхмүт Хәсәнов һәм Сибгат аганың үзенә атап язылган хатыннан түбәндәге юлларны китерә: «Һәрвакыттагыча темаларны оста тотасың. «Шөгеровлар» бик кызык тема язар өчен, искиткеч кызык! Үзебезнең җир, Шөгер тавы, нефть һәм Шөгеровлар нәселе, токымы һәм Америка. Ясалма түгел, просто тормыш үзе. Бик әйбәт урыннар шушы өлештә. Әсәрнең күп урыннарын яратып укыдым. Китап итеп тапшырганчы әле эшләрсең дип уйлыйм. Эшләргә кирәк. Мин күбрәк

Шөгеровлар династиясенә игътибар итәр идем, шушы сызыкны гына алып барыр идем. Шөгер тавын да просто натуралистик бер тау гына түгел, безнең тарих, төрле вакытлар узган җир, бәйрәмнәр, гореф-гадәтләр белән. Шөгеровлар шунда туган. Америка вәкиле шул җир белән таныша бит! Бу тау — символ. Шушындый поэтик сурәтләү җитми. Син — егермедән артык әсәр язган кеше. Хәзер тәҗрибәң зур, көчең-энергияң Аллага шөкер. Шөгер тавын куптарырлык. Тик ятмыйсыңдыр, эшлисеңдер, минем фикерләрне дә искә ал...»

Бу чорда Мәхмүт Хәсәнов, беренче хатыныннан аерылып, Мәрьям ханымга өйләнә. Мәрьям ханым бүген дә Мәхмүт Хәсәновның якты истәлеген саклый.

Һәм нәтиҗәдә укытучысының да «фикерләре искә алынган» «Шөгеровлар» романы дөньяга килә.
Исеменнән үк аңлашылганча, әсәрнең үзәгендә Шөгеровлар династиясенең язмышы; ләкин язучы моның белән генә чикләнми, шушы «язмыш» аша ул татар халкының үткәнен, бүгенгесен, киләчәген тасвирлый. Әсәрнең сюжеты бик кызык коллизиягә нигезләнгән. Шөгеровлар — данлыклы нефтьчеләр нәселе. Рахман карт заманында Бакуда нефть чыгарган, герой дәрәҗәсенә ирешкән. Улы Корбан да нефтьче. Оныгы Ногман да өлкәннәр эзеннән атлый. Кыскасы, тормыш арбасы җай гына теркелдәп алга бара. Ләкин көтмәгәндә-уйламаганда, нәселне сискәндерерлек бер хәл булып ала — аларга АКШтан миллионер Шандор килеп чыга. Кызык ич: кем соң ул сәер миллионер, ни өчен ул нәкъ менә Шөгеровларга килгән? Бу романында да Мәхмүт Хәсәнов үзен әнә шундый укучыны кызыксындырырлык тормыш материалы таба белүче оста итеп таныта, иҗатында тагын бер матур сәхифә булырлык әсәр иҗат итә.
Мәхмүт Хәсәновның «ата балыкчы» икәнлеге «бөтен дөньяга» билгеле иде. Бу турыда булганын да булмаганын да кушып язучылар арасында күп сөйләнелде. Кем белә, язучы, бәлки, нәкъ менә табигать белән күзгә-күз очрашканда язарына ризык тапкандыр да соңрак ак кәгазьгә төшергәндер? Мөгаен, шулайдыр. Архивтагы ядкярләр әнә шул хакта сөйли.
Лениногорски шәһәрендә яшәп иҗат итүче Шамил Бикчурин белән алар озак еллар дус, фикердәш булып яшәделәр. Бу иҗади дуслыкка илаһи тын иртәләр, серле Ык елгасы, бөдрә таллар да шаһит. Әлеге рәсемдә Шамил Бикчурин Мәхмүт Хәсәновның чираттагы «балыкчы ялганнарын» тыңлап утыра.
Ә икенче рәсемдә...
*...Фотолар өемен актаруымны дәвам итәм. Хәсән Туфан, Сибгат Хәким белән бергә төшкән фотолар аеруча күп. Арада аеруча истә калырлыклары, бик тә кадерлеләре бар. Менә без таң кебек якты булып, җыр кебек матур булып ишелә-ишелә аккан гүзәл Ык буенда кармаклар салып ятабыз. Икенче бер фотода шул ук табигать бизәге — Ык буенда, учак янында утырабыз...*
*Алгы планда Хәсән ага Туфан утыра. Ул сырган чалбардан. Аякларында кирза итекләр. Өстендә дә сырма. Гадәттәгечә яланбаш. Кулындагы чыбыгы белән таралган кисәүләрне учаккарак тарта, мул булып төшкән күмерне бер тирәгәрәк җыя. Бары тик шуннан соң гына алдан ук хәзерләп куелган коры-сарыны учакка сала. Учак гөлт итеп кабына... Шуны гына көтеп торган кебек, эңгер-меңгер тагын да куера төшә. Елганың ике ярын кавыштырырга теләгәндәй, тирә-юньне сыек томан пәрдәсе сара. Елганың аръягындагы таулар тезмәсе артыннан, дозорга чыккан кебек, тулы ай калка.*
*Учакның икенче ягында Сибгат Хәким утыра. Мин палатка янында. Тынлык хөкем сөрә. Сөйләшмибез, һәркем үз уена чумган. Андый чакта сүз артык. Хәсән ага Туфанга игътибар итәм. Йөзе шултикле дә җитди, уйчан...*
*Шушы урынга җиткәч, сүзне Сибгат агага бирәсем килә. Аның Хәсән Туфан истәлегенә багышланган «Аккош күлендә сагыш, моң...» дигән язмасында мондыйрак юллар бар: «...Ә Ыкта нәрсә калган? Ыкка җилкендерүче кеше ата балыкчы Мәхмүт Хәсәнов иде. Октябрь, җилсез, йомшак, җылы. Ык әрәмәләре тартты безне. Мәхмүт борчакны күп сипсә дә, балыгы әллә ни эләкмәде, әмма җәелеп, тулып аккан Ык үзе, болыны, бай табигате белән ниндидер хыялый, шигъри дөнья эченә алып керде. Мәхмүт безне балыкка гына дип алып килгәндер. Әмма мин аңа шушында очраштырган өчен эчемнән рәхмәт укыйм... Кинәт Ык тынлыгына юлыккан Туфанга да бу сихри дөнья шулай сәер тоелгандыр дип уйлыйм. Ярлар тын. Әрәмәләр тын. Әрәмәдә гөлҗимеш, балан. Балыкчылар...»*
Шул ук язмасында әдип, Хәсән Туфанның учак ягарга яратуын, учак ягарга «изге бер эшкә тотынган кебек керешүен» сурәтли. *«Иплэп чыбык-чабык сындырды. Бөтен шартын китереп учак якты. Күмерләре төшкәч, учакның өстенә үк иелде, бөтен гәүдәсе белән шундый иелде, утка менә-менә төртелер төсле. И актарды утны, и болгатты утны... Ахак күмерләр эченнән нәрсәдер*

*эзли иде ул, нәрсә эзли? Нәрсәне югалткан!..»*
Мәхмүт Хәсәновның 1987 елда «Язгы аҗаган» романы басылып чыкты һәм аңа шушы әсәре өчен Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге тапшырылды. Гомеренең соң ноктасын ул әнә шулай егетләрчә — һаман да үргә күтәрелеп барышлый куйды.
Ул балык тотарга яраткан Ык ага да ага...
Ул яккан учаклар дөрли дә дөрли...
Тормыш дәвам итә.
*«Казан утлары», декабрь, 1997*

## ГОМЕР УЧАГЫНЫҢ ЯЛКЫНЫ

Әдәбият ул, тулаем алганда, гомуми иҗат җимеше. Аның туктаусыз хәрәкәт итүе исә турыдан-туры аерым шәхесләрнең эшчәнлегенә бәйләнгән. Бу нәүбәттән, бүгенге әдәби хәрәкәтнең үсеш тенденцияләре турында сүз алып барсак, аны Тәлгат әфәнде Галиуллин эшчәнлегеннән башка күз алдына китерүе мөмкин түгел.
Киң кырлы талант иясе 1938 елның 22 июлендә Татарстанның Норлат районы Кычытканлы авылында зыялы гаиләдә дөньяга килә. 1956 елда Казан дәүләт университеты тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген уңышлы тәмамлагач, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында кече гыйльми хезмәткәр вазифасын башкара.
Тынгысыз, максатчан яшь галимне «өлкән агайлар» бик тиз күреп ала һәм аңа берсеннән-берсе җаваплырак эш тапшыралар. 1965 елда ул Алабуга педагогия институтына эшкә күчерелә — анда татар һәм рус әдәбияты буенча лекцияләр укый, гамәли дәресләр алып бара; озак та үтми, ягъни 1967 елдан инде ул институтның уку-укыту һәм фәнни эшләр буенча проректоры; 1971–1986 елларда исә ректор булып эшли. Әйтергә кирәк, Тәлгат Галиуллин галим буларак та, җәмәгать эшлеклесе буларак та нәкъ менә шушы чорда җитлегә: Алабуга педагогия институты чын мәгънәсендә тугыз факультеты булган киң профильле уку йортына әверелә.
Иҗтимагый һәм педагогик эшчәнлек белән бергә ул татар әдәбиятына да армый-талмый хезмәт итә, аның, нигездә, татар шигъриятенә багышланган үткен фикерле, күзәтүләргә бай, фәлсәфи җегәрлеккә ия тәнкыйть мәкаләләре, эссе-уйланулары бер-бер артлы дөнья күрә башлый. Ахырдан алар «Яңа үрләр яулаганда» (1972), «Еллар юлга чакыра» (1975), «Безнең заман — үзе җыр» (1982), «Шагыйрьләр һәм шигырьләр» (1985), «Дәвамлылык» (1987), «Гомер догасы» (1991) дигән исем астында аерым китап булып басылып чыгалар. Безгә калса, әдәби тәнкыйтьтә ул соңгы дәвернең олуг шигырь белгечләре Х.Госман белән Н.Юзиев традицияләрен дәвам итә кебек. Аның мәкаләләре киң колачлы, сәламәт рухлы, кайнар пафослы һәм, иң әһәмиятлесе, Тәлгат ага авторларны яратып яза, аларны бер илаһи зат итеп күрә; үз чиратында шушы хис-кичерешләр аның мәкаләләренә җан өрәләр, нур өстиләр, колачын билгелиләр. Т.Галиуллинның «Шагыйрьләр һәм шигырьләр» дигән китабында сүз 80 нче елларда поэзиябездә җиң сызганып эшләп килүче ун шагыйрь — С.Хәким, Н.Арсланов, Г.Афзал, И.Юзеев, Ш.Галиев, Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Р.Мингалимов, Г.Рәхим, М.Әгъләмов иҗаты турында барды. Озак та үтмәде, тынгысыз җанлы әдип, иҗади эзләнүен дәвам итеп, Ә.Баянов, Роберт Әхмәтҗанов, Р.Гатауллин, З.Мансуров, Ш.Анак, Ә.Рәшитов һәм башка шагыйрьләрнең иҗатына багышланган мәкаләләре тупланган «Гомер учагы» дигән мәҗмугасын бастырып чыгарды. Әдипнең үзе әйтмешли, шагыйрьләр һәм шигырьләр... Ул шушы дөньяда яши, хезмәт итә, шигырь аңа яшәү көче бирә, ә шигырьдән көч алган кеше инде битараф, салкын канлы була алмыйдыр, мөгаен.
Соңгы елларда мөхтәрәм галимебез, принципиаль тәнкыйтьчебез әдәбият бакчасының башка жанрында да илһамланып эшкә кереште. Бай тормыш тәҗрибәсе туплаган күзәтүчән әдип үзенең «Замана балалары» дигән истәлек-уйлануларын бастырып чыгарды; күп тә үтмәде, аларның дәвамы да дөнья күрде («Дәгъва») һәм зур уңышка ирешде. «Истә калган кадәресен арттырмыйча һәм киметмичә сөйләп бирергә тырыштым», — ди автор үзенең җыентыкка язган «башлам кәлимәсе»ндә. Әйтергә кирәк, тормыш-көнкүрешкә тәнкыйди күз белән карый белгән әдипнең иҗат диапазоны шул рәвешчә елдан-ел киңәя, яңадан-яңа төсләргә байый бара: «Кияү», «Һавада Гагарин», «Колючник» кебек хикәяләрендә ул үзен чын, өлгергән прозаик итеп танытты: аның сурәтле фикерләвенә үткәндәге вакыйгаларга бүгенге көн күзлегеннән килеп бәя бирү, җиңелчә киная, юмор, җорлык хас. Шушы сыйфатлар Т.Галиуллинның «Тәүбә» романында тагын да ачыграк чагыла; бүгенге куркыныч, болгавыр чорыбызны җанлы вакыйгаларга нигезләп истә калырлык образлар белән яктырткан, ирония белән сугарылган бу күләмле әсәр тиз арада үз укучысын тапты, авторның һәм әдәбиятның уңышы дип бәяләнде.
Сер түгел, соңгы елларда прозаикларыбызның сафлары сирәгәйде: өлкән әдипләребез

өлкәнәйде, яшьләр «яшел» хәлдә. Сөенечлесе шул: шушы бушлыкны тутыру юнәлешендә Тәлгат ага кебек киң эрудицияле әдибебез уңышлы эшләп килә.
Бер-ике битле генә язмамда Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Русия Гуманитар академиясенең академигы, әдәбият өлкәсендә Гаяз Исхакый исемендәге премия лауреаты Тәлгат ага Галиуллин турында менә шуларны укучыларга әйтергә кирәк дип таптым. Һәм аңа олуг юбилей көннәрендә бәрәкәтле иҗат телик.
*«Шәһри Казан», 17 июль, 1998*

**АККОШ КҮЛЕНДӘ УТЛАР...**

Шулай да Ходай тарафыннан сихерләнгән урындыр бу язучыларның Аккош күлендәге иҗат йорты. Алай булмаса, анда бер-берсенә охшаш сәер хәлләр кабатланып тормас иде. Әллә югыйсә, язучылар үзләре тылсымлы көчкә ия булган, юктан да барны эзләүче гаувас затлармы соң? Тел төбем әйбәтрәк аңлашылсын өчен, фикер йомгагымныерактанрак сүтә башлыйм әле.
Әдәбиятта «күчмә сюжет» дигән төшенчә бар. Теге яки бу әсәрдән икенчесенә күчеп йөри торган, кабатланучан сюжет-вакыйга охшашлыкларын, идея-мотивларның бердәйлеген, эстетик принципларның тәңгәллеген аңлата торган төшенчә ул. Көтмәгәндә- уйламаганда, шушы «күчмә сюжет» дигән җилкәнле көймә минем пристаньга да сугылып үтәсе итте бит әле.
Бу хәл болайрак булды. Чордашым Мансур Вәли иҗатын, тормыш юлын кабаттан күздән кичереп, уй-хисләремне тәгаенләп, бер төенчеккә төйнәп шушы язмамны язарга җыенып йөргән көннәрнең берендә, аның белән Сибгат ага Хәким арасында булган гыйбрәтле бер вакыйга кылт итеп исемә килеп төште. «Шагыйрьнең уты» дигән җылы рухлы, «якты тәрәзәле» бер мәкаләсендә ул болай дип язып үтә:
«— Быел без яшьләргә дә аннан урын бирделәр. Ләкин ул әле яңа гына салынган булганлыктан, тулысынча көйләнеп, тиешле бөтен нәрсә белән дә җиһазландырылып бетмәгән. Шуңа күрә ут та юк.
...Үзем дә аңышып җитмәгән әнә шул халәттә утырганда, әкрен генә тышкы ишек ачылып китте һәм берәү өйгә үтте.
Аңа каршы чыккач, мин күршебез Сибгат ага Хәкимнең таныш тавышын ишеттем.
— Төн караңгы, ут кирәк булыр... — диде ул, кулындагы шәмен миңа сузып.
Шулай итеп, бу август кичендә Аккош күленең тагын бер йортында ут кабынды!»
Ни хикмәт, әйткәнемчә, шушы хәлләрдән соң шактый еллар узгач, Мансур белән безнең арада да «шәм шәрифләренә» бәйләнешле рәвештә шушыңа охшаш бер очрашу булып алды — моны «күчмә сюжет» димичә ни дисең. Бу очракта Мансур үзе Сибгат ага ролендә иде инде.
Шулай бервакыт, җәйдән көзгә авышып килгән көннәрнең берендә, Мөдәррис Әгъләмов мине, ай-ваема карамыйча, Аккош күленә кунакка кыстый башлады.
— Әйдә әле, дустым, — диде ул гадәтенчә җилкенеп, җилфердәп. — Соңгы вакытта шәп әйберләр яздым, җәелеп бер шигырь укып утырырбыз.
Шагыйрьләр арасында бер-береңә кычкырып шигырьләр уку түгел, язганнарын да караштырып бармаган бер заманда, мин сиңа әйтим, көтелмәгәнрәк тәкъдим иде бу. Хәер, Мөдәррис хәйләкәр кеше ул, минем шигырь тыңларга яратканлыгымны белә, бигрәк тә аның үзенең укуында тыңларга яратканлыгымны. Шулай да икеләнә калдым, ник дисәң, пыскаклап яңгыр сибәләп тора иде.
— Көне бигрәк шыксыз бит.
— Мичкә ягып җибәрербез.
— Автобус йөриме соң?
— Гөмбә дә тозлап куйдым, опяталар мыжлап торган чак бит.
— Шулаен шулайдыр да...
Инде болай да күндереп булмаслыгын аңлагач, Мөдәррис соңгы «снарядын» да җәлләмәде:
— Күңелле булыр, Мансур Вәли дә килә. Өчәүләп, шәпләп утырырбыз.
...Хуҗаның такта алачыгын җылытып, табын хәстәрләгәнче, караңгы да төште. Тышта яңгыр сибәли, әмма бүлмәдә рәхәтлек хөкем сөрә — томаланган мич авызындагы кузлардан, җанны изрәтеп, кызгылт шәүләләр тарала. Өй тулып, почмаклардан-почмакларга бәрелә-бәрелә, шигырь агыла. Менә шулай хозурланып утырганда гына, кинәт ут сүнде. Караңгылык эчендә утырып калдык.
Мөдәррис сикереп урыныннан купты:
— Хәерсез, тагын ни булды икән инде?
Шулчак күрше йорт ягыннан тавыш ишетелде:

— Әhe-he-həй! Мө-дәр-рис!..
Болдырга чыгып бастык. Мансур Вәли икән.
— Калдыгызмы утсыз? — Үзе шаркылдап көлә. — Үзегез — моңлы балалар, ә үзегезнең шәмегез дә юктыр әле...
Мөдәррис, сукмакка ук чыгып баскан манма су кураларны ера-ера, тавыш килгән якка китеп югалды; күп тә үтмәде тагын, Мансурны ияртеп әйләнеп тә кайтты. Ул төнне без, өчәүләп, мәгарә эчендә яшәгән мәҗүсиләр кебек, утка табынып, Хәсән ага Туфан, Сибгат ага Хәкимнәрнең Аккош күлендә яшәгән чакларын искә алып, өлкән әдипләребезнең рухларын тергезеп, галиҗәнап шигырь хозурында сәҗдә кылып утырдык... Шушы бәхетле минутларда яктылык сирпеп торган шәм миңа теге чакта Сибгат ага Мансурга кертеп биргән шәмнең үзедер кебек тоелып китте; Мансур бары аның утын шушы кичкә хәтле сүндермичә генә саклап алып килгәндер: нәкъ менә «Шагыйрьнең уты» дигән мәкаләсендә язылганча, «мондый утлар, сүнмичә, буыннан-буынга күчеп килә»дер.
Бүген исә мин шушы ут яктысында Мансур әфәнденең гомер китабының сәхифәләрен укып утырам. Укыйм, укыйм да, язмышларда уртак мизгелләр табып, тукталып уйга калам.
Татар әдәбиятына язучылар, башлыча, авылдан килә. Ә авыллар инде алар, ни дисәң дә, берберсенә охшашлар, андагы тормыш-көнкүреш тә, кешеләренең «язмышлар яры» да охшаш. Күзаллыйм: әнә Әгерҗе районының Барҗы авылында бер малай үсеп килә... «Мәктәпкә кергәнче үк хәреф танырга өйрәндем бугай. Авыл агайларының кибет почмагында көлә-көлә миннән афиша укытулары хәтердә калган», — дип яза Мансур Вәли әле беркайда да басылып чыкмаган «Үзем турында» дигән язмасында. Ул миңа аны, бәлки, кирәге чыгар дип, укырга биреп торган иде. Хәзер, кирәге чыккач, бик теләп, автор рөхсәте белән әлеге язмадан кайбер өзекләр китереп үтәм. Билгеле, китаплар бик күп укылды инде. Барҗы авылының китапханәсе минем өчен иң кадерле, иң якын урынга әверелде. Авыл китапханәсе ул инде сирәк ачыла, шуңа күрә кышкы салкын көннәрдә аның ишек төбендә сәгатьләр буе ачылганын көтеп торасың».
«— Ә инде эчкә уза алсаң, синнән дә бәхетлерәк кеше юк бу дөньяда. — Бусы Мөслим районының Бүләк авылында туып үскән Наис дигән берәү авызыннан әйтелгән сүзләр. — Авылның китапханәчесе Мирфәез абый Галиев иде...»
Китапханәдә һәрвакыт чиста, пөхтә, кояшлы иде, иҗади мохит хөкем сөрә иде. Мөдир киңәшче, өлкән сердәш, фикердәш иде. Китапның изге җан иканлегенә беренче булып ул төшендерде. Ул сиңа китапларны үзе тәкъдим итә, кире тапшырган вакытта үзенә күрә бер имтихан кебек нәрсә дә уздырып ала: китапның асыл мәгънәсен аңларга тырышып укыгансыңмы син, пычратмагансыңмы, таушалган булса, төпләгәнсеңме, ябыштыргансыңмы? — барысы да аның күз уңында. Аның болай төпченүенә китап җене кагылган малай-шалайларның кәефе кырылмый, киресенчә, үзеңә аерым игътибарны сизеп, китап тапшырасы көнне дүрт күз белән көтеп аласың. Әйе, элегрәк укый иде авыл халкы. Һәм, әлбәттә, кечкенә генә авылдан бер чорда дистәләгән егетнең югары уку йортлары ишеген үтә алуында китапханәченең дә йогынтысы булмый калмагандыр.
Мансур Вәлиев яза:
«— Мәктәптә беренче укытучым Хәдичә апа Шәрифуллина булды. Аннары Әстерхан ягыннан кайткан һәм безнең авыл кешеләренең яраткан кешесенә әйләнгән Гөлсем апа укытты. Ул минем язуга һәвәслекне сизеп алды һәм Казанга радиога, балалар өчен тапшыруларга хәбәрләр җибәрергә киңәш биреп (бигрәк беркатлы булган инде), «гариза язып сал, хәбәрче итеп алсыннар» диде. Гариза язуын язмадым, әмма тиздән хәбәрче булып киттем.
Өченче-дүртенче сыйныфта укыганда, Красный Бор район газетасына мәкаләләр җибәрә башладым. Алар басылып чыкты. Күңел үсеп китте. (Хәтерлим, таныш халәт, беренче шигырем район газетасында күренгәч, мин дә кош тоткан кебек очынып йөргән идем. — *Н.Г.*)
Безнең Барҗы авылында атаклы драматург Юныс абый Әминевнең яшәве ничектер, үзем дә сизмәстән, мине шундыйрак шөгыльгә тартты, ахрысы. Башлангыч сыйныфларда укыганда бугай, дәфтәрләрне бергә теркәп китап шикелләрәк бер әйбер оештырып куйдым. Беренче хикәяләрем шунда язылган. Әле дә булса саклананалар. Колхоз радиосы аша «Мәктәп тәрәзәләре» дигән радиогазета оештырып, бик мавыгып йөргәннәр дә истә калган. Мәктәптәге күңелле хәлләр турында Әгерҗе район газетасына да күп яздым. Актив хәбәрче идем.
1966 елда 10 нчы сыйныфта укыганда, минем турыда Мәскәүдә чыга торган «Рабоче-крестьянский корреспондент» дигән журналда фоторәсем белән бергә язып та чыктылар.
Урта мәктәпне бетергәч, ни өчендер тагын да уку теләге булмады. Уку туйдырган кебек булды. Мине Әгерҗе район газетасы редакторы Тәүфыйк абый Рәхмәтуллин үзенә эшкә алды».
Шушы юлларга килеп төртеләм дә, эсселе-суыклы булып китә. Мин дә бит, моннан күп еллар элек, хезмәт юлымны район газетасыннан башлап киткән идем. Күрде инде күрәчәк башлар...

Язгы юл өзеге дип торылмаган, җәйге чиллә яки кышкы зәмһәрир суыклар да туктатып кала алмаган, ачлы-туклы килеш хәбәр эзләп авылдан авылга чабылган... Олыларча кыяфәткә кереп, бик тә әһәмиятле сүз әйткән кебек, редакция бүлмәсендә төнгә кадәр мәкаләләр язылган. Акыл өйрәтүләр, кыекны турыларга ясканып йөрүләр... Без идек микән соң ул, Мансур дус?
«Әгерҗедән 70 чакрым ераклыктагы Барҗы дигән туган авылыма күмер төягән трактор чанасы өстендә төн буе кайтулар бик тә хәтергә сеңеп калган. «ДТ-54» тракторы кырмыска кебек кенә үрмәли: төн салкын, ара бик ерак, өстә юка... Шыкраеп катасың... Әле җитмәсә, батып та ятасың. Салкын трос сөйрәп әрле-бирле чабасың. Таң аткандарак кына авылыңа кайтып керәсең. Анда сине, борчылып, әти-әниең көтә инде, ачулана-ачулана...
Әнә шулай үз башыңа үзең кыенлык табып, хәбәрче булып йөрисең. Атаң яшендәге колхоз рәисләренә дә авыр сүзләр әйткәләргә туры килде, гаделлек өчен дип. Кешеләргә кирәк дип. Казан газеталарында да усал-усал мәкаләләр, фельетоннар бастырырга туры килде. Ике ел эшләгәч, әнә шулар белән Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга керү җиңел булды».
Буш сүз түгел бу. Яшь каләм иясе үзен киләчәк өчен әнә шулай чыныктыра килгән. Һәм 1968 елдан башлап, Әгерҗенең колгасар егете, студентлык кысаларына гына сыеша алмыйча, гәзитә-журнал редакцияләре бусагасын да таптый башлый. Бүгенге көндә исә без әнә шул егетне үҗәт, максатчан, хөр фикерле, компромиссларга бик авырлык белән бара торган тәнкыйтьче Мансур Вәли дип күреп беләбез. Әйе, үз гомерендә ул бик күп язучы агай-апайларның күңеленә хуш килерлек ягымлы, җылы, хакыйкый сүзләр әйтергә өлгерде, бик күпләрнең яраларын төзәтешергә ярдәм итте һәм вакыты белән, кирәк чагында узгынчыларның канына тоз салырга да тайчанып тормады. Шулай, Мансур әфәнде каләмдәшләренең аз гына уңышын да күреп сөенә белә, аңа ярдәм кулы сузарга ашыга. Кайчак, үзсүзле кешеләргә хас булганча, бәяләмәләрендә бер яккарак ташланган чаклары да булды, әмма күпме генә тырышма, син аны сайлап алган юлыннан, инанган фикереннән кире чигендерә алмыйсың. Һәрхәлдә, бу җиңел эш түгел. Кыскасы, әдәбиятка караш мәсьәләсенә килгәндә, максималист ул, кирәк кадәр генә башбаштак та. Шушы сыйфатлары өченме, әллә төс-кыяфәтендә берәр охшашлык табыпмы, Гариф абый Ахунов аңа яратып, үзаралай-юрамалай гына «татар Белинские» дип эндәшкәли, ә Мансурның исе дә китми: «Үз илең булган булсамы, матбугат ирекле булган булсамы... кем белә...» — дип куя, колакка рәхәт сүзләрдән хуш килеп. Сүз дә юк, мөмкинлекләр, колачлар бөтенләй башка, чагыштырып карарга да куркыныч, әмма аның җанында «тәнкыйтьче» дигән гайяр ат ятуы бәхәссез: фикер сөреше белән ул «бәйләнчек»; ул әдәби хәрәкәтнең үзәгендә булырга тырыша, яшьрәк чагында аның бу сыйфаты аерата күзгә ташлана иде. Хәер, тәнкыйтьче өчен моннан башка мөмкин дә түгелдер, күрәсең, үзеңне тәнкыйтьче итеп хис итсәң мөмкин түгелдер. Мансур әфәнде моның шулай икәнлеген яхшы аңлап, җаваплы миссиягә үзен яшьтән үк әзерләп килә. Бу хакта ул болай дип искә ала:
«— Бәләкәй вакытта үзебезнең оч бала-чагасын җыеп, концерт сыман нәрсәләр дә оештыра торган идем.
Казанда, университетта укыганда да татар журналистларының түгәрәге «Яңавазʼ»ны оештырып йөрергә туры килде. Аның стена газетасын чыгардык. Укытучыларга буйсынып та бетми идек, чөнки алар куркалар, ә без әтәч кебек инде, калай әтәчләр! Ләкин ул бик романтик, ямьле, истәлекле чор булды. Атаклы язучыларны очрашуга чакыра идек, кыю-кыю мәсьәләләр күтәрә идек.
Шул кыюлык белән 1971 ел ахырларында атаклы язучы Фатих ага Хөснигә бер ачык хат та язып ташладым. Һәм ни гаҗәп, өлкә комитеты газетасы «Социалистик Татарстан» аны бастырып та чыгарды. Студент малай зур күсәк күтәрә — «сез тормышны бизәп, буяп язасыз!» димәк була... Ул чагында татар язучылары Мансур Вәлиев дигән кеше барлыгына ышанмыйча, бу берәрсенең ялган исемедер, псевдонимыдыр дип уйлаганнар икән. Соңыннан миңа моны сөйләп күрсәттеләр, минем фамилияне хәрефләп тарката-тарката чынлыкта кем язганын белергә теләгәннәр. Үземә күрсәттеләр анысын».
Язучы-тәнкыйтьче булырга теләгән яшь кеше әнә шулай бераз гына әрсезрәк тә, кыю-актив та, амбицияле дә булырга тиеш. Әдәбиятта үз кишәрлегеңне даулау өчен бу аеруча зарур. Әйтергә кирәк, Мансур әфәнде әлеге язылмаган законны бик яхшы үзләштереп юлга чыкты, бәлки, шуңа күрәдер беренче адымнарыннан ук гавам күзенә ташланды:
«— Аннары тагын бер китапка рецензия язган идем, анысы озынрак килеп чыкты да, «Казан утлары» журналына кертеп кара, диделәр.
Таптым ул редакцияне, беркемне дә күреп белми идем, әлбәттә. Язмамны калдырып чыктым. Байтак гомер үтте, барырга куркып йөрим. Ә бер кичне тулай торак коридорында егетләр сөйләшеп тора: алар арасында редакцияләргә еш барып йөри торган Марат Сәгъди дигән егет тә

бар иде, аңа мин язганнарны журналда эшләүче Фәрваз абый Миңнуллин бик мактап сөйләгән, имеш. Шулай итеп, мин «Казан утлары» белән танышып киттем. Фәрваз абый Миңнуллин исә (ул миңа иҗади үсешемдә бик зур ярдәм күрсәтте, урыны җәннәттә булсын) гомере буе минем остазым, бик якын дустым, ярдәмчем булды. Соңгы курста укыганда, мин ул редакциядә бер ел чамасы эшләп тә алдым әле.
1973 елда мине бер айга язучыларның Мәскәү янындагы иҗат йортына җибәрделәр. Гариф абый Ахунов тырышлыгы белән. Мин шунда исемнәре бөтен илгә билгеле булган атаклы язучылар арасында берүзем бер бүлмәдә яшәп, бушлай ашап дигәндәй (әле студент чак бит), бәхетле көннәр кичердем; чын иҗат ләззәтен татып, әдәбият мохитен күреп-тоеп кайттым. Валентин Катаев, Евгений Евтушенко, Мостай Кәрим, Андрей Вознесенский, Мирза Торсынзадә, Сильва Капутикян, Фазу Алиева, Мариэтта Шагинян кебек шагыйрь-язучылар белән очрашу күңелдә тирән эз калдырды».
Ничек кенә булмасын, менә шушы хәлләрдән соң Мансур күзгә күренеп җитдиләнеп, олыгаеп китте; шушы чордан башлап ул «әдәбият ахшамы»нда тәнкыйтьче буларак катнашу өчен тавышын көйләп, җиңен сызганып куйды.
«— 1975 елда, Ерак Көнчыгышның Спасск-Дальний шәһәрендә ике ел армиядә хезмәт итеп кайткач, Язучылар союзына әдәби консультант итеп эшкә алдылар. Бер елдан «Идел» альманахына мөхәррир итеп күчерделәр».
Һәм шушы чордан «Идел» альманахына журнал статусын яулау өчен, нәкъ менә яулау өчен эпопеяга тиң (алырсың тартып эт авызыннан сөяк!) көрәш башланды. Бүгенге көндә, чат саен шикле басмалар дөнья күргән бер мәлдә, бу сүз, бәлкем, кайберәүләр өчен, бигрәк тә «теге еллар»ны күреп үсмәгән яшьрәк буын язучылар өчен купшы бер аклану, арттыру булып та ишетелер, ләкин империя тарафыннан халыкларның тимер кыршау белән уратып алынган (черек булса да!) агач мичкәдә сөрсеп ятарга мәхкүм ителүен истән чыгармасак иде (сабак алу өчен!). Шөкер, кыршау өзелде... «Идел»ебез дә иркен сулыш белән, ярларга тулып ага. Димәк, көрәш бушка китмәгән. Ә ул чакта...
«— Без, яшьләрне оештырып, татарча яшьләр журналы ачу өчен көрәш башладык, — дип искә ала Мансур Вәли. — Мәскәү рөхсәтеннән башка моңа ирешү мөмкин түгел иде, шунлыктан КПССның Үзәк Комитетына хәтле барып җиттек. Үземне КПСС Үзәк Комитетының матбугат бүлеге мөдире кабул итте. Хәтта Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Ф.Ә.Табеев белән Россия Язучылар берлегенең җитәкчесе — кайда да үз сүзе үтә торган С.В.Михалков — илнең төп идеологы М.А.Суслов янында булып, шушы мәсьәләне күтәреп карадылар, әмма аларның да аргументлары яклау тапмады: Мәскәү өчен бәләкәй генә милли журнал чыгарырга рөхсәт бирү «стратегик әһәмият»кә ия иде. Ләкин «эт өрә тора, бүре йөри тора» дигәндәй, «Идел» альманахы хәл кадәренчә үз миссиясен әйбәт кенә үтәп килде. Ул үзенә күрә хөр фикерле яшьләр үзәгенә әверелде: аның битләрендә табадан гына төшкән әсәрләр урын алды, «Дискуссион клуб»та яшь әтәчләр чәкәләште. Әмирхан Еники, Нурихан Фәттах, Аяз Гыйләҗев белән булган очрашуларга урта буын язучылар да «рөхсәт сорап, кача-поса» арткы рәтләргә кереп утыралар иде. Күрәсең, аларга безнең фикерләү рәвеше кызык тоелгандыр һәм үзләренчә безне сынап, җиз иләктән үткәреп тә йөргәннәрдер — әдәбиятка кемнәр килә, янәсе».
Бу тормышта күп нәрсә кабатлана. Хәзер Мансур Вәли инде үзе урта буын вәкиле. Ә аның иҗат кредосы нәкъ менә «Идел»дә эшләгән чорда тәгаенләнде. Күптән түгел миңа аның шәхси китапханәсендәге китаплары белән танышырга туры килде. Шунда «Яшьләр мәйданга чыга» дигән беренче китабындагы «Яшьләр» исемле мәкаләгә күзем төште: анда «картая барган саен кешене рәхәтлекләр берәм-берәм ташлап китә икән. Ләкин хакыйкать өчен көрәш һәм хезмәт ләззәте — кешенең иң ышанычлы юлдашы, алар кешене мавыктырып, юатып яшәтә. Яшьлектә менә шуны аңламый икән кеше, кулында шул ике нәрсә калачагын, әгәр инде аларны да югалтса, гомумән, япа-ялгыз каласын уйламый икән... Менә нәрсә икән ул яшәү серләренең берсе!» дигән сүзләрнең астына сызылып куелган иде. Димәк, Атилла Расихның «Каһарманнар юлы» романындагы Хәбибрахман карт авызыннан әйтелгән әлеге сүзләр аның өчен гади бер персонаж сөйләме булудан битәр, авторның дөньяга карашын, уй-хисләренең асылын билгеләүче концепция дә икән. Бүген шулай дип әйтергә тулы нигез бар: чөнки Мансур Вәли, ярты гасырлык иҗат гомерендә әдәби әсәрләргә әнә шундый идеаллардан чыгып бәя бирде; ул эстетик категорияләр белән артык «вакланып» тормады, күбрәк социаль-иҗтимагый проблемаларны үзәккә алып эш итте. Әлбәттә, «фәрештә»нең дә ике канаты булган кебек, мондый алымның да уңай һәм тискәре яклары булгандыр, әмма ул иҗатында әдәби мохиттә барган процессларга битараф булмады, әдәби процессның тирбәнешләрен йөрәге аша уздырып, сөенеп һәм көенеп яшәде.
— Кем ул тәнкыйтьче? — Мансур Вәли гомере буе шушы сорауга җавап эзләде.

Бу хакта ул болай уйлана:
— Тәнкыйтьче дә, кайберәүләр уйлаганча, бик алай куркыныч кеше түгел, гел күсәк күтәреп кенә тормый. Ул — кайнар йөрәкле һәм тәҗрибәле, югары зәвыклы укучы. Билгеле инде: дөнья булгач ул укучыга ошамаган, ачуын китергән әсәрләр дә очрый. Менә шул чагында инде әлеге югары зәвыклы, намуслы укучының йөрәге дәшми кала алмый. Ул борчылып, әрнеп, бу хәлнең сәбәпләрен аңларга һәм ачарга теләп яза. Аның болай чыгыш ясавы һич тә «күсәк күтәрү» булмый, ә бәлки әдәби иҗат эшендәге түбән сыйфатка, «бракка» каршы төшү була. Бу Мансур Вәлинең үзе инде.

*«Казан утлары», гыйнвар, 1998*

**АВЫРТУЫ БУЛЫП КАЛДЫ**

Ул татар шигъриятенең ышанычы иде. Һәрхәлдә, аңа шундый өметләр багланды. Өлкән агайлар аны беренче җитди адымнарыннан ук күреп алдылар да шигъри бишеккә салдылар. Ул «беренче адымнарны» миңа үз күзләрем белән күреп-күзәтеп торырга насыйп булды, чөнки без сабакташлар идек.
Хәтердә, хәтердә... 1969 ел. Казан университетының Красная Позиция урамындагы тулай торагы, дүртенче кат, баскычтан күтәрелү белән сул канаттагы беренче бүлмә. Бүлмәдә һәр студентның аерым дәүләте — сиртмәле тимер караваты. Без сабакташлар гына түгел, бүлмәдәшләр дә. Фәннурның кайтып керүе гел бер ритмда була, киемен салып шкафка элә дә, папкасын шакылдатып ябa, бөтен авырлыгын салып караватына утыра. Ниләр хакында уйланып утырды икән ул андый минутларда? Әлбәттә, олы юлга чыккан һәр яшь кеше кебек алгысытып һәм борчылып серле дә, билгесез дә, өметләндергеч тә киләчәк яшәеш турында уйланып утыргандыр! Һәм караватында көне буе ятып ул дәфтәр битенә, энә төртерлек тә урын калдырмыйча, сызган-бозган, өсте-өстенә язган сүзләр белән тутыра...
Фәннур университетка килеп кергәндә үк инде исеме «шагыйрь» иде: аның беренче шигырьләре «Ялкын» журналында һәм «Яшь ленинчы» газетасында басылып, уңай бәя алырга өлгергән; 1966 елда урта мәктәпне тәмамлап, Түбән Кама нефть-химия комбинатында эшләү дәверендә әдәби түгәрәкләргә йөреп (ләкин какча сөякле бу дустымны мин беркайчан да эшче-слесарь кыяфәтендә күз алдыма китерә алмадым), тулай тораклар һавасын сулап шактый шомарган егет иде. Шунлыктандырмы — хәер, кешеләр белән ул бик тиз аралашып китә иде — беренче курстан ук Фәннур каршында редакция ишекләре уңай якка җәелеп ачылды, җитмәсә, Туфаннан дәресләр ала башлады.
Менә бүген дә ул җил-җил генә кайтып кереп гөрселдәп караватына ауды да, стенага таба борылып ятып «йокыга» китте. Аннары кыштыр-кыштыр килеп, кагып кына дәфтәрен актаргалады, сүзсез генә язды, сызды, бозды. Шушы им-томга тиң серле процедура тәмамлангач кына ул торып утырды.
— Хәсән ага Туфан янында булып кайттым әле. — Егетебезнең күзләре ут яна иде. — Ак бабай дәфтәремне карап чыккан, кайбер шигырьләремне охшатып та калган, ахрысы, яшел кара белән тамгалар да салып киткәләгән... Карагыз әле, Туфан ага гел яшел кара белән яза икән бит... Гаҗәп...
Әйе, Фәннур шат, бәхетле иде бу минутларда. «Яшел тамгалар» игътибарына чалынган шигъри юллар аны ләззәтле канатларында күкнең җиденче катына алып менеп киткәннәр иде.

Тәгәрмәчләр шпал санап бара,
Баганалар каршы йөгерә.
Һәр багана җирне сөйри, гүя
Кабельләрен салып иңенә.

Вәт могҗиза! — «кабельләрен иңенә салып җирне алга сөйрәүче ул баганалар» һич тә гади бер чыжым баганасы гына түгел ләбаса, ул — шигърият йөген җилкәсенә салган ашкын күңелле яшь бер шагыйрь ич. Үземнең дә мәктәп елларыннан ук Туфан белән җенләнеп, серле иҗатына мөкиббән китеп йөргәнгәме (абзыең да төшеп калганнардан түгел, янәсе, Мөслимдә әдәби атналык узган көннәрдә — ә мин ул чакта, «Авыл утлары» исемле район газетасында эшли идем — өлкән шагыйрьдән фатиха алган «шәкерт» тә бар әле), яшел төстәге бәяләмәләрен күргәч йөрәгем кысылып куйгандай булды: димәк, Фәннур дигән яшь дустымның кешеләрдән яшерен шигырьләр язып ятуы бер дә тикмәгә түгел икән. Шушы көннән башлап мин аны шагыйрь буларак кабул иттем, бераздан бу фикерем тагын да ачыграк тәгаенләнә төште. Биектау районының Ямаширмә авылы клубында булды бу хәл. Курс җитәкчебез Лена ханым Таҗиева үзенең «бөек»ләрен авылдашлары белән очрашуга алып кайткач. Әйе, Фәннур шигырьне

ташбака шикелле хәйран интегеп яралдырса да, бер тында язган шикелле йөгерек хис белән сәхнәдән укый белә иде. Яшь шагыйрьгә танылу өчен бу инде аз түгел. Менә Фәннурыбыз халык алдында ярды да салды, әйтерсең лә гомере буе шул эш белән генә шөгыльләнгән:

Синең якка карап бер кычкырдым:
— Миңа булмас синнән башка яз!
Биек тауга килеп бәрелде дә
Егылып төште җиргә кайтаваз.

Билгеле, аның чыгышы алкышларга күмелде.
Менә шулай шигырь аша башланган дуслык, шөкер, шагыйрьнең соңгы сулышына кадәр дәвам итте.
...Тормыш дигәнең су кебек ага торды, Фәннурның да шигырьләре вакытлы матбугатта басыла торды, шул рәвешле ул «яшь шагыйрьләр» обоймасында үз урынын алды. Студентлык елларында иҗат иткән шигырьләре бер-бер артлы «Беренче карлыгачлар» (1970), «Юл башы» (1972) исемле күмәк җыентыкларда да дөнья күрде.
«Юл башы» Фәннур өчен генә түгел, шәхсән минем үзем өчен дә юл башы булды — озакламый «Казан утлары» кебек мәртәбәле басмада бу җыентыкка карата беренче әдәби язмам басылып чыкты. Ул чакта дустымның иҗатына мондыйрак бәя биргәнмен икән.
«Сүз хәнҗәрен ал кыныннан» дигән юллар аның иҗат программасы. Ул шигырьдә кыю хәрәкәт итә. Сыгылмалы формалар табарга омтыла, вакыт-вакыт матур чагыштырулары, образлы сурәтләре ялтырап китә. Шигырь тупламасына халык иҗатыннан килгән мотивлар килеп керә. Кайчагында шигырьнең буеннан-буена бер фикерне үстереп килә дә соңгы строфада «ә чынында мәсьәлә менә болайрак тора бит ул» дигән кебек, баштагы фикерне кире кагып, көтелмәгән нәтиҗә ясап куярга ярата. Сүз дә юк, болар — эзләнү җимешләре».
Әдәбият кырында тагын бер буын төртеп килә.
Ниһаять, икенче курсны да тәмамладык. Соңгы экзаменны тапшырып чыккач, ул мине башкалардан читкәрәк алып китеп: «Әйдә әле, дустым, Идел буенда ял итеп кайтыйк, — дип кыстый башлады. Идел буйлап югары күтәрелгәч, пионер лагерьлары башлана. Шунда укытучылар институты кызлары практика үтәләр. Хәтерлисезме, институтта әдәби очрашу вакытында танышып калган идек, шул кызлар кунакка чакырдылар... «Омик»та бер сәгатьлек юл.
Минем һаман да икеләнеп торуымны күргәч, җилкәмә сугып куйды.
— Борчылма, бүген генә уч тутырып гонорар алды абзаң.
Онытылмаслык бер сәфәр булды ул. Без — ике яшь пар — Идел ярында төне буе учак ягып, таңны каршыладык. Идел өстенә җәелгән зәңгәрсу, җилбәзәк томан аша аргы ярларны — киләчәкне — абайларга тырышып уйга чумып утырдык. Ул кичәнең онытылмаслык матур истәлеге булып түбәндәге шигъри юллар гына калды.

Икебезгә ике учак яктык,
Берсе сүнсә, берсе калыр дип;
Юл югалткан якын туганнарның
Күңеленә өмет салыр дип.

...Учакларны җилләр сүндерер дә,
Ә күңелдә алар янар күк.
Күңел уты сүнсә, еллар аша
Ике учак дөрләп янар күк!

Аһ, синсез моңсу, моңсу Фәннур туганым... Гомер дигәнең, әнә ул яшьлектә янган учак төтене кебек күккә аша да бетә икән шул; яшәү дә учактагы утын кебек, яна-яна да көлгә кала икән. Ләкин Фәннур Сафинның татар әдәбиятында якты исеме, олы иҗаты калды. «Кеше юлга чыкса» (1976), «Сез кемнәр?» (1980), «Тынлык» (1982), «Күкчәчәк» (1985), «Чәчәк гомере» (1988), «Яңгыр малае» (1993) кебек шигырь җыентыкларында шагыйрьнең кешеләргә булган җылы хисләре дә, җан җылысы да, уй-хыяллары да саклана, сакланыр Ходай насыйп итсә.
Фәннур Сафин нечкә тоемлы, лирик шагыйрь иде. Аның шигырьләре яшьлек романтикасына хас ашкынулы хисләр, туган җир, табигать, замандашлар, тормыш турындагы уйланулар белән сугарылган. Аның лирикасына халыкчан гамь, моң канат куйган. Бәлки, шуңадыр Фәннурның шигырьләренә нигезләнеп бик күп композиторлар җыр иҗат иттеләр. «Ялгыз көймә» (Р.Гатауллин музыкасы), «Җырымда юатырмын» (Б.Мулюков) кебек җырлары бүген дә яратып җырлана. Әмма шагыйрьнең күпсанлы җырлары арасыннан «Хушлашырга ашыкма» дигәнен халык аеруча якын кабул итте. Композитор Риф Гатауллин белән иҗади дуслыкта туган бу җыр мәшһүр җырчы Илһам Шакиров башкаруында күкләргә китеп иңри, күкрәк читлегенә, күңел киңлекләренә сыеша алмыйча гамәли киңлекләргә тарала. Ул реквием булып яңгырый.

Сайрар кошлар синсез нишләр?
Ничек агар бу сулар?
Урман ничек шаулар,
Ишелмәсме таулар? —
Икебез дә моңсулар!..

Ни кызганыч, Фәннур газета-журналлар каршындагы тыз-быз машиналар чабучы урамны гына түгел, тормыш урамнарын да бик авырлыклар белән кичте шул.
Фәннур Сафин татар шигъриятенең ышанычы иде. Талантлы улы иде. Ул аның авыртуы булып калды.

*«Казан утлары», июнь, 1998*

## «ӘЙДӘ, ХАЛЫККА ХЕЗМӘТКӘ!..»

Татар халкының борынгы мәдәни мирасын барлаучы, тикшерүче, яңадан халыкның үзенә кайтаручы, сәнгать традицияләрен дәвам иттерүчеләр арасында Нәҗип Нәккаш дип исеме чыккан бер затлы шәхес бар. Әйе, Нәҗип әфәнде милләт өчен кирәкле һәм файдалы олы эшләр башкара: беренчедән, ул әдәбият галиме, текстолог буларак, архивлардан, сирәк кулъязмалар арасыннан энҗе-мәрҗәннәр табып, әдәби мирасыбызны барлый, текстологик яктан эшкәртә, ягъни без яшәгән буын җәмәгатьчелеге аңлый, укый алсын өчен, аларны хәзерге гамәли алфавитка күчерә, аңлатмалар яза, китап итеп чыгарырга әзерли. Ул күп белем, көч, тырышлык сорый торган мәшәкатьле, әмма игелекле эш башкара. Икенчедән, аның бөтен күңелен биреп, яратып эшли торган тагын бер шөгыле бар: ул, — сәләтле рәссам буларак, соңгы 80 ел эчендә онытылуга дучар ителгән борынгы сәнгатебезнең бер төрен — гарәби каллиграфия сәнгатен тергезеп, яңартып җибәрүче. Нәҗип Нәккаш иҗат иткән гүзәл гарәби язулар, шәмаилләр менә 8–9 ел инде Җөмһүриятебездә чыгып килүче газета-журнал һәм альбом битләрен, музейларны, мәчетләрне, аерым кешеләрнең өй эчләрен бизи.
Ниятебез — укучыларны шушы сирәк һөнәр иясе, талантлы шәхес белән якыннанрак, тулырак таныштыру. Шәхеснең үзен һәм эшен аның үзеннән дә яхшы белүче юк, шуңа күрә без күбрәк Нәҗип әфәнденең үзен сөйләтергә булдык.
— *Нәҗип әфәнде! Әңгәмәбезне традицион сораудан башлыйсыбыз килә: кем сез, кайдан сез, әдәбият фәненә ничек килдегез дә, сәнгатькә ничек кереп киттегез?*
— Мин үзем тумышым белән Мамадыш төбәгеннән, Чулманга коя торган ямьле Бүрсет елгасы буена урнашкан үрле-үзәнле, елга-чокырлы, бик күп чишмәләре булган борынгы Өчөйле (рәсми исеме Усали) авылыннан. Әтием Фәйзерахман һәм әнием Бибигайшә исемле колхозчылар гаиләсендә беренче бала булып 1948 елның август аенда дөньяга килгәнмен. Атам ягыннан булган бабаларым, Сөләймановлар нәселе игенче һәм һөнәрчеләр, балта осталары булганнар. Балта остасы булу өчен рәссамнардагы кебек «кул» белән «күз» арасында тыгыз бәйләнеш булу кирәк, шуңа күрә мин үземдәге рәсем ясау сәләтен нәселебездән киләдер дип уйлыйм. Әтием клуб яисә ферма мөдире булып эшләгәндә белдерүләр, плакатларны үзе яза иде. Элекке заманда фанердан эшләнгән чемоданнар бар иде бит. Бервакыт шундый чемодан белән яңа гына армиядән кайткан Мөбарәкҗан абый (әтинең энесе), чемадан капкачын ачып җибәрде дә шуның өслегенә акварель белән үзенең портретын ясап куйды. Әгәр уку, тәрбия эләккән булса, алардан рәссамнар чыккан булыр иде, бәлки. Мин үзем дә рәссам булу өчен махсус белем алмадым. Кечкенәдән үк рәсем ясарга, матур язарга яраттым. Бишенче сыйныфтан башлап укуны тәмамлаганчы класс дивар газетасының бизәүче рәссамы булдым, мәктәп һәм авыл китапханәләрен бизәүдә катнаша идем. Урта мәктәпне тәмамлагач, «күп балалы атам-анам гаиләсенә булышыйм» дип, 7 ел үзем укып чыккан мәктәбемдә эшләргә туры килде. Сынлы сәнгать дәресләрен укыттым, түгәрәкләр алып бардым, шуның өчен сәнгатькә багышланган китаплар җыйдым, сынлы сәнгатькә кагылышлы барлык журналларны алдыра идем. Шулар аша үзлегемнән өйрәнергә тырыштым. Шулай итеп, рәсем ясаудан мин һичкайчан өзелеп тормадым. Үзем белән бергә эшли торган, электәге әдәбият һәм татар теле укытучым Мәрьям апа: «Нәҗип, бу сәләтләрең белән монда йомылып калма, сиңа укырга кирәк, укырга бар!» — дип кыстый торгач, ниһаять, 1974 елда 26 яшемдә университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга барып кердем. Беренче курстан ук гарәп телен өйрәнә башладым. Кечкенәдән үк шул серле хәрефләрнең мәгънәләрен белергә омтыла идем. Университетта «Әдәби сүз» дивар газетасын бизәүдә күп көчемне куйдым. Профессор Хатыйп ага Госман сәләтле студентларга бик зур игътибар бирә торган шәхес иде. Дүртенче курста укыганда, ул мине берничә егет белән бергә Бакый ага Урманчега каллиграфия өйрәнергә йөртте. Атаклы остадан 3–4 дәрес алып кала

алдым, ул безне каләм тотарга, матур язуның кайбер серләренә өйрәтте.
Борынгы әдәбият белән кызыксынуым гыйльми тикшеренүләргә — моңарчы өйрәнелмәгән урта гасырлар татар прозасын өйрәнүгә этәрде. Бу эштә иң беренче фәнни җитәкчеләрем Хатыйп абый Миңнегулов, Хатыйп ага Госманнар булды. Өченче курста укыганда ук Хатыйп ага миңа XVIII гасырдан сакланып калган зур күләмле хикәятләр җыентыгын тикшерүне тәкъдим итте. Шул китап хакында диплом эшемне якладым һәм кулъязманы басмага әзерләү эшен Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшли башлагач та дәвам иттем. Менә 18 ел инде шул фәнни-тикшеренү институтында эшлим. Төп гыйльми шөгылем — урта гасырлар татар прозасын өйрәнү, тикшерү һәм әдәби текстны басмага әзерләп, китаплар итеп чыгару. Нигездә, мин кулъязмалар буенча эшлим, хикәят, кыйсса, ләтыйфә, нәсихәт, гыйбрәт жанрларындагы чәчмә әсәрләрне гарәп хәрефеннән хәзер кулланыла торган алфавит хәрефләренә күчерәм, сүзлекләрен төзим, шәрехләр язам һәм аннан соң, хәзерге әдәби телгә яраклаштырып, басма өчен әзерлим.
XIV йөздән башлап, XIX йөз ахырына кадәр Көнчыгыш әдәбиятларыннан татарларга гаҗәп күп хикәятләр үтеп кергән. Хикәят дигәннән, иң әүвәл Г.Тукайның мәшһүр «Туган тел»еннән шул юллар хәтергә килә:

Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.

Чынлап та, ул хикәятләр шулкадәр күп булган ки, аларны көннәр-төннәр буе укып, сөйләп булган. Хикәят — язма әдәбият әсәре, хикәят жанры исә әкият белән хәзерге хикәя арасында торган үзенчәлекле жанр. Хикәятләрдә әкият хыялы, тылсымы белән бергә хикәя чынбарлыгы тыгыз үрелеп барелә. Г.Тукай әлеге юллары белән безнең зур язма әдәбиятлы мәдәни милләт икәнебезне искәртеп тора.
Таҗиклар хикәятләрдән генә торган «Җәмигыль хикәят» исеме белән 5 томлык чыгардылар. Таҗик-фарсыларда булган хикәятләрнең барысы да диярлек бездә дә бар. Димәк, бездә дә рәхәтләнеп 5 томлы җыентык төзеп чыгарырга була. Шуны истә тотып, мин «Борынгы татар прозасы» дигән серияне төзи башладым. 1994 елда дөньяга чыккан 25 табаклы «Мәҗмугыль хикәят» китабы сериянең беренчесе булды. Хәзерге вакытта тагын ике китап: «Маҗаралы хикәятләр» һәм «Гыйбрәтле хикәятләр» китаплары әзерләнеп бетеп килә. Ә бу көннәрдә исә мин хәзергә билгеле булган иң беренче чәчмә әсәр — Насреддин Рабгузиның 1311 елда язылган «Кыйссасел-әнбия», ягъни «Пәйгамбәрләр тарихы»ның текстын матбугатка әзерләү белән шөгыльләнәм. Әгәр дә гаҗәеп бай эчтәлекле бу дини-әдәби китапны хәзерге әдәби телдә бастырып чыгарып булса, мөселманнар өчен бу зур яңалык, кадерле бүләк булыр иде.
*— Нәҗип әфәнде! Белүебез буенча, дини-әдәби мирасны халыкка кайтаруда бу сезнең беренче генә эшегез түгел. Дини әдәбият үрнәкләрен газета-журналларда бирү, радио аша пропагандалау эшен күптәннән алып барасыз. Сез үзегез дин эшлеклесе, мәчет әһеле түгел, бу эшкә ничек кереп киттегез?*
— 80 нче елларның ахырында халыкка дин тотарга ирекләр бирелгәч, халык онытылган Ислам диненә кире кайта башлагач, хәзерге хәрефләр белән язылган җиңел аңлаешлы китаплар, белешмәләр кирәклеге сизелде. 1991 елда З.Шәфигуллин үзе төзи башлаган «Ислам. Белешмә сүзлек» китабына татар халкында популяр булган дини китаплар турында кыскача белешмәләр язарга тәкъдим иткән иде. «Бу минем өчен әллә ни авыр эш булмас, алар турында инде әдәбият бардыр, шулардан җыеп алып, бер системага салып кына бирермен», — дип, җиңел генә уйлап, ризалык биргән идем. Әмма эшкә чынлап тотынгач, әдәбият тарихы китапларын актарып карагач, борынгы дини әдәбиятыбыз турында бөтенләй диярлек мәгълүматлар юклыгын белдем. Дөрестән дә, Совет власте елларында язылган әдәбият тарихларында ул әсәрләр турында сөйләп мәгълүмат бирү кирәкмәс эш саналган, бары тик аларны сүгеп, тибеп үтү генә яраган. Шулай итеп, миңа турыдан-туры чыганакларга мөрәҗәгать итәргә туры килде, оятыма каршы, борынгы әдәбият белән эш итүче саналсам да, мин аларның кайберләрен бөтенләй укымаганмын яки өстән-өстән генә белгәнмен икән. Минем алдымда яңа бер зур дөнья ачылды — гаҗәеп бай мәгънәле, мавыктыргыч, нәфис дини әдәбият дөньясы. Ул әсәрләрнең кайберләре турындагы иң тулы мәгълүматны, әдәби анализны Гали Рәхим белән Газиз Гобәйдуллин чыгарган «Татар әдәбияты тарихы»нда (Казан, 1923) таптым.
Үземнең белемнәремне шактый баеткан бу белешмәләрне язып тапшыргач, шулар нигезендә «Ватаным Татарстан» газетасында 1992 елда «Дини әдәби мирас» рубрикасын ачып җибәрдем һәм анда Әхмәд Ясәвинең «Диване хикмәт»еннән башлап XIX гасыр уртасы әсәре «Фәзаилеш-шөһүр»гәчә булган иң популяр китаплар хакында белешмәләр һәм әсәрләрдән үрнәкләр биреп бардым. Аларның күбесе хәзерге алфавитта һәм хәзерге әдәби телдә чыккан иң беренче үрнәкләр булдылар. Мәсәлән, XIV йөз әсәре саналган «Кисекбаш» дастаны хакында Г.Тукай

пародия рәвешендә язган «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» аша өстән-өстән генә белгән халык аның борынгы үрнәге белән танышты. Ә «Фәзаилеш-шөһүр» китабы исә халык арасында көтелмәгән популярлык казанды. Авторы Мамадыш төбәге Шәдче авылының имамы Җамалетдин Бикташи булган, әмма аның исеме күрсәтелмичә генә кат-кат күп тиражлар белән чыккан кадими мәдрәсәләрдә беренче татарча уку китабы булган бу җыентыкның шактый өлешен башта «Ватаным Татарстан» газетасының «Әллүки» чыгарылышында биреп барган идек. Яңа гына дингә тартыла башлаган халык, бигрәк тә өлкән яшьтәге апалар аңа шунда ук игътибар иттеләр. Чөнки монда Ислам диненең төп кануннары, кайбер гадәтләре, әхлак кагыйдәләре җиңел тел белән, пәйгамбәрләр, изгеләр тормышыннан кыска хикәятләр аша эмоциональ рәвештә аңлатылган иде. Китап итеп бастырып чыгаруны сораучылар күп булгач, мин аның текстын әзерләп, бизәлешен дә үз кулым белән эшләп «Иман» нәшриятына тапшырган идем. Китап 25 мең тираж белән басылып чыкты һәм бик тиз арада сатылып та бетте. Шулай итеп, иске мәдрәсәнең бик гади, самими уку китабы булган, җәдитчеләр тарафыннан заманында сүгелгән бу китап Ислам диненә яңадан кайту чорына, XX йөзнең ахырында да популяр булды.

*— Элек дини һәм әдәби мирасны яңадан халыкка кайтару — сезнең эшчәнлекнең бер ягы. Без әле аның икенче ягын да, шулай ук борынгы мирас белән — бу юлы каллиграфия сәнгате белән бәйле эшчәнлегегезне беләбез. Сез борынгы традицияләрне тергезү-яңартуга зур тырышлык куясыз. Бездә әле каллиграфлар күп түгел, бармак белән генә санарлык. Сез исә каллиграфия сәнгатенең берничә төре белән берьюлы шөгыльләнәсез һәм һәр өлкәдә уңышларыгыз юк түгел. Шуңа күрә күпсанлы укучылар, тамашачылар ул әсәрләрне көтеп алалар, яраталар. Сезнең «Нәккаш» дигән кушаматыгыз кызыклы, Такташ, Сәйдәш, Борнаш, Гаташлар кебек бик тә татарча яңгырый, гәрчә ул гарәп сүзе булса да. Кушаматны гадәттә шагыйрьләр, әдипләр ала, сез исә гыйльми хезмәтләрегездә үзегезне «Н.Исмәгыйлев» дип күрсәтсәгез, сәнгать әсәрләрендә исә «Нәккаш» дип исемләнәсез. Ни өчен кушамат алдыгыз, аның мәгънәсе нидән гыйбарәт?*

— Бу псевдоним-кушаматны мин 1991 елдан башлап «Мирас» журналында беренче эшләрем басыла башлагач та алдым. Беренчедән, Исмәгыйлев нык таралган фамилия, мине башка Исмәгыйльләр белән бутамасыннар, дидем. Икенчедән, минем бу шөгылем әдәбият белән турыдан-туры бәйләнгән. Хөрмәтле Рабит Батулла үзен «мин язучылар янында язучы, артистлар янында артист» дигән шикелле, мин дә галимнәр янында галим, рәссамнар янында рәссам. «Нәккаш» — гарәпчәдән тәрҗемә иткәндә иң беренче тар мәгънәсе «ташка уеп бизәк ясаучы, ташка язучы» дигәнне аңлата. Киңрәк мәгънәдә рәссам-график дигәнне белдерә. Шулай булгач, бу кушамат минем шөгылемә бик тә туры килеп, ябышып тора, дип уйлыйм. Соңрак, инде бу кушаматны үземә алгач, мин төрекләрдә бер язучының һәм гарәпләрдә бер каллиграфның Нәккаш кушаматын йөрткәнен белдем.

*— Тагын бер традицион сорау: бу борынгы сәнгать белән сез кайчан, ни рәвешле шөгыльләнә башладыгыз?*

— Балачактан ук мине ул серле хәрефләр үзләренә тартып, күңелне әсәрләндереп тора иде. Әбидән калган Коръән кисәкләрендәге язулар, әни ягыннан булган күрше авылдагы бабайлар өендәге пыялага ясалган, нурланып, җемелдәп торган тылсымлы шәмаил минем хәтеремә мәңгегә уелып калды. Ул төсле шәмаилләрне безнең авылда Хәсәнша Әхмәтшин исемле бик укымышлы, бухгалтер булып эшләүче өлкән яшьтәге кеше ясый иде. Хәллерәк кешеләр үзләренең өйләрендә аның картиналарын булдыруны бурыч итеп куялар иде, шуның белән горурланалар иде. Ә гарәп хәрефләре белән чын-чынлап танышу, гарәп телен өйрәнү миңа шактый соң — Казан университетында укыганда насыйп булды. Тик ул чакта, 70 нче еллар ахырында, аның бу заман өчен шулкадәр кирәк булачагы хакында кем уйласын!.. Нәселдән килә торган табигать бүләге, Алланың рәхмәте — азмы-күпме рәссамлык сәләте булганга, гарәп хәрефләрен матур язарга өйрәнү әллә ни кыен булмады. Күбрәк мин үзлегемнән, элеккеге осталарның эшләрен күчерә-күчерә өйрәндем. Студентлык елларыннан башлап 1989 елга кадәр бу сәнгать белән үзем өчен, үз күңелем өчен генә шөгыльләнә идем. 1989 елның җәендә Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул итүнең 1100 еллыгына багышлап Казан шәһәренең күп музейларында күргәзмәләр оештырдылар. Шул вакытта минем үзем өчен генә иҗат ителгән уртача гына эшләремне дә экспозицияләргә куяр өчен кырып-себереп алып бетерделәр. Шул елларда бер-бер артлы яңа журналлар, газеталар чыга башлады. Халыкның бу сәнгатькә ихтыяҗын канәгатьләндерү йөзеннән алар миңа бер-бер артлы заказлар бирә башладылар. Минем шәмаил-миниатюраларым бигрәк тә «Мирас» журналына туры килеп, аның йөзенә әверелде һәм мин ул журнал белән даими хезмәттәшлек итә башладым. Хәзерге вакытка аның тышлыгында минем 30 дан артык эшем басылып чыкты.

*— Менә сезнең әүвәлге традицион шәмаилләргә якын булган эшләрегез дә, шулай ук алардан*

*аерылып торган, үзегезгә генә хас булган яңача әсәрләрегез дә бар. Бигрәк тә «Мирас» журналындагылар. Аларның үзенчәлеген, яңалыгын сез үзегез яхшырак аңлатып бирерсез дип уйлыйм.*
— Традицион шәмаилләрдә гадәттә Коръәннән аятьләр, Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәдисләре, Алланың бөек исемнәре; Мөхәммәд галәйһиссәламне данлаган сүзләр, аның сәхабәләре Әбүбәкер, Гомәр, Госман, Галинең исемнәре; дүрт олуг фәрештә: Җәбраил, Газраил, Микаил, Исрафилнең исемнәре языла. Шулай ук, сирәгрәк булса да, атаклы һәм фарсы шагыйрьләренең Аллага, Мөхәммәд пәйгамбәргә, Ислам диненә багышланган хикмәтле юллары языла.
Мин исә үземнең шәмаил-миниатюраларымда Коръән аятьләре, пәйгамбәр хәдисләре белән бергә үзебезнең татар шагыйрьләренең дә шул эчтәлеккә туры килеп торган, авазлаш булган шигъри юлларын урнаштырам. Мәсәлән, Коръәндә (2 сүрә, 153 аять) сабыр итү турында шундый гыйбарә бар:
«Иннә Аллаһа мәга-сабирыйна» («Аллаһу Тәгалә сабырлар белән бергә»).
Нәкъ шуңа туры килеп тора торган мәгънә Тукайның «Сөткә төшкән тычкан» шигырендә бар:

— И карындәш! Син кирәксә суга бат, йә сөткә бат —
Ит сабыр, күрсәт чыдамлык һәм дә ит гайрәт, сәбат!

Менә тагын Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәдисе:
«Утлүбү-л-гыйльмә минә-л-мәһди илә-л-ләхди» («Бишектән башлап ләхеткә кергәнче гыйлем өйрәнегез»).
Тукайда да шул ук мәгънә:

Өч наданга алмашынмас бер язу белгән кеше,

Мәгърифәт эстәр, иренмәс һич кеше булган кеше.
Гомумән, Коръән аятьләренә һәм хәдисләргә тәңгәл булган шигъри юлларны, хикмәтләрне Тукайдан еш табарга була. Шуннан соң да Тукайны бөек дими ни дисең!
Шәмаилләремнең үзенчәлекле икенче ягы — аларның ачык күренеп торган милли төсмере, татарчалыгы. Мин моны XX йөз башы типографик шәмаилләрдән һәм бүгенге башка авторларның эшләреннән аерып торган иң зур үзенчәлек дип саныйм. Бу төсләрнең кулланылышында, бизәкләрдә дә, композициядә дә күренә. Безнең халык ачык, якты, шатлыклы төсләрне, һәр детальнең аермачык күренеп, беленеп торуын ярата. Мин шул таләпләргә авазлаш булырга тырышам. Гәрчә, ул милли төсмер миндә үзеннән-үзе килеп чыга, чөнки ул миллилек минем канымда, җанымда һәм дөньяга карашымда.
— *Нәҗип әфәнде! Сез әле каллиграфия сәнгатенең онытылган, күпләр бөтенләй белми торган төре — тугра сәнгате белән дә шөгыльләнәсез. «Герб» сүзен алмаштырган «тугра» терминын да матбугатка, сөйләмгә кертеп җибәрүче дә, ялгышмасам, сез булдыгыз кебек.*
— Әйе, шулай туры килде. Җөмһүриятебезнең туграсын иҗат итү конкурсында мин дә катнашкан идем. Алтын Урда чорында ясалган чүлмәктәге гаҗәеп көчле, мәгърур барсны үрнәк итеп алып, беренчеләрдән комиссиягә илтеп биргән идем. Ләкин үтә милли төсмерле булу сәбәпле комиссия минем туграмны халыкка күрсәтмәде... Аннары мин М.Бакиров идеясенә тәңгәлләштереп дәүләт тугралары ясаган идем. Шул мин ясаган сурәтләр белән аның мәкаләләре матбугатта күренде, тугра сүзе шул вакытта таралды.
Тугра борынгы төрки сүз. Ул билге, тамга, шәхси герб дигәнне аңлата. Тамырында «ту», «тугъ» дигән сүз ята. Гаскәри берләшмәнең, бүлекчәнең билгесе булган әләмне, байракны шул сүз белән атап йөрткәннәр. Әле язу кулланылмаган борынгы чорларда күчмә төркиләр гади генә сызыклардан торган бакыр, бронза, тимер тугралар белән кыздырып басып, далага көтүгә чыгарып җибәрәсе атларын тамгалый торган булганнар, һәр кабиләнең, ыруның үз тамгасы булган. Атлар далада йөргәндә бергә кушылып зур табуннар хасил иткәндә, аларны шул сугылган тугралары буенча аера торган булганнар. Ә инде Ислам дине белән бергә гарәп хәрефләре кабул ителгәч, ханнар, солтаннарның фәрманнарда, хатларда, ярлыкларда аларның исемнәре үзенчәлекле матур монограммалар рәвешендә язылып куела торган булган. Шуны электән килгән төрки сүз белән «тугра» дип атаганнар. Ярлыкларны язучы, тамганы ясаучы хаттатларны исә туграчы, тугракеше дип атый торган булганнар.
Урыслардагы «клеймо»ны белдергән «тавро» сүзе нәкъ менә шул төрки сүздән алынган.
XIV гасыр ахырларында Төркиядә махсус тугра стиле формалаша, канунлаштырыла. Ул көчне, мәгърурлыкны, җегәрне белдереп торучы мәһабәт бер композиция рәвешен ала.
Соңгы чорларда ханы, солтаны булган милли дәүләтебез юк ителгәч, ул туграларны укымышлы кешеләр, муллалар, сәүдәгәрләр үзләренең шәхси мөһерләре, китап билгеләре рәвешендә куллана башлаганнар. XIX гасыр ахырларында үзеңнең туграң сурәтләнгән шәхси мөһерең булу мәдәнилек билгесе саналган. Безнең Казанда Берләштерелгән дәүләт музеенда 48 мөһердән

торган бай һәм матур коллекция саклана.
Гарәп хәрефе — матур сурәтле, сыгылмалы, сурәтләү мөмкинлекләре зур булган хәреф. Хыялың бай булса, аннан әллә нинди күп сурәтләр, бизәкләр ясап була. Мәсәлән, «Бисмилла» сүзен, җиңел генә, кош рәвешендә яки кувшин рәвешендә язып була. Кешенең исеме, атасының исеме, нәсәбатыннан (фамилиясеннән) торган монограмманы да төрле сурәтләр рәвешендә язып була. Кайсыбер очракта аларга кешенең кайбер холык сыйфатларын да, профессиясен яки бер-бер мавыгуын да чагылдырып була. Мәсәлән, мин үземнең якташым атаклы җырчы Миңгол Галиевнең туграсын музыка билгесе «скрипка ачкычы» рәвешендә ясадым.
*— Бу туграларны хәзерге көндә дә гамәлгә, ягъни кулланылышка кертеп буламы соң?*
— Ник булмасын, бик була! Туграны үзеңнең визит карточкаңда, шәхси мөһереңдә, китап мөһерендә (экслибриста) кулланырга мөмкин. Мәсәлән, мәгълүм әдип Марсель Гали аны үзенең визит карточкасында да, үзенең юбилей кичәсенә чакыру билетында да кулланды.
Шулай ук аны үзеңнең гербың (туграң) итеп, пыялалы кысага урнаштырып, диварга эләргә була. Эшмәкәр Р.Һибәтуллин нәкъ шулай эшләде дә. Бөтен гаилә әгъзаларының исемен берләштереп уртак гаилә туграсы да ясарга була. Диварда эленеп торган мондый тугра бүлмәгә үзенчә бер экзотика, милли төсмер бирә, бизәп тора.
*— Нәҗип әфәнде! Дөресен әйтергә кирәк: бу гарәби каллиграфия сәнгате бу көндә һәркемгә дә әле аңлашылып җитми, сезнең картиналарны аңлау өчен иң элек гарәп хәрефен таный, укый белү сорала. Димәк, бу элитар сәнгать?*
— Мин моны алай ук димәс идем. Элитар сәнгать ул — аерым бер катлау, бер төркем өчен генә хезмәт иткән сәнгать. Ә моны гарәп хәрефен таныган һәркем аңлый, укый ала — бае да, ярлысы да. Гарәп язуын, бабаларыбызның мең еллык мирасын өйрәнү өчен берәүгә дә юл ябылмаган. Бүгенге заманда мәктәп-гимназияләрдә гарәп язуын өйрәнүче балалар һаман ишәя бара, димәк, бу сәнгатьне аңлаучыларның да аудиториясе киңәя дигән сүз. Ә бит Алла сүзе, пәйгамбәр сүзе кергән шәмаилләрне гарәп язуын танымаган күп татар кешеләре өйләрендә тотканнар, алар аны динлелекнең, Аллага ышануның, татарлыкның символы итеп санаганнар, атеизмның һөҗүмнәре вакытында да өйләрендә саклаудан курыкмаганнар. Алар ата-бабаның ядкяре, реликвиясе булып, буыннан-буынга күчә барганнар, әле дә аларны һичкем йә сатарга, йә музейга илтеп тапшырырга җыенмый. Безнең музейларыбыздагы шәмаилләр бик авырлык белән генә җыелганнар.
Рәссам-хаттат эшчәнлегенең тагын бер өлкәсен — матур язу сәнгате белән турыдан-туры бәйле китап бизәлеше белән шөгыльләнүен дә искә алып үтү кирәктер. Хәзергә көнгә ул — 40 лап китап тышлыгының рәссамы. Ул бизәгән китаплар хәрефләренең ачыклыгы, төгәллеге, оригинальлеге белән, төсләренең ачык һәм якты булулары, чып-чын милли төсмерләре белән «менә бу татар китабы!» дип әллә кайдан әйтеп торалар. Аның бизәлешендә чыннан «Мәҗмугыль-хикәят», «Фәзаилеш-шөһүр, яки Саваплы гамәлләр» китаплары, Ф.Яруллинның өчтомлыгы, Ш.Зәбиров һәм Ф.Хуҗиәхмәтовалар инде менә 5 ел чыгарып килгән татар мөселман календарьлары, «Иман» нәшрияты чыгарган күптиражлы календарьлар, «Раннур» нәшрияты чыгарган «Ислам дине нигезләре» китабы үзләренең милли яңгырашы, милли төсмерләре белән соңгы 80 ел эчендә чит-ят халыкларның мәдәнияте тәэсиренә бирелеп, үз йөзен югалта башлаган татар халкының зәвыгын тәрбияләүдә, яңадан формалаштыруда уңай йогынты ясыйлар.
Н.Нәккашның тагын да бер юнәлештәге игелекле эше игътибарга лаек, ул да булса, остаз буларак, шәкертләр тәрбияләү.
*— Нәҗип әфәнде! Сез кайда укытасыз һәм инде күпме шәкертегез бар?*
— Менә инде 6 ел мин Татар дәүләт гуманитар институтында каллиграфия дәресләре алып барам. Бу эш шушы яңа институт оешкан елны ук, хәзер шунда проректор булган Ф.Ә.Ганиева әйдәкләве белән башланган иде. Бу көнгә инде минем 400 ләп шәкертем бар, шулар арасыннан иң сәләтлеләре каллиграфия конкурсларында катнашып, алдынгы урыннарны яулап алдылар. Инде профессиональ дәрәҗәдә иҗат итүче шәкертем Ә.Хәлиуллина үзе каллиграфия дәресләрен укыта башлады. Аллага шөкер, без башлаган эш уңышлы гына бара.
*— Менә сезнең шәхси туграгызда очып баручы кош сурәтләнгән. Моның берәр символик мәгънәсе бармы?*
— Очып баручы кош сурәтеннән төрле мәгънә чыгарырга була. Үземчә мин моның белән очкан кош кебек тиз үтеп китүче фани дөньяны, шул вакыт, шул дөнья эчендәге үземне сурәтләдем. Менә шул очкан коштай тиз үтеп китүче гомердә эз калдырып, үзеңнән соң игелекле эшләр калдырып китәргә иде. Бу тугра минем шуңа омтылышымны аңлата.
*— Омтылышыгыз, максатыгыз изге икән, Нәҗип әфәнде. Шул изге юлда, халкыбызның мәдәни мирасын кире кайтаруда, шул эшчәнлегегезнең һәр ике төрендә Сезгә иҗат уңышлары насыйп*

*булсын, һәм ихлас күңелдән «әйдә, халыкка хезмәткә!..» дибез.*

*«Казан утлары», сентябрь, 1998*

## СҮЗ ГАМЕ

Айрат Арслан...
Әнә ул безнең тәрәзә каршысыннан үтеп бара — без алар белән күршедә генә яшибез. Өстендә кара-кучкыл төстәге озын плащ, башында (таушала төшсә дә) затлылыгын югалтмаган киез эшләпә, җилкәсендә шыплап тутырылган авыр букча. Алга иелә төшеп салмак кына атлый бирә; ул әйтерсең лә ярты дөнья йөген иңенә салган да, җай гына тирбәлеп, киләчәгенә китеп бара. Шигъри Галиҗәнапның берәр җиргә халык каршына чыгып Сүз сөйләргә китеп барышыдыр инде. Әле кичә генә мин аның белән Сүз хикмәте хакында озаклап сөйләшеп утырган идем, бүген шулар хәтергә килеп, күңел чымырдап китте һәм ирексездән:

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Түгеп күз яшьләреңне бу кәгазьгә,
Ни моңлы уйларың бар — сөйлә безгә!..* —

дип әйтәсем килә башлады. Ә каләм дигәнең кеше яки бик тә сөенгәндә, яки бик тә көенгәндә генә кулга сикереп менә бит ул. Үзе кулга килеп кунаклый. Йә кара кош булып, йә ак кош булып. Ә мин бүген сөенәм дә, көенәм дә — җанымның шундый чагы.
— Әллә нәрсә булды бу дөньяга, әллә нәрсә булды бу кешеләргә — күңелләрдән моң качты, матурлык качты, илаһи сүзнең кадере китте, — дигән иде Айрат ага Арсланов кичә, уфтанып. Цензура тәрәзәләре ачык дип, эчке цензура очсызлангач ни хәл итәсең, тормыш сәхнәсенә дә, эстрада сәхнәсенә дә үзгәрешләр үрмәли дә үрмәли. Гавам күреп тора, әмма берни эшли алмый. Айрат ага белән килешми мөмкин түгел иде, тормышның бер чагылышы буларак, сәнгать сәхнәсенә дә, тулаем алганда, моңсыз, тозсыз сүз хуҗа була бара. Ә тозсызлык, ягъни талантсызлык әрсез була ул: хак сүзне ялган сүз, профессиональлыкны үзешчәнлек чын-чынлап... пумала белән куып төшерергә маташа. Бу хакта олуг композиторыбыз Фасил абый Әхмәтов та ачынып язып чыкты («Мәдәни җомга», 1997, № 40). Кыскасы, эстрадада әдәби сүзнең абруе бик тә мөшкел хәлдә. Фәйзи ага Йосыпов белән Әзәл ага Яһудиннарны сагынып кына сөйләргә калды; ярый әле Айрат ага Арсланов, Хәлим Җәләлов, Илдус Әхмәтҗанов кебек осталар исән; безнең авылның Мосаллия апае әйтмешли, гомерләре булгыры.
...Әнә ул борылмадан кереп югалды: сүзләре — колак төбендә, кыяфәте күз алдында тора. Үзем күреп белгән яки читтән генә булса да карап-күзәтеп йөргән өлкән буын әдәбият-сәнгать әһелләреннән төсе-кыяфәте, үзен-үзе тотышы белән башкалардан әллә каян ук аерылып торган андый берничә генә кешене хәтерлим бугай мин. Һәрхәлдә, күп түгел алар. Сөлектәй зифа буй-сын; бераз какчарак күренсә дә, асылда, җегәрле, киңчә җилкәгә килешле итеп утыртылган баш шәрифләре; күңел түреннән саркып торучы мөлаем нурлар белән өртелгән мәгъруур-горур да, уйчан-җитди дә караш; күгелҗем тутлы йөз-чырайга ихтыяр көче салып үткән үзән-ерганаклар; чал керсә дә, коелу-буйсынуны белми торган күперек чәчләр... Кыскасы, Ходай тарафыннан андыйларның барлык вөҗүденә ирләрчә матурлык, затлылык, үзенчәлекле холык-фигыль иңдерелгән булыр... Булса да була бит шундый сөйкемле сөякләр — аларга ни кисә дә килешә, тәненә сыланып-ятып тора. Хәтта кайбер килешмәгән якларны да гафу итәсең.
Шундый шәхесләрнең берсе — арабыздан вакытсыз китеп барган укытучым Мөхәммәт Мәһдиев иде. Ул безгә — ничәмә-ничә буын студентларына — ярату һәм сарказм, әрнү һәм шаяру белән сугарылган лекцияләрендә, аралашу минутларында, һәм, әлбәттә, иҗатында, гүяки, «мескен булмагыз!» дип әйтеп килә иде. Шуңа күрә микән, аның баштарак сәер тоелган тәкәбберлеген дә шуңа карап аңларга тырыша идек.
Мәшһүр дирижер Фуат ага Мансуров оркестр каршындагы күперчеккә менеп баскач та шундыйрак горурлану хисе кичерми мөмкин түгел; ирексездән, янындагы чит милләт кешесенә, күрегез, татар зыялысы менә шулай затлы булырга тиеш ул, дип әйтәсе килә. Атаклы галим-педагог Мирза ага Мәхмүтов белән урамда яки берәр җыелышта очрашырга туры килгәндә, Айрат ага Арслан шигырь укыганда да татар булып туганың өчен күңелгә шундыйрак рәхәт тойгылар кереп урнаша. Юк, шовинистик караштан чыгып кайбер чит ил һәм урыс галимнәре тасвирлаганча, безнең ата-бабаларыбыз гел генә кәтәнә буйлы, мескен кыяфәтле булмаганнар, дип сөрән саласы килеп китә (кыскарак буйлылар кичерсеннәр мине). Юкса Көнбатышта ир-атлар эталонын эзләп баш ваталар, әле француз артисты Ален Делонга тынгылык бирмиләр, әле Ричард Гир дип авыз суын корыталар. Ярар, бусы аларның «үз эше» — үз иле булган, дөньяга

чыгып үз сүзен әйтергә оялмый торган халыклар нишләмәс тә, ни генә кыланмас... Шулай да Айрат аганың сәхнәгә чыгып шигырь укыганын күрсәтәсе иде ул цивилизацияле халыкларга, нишләрләр иде икән? Татарча бер генә авыз сүз белмәсәләр дә, барыбер татар кешесенең, татар сүзенең көч-кодрәтен сизми калмаслар иде — сүз яңгырашы белән башкаручының төс-кыяфәте, гармониясе, эчке рухи җегәре әсир итәр иде аларны. Әйе, «татар» зыялысы менә шулай була ул дип, Парижларда йөртәсе иде ул шигъри сүз остасы Арсланыбызны. (Язмыш шуклыгы димичә ни дисең, шагыйрь Нури ага Арслан да нәкъ менә арсландай мәһабәт бер кеше иде бит.) Һәм тагын Сибгат ага Хәким әйткәнчә, «Халыкның Тукайлары, Җәлилләре, Такташ, Хәсән Туфаннары кебек гаҗәеп үзенчәлекле олы талантлары бар. Аларны да зур дөньяга чыгарасы иде... Айрат Арслан — татар поэзиясенең илчесе, вәкиле... Димәк, безнең әсәрләр аралаша, дуслыкка, туганлыкка хезмәт итә».

Болай дигәндә, Казанга Кайбыч якларыннан кунакка килеп төшкән бер агайның сүзләре хәтергә килеп төште бит әле. «Минем бер дустым бар, — дигән иде ул, сүз иярә сүз чыгып. — Ну, җырлап та куя инде. Бигрәк тә урманга сәйран-вәйранга чыккач «Карурман»ны җырлаганын яратам мин аның. Юк, болай дип әйтү генә аз, чынлап менә, ул җырлаганда әллә нишлим мин, тәмам әсир булам. Илһам Шакиров дип торырсың, валлаһи. Менә ул күкрәк тутырып башлап җибәрә, мин сиңайтим, колач җитмәслек Кайбыч имәннәренең данын үзегез беләсез инде — әсәрләнүдән нишләргә белмичә тамырларыннан кубарылып, бермәл һавада асылынып торалар да, җыр туктагач, уп итеп кабат урыннарына төшеп утыралар. Менә бит ул, җәмәгать, ихлас күңелдән чыккан моң кешене нишләтә. Бу авыл гыйбаты килеп безгә акыл сатып утыра дип уйламагыз тагын, әйтәм ич, башка болай иләсләнсәм дә Илһам Шакиров «Карурман»ны җырлаганда гына иләсләнә торганмындыр. Менә шулай, җәмәгать...»

Бу сүзләрне, әйе, бер авыл агае әйтте. Ләкин ничек итеп әйтте бит, чыдап кына тор.

...Әлеге сөйләшү сынчы Фәһим Фәсхетдиннең остаханәсендә булды. Бүкән яны тынып калды. Мин исә, тынлыкны бозмас өчен, әкрен генә урынымнан кузгалдым да остаханәнең ян бүлмәсенә чыгып, әлеге сүзләрне түкми-чәчми куен дәфтәремә төшереп куйдым. Әнә бит ул ничек ди: «...колач җитмәслек Кайбыч имәннәре... әсәрләнүдән нишләргә белмичә... тамырларыннан кубарылып... бермәл һавада асылынып торалар да... җыр туктагач, уп итеп... кабат урыннарына утыралар..., — ди.

Кем ничектер, яшермим, Айрат ага Арсланның сәнгать әсәре булырдай шигырьләр укыганда, мин үзем дә еш кына әнә теге җанлы-канатлы Кайбыч имәннәре хәлендәрәк калгалыйм. Әйтик, аның башкаруында «Кыйссаи Йосыф»ны ничек дулкынланмыйча тыңларга мөмкин — күз алдыннан бөтен бер тарихи чор картинасы йөгереп уза ич. Озын сүзнең кыскасы шул: Айрат ага Арслан — татар тарихында бөтен гомерен нәкъ менә сәнгатьле укуга багышлаган, үз мәктәбен булдырган әдәбият галиме дәрәҗәсенә җиткән бердәнбер сүз остасы ул.

...Икенче көнне Айрат ага үзе безгә килеп керде. Дөресрәге, кыюсыз гына ишек төбендә басып торды (чын олпатлар ертлач булмыйлар) һәм язмаңны әзерләгәндә, бәлки, кирәге чыгар дип бер төргәк кәгазь сузды. Сүз сәнгате турында ачынып язылган уйлар иде ул. Хөрмәтле укучым, автор рөхсәте белән аның бер өлешен синең хөкемгә тапшырырга җөрьәт итәм.

«Үткәннәргә әйләнеп карасак, татар эстрадасында сәнгатьле уку жанрының да үз тарихы, үз башкаручылары, үз авторлары бар иде. 50–80 нче еллар эстрадасына күз салсак, без чын әдәби сүз осталары — шагыйрьләр Х.Туфан, Ә.Фәйзи, Ә.Исхак, С.Хәким, Ә.Давыдов, Н.Арслан, И.Юзеев, Ш.Галиев, Ә.Баян, язучылар Г.Бәширов, Ә.Еники, Ф.Хөсни, М.Мәһдиев, М.Әмир һ.б. әсәрләре зур уңыш белән башкарылганын, тыңлаучыларның аларны яратып тыңлауларын, авторларга һәм аларны башкаручыларга мәхәббәтен күрербез.

Ә татар сәхнәсендә сүз жанрын үстерүдә хезмәт күрсәткән шәхесләрне санап китсәк, алар арасында Г.Кариев, С.Гыйззәтуллина-Волжская, Х.Сәлимҗанов, Ш.Сарымсаков, Г.Ибраһимова, Р.Җиһаншина, Г.Шамуков, Ф.Йосыпов, Ә.Яһудин һ.б. бар иде. Алар арасында зәвыксыз, мәгънәсез язылган әсәрләрне очрату гайре табигый хәл була торган иде. Башкаручыларның үз сәхнә эшчәнлегенә җитди, зур җаваплылык белән карауларының бер мисалы булгандыр бу.

Тагын бер мәсьәләгә тукталып үтәсе килә. Профессиональ сәнгать белән бергә үзешчән сәнгатебез дә үсә, алга бара. Яңа коллективлар барлыкка килә, ансамбльләр оеша, аерым башкаручылар үсеп чыга, әмма аларга сәнгатьтә дөрес юнәлеш бирүдә, башкару осталыгын күтәрүдә ярдәм итүнең җитәрлек булмавы күзгә ташлана. Казан урамнарында бихисап афишалар күрәбез, аларда «фәлән районнан килгән фәлән сәхнә йолдызы җыр остасы, фәлән нәфис сүз остасы» һ.б. шундый сүзләрне укыйбыз. Ә баксаң, бу «осталар» берничә үзешчән композитор әсәрен яки берничә юмореска башкаручы, вокаль осталыклары түбән, сәнгатьле уку әлифбасын да үзләштермәгән үзешчән артистлар булып чыгалар. Ә бит «нәфис сүз остасы» дигән исем ул «халык артисты» исеме белән тәңгәл тора торган, сүз сәнгате фәнен үзләштергән,

сөйләм техникасын күп еллар дәвамында чарлаган, репертуарын даими баетучы чын сәнгать кешесенә генә бирелә торган исем. Шуны әйтү генә дә җитәр дип уйлыйм. Без яшьрәк вакытларда бу исемгә лаек өч кенә башкаручы бар иде: Хәким Сәлимҗанов, Ширияздан Сарымсаков, Габдулла Шамуков. Без бу башкаручылар белән горурлана идек. Әгәр башкаручы, сүз техникасын бөтен нечкәлекләре белән үзләштермичә, сәнгатьле уку кануннарын белмичә укый икән, аның нинди генә мактаулы исемнәре булса да, «нәфис сүз остасы» дигән исемгә лаек була алмый торгандыр. Нәфис сүз остасы дигән исемне йөртеп тә, сәхнәгә чыккач ул сайлаган әсәренең идея тирәнлеген ача белмәсә, бу жанрда эшләүнең бөтен нечкәлекләрен бирә алмаса һәм, иң әһәмиятлесе, телебезнең аһәңен, матурлыгын, тәмен тыңлаучының күңеленә ярып сала белмәсә, ул нинди сүз остасы була инде? Элегрәк заманда андый башкаручыларны «тел бистәсе» дип тә атый торганнар иде.
Бу мәсьәләгә, бигрәк тә сәнгатьле уку өлкәсендә эшләүче кадрлар тәрбияләүгә сәнгать оешмаларында, Мәдәният министрлыгында аеруча җитди карау, зур әһәмият бирү сораладыр. 1997 елның март урталарында газеталарда халык иҗаты буенча фәнни-методик үзәкнең бөек шагыйребез Г.Тукай призына III Республика бәйгесе үткәрәчәге турында белдерүләре басылды. Белдерүдә мондый сүзләр бар иде: «Бу бәйгенең тагын бер бик әһәмиятле максаты — профессиональ үзешчән башкаручылар арасыннан яшь, талантлы нәфис сүз осталарын сайлап алу, халкыбызда сәнгатьнең бу төренә мәхәббәт уяту». Белдерүнең исеме дә «Нәфис сүз осталары игътибарына» дип куелган. Бәрәкалла, сәнгатьнең бу жанры турында да җитди уйлана башлаганнар, боз кузгала башлады, ахры, дигән уй килде башка. Ләкин белдерүне төзүчеләр дә «нәфис сүз осталары» дигән төшенчәнең асылын аңлап бетермәгәннәр. «Нәфис сүз осталары» дәрәҗәсендә булгач, аларны сайлап алу кирәк. Аннары үзләре үзешчән башкаручылар да, үзләре яшь тә булгач, кай арада шундый осталар булып җиткәннәр соң алар? Үзешчән сәнгатьтә эшләүчеләр арасында «күренекле», «мәшһүр», «оста» һ.б. төшенчәләр белән сак эш итү кирәклеген раслаучы бер генә факт бу.
Мин ышанам, киләчәктә сәнгатебезнең күркәм, бик кирәкле жанры булган сәнгатьле укуга да игътибар артыр, аның халкыбызны эстетик тәрбияләүдә зур чара икәнлеге сәнгать белән җитәкчелек итүчеләрдә дә кайгыртучанлык уятыр, бүгенге көндә эстрадабызда «чәчәк атучы» зәвыксыз «әдәби» эшләнмәләр урынына, ниһаять, чын әдәби әсәрләр кайтыр, аларны бөтен тирәнлеге, матурлыгы, аһәңе белән башкара алучы әзерлекле, талантлы башкаручылар килер». Останың әлеге сүзләреннән соң: «Иншалла!» — диясе генә кала.

*«Мәдәни җомга», 3 апрель, 1998*

## ШИГЫРЬ ТАМЫРЫ

Һәр шагыйрь Шигырьгә үзенчә килә...
Шушы юлны күзалларга тырышып, иҗатның тамырын эзләп Галиҗәнап шигырь турында сүз чыкканда шагыйрь дусларыма мин менә мондыйрак сорау белән мөрәҗәгать итәргә яратам:
— Беренче шигырьләреңне кайчан яза башладың син, шагыйрь туганым? Үзеңне кайчан шагыйрь итеп тойдың?
Беркатлылык, әлбәттә, әмма минем шул рәвешле шагыйрь дустымның үсеш эволюциясен күз алдыма китерәсем килә — кызык ич, нәрсә мәҗбүр иткән аны кулына каләм алырга, шигырьдә нинди уйлар җилкендереп яшәтә аны? Һәм минем шушы сорауны биргәндә, яшьтән үк иҗат белән җитди рәвештә шөгыльләнә башлаган шагыйрьләр генә (талант мөмкинлек биргән кадәренчә, әлбәттә), профессиональлек дәрәҗәсенә ирешәләр, дигән гипотезама уңай җавап та аласым килә бугай. Чөнки, ерактан килгән генә еракка китәр, диләр ич.
Танылган шагыйрь Госман Садә белән дә безнең шушы хакта озаклап моназара кылып утырганыбыз бар. Булды андый хәлләр.
— Башкалар турында әйтә алмыйм, — дигән иде ул сөйләшүләрнең берсендә, — шәхсән үземә килгәндә, бәхет эшедер инде, Ходай миңа шигъри җимне имезлек белән бергә салган булган. Дәү әни — әтиемнең әнисе — Хәкимә картый сөйләвенә караганда, минем телем бик иртә ачылган: әле сәке буйлап мүкәләп йөргән чагында ук ул миңа җырлар җырлаган, Габдулла Тукай китабыннан көйләп «шыерлар» укыган. Әйе, мин: «Бәбкәм, кем бу? Кем китабы бу?» дигән сораугa: «Актүнәкәй... Актүнәкәй шаирли булган, ул шыерлар язган», — дип әйтә торган булганмын; Габдулла Тукай дип әйтә алмаганмындыр инде, күрәсең.
Әбиле үскән бүгенге урта һәм өлкән буын әдипләр өчен таныш кичерешләр бу: аларның күбесе беренче шигъри мәктәпләрен шул рәвешле үтте ләбаса.
— Монысы сабыйчак хатирәсе, — дип сүзен дәвам итте Госман әфәнде. — Балачактан исә

мондый бер вакыйга истә уелып калган. Нәкъ менә Такташча инде, үземнән бер генә яшькә олы Мәүләви абый белән «зурлар кебек кулны артка куеп», якында гына агып яткан Төй елгасы буена мурда үрер өчен тал чыбыклары алып кайтырга төшеп барабыз. Абый сөйли, мин тыңлыйм.
Шунда ул миңа:
— Шигырьләр язып карадым әле, энекәш, — ди.
— Аны ничек язалар соң? — дим мин, исем китеп. Шигырь хәтле шигырь язып кара әле син…
— Башта күргән-уйлаганнарыңны хикәя итеп язасың, аннары юлдан-юлга шигырь итеп күчерәсең.
Абыйдан калышасым килмәгәндер инде, качыра-качыра шигырь чыгара башладым; кыскасы, ләззәтле дә, сихри дә билгесезлеккә чумдым. Беренче шигырьләрем 6 класста укыган чагында «Башкортстан пионеры» газетасында басылып чыкты. Шуннан соң китте инде. Бөтен класс мине «язучы» дип атап йөртә башлады.
— Үзеңне кайчан шагыйрь итеп тоя башладың?
— Уфа дәүләт университетының өченче курсында укыганда мин беренче зур тетрәнү кичердем. Уфада «Мөселманнар зираты» дигән бер зират бар. Салават баһадирга куелган һәйкәл дә янәшәдә генә. Шәһәр белән танышып йөри торгач, көннәрдән бер көнне шул тирәгә барып чыктым бит. Үземчә уйлыйм инде, татар зираты булгач, татарлар яши торган урам да булырга тиеш бит, дим. Шунда бер карт кына абзыйдан сорыйм, ә ул бәләкәй генә тыкрыкка төртеп күрсәтә. Йөрим, карыйм, саныйм: алты гына өе бар. Шул чакта миңа халкым өчен бик тә, бик тә кыен булып китте: 6 миллионлы татарның (официаль мәгълүматлар буенча шулай иде) Уфада татарның алты йортлык урамы бар... «Татар урамы» дигән шигырем шундый хисләр шаукымында дөньяга килде.

Урамнарга берүк чыга күрмә,
Бурый гына февраль бураны;
Бар Уфаны айкап-айкап киләм:
— Кайсы якта татар урамы?
...Табалмагач эзләп, сорап та,
Мин эндәштем ак сакаллы картка,
Ул күрсәтте төртеп зиратка...

Бу юлларның «гонорары» миңа шактый кыйммәткә төште: татарлыгым өчен стипендия дигән сәдакадан мәхрүм иттеләр, кырын карый башладылар. Кемнәрдер (кемнәр икәне билгеле инде) астыртын киная белән: «Исәнме, татар урамы?» — дип эндәшә башлады, икенче берәүләр исә (алары азлар иде), бу сүзне горурланып әйттеләр. Шушы ярлык тагылгач, миндә Казанга китү теләге уянды. Бары тик Казанга, Казанга...
Бер «теле ачылгач», билгеле, минем Госман әфәндене сөйләтәсем дә сөйләтәсем килде, чөнки кеше дигәнең күңел түрендәге изге хисләрен тышка чыгарып салырга бик ашыкмый ул.
— Сөйлә әле, Госман дус, «бер матурның балдагын йә калфагын!»
— Шагыйрь дигән «паспорт»ны миңа Хәсән ага Туфан үзе тапшырды. Ул болай булды. 1972 ел. Октябрь айлары иде бугай, язучыларның Тукай клубында «Казан утлары» журналының беренче алты санына ел саен үткәрелә торган күзәтү бара. Шунда Хәсән ага 9 нчы санда басылып чыккан «Язгы җыр» исемле шигыремне (миңа калса!) бик мактап телгә алды. Тагын бер айлап вакыт узды. Зөлфәт белән Язучылар союзы коридорында басып торабыз. Кайсыдыр бер бүлмәдән Хәсән ага килеп чыкты. Зөлфәт инде үз кеше иде, могтәбәр әдип белән ике куллап барып күреште. Һәм миңа таба борылып: «Хәсән ага, Сез трибунадан мактап телгә алган Госман Садә дигән егет шушы була инде!» — диде, мәгънәле генә елмаеп, кил, күреш, янәсе. Хәсән ага мине ике кулы белән кочаклап алды: «Һи, улым, ул син буласыңмыни инде Садә дигән егет? Яз, язарга, язарга кирәк сиңа...» Бу сүзләр миңа наказ булып ишетелде һәм мин үземне шушы кыска гына сөйләшүдән соң Хәсән аганың мине шагыйрь итеп кабул иткәнен тойдым...
Әйе, олуг шагыйрьнең фатихасын алган Госман Садә бүген татар шигъриятенең үзенчәлекле бер таланты булып танылды. Ә ул үзенчәлек шуннан гыйбарәттер: Госман «ачык текст» белән яза, ул фикерләрен ассоциатив кинаяләргә яшереп маташмый, ә бәлки билгеле бер эзлекле калыпка салып, ачыктан-ачык әйтеп бирергә ярата. Хисләр вакыйгалар белән бергә үрелеп бара. Шушы хасияткә буйсынып булса кирәк, күп очракта аның шигырьләре динамик үсешле сюжетка, вакыйгалар агышына корылган булалар. Госман Садә үзе бу алымны «Уфа мәктәбе» дип атый. Шулай булуы да бик мөмкин, чөнки ул Уфа чорында Әнгам Атнабаев кебек күренекле шагыйрьләр белән аралашып яшәгән, алар белән бер үк иҗади мохиттә кайнаган. Әнгам ага аны «мин олы мыек булсам, син кече мыек» дип атап йөрткән (Госманның журналдагы сурәтенә генә карагыз: аңарда, чынлап та, Әнгам аганың төсмер-чалымнары чагыла түгелме соң?), мондый

рухи якынлык, әлбәттә, шагыйрьнең иҗатына да йогынты ясамый калмагандыр. Кайчак Госман Садә иҗатында Фатих Кәрим аһәңнәре дә яңгырап киткәндәй була; бу аһәң аеруча шагыйрь яратып иҗат итә торган балладалар жанрында ачык ишетелә. Әйе, әйе, Чечняның күз яше төшкән «Фирүзә чишмәсе» дигән балладаны укыганнан соң, ирексездән, бөек шагыйребезнең «Аникин», «Пионерка Гөлчәчәккә хат» поэмалары телгә килә. Шул ук халыкчан иңрәү, моң, фаҗига... Вакыйгалар гына башка...
Сизгер тоемлы Рәдиф Гаташ исә Госман Садә иҗатындагы «йолдызларны җиргә коя хыял-атның тоягы...» дигән юлларда «Мостай Кәримнең тавышын» ишетеп куана.
...Госман Садә — татар шигъриятенә, мәдәниятенә игелекле хезмәт итеп килүче шәхесләрнең берсе. Ул — «Мәхәббәт елы», «Җиләкле тәрәзәләр», «Тайфун күзе» кебек җыентыклар авторы. Аның утыздан артык шигыренә композиторларыбыз көй язганнар. «Әссәламәгаләйкем», «Рамазан», «Җомга азаны», «Кәккүк яме» кебек милли рухлы җырлары исә халык күңеленә «язылганнар».
Болары шулай... Әмма Госман Садәнең эш өстәлендә беркайда да басылып чыкмаган көлтә-көлтә шигырьләрен күргәч, моннан берничә еллар элек булып узган гыйбрәтле бер вакыйга хәтергә төшеп, күңелне әрнетеп куйды әле. «Чаян» журналында бергә эшләгәндә, мәрхүм Фаил Шәфигуллин Зөлфәтнең өстәлендә тузгып яткан шигырьләренә текәлеп карап торган-торган да, киная белән: «Син, Зөлфәт, кәнишне, бөек шагыйрь, әмма син үзеңнең кадереңне үзен белмисең», — дигән. «Ничек инде, ничек?» — дип акланмакчы булган Зөлфәт. Фаил исә аңа гына хас үҗәтлек белән Зөлфәтне стенага терәгән: «Кая китабың?» Икенче бер вакыт, җаен туры китереп, Зөлфәт бу төртмәле сүзне Госман Садәгә күчерә: «Син, Госман, билгеле, зур шагыйрь, әмма... Фаил әйтмешли...»
Әйе, Фаил әйтмешли, юк ла, Зөлфәт әйтмешли, кая дүртенче китабың, Госман дус? Бу синнән генә тормый, әлбәттә. Барыбер... бар иҗатны ташка басылган Сүз итеп күрәсе килә. Төй һәм Караидел буйларыннан, Урал төбәгеннән башланып Казансу белән Идел киңлекләренә җәелгән җырыңның дәвамын ишетәсе килә. Ишетербез, Ходай насыйп итсә, чөнки җырларыңның тамыры халык күңеленнән күтәрелә синең...

*«Казан утлары», февраль, 1999*

## ТУКСАНЫНЧЫ ЕЛЛАР ӘДӘБИЯТЫ

*Кешелек җәмгыяте өчен гаять мәгънәле дата — 2000 ел якынлашып килә. Бу дата тормышыбызның төрле тармаклары турында җитди уйлануларга этәрә, үткән чорга нәтиҗәләр ясауны, киләчәк елларга күз салуны сорый.*
*Шул уңайдан «Казан утлары» журналы редакциясе язучыларга һәм киң катлам укучыларга, әдәбият сөючеләргә гасырыбызны йомгаклаучы 90 нчы еллар әдәбияты турында түбәндәге сораулар белән мөрәҗәгать итә:*
*— Соңгы ун-унбиш елда басылган кайсы әсәрләрне (проза, поэзия, драматургия, публицистика) әдәбиятыбыз казанышы дип саныйсыз? Ни өчен?*
*— Сезнеңчә, 90 нчы еллар татар әдәбиятында нинди уңай сыйфатлар бар? Ә кайсы яклар Сезгә ошап җитми? Киләсе гасырга Сез кайсы әсәрләрне алып керер идегез, һәм татар әдәбиятында нинди сыйфатларның өстенлек алуын теләр идегез?*
*— Әдипнең җәмгыятьтәге урынын киләсе гасырда ничек итеп күз алдына китерәсез?*
Наис Гамбәр:
— Сөенечләр һәм көенечләр уртасында яшим. Әйбәт әсәрләр укысам — сөенәм, начарраклары кулга эләксә — көенәм...
Әле күптән түгел генә миңа Г.Исхакыйның «Г.Тукайның вафатына 25 ел тулу мөнәсәбәте илә» дигән мәкаләсе белән (ул 1938 елда Берлинда Г.Исхакый мөхәррирлегендә чыгарылган «Яңа безнең юл» журналында басылган булган) танышып чыгарга туры килде. Әйтергә кирәк, беренче җөмләләрен укый башлауга ук йөзем яктырып китте (менә кайда ята икән ул бүген язарыма эзләгән тел ачкычы!), шушы яктылык җавапларымны язып утырганда каләмем очына да нур булып тамсын иде (менә кайда ул фикерләремә терәк-баскыч!).
Шагыйрьләр һәм шигырьләр...
— Әйе, «Кем ул Шагыйрь?», «Нәрсә ул Шигърият?» дигән мәңгелек сорауга борынгыдан алып, хәзергегә чаклы йөзләрчә халыкларның меңнәрчә фикер ияләре төрледән төрле кимәлдә җаваплар биргәннәр, җаваплар эзләгәннәр һәм әле дә булса эзлиләр... Менә тагын шундый җавапларның берсе Гаяз Исхакыйныкы. «Үзләренең шәхси кабилиятләре берлә бер-берсенә охшау-охшамауларына карамастан шагыйрьләр... икегә бүленәләр, — дигән ул. — Бер төрлесе

үз-үзен тирә-юньнән аерып алып, үзен чорнаган мохиттән рухан аерым була ала торган, үзенең төшенчәләре, хиссиятләре эчендә генә тәҗәрред итә (ялгыз яши) ала торган, вә бу вакытта гына шигырь ярата (тудыра. — *Н.Г.*) ала торган шагыйрьләрдер. Икенчесе үзен тирә-юньнең, мохитнең бер өлеше итеп хис итеп, шуның бөтен күңел алышуларына үзенең йөрәк тибүе берлә катышып, аның шатлыгына сөенеп, аның кайгысына янып, шул шатлык-кайгыдан дәрт алып кына шигырь яратучылардыр... Икенчедән, туган халкы, аның тирә-юне, яшәгән мохитенең шул вакытта кичергән уйлары, хисләренең тәрҗеманы булып, шул халыкның шатлыгын, кайгысын, өметен сөйләүче, аның үзенең мохитенең иҗтимагый омтылышларын төрләндереп эшләүче, җәмгыять эшләренең һичберсе яныннан күз йомып, колагын тыгып үтә алмаучы, җәмәгатьче шагыйрьләрдер. Бу төрлесе үзенең көче, сәләтенең зурлыгы, кечкенәлеге, тирәнлеге, сайлыгына карап, яшәгән мохитенең термометры ролен уйнап килеп, үзенең шул термометр дәрәҗәсенең нечкәлек-тупаслыгына карап, халыкның күзеннән кан-яшь агуын, йөрәк тибүен җырлап торалар. Бездә Сәгыйть Рәми беренче груһтан булса, Габдулла Тукай менә соңгы төстәге шагыйрьдер».

Бөекләр кайда да — бер-ике кәлимә сүздә дә — бөек булып кала шул: никадәрле төгәл күзәтүләр, никадәрле хакыйкый бәяләмәләр.

Сүземне яшьтәшләремнән башлыйсым килә.

Икенче төрле шагыйрьләр рәтенә мин, беренче чиратта, Мөдәррис Әгъләмовны кертер идем. Гаяз Исхакый әйтмешли, ул — «үзенең мохитенең шатлыгын, кайгысын, дәртен шигырь төсенә сугучы бер тел остасыдыр». Мөдәррис — барлык вөҗүде белән, эче-тышы белән, бары-югы белән, чыны-ялганы белән халыкчан шагыйрь. Аның иҗаты буеннан-буена шундый да халыкчан тирән моң, саф сагышлар, ихлас әрнү, киная катыш усаллык вә үҗәтлек белән сугарылган ки, әдәбиятны аңлау-аңламавы, дөньяга карашы төрле булуга да карамастан, аны төрле социаль катламнар — гыйлем иясе дә, гади халык та, яше дә, карты да — үз шагыйре итеп кабул итә. Мөдәррис шигърият «сабантуе мәйданына» яшь булса да олыларча зирәклек белән (бу юллар бүген дә актуаль булып яңгырыйлар):

Дошманнар таптаса җиреңне,
Сорамый: «Син батыр идеңме?»
Мәйдан күк кысыла бар халык:
— Бирмә илеңне!
— Бирмә! —

дип чаң кагып килеп керде һәм бүген дә, менә утыз елдан артык инде, сулкылдый-сулкылдый, «Акмулла арбасы»нда безнең бүгенге буынга мирас булып ирешкән «Тукайдан хатлар»ны укый. Укый дигәннән, бездә шигырьне үзәкләргә үткәрерлек итеп укучылар бик сирәк, ә менә Мөдәррис шул сирәкләрнең берсе; ул шигырь укыганда, тәннәр кымырҗып китә, сулыш алу кыенлаша башлый, тамак төбенә төер утыра... Әнә ике ел элек, үзенең иҗат кичәсендә шигырь укып киләндерде генә шагыйрь, артистларың да тоныкланып калды: тавыш гөбедән чыккан кебек ярсып чыга, күзләр ут кебек яна, борын яфраклары киңәйгән, сул кул кылычтай башөсте күтәрелгән — шагыйрь яньчә генә; ул гади дә, интим да хисләрен мәңгелек хакыйкатьләр ефәгенә төреп болай ди:

Илләр бәхетенә җиткән хәтле
Саклармы Җир затлы хакыйкатьне
Ялган матурлыкка төрмичә?
...Киләчәккә бара алмый шагыйрь,
Бара алмый шуны белмичә!

Әйе, Мөдәррис — чичән шагыйрь; егетләр мәйданнарда ат уйнаткан кебек, шигырьдә саллы сүз уйната белә:

Юридик яктан шагыйрь юк,
Юридик яктан — патша юк.
Әкияттә калган алар:
Калыкса — бар,
Батса — юк!

Мөдәррис турында сүз чыкканда еш кына «анда өйрәнчеклек чоры булмады, шигырь аңа болыты белән ишелеп кенә төште» диләр. Хаклык юк түгел монда (йөрәкләргә ничек кан савылуын шагыйрь үзе генә беләдер), шөкер, баскан урыны тар булса да, ул әйтәсе сүзен әйтеп, күкрәк киереп җырлап тора — Тукайчарак итеп:

Сүз җибәрдем... Гаебем зур.
Яратмыймын болгануны.
Күлне — балык,
Илне халык болгатачак;

Мин — ил улы.

Ил улы булып яши алу ул олуг шагыйрьләргә генә бирелә. Ә Мөдәррис — олуг шагыйрь! Татар шигъриятендә Зөлфәт белән Мөдәррис, бер нигездән бергә калыккан манаралар кебек, бергәлектә янәшә басып баралар. Зөлфәт Зөлфәтчә, үзенчә олуг шагыйрь. Менә кайда ул көч, җегәр, биек очыш; менә кемдә ул галәми киңлекләргә иңрәп таралган гасабиле тавыш. Ул үтә дә шәхси тоелган хисләрне дөньяви орбитага чыгара алу кодрәтенә ия; ул көндәлектәге гадәти кичерешләрне дә галәми биеклеккә күтәрә ала; вакытлыча туган омтылышларны да мәңгелек белән бәйли:

Мин бит монда бер яшәгән идем! —
Гафу ит син берүк Дөньялык!
Тагын менә чыклар ярып йөрим,
Мәңгелектән капылт уянып.

Тирәннән, метафорик төпкелләрдән, «патша булып утырган бушлыклардан», урман араларыннан, «яшеннәр оясыннан» ургып-ургып чыккан Зөлфәт шигъриятендә Хиражчча дуамаллык та («килде иҗатчылар янына ул шактый гына «иҗадиланып»; килеп китә иде ул бер көнгә, ун ел кыйланасын кыйланып»), Хозыр Ильяс кебек хозурлык та бар («Хозыр Ильяс идем. Мин идем»). Зөлфәтнең шигъри гомер елгасыннан Ут белән Боз бергә агып бара. Әйе, Зөлфәт — антитезалар остасы: аның «күңел кошы», бер карасаң, күкләрдә талпына, икенче карасаң, «кайнар кәлтә эзләреннән» мәңгелеккә үтеп бара. Менә шулай бер чикләрдән икенче чикләргә барып тоташа аның авазы; шуның нәтиҗәсе буларак, ул Галәм, Җир, Күк һәм башка шундый «һавалырак» сүзләрне дә еш куллана, әмма бу «шапырыну» Зөлфәткә шундый килешеп тора ки, аны тыйнаксызлыкта гаепләргә һич кенә дә тел әйләнми... Әйләнми, чөнки алар очышның («Күкнең һәр йолдызы эри-эри тамган ут сыман»), фәлсәфи сурәтнең тәңгәл кайтавазы буларак яратылганнар. Шулай, Зөлфәт белән Мөдәррис шигъриятендә хис, фикер, тойгы, сурәт элмәкләнә-элмәкләнә, бөтерелә-бөтерелә бергә укмашып, тоташ агыш булып агылалар. Алар бер тотып алынган детальне, сурәтне кулдан ычкындырмыйлар, шигырь ахырында кабат, әмма яңа сыйфатларда тергезеп, уятып вә уйнатып җибәрәләр. Алар безне менә шулай «алдыйлар». Берара Зөлфәт, кайнар Зөлфәт бераз сүлпәнәя башлаган да кебек тоелган иде (хәер, И.Тургенев билгеләп үткәнчә, заманында Пушкин булып Пушкинны да «бирешә башлады» дип битәрләүчеләр табылган); баксаң, бу тын алу гына булган икән. Әнә Зөлфәт соңгы араларда гына 15–16 табаклык, ягъни ун-унбер мең юллар чамасы өр-яңа шигырьләр тәгәрәтеп атты. Бер әңгәмәсендә күренекле рус шагыйре Е.Евтушенко «өч-дүрт ай эчендә 80 ләп шигырь яздым» дигәч, вәт «продуктивность» бу ичмасам дип шаккатып торган идем, мондый җенлелеккә безнең егетләр дә сәләтле икән ләбаса.
Шигырьләр арасыннан үзенең сурәтлелеге белән берсе аеруча сискәндерде. «Дала уртасында ак теплоход...» дип атала ул («Казан утлары», 1998, № 2):

Күз алдыма гел килә дә баса:
Без яшәгән сәер бу заман —
Дала уртасында ак теплоход!
... «Титаник»ка никтер охшаган...

Аклык һәм һәлакәт!.. Һәлакәткә таба йөзеп баручы ак теплоход!.. Җитмәсә, ул дала уртасыннан йөзеп бара бит әле — моннан да зуррак хата, мәгънәсезлекнең, чынбарлык белән хакыйкать арасындагы аңлашылмаучылыкның булуы мөмкинме соң? Әмма бу — бүгенге чор, бүгенге заман сурәте. Ирексездән Чыңгыз Айтматовның «Ак пароход» повестендагы мотивлар күз алдына килеп баса: шундый ук гаҗизлек, шундый ук өметсезлек.
Зиннур Мансуров артык күзгә ташланмыйча гына, яфрак-үләннәр арасыннан үзенә азык эзләп чыккан керпе шикелле, кыштыр да кыштыр иҗат итә бирә. Аның шигырьләрендә ниндидер үзгә, фәлсәфи, парлак моң, җилбәзәк шом бар. Ул яши-яши акыл җыйган авыл карты кебек тирән уйга чума, мәҗүсиләрчә матурлыкка табына, тын сагышка бата, шуңадырмы, аның шигырьләрендә әүлиялык чаткылары да чагылып киткәндәй була:

Нигә әле шаһит булдым
Туган чакта могҗиза?
«Бөтнек исе! Бөтнек исе...» —
Эчтән кылдым мең нида.

Гаяз Исхакыйча бүленештә Рәдиф Гаташны беренче төр шагыйрьләр рәтенә кертеп карарга мөмкин булыр иде. Рәдиф Гаташ — романтик шагыйрь; ул дөньяны йөрәге аша күрә. Гаташ иҗатының башлангыч чорында татар шигъриятенә Александр Гринның «Ал җилкәннәр» әсәрендәге Ассоль кебек садә, саф, романтик рухлы героиняларны алып керде, аннары гомере

буе мәхәббәткә мәдхия җырлады. Зөлфәт аның турында болай дип язып чыккан иде: «Әгәр чынлап, «Мәхәббәтнең мәҗнүн исемендәге премиясе» булдырылса һәм ул премиягә Рәдиф Гатауллин кандидаты тәкъдим ителсә, мин аны яклап чыгыш ясаудан тыелып кала алмас идем һәм ул күпләрнең күңел тавышы белән Мәҗнүн дигән ат алды да.» Дөрес, бервакыт, иҗатының урта бер чорындарак, ул башка темалар белән дә мавыгып алды (шагыйрь хәзер бу хакта «йөргәнмен шунда саташып» дип искә ала), әмма тора-бара тагын үз ярларына кайтып төште. Бөтенләй башка сыйфатта, акыл утырткан, акыл иясе сыйфатында кайтып төште ул. Гаташ гаҗәеп эрудицияле шагыйрь, ул Көнбатыш поэзиясен дә, Көнчыгыш-Шәрык поэзиясен дә яхшы белә. Баштарак Байрон, Гете, Бернс, Вийон, Ронсар, Бодлер, Лорка шигърияте белән җенләнеп йөргәннән соң, соңрак Шәрык шигъриятенә кереп чумды. Нәтиҗәдә бу гауваслык бушка китмәде, Гаташ әдәбият диңгезе төбеннән робагыйчы, газәлче булып калкып чыкты. Шагыйрьнең борынгы Шәрык поэзиясе жанрларына, аеруча газәл жанрына мөрәҗәгать итүе бер дә гаҗәп түгел, бу жанр аның поэтик фикерләвенә ярашып, ятып тора. Газәлләр — Гаташ иҗатында гүзәллек символы ул.

...Үкенмәм дим, Гаташ исемен бәеттә,
Гыйбрәт итеп, авылың, нәселең сөйләсен!
Бәлки, әйтерсең үзең дә, син Гүзәл:
— Милли йолдыз саклар, ышан — үлмәссең!

Мондый алым, лирик геройның кемгә булса да эндәшү алымы, эчке импульслар аша гүзәллек объектына мөрәҗәгать итүе Гаташ иҗатына элегрәк тә хас күренеш иде. Газәлләрдә исә бу алым, жанр хасиятләреннән чыгып, тагын да киңрәк урын ала; чөнки, безгә калса, ул күңел кичерешләре аша олы дөньяга эндәшә — борчыла, шатлана, оча, очына... Аннары тагын шунысын да искәртеп үтик: Гаташның шигырьләре ритмик төзелеш, структура ягыннан элек тә катлаулы, күп катлы, күп чылбырлы, динамикалы иде, шушы сыйфатның газәлләрдә дә саклануы һәм тулаем әсәрнең, һәм аерым бәетләрнең экспрессив яңгырашын, тәэссоратлы аһәңен көчәйтеп җибәрәләр.
Кыскасы, татар шагыйрьләре арасында Шәрык классик шигъриятен яхшы белүчеләрнең берсе буларак, Гаташ иҗатында әледән-әле борынгылык чалымнары төсмерләнеп китә, аның шигырьләрендә борынгы диварларга сеңеп калган илаһи тавышлар ишетелгәндәй була. Шушының белән ул 90 нчы еллар шигъриятенә яңача колоритлы рух, эстетик яңарыш алып килде. «Бу — сиңа кылган догам...» китабы (Казан, 1997) шуның ачык мисалы.
Равил Фәйзуллин соңгы елларда азрак язды кебек, аның каруы, 4 томлык «Сайланма әсәрләр» сыйфатында күпьеллык хезмәт җимешен гавам кулына тапшырып зур егетлек эшләде. Хәтердә ич, шагыйрьләрдән Хәсән ага Туфан белән Сибгат ага Хәким генә үзләре исән чагында ике томлык әсәрләр җыентыгын чыгарып кала алганнар иде һәм бу ул чагында хаклы рәвештә олы вакыйга итеп кабул ителгән иде. Менә тагын шуларга тиң тантана, иҗат тантанасы. Шәхсән бу минем өчен аеруча истәлекле, чөнки томнар туу процессында миңа әдәби редактор буларак катнашырга туры килде. Җаваплы да, борчулы да, шатлыклы да көннәр иде ул. Равил Фәйзуллин никадәрле генә катлаулы шәхес булмасын, аның белән эшләве үзе бер сабак икән: беренчедән, үзенә дә, редакторга да таләпчән; икенчедән, үзе дә эшли белә, кешене дә эшләтә белә. Кыскасы, ярты сүздән аңлашып эшләдек кебек. Аннары, зур иҗатка күңелең белән орынуың, аның эчендә кайнап яшәп алуың, автор белән бергә шатлануың вә борчылуың үзе бер бәхет бит ул. Редактор булуның, гади укучылар белән чагыштырганда, өстенлекләре менә шуннан гыйбарәт, минемчә.
Равил Фәйзуллин иҗатына багышлап йөзләрчә мәкаләләр язылды, мин фәкыйрегез дә, кодрәтеннән килгәнчә, моңа үзеннән өлеш кертте (Р.Фәйзуллин. Сайланма әсәрләр. 3 том, 269–306 б.), шуңа күрә дә язылганнарга өстәп әллә нәрсә әйтә алмам, шулай да сөземтә рәвешендә генә кайбер күзәтүләрем белән уртаклашып китим әле.
Р.Фәйзуллин — хәзер дә үз стихиясендә, ул метафорик ассоциацияләр аша зур дөньяның асыл сурәтен эзләвен дәвам итә, эмоциональ-психологик, метафорик ассоциацияләргә корылган шигырьләр аның төп кредосы. Әйе, ул вакыт агышына, дөнья барышына чын фәйләсуфләрчә карый, хис-фикернең сүлен — сыга, түбен — түгә. Кайчагында соңгы баш хөкемдар булып хөкем чыгарып куярга да ярата. Әйтик, «Казан утлары» журналында басылган шигырьләре (1998, № 12) тулаем шундый рух белән сугарылганнар.

Һәм, ниһаять, бусы да булды!
Яптык бер сәхифә!
«Ах! Ялгыштым!..» була алмый
Кичә үткән кичә!

Шагыйрьләр әдәбиятка төркем-төркем булып та, аерым-аерым да киләләр. Роберт Әхмәтҗанов исә Х.Туфан, С.Хәким, Н.Арслановлар буыны белән Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Р.Гаташ, Р.Мингалим, Г.Рәхимнәр буынын тоташтырып торучы иҗатчы — «җәяүле күбәләк» булып килеп керде. Батулла әйтмешли, ул — буыннар алмашында барлыкка килгән бушлыкны, упкынны яулаган шәхес; нәселдәнлек чылбыры өзелде дигәндә, күпер булып ике ярны тоташтырган шагыйрь ул — Роберт Әхмәтҗанов. Әйе, әнә шул «җәяүле күбәләк»леге аңа күп вакыт кыенлыклар да китергәндер, әмма Роберт Әхмәтҗановның күңел дөньясын, аның иҗади принципларын, рухи эзләнүләрен, ахыр чиктә, эстетик карашларын, поэтик идеалларын шушы метафорик образдан төгәлрәк әйтеп бирү мөмкинме соң? Берникадәр миститиклыгы, шашкын хыялыйлыгы, бәлки, табигатькә үтә якын булуыннан, «Җил һәм Кояш Республикасы кочагында» эреп бетә алуыннан киләдер? Шундый шагыйрь генә (башкаларга килешмәс тә иде):

Ятам ярда. Тыныч дәүләт сыман.
Баш очымда шаулый тупыллар.
Баш очымда Идел әкият сөйли.
Йөрәгемне юа дулкыннар, —

дип әйтә ала. Ул тормышны «тургай тәрәзәсе» аша тоя, «пыяласы аның күк фирүзә», аны «якты җилләр, якты яңгырлар юа», әмма тирәндә нәзберек моң ята:
Күрдем кунган очар кошларның гел Җилгә каршы карап торуларын.
Тормышта «җәяүле күбәләк» булып та, шигырьдә шоңкар булу шушыдыр инде ул!
Хатын-кыз шагыйрьләрдән өч буын вәкиленең — Лена Шагыйрьҗан, Илсөяр Иксанова һәм әле бөтенләй яшь Луиза Янсуарның авазлары башкаларныкыннан аермалы булып, ачык ишетелеп торалар.
Дөрес, мин бу җавабымда бик күпләрнең иҗатына күз салып үтәргә тиеш идем дә бит, күңел тарлыктан түгел, урын тарлыктан шушы урында нокта куеп торырга мәҗбүрмен.
Ә гомумән алганда, соңгы дәвер шигърияте иманга кайту, иман яңарту шигърияте булды.

*«Казан утлары», март, 1999*

## ХАЛАТЫ АК, КҮҢЕЛЕ ПАКЬ

### Көйләр түгел иде...

*Татарстанның атказанган табибы Равил Шәймәрдәновка*

*Исем китеп торам: хирургның*
*Бармаклары — гармун телләрендә.*
*Бүген илгә кирәк моңны, Ходай,*
*Биргәнсең лә менә кемнәреңә!*

*Менә кемнәреңнең җаннарында*
*Дөньяларга бүген кирәк иман! —*
*Көйләр булып саркый*
*Ил табибы*
*Бары үзе генә белгән юлдан.*

*Агыла да һаман агыла ул,*
*Гармун юк чакта да кулларында...*
*Яши икән халык, яши икән*
*Мең шифага ия улларында.*

*Әйтерсең лә гармун урынына*
*Гомерләрне шулай кочаклаган.*
*Эзли бармаклары, таба көен,*
*Игелекне менә кем саклаган!*

*... Исем китеп тыңлап тордым беркөн*
*Хирургның гармун уйнаганын:*
*Бик күпләрнең язмышлары иде —*
*Көйләр түгел иде тыңлаганым...*

*Харрас Әюп*

Үзәнлектән тауга күтәрелеп килә идем. Аккош күле төбәгендәге Кече Күл тавыннан. Җилкәмдә

«кеше йөге» — төрледән-төрле кулъязмалар шыплап тулган букча. Шушы минутларда минем баш миемнән: «Син бит, туганкай, Эверест тау түбәсенә үрмәләүче амбицияле альпинистларның кирәк-яракларын база тукталышына кадәр тиеннәр бәрабәренә ташырга яллланучы йөкче Непал кешеләре — шерплар хәлендә ич», — дигән кебегрәк гөнаһлы уй да йөгереп узган иде. Әйе, бу халәт бер генә мизгел булып алды, әмма мин икенче караууда ук, гомере буе кеше көен көйләп яшәгән, гомере буе кеше сәламәтлеге сагында торган атаклы табиб-хирург Равил Шамил улы Шәймәрдәновның сабак алырдай сүзләрен хәтергә төшереп, үземнән-үзем оялып куйдым.
Әнә бит ул моннан берничә сәгать элек кенә нәрсә диде:
— Җир йөзендә кешеләргә хезмәт итүдән изге бернәрсә дә юк. Безнең һөнәрне сайлаган кеше эчкерсез-ярдәмчел булырга тиеш. Кешене яратмаган кешенең табиб булырга хакы юк. Шулай булмаса, син табиб түгел, көнлекче генә. Бәхетсез кешеләр алар. Чөнки беләбез ич, эшеннән тәм таба алган кеше генә чын профессиональлеккә ирешә ала. Канәгатьләнү хисе — сәламәтлек өчен иң уңай йогынты ясаучы эмоциональ кичерешләрнең берсе.
Бу сүзләрнең буш декларация генә булып калмыйча, табибның яшәү ысулы, иманы икәнлеген авыру-пациенты буларак та, гомумән, күпьеллык күзәтүләрем аша да исбатлый-дәлилли алам дип уйлыйм.
Менә без аның белән Казан шәһәренең 39 квартал бистәсендә урнашкан 7 хастаханәнең кечерәк кенә эш бүлмәсендә сөйләшеп утырабыз. Без, дигәнем, шагыйрь Харрас Әюп белән икәүләп, табибның эч серләрен белмәкче булып, бер-бер артлы сораулар яудырабыз, ә ул алай бик ашыгып ачылырга теләми. Шәхси темаларны ташлап, табиблык этикасы турында сүз чыккач кына әңгәмәдәшебез бөтенләй үзгәреп, ачылып китте, ниһаять, сөйләттерә торган кирәкле, дөрес төймә-кнопкага бастык, ахры...
— Беләсезме, егетләр, — диде ул, җитди-моңсу күзләре белән безгә туп-туры карап. — Табиб өчен чин-дәрәҗәләр юк, авырулар гына бар. Табиб барлык авыруларын бердәй, тигез, үз күрергә тиеш, чөнки алар синең ярдәмеңә мохтаҗ. Алар синең күзеңә карап, синнән могҗиза көтеп ята лабаса.
Ул үзе белән булган бер гыйбрәтле вакыйга хакында сөйләп китте:
— Шактый еллар элек булды бу хәл. Шулай көннәрдән бер көнне республиканың ул чактагы КГБ рәисе — «всесильный» генерал Абдулла Хәлилович Бичуринны хастаханәгә салырга туры килде. Аркасының җилкә турынарак, грек чикләвеге хәтле булыр, өчме-дүртме чуан чыккан. Дорфарак бер фельдшерыбыз бар иде, акырта бит картыбызны. Тегесе кушеткага яткан җиреннән сикереп торды да фельдшерга җикеренергә тотынды: «Син нәрсә, понимаешь, күрмисеңме әллә, как-никак мин КГБ генералы булам, азрак иплерәк кылансаң да ярый торгандыр!»
Мин боларны күрше бүлмәдән ишетеп тордым, әлбәттә. Тегеләр янына чыктым да сабыр һәм басынкы булырга тырышып: «Абдулла Хәлилович, хастаханәдә, бу очракта менә бу бүлмәдә, безнең өчен колхозчы-эшче дә, прокурор-генерал да юк, авырулар гына бар», — дидем. Болай да бәләкәйрәк буйлы, әмма дөньяны дер селкетеп яшәргә күнеккән дәһшәтле генералыбыз тагын да кечерәеп калгандай булды. «Ярый, аңлашылды», — диде дә, мин сезнең иркегездә дигәндәй, кушеткасына менеп ятты. Соңыннан теге фельдшерны пешердем пешерүен, ә бу вакыйга мәңгелек сабак булып калды дип уйлыйм.
Равил Шәймәрдәновның әтисе Шамил ага — Мөслим районы, Ташлыяр авылының беренче шоферы — ул чакта космонавтка тиң һөнәр иясе — көннәрдән бер көнне 7 классны тәмамлаган улын янына чакырып китерә дә болай ди:
— Менә син, Равил, хәзер кем булырга дип уйланып йөрисең инде. Миңа кара да, фельдшер Лотфрахман абыең Фәйзрахмановка кара. Минем куллар гел май эчендә, ә ул ак халаттан гына йөри, кулы да пычранмый. Кешеләргә игелекле эш эшли.
Шулай итеп, булачак хирург Казан дәүләт медицина институтын тәмамлый.
— Ул елларда тормыш алып баруы гаҗәеп авыр, авылдан килгән гади крәстиян баласы өчен икеләтә авыр иде. Укый башлауның уникенче көненнән хастаханәгә медбрат булып эшкә урнаштым. Биш ел буена шулай. Көндезләрен дәрескә, кич эшкә чабам. Концерт-театрга йөрергә, спорт белән шөгыльләнергә дә вакыт табыла иде тагын.
Кешегә профессиональ яктан үсү, күтәрелү өчен билгеле бер шартлар, мөмкинлекләр кирәк. Динамика булганда гына кеше үсә. Шулай дип уйладым да 1970 елда ординатурада укырга калдым.
— Димәк, ординатурада калуыгызны тормышыгыздагы борылыш чоры дип исәпләргә мөмкин.
— Мөгаен, шулайдыр. «Үсү, күтәрелү өчен билгеле бер шартлар кирәк» дидем бит әле... Беренчедән, күңел сиземләвем булгандыр инде, үземдә көч тә сизгәнмендер, ахрысы, зур эшләрне зур һәм көчле коллективта гына уңышлы башкарып чыгып була дип уйладым. Бу шулай да. Икенчедән, инглизләрнең «һәр кеше үзен-үзе формалаштыра» дигән сүзләренең

хаклыгына гомерем буена инанып яшәдем. Шулар хакында уйланып йөргәндә, профессор Борис Леонидович Еляшевич мондый киңәш бирде: «Сиңа Казанны ташлап китү ярамас, профессиональ яктан үсү өчен Казаннан да бәрәкәтле урын юк», — диде. Яхшы кеше иде ул, ә яхшы кешеләр тормыш юлымда гел очрап торды. Атаклы хирург, профессор, Казан онкология мәктәбенә нигез салучы Юрий Александрович Ратнерның әле яңа гына ординатура тәмамлаган яшь хирургны, олы ышаныч күрсәтеп, ГИДУВның 5 нче номерлы хирургия базасы хастаханәсенә турыдан-туры бүлек мөдире итеп эшкә алуын шуның белән аңлатмыйча, нәрсә белән аңлатасың?! Калганнары күз алдында инде.
Ә «күз алдында» дигәне болайрак. 1980 елда ул профессор Олег Егорович Кочнев белән берлектә 7 нче хастаханә базасында ГИДУВның кабаттан оешып килүче хирургия үзәгенә нигез сала. Башта ассистент, соңрак доцент, кафедра мөдире; 1982–1995 елларда Казан шәһәренең баш хирургы, миллионлы шәһәрнең хирургия хезмәтен җайга салучы, структурасын төзек хәлдә тотучы!.. Казанда бит бу, һәр өлкәдә үз медицина мәктәбе булган Казаныбыз баш калада!.. Шушы елларда Равил Шамилович кандидатлык диссертациясе яклый, докторлык диссертациясе дә әзер, вакыт табып яклыйсы гына бар. Бүгенге көндә Казан шәһәре медицина академиясенең илгә танылган бавыр, ашказаны асты бизе һәм үт куыгын дәвалау буенча фәнни үзәге нәкъ менә 7 нче Казан шәһәре клиник хастаханә базасында урнашкан икән, монда, һичшиксез, Равил Шамиловичның да гаять зур өлеше бар.
— «Алтын куллы хирург» дигән нәрсә бармы ул? Бу гыйбарә хаклыкка туры киләме? Мин үзем менә, мәсәлән, энә дә саплый алмыйм, бармаклар каткан.
— Чыннан да, бар ул, бар! — дип ышаныч белән җавап кайтарды хирург. — Музыкант уен коралын ничек тоя-сизә, хирург та шул сәләткә ия булырга тиеш. Бу фәндә «тактильное чувство» дип атала.
Ә мин, үз чиратымда, бу ихлас бәяләмәгә бөек композиторыбыз Салих Сәйдәшев турында олуг әдибебез Әмирхан Еникинең әдәби каһарманы Гөләндәм туташ авызыннан әйттергән сүзләрне генә өстәп куяр идем. «Әйе, яшерә алмыйм, залга килеп керүемә аның чибәрлеге минем күземә ташланды: бик чиста ак йөзе, сөйкемле генә чокыраеп торган ияге, җыйнак тулы иреннәре, кечерәк, әмма килешле генә борыны, бигрәк тә ак мәрмәрдәй шома маңгае... — болар барысы да сокланып карарлык иде».
Татарстанның атказанган табибы Равил Шамил улы Шәймәрдәнов та менә шулай эчтән нурланып торучы чибәр затларның берсе. Аның яныннан мин үземне «шерп малае» итеп түгел, «шәп егет» итеп хис итеп чыгып киттем. Харрас Әюп тә, шул уйларымны сизенгәндәй: «Валлаһи, бу Равил Шамилович бер-бер изге кешедер», — дип әйтеп куйды.
*«Ватаным Татарстан», 30 июнь, 2000*

**ОЯСЫНДА НИ БУЛСА...**

Язучы, гомумән, шәхес буларак, Әхәт Мушинский турында сүз чыктымы, татар халкының шушы акыллы, күпьеллык тормыш тәҗрибәсен сыйдырган гыйбрәтле сүзләре искә килеп төшә. Хәер, Әхәт моны үзе дә яшерми, җае туры килгәндә: «Мин Казанның интеллигент татар гаиләсендә тәрбияләнеп үстем, — ди эчке бер нәзакәтлелек белән. Әтием — Хәй Хафиз улы Мушинский була инде, танылган профессионал фокусчы-иллюзионист иде, җыйнак кына гәүдәле, пөхтә кеше иде. Әнием дә, ул Рәбига исемле иде, гомере буена татар сәнгатенә хезмәт итте. Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында җырлады. Кыскасы, безнең өйдән артистлар, музыкантлар, язучылар өзелеп тормады. Әдәбият-сәнгать дөньясына тартылуымда болар да эзсез югалмагандыр, мөгаен».
Бүгенге көндә Әхәт Мушинский сәнгатьнең «өч яссылыгында» яши. Беренче чиратта ул, — әйе, язучы. Әйткәнебезчә, гаиләсендә татар тәрбиясе алса да — Әхәт урысча язарга мәҗбүр (ни дисәң дә, шәһәр баласы, татар мәктәпләре ябылып беткән бер чорда, гомуми урыслашу бәласен читләтеп үтеп буламы соң), ул — «Шейх и звездочет», «Треугольники», «Гол в девятку», «Тезка» дигән проза китаплары авторы. Аның «Кайту» һәм «Ак бүре» повестьлары «Казан утлары» журналында басылып чыгып, укучылар тарафыннан җылы кабул ителде. Шулай да әле яңарак кына дөнья күргән «Записки горбатого человека» романы авторның иң уңышлы әсәрләреннән саналырга хаклы. Биредә язучы, яшьлек идеалларына тугрылыклы калган хәлдә, югарырак кимәлдә фикер йөртә, тормыш, яшәү фәлсәфәсе турында тирәнрәк уйлана. «Мәхәббәт һәм нәфрәт, чын һәм ялган шигърият, чын һәм ясалма кешеләр, тормыш мәгънәсе һәм андагы мәгънәсезлекләр» — әсәрнең кредосы менә шуннан гыйбарәт. Миргазиян Юныс, әсәргә бәя биреп, «Лирик геройның башы белән «кызыл стенага» һөҗүм итүен» дә, чор-заман фаҗигасен

дә, шәхес һәм җәмгыять арасында барган көрәшнең аянычлы якларын да дөрес билгеләп үтә. Кыскасы, Әхәт Мушинский бу әсәре белән үзен җитлеккән прозаик, каләм остасы итеп танытты. Әхәт «өч яссылыкта» яши дигән идек бит... Ул — татар ПЕН-үзәгенең башкаручы директоры да бит әле. Мәгълүм булганча, ПЕН-үзәк моннан алты ел элек оешкан иде. Шушы дәвер эчендә ул шактый гына эшләр башкарды. Әйтик, Халыкара ПЕН-клуб ел саен конгресслар үткәрә. Татар ПЕН-үзәге шуларның Мексикада, Шотландиядә һәм Финляндиядә уздырылганнарында катнашырга өлгерде инде. Бу гамәл дә — ник кирәк ул тагын бер эшләмәгән бюрократик оешма, дип әйтүчеләргә җавап булсын! — татар милләтенең гомумкешелек аудиториясенә чыгуына, ә аудиториянең кабул итүенә бер дәлил. Әйтик, Бөтендөнья Язучылар ассоциациясе 140 илнең ПЕН-үзәкләрен берләштерә, Русиядә мондый үзәкләр икәү генә — урысларныкы һәм татарларныкы. Бу безнең абруебыз үсә бару турында сөйли түгелме?
Белмәгәннәр белеп торсыннар дигәндәй, ПЕН-клуб — беренче чиратта хокук саклау оешмасы: ул сүз иреге, иҗат иреге һәм иҗатчыларның иреге һәм хокуклары сагында тора. Әлбәттә, клуб хокук саклау функцияләрен генә башкара дип уйлау дөрес булмас иде, шуңа күрә клуб эшчәнлегенең конкрет юнәлешләрен, кайбер тармакларын гына билгеләп үтү дә кайбер уйлануларга этәрер, мәгаен: «Әдәбиятларның үзара тәэсир итешүе», «Әдәби тәрҗемә һәм лингвистика хокуклары», «Төрле халыкларның телләрен һәм әдәбиятларын саклау». ПЕН-клуб каршында шушы эшчәнлек — әдәбият мәсьәләләренә караган эшчәнлек — хәзерге вакытта иң мөһиме булып тора. Үз чиратында, татар ПЕН-үзәге дә бу юнәлештә хәл кадәри эш башкара. Хельсинкида үткәрелгән конгресска ул инглиз телендә чыккан «Бүгенге татар әдәбияты» дигән китапны әзерләгән булса, Варшавада үтәсе конгресска, шулай ук инглиз телендә, «Татар халык әкиятләре» дигән сюрприз-бүләк алып барды. Татарның танылу юлы, шөкер, менә шулай төрле юнәлешләрдә дәвам итә. Узган ел Мәскәүдә уздырылган конгресста Рус ПЕН-үзәге президенты Андрей Битов сүзләре белән әйтсәк: «Күпмилләтле дөнья әдәбияты — зур болын ул, анда кирәкле яисә кирәксез чәчәкләр юк. Бер төр үсемлекнең юкка чыгуы — бөтен Җир табигате өчен зур югалту ул». Ә татар әдәбияты югалмаска, башка бик күп дөнья әдәбияты белән, аның алдынгы вәкилләре белән аралашып яшәргә тиеш.
«Өченче яссылык» дигәнебез, Әхәт Мушинский «Татарстан» дәүләт телевидениесе аша «Яшел камин янында» дип исемләнгән тапшыруларны алып баручы буларак дан-шөһрәт казанган тележурналист та бит әле. Сәгать буена сузылган, әмма бер дә ялыктырмый торган бу тапшыру, әйтергә кирәк, үзенең интеллектуаль югарылыгы ягыннан, рейтингы ягыннан бер дә мактаулы Мәскәү тапшыруларыннан калышмый; димәк, бу нәүбәттән Әхәт үзе дә Мәскәү йолдызларыннан ким түгел дигән сүз. Әйе, президентыбыз М.Ш.Шәймиев, Дәүләт Югары Советы рәисе Ф.Х.Мөхәммәтшин кебек сәясәтчеләребез, Әмирхан Еники, Миргазиян Юныс, Разил Вәлиев кебек язучыларыбыз, Вил Мирзаянов, бертуган Акчуриннар һәм башка бик күп зыялыларыбыз катнашында алып барылган әңгәмәләр (барысы 70 кә якын) чын мәгънәсендә «хит»ка әйләнде. Монысы да Әхәт Мушинскийның киң эрудицияле, тыйнак, әмма кирәк чакта әйдаман әдип булуы хакында сөйли.
Яз, эшлә, иҗат ит, Әдип!

*«Казан утлары», февраль, 2001*

## КҮҢЕЛ КОШЫНЫҢ БИЕК ОЧЫШЫ

Һәр талантлы шәхескә хас булганча, Марсель Галине «артык тыйнаклыкта» гаепләп булмый, әлбәттә. Чөнки моңа ул үзе гаепле. Гадәтен беләбез...
Моннан берничә еллар элек, көз айлары иде бугай, «дуслар җыелган җирдә» — Язучылар берлегенең ишегалдында (Туфан ага Миңнуллинның шул исемдәге пьесасы буенча куелган спектакль дә искә төшеп ала) — өйләргә таралышыр алдыннан Марсель Гали, улым сиңа әйтәм, киленем син тыңла дигәндәй, сак кына итеп, бер үк сүзне берничә тапкыр авызыннан ычкындырып алды: «Их, егетләр, корыны бушка әйләндереп йөрисез бит сез, ә менә абзагыз гасыр китабы язып ята...» Бу «сценарий» төрле вариацияләрдә берничә тапкыр кабатланды. Ул шулай дип әйтер иде дә, инде борылып китеп барган җиреннән сул кулын җилкә аша гына ташлап саубуллашып, горуранә күздән югалыр иде. Күкләргә очынып, сипләнеп-давылланып канат җәюче, тегеяки бу мәсьәләгә үтергеч бәя биреп уйга калдыручы, йә булмаса мәгънәле бер кызык сүз әйтеп алучы Марсель булмагач, сөйләшеп торуның бөтен тәме-кызыгы бетә, ипле генә барган моназара базары тынып кала. Шунда кемдер ачусыз гына Марсельнең үзе яраткан сүзне әйтеп куя: «Купык!» Мактанчык, янәсе. Икенче берсе болай дип өсти: «Бөек!»
Андый вакытта дөнья борчуын җилкәсенә салып бер читтәрәк тәмәкесен пыскытып торган

Рөстәм Мингалим дә телгә килә:
— Юк, агай-эне, Марсель Галине бик яхшы беләм мин, уйнап сөйләшсә дә, уйлап сөйләшә ул: бу, мөгаен, бер-бер «бомба» әзерләп ята торгандыр әле. Шулай булмый калмас.
Шулай итеп, төркем тарала, һәркем үз уен эченә йотып юлга кузгала. Язучылар берлегенең чуеннан чүкеп ясалган бизәкле капка баганасы моңсу гына озаеп озатып кала.
Әйткәнемчә, бүлмәләргә сыеша алмыйча ишегалдына бүселеп чыккан мондый әдәби «моназара базары» шактый еш кабатлана торган иде. Әлбәттә, анда гел Марсельнең генә «гайбәтен» сатмый торган идек, беткәнмени «кичекмәстән» хәл итәсе мәсьәләләр... Шулай да берсендә Марсельнең булачак китап исеме дә мәгълүм булды: «Догалы еллар» икән. Озакламый китап үзе дә дөнья күрде һәм, укып баккач, әдәби мохит бердәм «ах» итте. «Афәрин!», «Машалла!» дигән сүз иде бу.
Һәм әсәр авторына телдән дә, хатлар аша да котлаулар ява башлады. Укытучыбыз һәм яраткан апабыз, күренекле тел белгече Флера Сафиуллина әсәргә менә нинди бәя бирде: «Догалы еллар»ны ул эссе дип атаган. Йа Хода, ниндәен өслүб! Ул бит әдәби телнең иң бөек мөнбәренә менгән. Бу мөнбәргә аны Чатыр тау, туган ягы мендергән. Сүз белән шулкадәр дә могҗиза ясар икән! Татар теле соңгы елларда прозабызда бу дәрәҗәдә затлы, нәзакәтле, моңлы яңгыраганы юк иде кебек».
Ул да булмый, әдәбият аксакалы Мостай ага Кәримнән хат килеп төшә: «Шаукымлы, женле китап язгансың. Үзең болай шаталак булсаң да, иманлы, әдәпле китап язгансың. Үзеңнән дә шәбрәк, үзеңнән дә акыллырак булырга тырышмагансың... Китабың — күзәтүләрең, фикерләрең мавыктыргыч. Афәрин, Марсель!»
Сүз куешканнар диярсең, икенче бер остаз — Наҗар Нәҗми дә яшь дустына рәхмәтле хисләрен җиткерергә ашыга: «Догалы еллар»ыңны рәхәтләнеп укып чыктым. Күпме күзәтү, күпме осталык — сокландыргыч! Миңа таныш, мин белгән кешеләрне үзенчә ачу бик зур тәэсир калдырды».
Шушы урында хатлардан өземтәләр китерүдән туктап тормакчы идем дә кулыма гаҗәеп бер «документ», үзе дә догага тиң хиссиятле язма кулыма килеп кергәч, булдыра алмадым — дәвам итәм. Аны Марсельнең якташы, нечкә тоемлы шагыйрә Фәйрүзә Исмәгыйлева җибәргән: «Догалы еллар»ның соңгы битләренә җитеп киләм. Күп әсәрләр укыганым бар. Ләкин җанның мондый биеклеген тоеп, йөрәкнең шулкадәр нечкәргәнен күптән тойганым юк иде. Җанымның җиде дулкыны да хәрәкәттә, һәм беренче дулкыны Җирдә булса, җиденчесе — Бөек Күк катында. Миңа бу чаклы ләззәтне татырга ярдәм иткән өчен мең-мең рәхмәт сиңа! Сине Аллаһы Тәгалә милләт өчен генә түгел, Кешелек өчен яраткан икән!
Аһ, безләргә җитми торган хис синдә хәттин ашкан. Ул — Олы Мәхәббәт хисе! Бу дөньяның кыек-мыегын Аңлау һәм Ярату. Ә олы мәхәббәт — ул безнең җаннарыбыз өчен реаль бәхет. Мин — хисләр өермәсендә. Һәм миндә шундый тойгы: синең хисләрең йомшак, гамьле, «ак болытлы» — минем баш очымда. Аларны ниндидер Илаһи җилләр куып китергәндер миңа... Бүтәнгәдер ул: һәрбер җөмләңне йөреп торган хис-биләү сүтелә дә, минем хисләргә кушылып, югары күтәрелә. Синең биеклектә шундый рәхәт! Бу биеклектән дөнья матур күренә. Һәрбер кешенең «фәрештәсен» «Догалы еллар» биеклегенә күтәрәсе иде».
Бу ярату тулы хиссами хаттан өзекләрне озынрак китерүемнең сәбәбе аңлашылса кирәк, гап-гади ләбаса: «Догалы еллар» әсәрен укыганда, күкрәгендә ашкынулы йөрәге булган, зиһенле һәрбер кеше шушыңарак охшаш хисләр кичергәндер дип уйлыйм. Уйлыйм һәм ышанам!
Ә бит югыйсә... Югыйсә Марсель гадәти тормышта башкарак, бик үк ипле-җайлы кеше түгел кебек. Бигрәк тә талантсызлар өчен рәхимсез ул... һәм үзе өчен...
Әйе, ул бик катлаулы шәхес, кешеләрдә нинди сыйфатлар була, Марсельдә барысы да бардыр сыман төсле миңа кайчакта. Ләкин иманым камил: шушындый катлаулы шәхесләр генә катлаулы, күп сыйдырышлы, югары очышлы, киң полотнолы әсәрләр тудыра алалар; моңа инде эрудицияле булу гына җитми: гомуми белем өстенә сине чолгап алган тирәлекне бөтен каршылыгын да һәм матурлыгын да тоя алучы җан, образлы фикерләү куәсе, тарихи аң, хисләрдә алдашмау, Ана теленең табигый агышын сизгер тотып алучы йөрәк һәм кешеләрне ярата белү дә кирәк (санап бетерә алмасам, үзегез өстәгез!). Марсель исә боларның барсына да ия шәхес. Ул тудырган портретлар галереясында кешеләр әйбәт күңелле, миһербанлы, мәгърур; хәтта бөтен кимчелекләре белән димме, үзенчәлекләре белән димме — матурлар! Әйтергә кирәк, Кешене олылый алу ул — ихлас, чын талант ияләренә генә хас сыйфат. Иҗатта үзеңнән дә олырак булып калуның мең төрле сере булса, монысы иң әһәмиятлеседер, мөгаен.
...Марсель Гали белән Рәшит Әхмәтҗан көндәлек тормышта (гадәти аңлаешта!) беркайчан да «дус» яшәмәделәр кебек. Мәрхүм үзе дә төртмә телле, сәеррәк холыклы кеше иде шул. Тыштан караганда. Ә менә Марсель, Рәшит абыйның дуслары көнләшерлек итеп — көнләштерерлек

итеп! — аның җанлы сурәтен тасвирлап бирде, Олуг әдипнең Олуг җанын ачты («поэзиянең көче гомерне ярата алуда»), җан ачысы белән аның хозурына реквием укыды: «Казанның Татар зиратында, гасырның мәртәбәле затлары куелган урында, бөек Тукай янында күмелү бәхете... очраклымы? Ике шагыйрьнең янәшә килүе алдан билгеләнгән тәкъдирме?»
«Минем гасыр башындагы шигъриятемне гасыр азагына менә кем ялгар!» — дип, Тукай рухы дәшеп китергәндер, бәлки...
Җавап эзләп мин аның китабына иеләм. Тормыш агачына сәҗдә кылган шагыйрьнең юату сүзе шәмаилгә күчә:

Мин җылытыйм әле, дөнья, сине,
Җаным суынганчы җылытам.

Әдип һәр новелла-нәсерендә әнә шундый күзгә яшьләр китерерлек сурәт-образлар аша Үткәннәр белән Киләчәкне тоташтыра. Фанилыкның Бакыйлык серләрен ача.
Без Марсель белән шәрикләр, хәтта бер бүлмәдә яшәп тә алдык. Хәтерлим: башлангыч чор иҗатында, озын юлга чыккан мосафирның алда агымсу миражы күреп кабалана-кабалана йөгергәне кебек, максималистларча кайнарлык белән урыс, чит ил әдәбияты классикасын, философиясен «эчәргә» тотынды; теленә тәм, уена гамь биргән туган кизләве генә аның сусынын басалмас шикелле тоелды. Әмма ташкыннар барыбер бер ярларына кайтып сыеналар — Гарсиа Лорка, Евтушенко, Хемингуэй, Шопенгауэрлар белән җенләнеп йөргән гыйсъян-сәясәтче (җилкуар түгел!), үз туган стихиясенә әйләнеп кайткач, тирәлегендә матурлыклар күреп шаккатып, читтәге Олуглар янына куярлык Олуглар барлыгын тоеп сөенде.
Хәсән ага Туфанны ул шулай ачты. Тагын парадокс: «Туфанчылар» фәһемле сүз әйтергә өлгерә алмый калды, Марсель өлгерде. «Туфанлы хәтер»ен гасабиле уйлар эчендә актарып утырганда, шагыйрьнең «йөрәк биеклегендәге» шигъриятенә — сүз-хис канатларында хозуранә дөньяга күтәрелде:
«Хәтерең түрендә, йомшак мендәр куелган урында, Хәсән Туфан утыра.
Туфан — бөек Тукайның имгәтелгән дәвамы иде.
Туфан — канаты киселгән җәяүле кош иде.
Туфан — эчке әрнүен җиңгән, ак буйлы, үтәли күренгән өрфия җылы шәхес иде».
Йә, шулай түгел идемени, исән кардәшләрем!
Марсель Галинең иҗади фантазиясе Вакыт һәм Пространство чикләрен белми, кайчак анда дөнья белән реаль чынбарлык бергә үрелеп китә, ул чорлардан чорларга иркен күчә; шул рәвешле хис-кичерешләр калейдоскобындагы төсләр, бер-берсен баетып, тулыландырып, Кеше сурәтенә керә.
Язучылар берлегенең пропаганда бюросында эшләгәндә, Марсель язучылар белән Татарстанны иңләп-буйлап йөреп чыкты. Күп чагында ул үзе командир булса, комиссары Хәсән ага Сарьян була торган иде. Хәсән ага «чын төрекче», әдәби тел остасы, әмма бераз йомыкыйрак кеше булып хәтердә калган. Картина-сурәтләр тудыру остасы буларак, Марсель аның образын менә болайрак тасвирлый: «Төнге дала... Караңгы күренгән балбалның мең еллар буена җил-су-кояш ашаган таш чыраен учак шәүләсе ялмап-ялмап ала.
Сарыҗан... Сарьян... Борынгыдан килгән әнә нинди мәгънәле исем кушканнар икән аңа. Сәер дә, серле дә... Мин аны беренче күрүдә ошатып бетермәдем шикелле. Кырыс күренә. Төмсәрәк чырай. Аз сүзле. Кара кысалы калын күзлек, кара чәч, үҗәт кысылган иреннәр, арасыннан маңгайга үрләгән таләпчән ике җыерчыкны да өстәсәк, тиз генә якын мөгамәләгә кереп китәрдәй, күңел капкаларын шар ачып ташлаган беркатлы шәхес дип уйламыйсың син аны. Нәзберек гөл шытымын иң нечкә тамырларына кадәр имгәтмичә казып алган кебек, һәр сүзне кадерләп, күкрәк эченнән ала, җеген-җепкә китереп, ашыкмыйча әйтә, нәкъ язуындагыча тулы җөмлә белән сөйли. Тавышыннан талгын җил канатыннан саркып киткән әрем исе килә төсле.
— Төркияне барып бер күргән кеше икенче тапкыр бармыйча түзә алмый. Дөресен сөйләсәм, юлымны ябам бит, — диде. — Төрки халыклар арасында бердәнбер бәйсез ил бит ул, — дип, әллә ниләр сөйләргә җыенган сыман булды да кәефсезләнеп туктап калды. Күңелендәген ачып салмыйча вакытында тыела белү утызынчы елларда туып үскәннәргә гомумән хас сыйфат шикелле тоела миңа.
Төркиянең Измир, Конья, Анкара, Истанбул кебек калаларын тамаша кылып йөрербез дә, Рәдиф Гаташ белән шунда Хәсән Сарьянны еш кына искә алырбыз дип кем уйлаган...»
Борынгы дала. Балбал сурәте. Әрем исе. Бердәнбер ирекле төрки ил... Һәм татар әдибе язмышы! Кичәләр үткәреп Мари ягында, Бәрәңге районында йөргәндә күңеленә килгән уйлары бу Марсельнең. Никадәр төгәл тарихи экскурсия, никадәрле экспрессия... Бер кечкенә өзеккә кеше даны да, аның характер төсмерләре дә, чорлар фаҗигасе дә, Сибгат ага шигырендәгечә, «кергән

дә утырган». Сурәтләү осталыгы шуннан гыйбарәт ләбаса.
...«Ак кәгазь каршында сәҗдә кылып кына күк капусыдай ачылмый хәтер, аның өчен елларга һәм юлларга чәчелгән вакыт белән кабаттан яшәп алырга кирәк» һәм Марсель Гали нәкъ шундый тынгысыз, гамьле вакытында, «әдәби олимплар» тарафыннан бердә читкәрәк этәрелгән, тыштан мондый мөнәсәбәтне затлы сигарет төтене кебек кенә өреп җибәргән, ни газаплар күреп тә сынмаган вә сыгылмаган Нәби ага Дәүлигә, һичнигә карамыйча, мәдхия укыды. Әдәби әсәрләреннән битәр сынмас рухына. Сынмас, матур шәхесенә. «Аяклы чор энциклопедиясе», туксан яшәр карт Фәйзи ага Йосыпов аның белән: «Исәнме, яшьти», — дип кенә исәнләшә иде (әйе, Марсель сүз һәм үз-үзен тотышы, шәхси сөйкемлелеге белән кешеләрне гипнозлый белә. Әдәби кичәләрдә, мәҗлесләрдә тәгәрәп үсү галәмәте дә юк түгелдер, бер уйласаң). Яшьтәше Разил Вәлиевнең шатлык-бәхетләрен, кайгы-хәсрәтләрен ул уртаклашты. Саный китсәң... Урмандагы агачларны, болындагы чәчәкләрне кем санап бетерә алган.
Кешеләр язмышы гына түгел, илләр язмышы да сыйган бу китапта. Хәтта хыялдагы илләр язмышы да.
«Бисмиллалы табын күрке»ндә мин, мәҗүси чагыма кайтып төшеп, учакка асылган Казан каршында басып тордым, дәстәрхан түрендә утырдым, олпат затлар янында ризык җыйдым... Бүтән уйларга бирелеп онытылуны ризык өнәми, үчләшеп, ташый яисә тәмен яшерә... «Аллалар ризыгы»нда пешеп җитә дигәндә, син үзеңне кая куярга белми башлыйсың. Тәрәзәдән татлы куәт, бәрәкәтле дулкын булып, урамга ыргыла. Бу полосаны үткәндә этләр абынып егыла, песиләр саташып койрагын болгый, таныш түгел кешеләр бер-берсе белән ялгыш исәнләшеп үтә».
Бәлки, бик үк уңышлы, бу очракта иң әйбәт өзекне дә сайламаганмындыр, әмма дөрес сөйлисең, иҗатташ дустым, ризык әзерләү «ризык җыю, мәҗлес, табын культурасы бу тормышның кадере хакында уйламаганнар өчен зур фал» — бу фани дөньяда бергә җыясы, уртак ризыкларыбыз шул булсын иде әле...
Марсель хәтле «хәйләкәр» язучы булыр микән. Ул гасырлар җырчысы — татар җырына тиң татар җырчысы Илһам Шакиров турында иңрәүгә тиң аваз сала да («җырла Син, сулкылдасын бәгырь, тетрәсен рух, җылытып юат мәртәбәле татар дөньясын!»), татар җырының тарихи ретроспективасын җаннан кәгазьгә күчерә:
— «Татар җырында — Бөек Кытай дивары артындагы борынгы чин халыкларыннан күчкән ефәктәй нәфис көй борылмалары бар;
— Татар җырында — Алтай-Саян төбәгеннән кайнап чыгып, гасырлар аша килә-килә, Цезарьлар шәһәре — Римга кадәрле ераклыкларны тояк тетрәүләре белән уяткан Атилланың тантанасы бар;
— Татар җырында — Хазар каганлыгы биләгән ярларны тетрәткән диңгез дулкыннарының кылыч кыяларга бәрелеп кире чигенгәндәге яралы сызлануы бар;
— Татар җырында — Идел карамаларыннан алып малахит Урал сыртлары аша Себер карагайларына кадәрге киңлектә дәрья булып шаулаган кара урманнарның гөнаһсыз-шомлы тирәнлеге бар!
Татар җырындагы кодрәтле тылсымны, күк катламнарыннан иелеп, Тәңре үзе тыңларлык...» Әйе, кодрәтемнән килсә, нибары унбер абзац-җөмләдән торган шушы мең тавышлы коралны мин, аерым китап итеп чыгарып, һәр татар баласының күкрәк кесәсенә — йөрәгенә! — салып куяр идем.
Белүемчә, Марсель Гали берничә генә чит илдә булды кебек. Ә язмаларында уннарча, йөзләрчә илләрдә, меңнәрчә шәһәрләрдә булган кебек «кылана». Белә чөнки. Китаптан укып булса да. Марсель ул тыштан гына батыраеп, кукыраеп йөри, ә эчтән... Эчтән моңсар күңелле, ярларына сыеша алмыйча тулышып түгелергә дә күп сорап тормый. Була аның шундый вакытлары: кинаяле, чәнечкеле, җор телле Марсель күңел капкаларын ябып куя да тынып-боегып кала, хәле бетеп үлән арасына карап поскан давыл шәүләсе кебек.
Бу — аның хисләрдән бушанып алган көннәре була торгандыр, мөгаен; тулышу алдыннан була торган газаплы да, ләззәтле дә күңел мизгелләредер. Мондый чакларда ул, исәнләшкәндә дә, хәлсезлектән бармак очларын гына суза. Күрешергә сузылган куллар арасында Гибралтар чаклы гына ераклык асылып кала. Мондый чакларда ул бик тә, бик тә бәхетсез бер мәэюс бала кебек тоела.
Йә, шушылардан соң Марсель Галине ничек тыйнаксызлыкта гаепләргә мөмкин булсын ди! Тел бармый. Кешене аңлап бетерүе кыен, бик кыен шул. Бигрәк тә язучы халкын.
Ә шулай да утыз елдан артык аралашып йөреп тә аңлап бетерә алмаган әдипне Марсельне «Догалы еллар»ындагы догалары аша, кеше буларак, күбрәк аңладым шикелле. Башкалар да аңладылар микән?

Аңлау-аңламау хакындагы шик-шөбһәләремне уртаклашкач, бер яшь шагыйрь дустым болай дип тынычландырган иде:
— Борчылма, абый кеше, быел әдәбиятка амнистия елы. Күпләп «азат» итәчәкләр!
...Күп кенә татар хикәяләренең башламынча, ә тышта кояш көлә иде...
*«Мәдәни Җомга», 13 апрель, 2001*

**ТАМЧЫ КҮЗЕНДӘГЕ СУРӘТЛӘР**

Бар идедер Әмәт бистәсенә күтәрелгән юл өстендә алмагач бакчасына күмелеп утырган җыйнак кына бер йорт; бу йортта яшәрләр иде аш-сулы Фәйзуллиннар гаиләсе. Йорт хуҗалары — киң күңелле, ачык чырайлы Әминә апай белән ирләрчә бераз кыркурак холыклы, зирәк акыллы Габдрахман агай безнең нише студент халкын, уллары Рөстәмнең студент дусларын үз балаларыдай якын күреп каршы алырлар иде. Һәм бу йортта бар иде бер «хөҗрә»: Равил Фәйзуллин тормышның вә әдәбиятның чиксез киңлекләрендә аерым дәүләт булып яши башлагач, анда энесе Рөстәм — әле ул вакытта шагыйрь Акъегет тә түгел, Казан дәүләт университетының гади бер студенты гына — варис вә хаким булып урнашып калган иде. Хөҗрә дигәнебез гади генә бер бүлмә иде (ялгызак студентка ни кирәк тагын): урамга караган тәрәзә каршында язу-эш өстәле, ике-өч урындык, түрдә агач карават, идәннән түшәмгә хәтле китап-журналлар белән шыгрым тулы шүрлекләр сузылган — бар булган байлык шушылар иде булса кирәк. Аның каравы бирелә рухи байлык хөкем сөрә иде.
Әйе, менә шушы хөҗрәдә без — «яшь әтәчләр» — киләчәккә матур-матур планнар корып (ул планнарның зурлыгыннан куркып вә өркеп), яңа укылган китаплар, гомумән, әдәбият-сәнгать турында моназара кылып утырырга ярата идек. Әмма баштагы мәлдә, әле әдәби карашлар берлеге пәйда булганчы, Рөстәм белән мине, икебез ике бүлектә укуга карамастан, француз теле дәресләре якынайтып җибәрде. Бу хакта аерым сөйләмичә булмас, ахры.
Гөнаһ шомлыгына күрә димме, без үзебез теләгән гарәп телен түгел, бөтенләй чит-ят француз телен өйрәнергә тиеш булып чыктык; билгеле, киләчәктә кирәк булмаячагын чамалаганга күрәдер, без моңа күңелебез белән чата-кармак каршы идек. Өйрәтергә теләүчеләрнең теләкләре белән өйрәнергә теләмәүчеләрнең теләкләре уртак булгангадыр инде, без дүрт ел дәвамында «Parle vu france?», ягъни «Син французча сөйләшә беләсеңме?» дигән гыйбарәдән ары китә алмадык. Шулай беркөнне, семестр башындарак бугай, француз теле укытучыбыз, Амур исемле яһүдә кызы, Рөстәмнән шушы гыйбарәне укып күрсәтергә кушты. Әллә укытучыбызның бигрәк яшь булуыннан кыенсыныпмы, әллә башка бер-бер сәбәп бар идеме, бурлаттай кызарып чыккан Рөстәм, миңа чират җитмәсә ярар иде дип арткы рәтләрдә посып утырган җиреннән (димәк ки, минем яннан) торып басты да Тукайның Сабиты кебек «шартлатып» җавап та бирде:
— Parle vu france?
Укытучыбызның исеме җисеменә туры килә иде шул, чибәр иде, чукынчык, болай да нур чәчеп торган йөзе тагын да яктырып китте, урыслар әйтә алмый интеккән французча «к» катыш каты «гъ» авазының Рөстәм башкаруында бигрәк «французча», бигрәк ятышлы яңгыравына сөенеп булса кирәк (һәрхәлдә, без шулай юрадык), көлемсери төшеп:
— Странно, у вас истенно парижский акцент, — дип куйды.
Чират миңа җитте. Сабый чактан ук «тел көреше» белән интеккәнлектән, минем акцент бөтенләй «татарчалаштырылган французча» килеп чыкты... Шушы көннән башлап без француз теле дәресләрендә бик сирәк кунак була башладык, озакламый Амур җиңгиебез дә бер капитанга кияүгә чыгып китеп барды, кыскасы, без үз иркебездә калдык. Ә уртак бәла-каза кешеләрне якынайта бит ул: дәресләрдән буш арада Казан урамнары буйлап, Казансу тирәсен иңләп, «милләт язмышын хәл итеп» йөргән көннәр, хөҗрәдә — «конспиратив фатир»да — Марсель Галиев, Азат Ганиев кебек шәрикләр белән үткәргән яшерен әдәби кичәләр бу якынлыкны дуслыкка әверелдерде. Шөкер, еллар кайбер төзәтмәләр кертсәләр дә, бу дуслык бүгенге көнгә кадәр дәвам итә.
Университетны тәмамлауга исә, без икебез дә әйбәт кулларга эләктек: мин Татарстан китап нәшриятында «халык академигы» Рәис абый Даутов канаты астында эшли башладым, ә Татарстан радиосында Рөстәмнең остазы итагатьле, кешелекле кеше, үз эшенең остасы Рим абый Кәримов булды.
Менә 27 ел инде Рөстәм радиода эшли. Шушы дәвер эчендә ул әдәбият-сәнгатькә багышланган, мөгаен, меңнәрчә булмаса да, йөзләрчә тапшыруны эфирга әзерләгәндер. Әмма татар теле базар теленә әйләндерелгән бер мәлдә (мәктәпләр ябыла, рәсми даирәдә татар теле бөтенләй

кулланылмый диярлек) Татарстан радиосында «Тел күрке — сүз» тапшыруының башланып китүе үзенә күрә бер революцион күренеш булды һәм бу тапшыру татар җанлы һәрбер кеше тарафыннан тел ачкычы, рухи терәк, аны әзерләүчеләрнең шәхси егетлеге буларак кабул ителде. Мәгълүматлы, тирән эчтәлекле булганга да, туган телебезнең чиксез матурлыгын вә байлыгын күрсәтә алганга да, тел каршында торган хәвефле проблемаларны ачып бирүдән курыкмаганга да бу радио-дәресләр дистә еллар инде үзенең рейтингын югары кимәлдә саклап килә. Һәрхәлдә, татар теле яшәгәндә, радио аша мондый аралашуның зарурилыгы бәхәссез.
Мәгълүм ки, радиожурналистика Рөстәм иҗатында бер сәхифә генә. Ул бит әле шигъриятнең мең тавышлы симфониясендә үз көен тапкан (үз исемен тапкан — Акъегет) шагыйрь дә. Дөрес, аның шигъри байлыгы күләм ягыннан, бәлкем, артык зур да түгелдер, гомер уртасына җиткәндә ул нибары ике җыентык чыгарырга өлгерде («Ак болыт шәүләсе», 1987; «Төнге сулар», 1990). Болай дигәч, шагыйрьнең кыска, тыгыз формалы яшәеш турындагы, табигатькә бәйле күзәтүләргә нигезләнгән шигырьләре хакында Сибгат ага Хәким әйткән сүзләрне кабатлап үтү урынлы булыр кебек: «Бик күп язып та, үз урынын таба алмыйча буталып йөрүчеләр аз түгел поэзиядә. Акъегет шигырь үзен мең еллар буена сынаган юлны сайлаган».
Әйтергә кирәк, авыр юлны. Чөнки, фәлсәфи күзәтүләргә корылган кыска формадагы шигырьләр алар, гадәттә, күп язылмыйлар. Моның үзенә күрә табигый сәбәпләре дә бар, әлбәттә.
Соңгы дәвердә, бигрәк тә 60–70 нче еллар тирәсендә, күпсүзлелеккә, төссез-образсызлыкка протест йөзеннән булса кирәк, кыска-җыйнак шигырьләргә, ассоциатив сөйләмгә игътибар-хаҗәт арта төште, яңа формалар, яңа алымнар табу юлында эзләнүләр башланды. Ә ул эзләнүләр, нигездә, ике юнәлештә — Көнбатыш һәм Көнчыгыш (Шәрык белән бутамыйк) шигърияте мирасын үзләштерү юнәлешендә барды. Бу җәһәттән Кытай һәм Япон поэзиясе үрнәкләре («танка» һәм «хокку» гыйбарәләре нәкъ менә шушы чорда колакка килеп иреште) татар шигъриятенә бәрәкәтле тәэсир ясады: күрәсең, биредә халыкларның чынбарлыкны кабул итүдә борынгыдан ук килгән кайбер уртаклыкларның булуы да билгеле бер роль уйнамый калмагандыр («Көнчыгышта художник табигатьтә сибелгән гармониянең асылын аңларга омтылып яши һәм ул шушы гармониянең алыштыргысыз бер өлеше булып тора». — *А.Генис*).
Мондый яңа аһәңне беренчеләрдән булып (эчке тибрәнешләр туры килгәнгәдер, бәлкем) татар шигъриятенең яңа дулкын вәкиле Равил Фәйзуллин тоеп алды һәм ачышларга ирешә. «Бары бер яфрак коелды — көз җитүен бөтен дөнья белде» кебек тулы бер халыкның ничәмә-ничә гасырлар буена тупланган зирәклеген вә тәҗрибәсен чагылдырган борынгы Кытай мәкаленә аһәңдәш күзәтүләр ясады:

Торналар китеп бара.
Кош канатлары орынгач,
болытларның күңеле тулды.

Мондый кечкенә формага тулы дөнья кереп утырган Табигать вә Күңел сурәтләрен тиктомалдан гына уйлап чыгарып, ясап булмый; болар — чынбарлыкны танып-белүнең, дөньялыкны кабул итүнең үзенчәлекле бер формасы, күңел-хис хәрәкәтенең табигый дәвамы, үзеңне табигать — дөнья уртасында итеп тоюның чагылышы.
Геннарның уйнавы нәтиҗәседер, күрәсең (туган туганга охшамаска да мөмкин бит югыйсә), Акъегет үз иҗатында шигъриятнең шушыңарак охшаш өслүбен сайлады. (Хәер, «сайлады» дип әйтү бу очракта бик үк дөрес тә булмастыр әле ул, чын иҗатчы, бигрәк тә шагыйрь кеше, мин тегеләй, мин болай языйм әле дип, иҗат алымын сайлап утырмый лабаса; дөресрәге, иҗат алымы аны үзе бер билгеле юнәлешкә этәреп кертеп җибәрә. Чөнки шигърият — фикер һәм хис уртаклыгыннан туган көтелмәгән ассоциацияләр гамәле ич.)
Шигърияте турында сүз чыккач, дөресрәге, шушы мәкаләне язарга алынуымны белгәч, Акъегет миңа кат-кат: «Игътибар ит әле... Чык бөртекләре. Яңгыр тамчылары. Һәм... Күз яшьләре, — дигән иде нәзер-васыять әйткән кебек эчке бер дулкынлану белән. — Күз яшьләре... Яңгыр тамчылары. Чык бөртекләре».
Нәрсә бу? Бер тамчы күзендә! — бөтен бер дөньяны күрергә омтылумы? Шулай булса кирәк...

Печән чаптым,
яттым пакусларга...
Җир — бер бишек,
ә мин — бер бәби.
Күктә — кошлар.
Оялары — Кояш —
әйләнәләр оя тирәли!..

Мәгълүм булганча, японча танкага тартым мондый шигырьләр, татарчалаштырып без аны әйбер-предметлар арасындагы беренче карашка эфемер тоелган бәйләнешләргә, шул

бәйләнешләрнең тәэссоратына, метонимик стратегиягә корылган кыска шигырьләр дип алыйк, шагыйрьләрдән дөньяга, аны әйләндереп алган мохиткә үтәли күз белән карауны, кирәк икән, яшәеш-табигать дигән «электр челтәрендә» кыска тоташтырулар аша экспериментлар ясап алуны таләп итә. «Язмыш» шигырендәге кебегрәк:

Мәһабәт тупыл үсә чокырлыкта,
манарадан биек диярсең...
Берәү, әнә,
иелеп печән чаба,
чалгы очы
агач башына
менә-менә тияр күк...

Үз чиратында, мондый шигырьләрне укыганда, автор артыннан ияреп барып, укучы эзтабарга әверелә. Чөнки эзләр рәсемен — шигырь сюжетын — шагыйрь биредә сөйләп бирми, ә бәлки аңа илтүче сурәт-маякларны гына билгели. Шагыйрьнең кая таба алып барганын аңлау өчен, укучы шагыйрь артыннан ияреп барырга, ул туктаган урында туктап фикер туплап торырга мәҗбүр. Аннары, укучы да җансыз бүкән түгел: шагыйрьнең әйбер-предметлар сөйли алган информация-тавышының бер өлешен генә ишетә алганын ул да сизә-тоемлый... Шагыйрьнең осталыгы да шунда ки, бер-берсен каплап китмәсен өчен отышлы тасвирый объектны сайлап ала белүдә, артык детальләрне төшереп калдырып, көтелмәгән чишелеш тәкъдим итүдә. Акъегетнең бик күп шигырьләрендә гадәттән тыш кыскалык, текстның сутын соңгы чиккәчә сыгу стилистик алым булу белән бергә конструктив стратегия хезмәтен дә үти.

И ашкына бу күңел!
Беренче вагонга утырдым,
тизрәк кайтырмын кебек...

Күренә ки, шифрга ачкыч авторның үзендә түгел, шигырь өчен алынган материалда, безне һәм аны чолгап алган тирәлектә. Шигырь, поэтик уйлануларның нәтиҗәсен саклаган хәлдә, беренчел импульслардан да еракка китми, шуның белән укучыларын да билгеле бер киеренкелектә тота. Биредә иң мөһим нәрсә шул: бер мизгелдәге җан тирбәлешләрен бөтен тулылыгында чагылдырып калу. Миңа калса, Акъегет андый мизгелләрне гомере буена эзли кебек, ялгызы гына эзли, дөнья белән күзгә-күз калып. Дөнья уртасында яшәгән хәлдә, үз эченә бикләнгән андый шагыйрьләр, әлбәттә, уйсыз, борчусыз була алмыйлар.

Гөрләгән сулар туктаган,
җаным аша
ага тоташ,
Ага Киек Каз Юлы;
Күп йөгәнләдем йөрәкне,
чыдап булмас бу юлы...

«Минем хәлне аңлап кына була, минем хәлне булмый аңлатып» дисәң дә, Шагыйрь, «аркылы гына үтәсе дөньяны буйлап йөрисе» бар әле. Чөнки бу Олы Дөньядагы тамчылар күзендә шигъри сурәтләрнең бетәсе юк. Күз яше генә кипмәсен...

*«Казан утлары», март, 2001*

## ВАКЫТЫМ ТАР, ШУҢА КҮП ЭШЛИМ...

40 еллык иҗат... Азмы бу, күпме бу? Ниләр эшләнгән дә, ниләр кылынган? Яисә ниләр кылынмаган? Күренекле әдибебез Рабит Батулла белән каләмдәше Наис Гамбәрнең әлеге әңгәмәсендә сүз, әлбәттә, әнә шул хакта да бара.

— Рабит агай, синең үз иҗатыңа, башкарган эшләреңә ниндидер бер мирас буларак бәя биргәнең бармы?

— Дөнья хәлен белеп булмый, дип, хастаханәдә, пычак астына ятар алдыннан, мин бөтен кылганнарыма исәп-хисап тоттым. Хисабым төгәлләнгәч, шул ачыкланды: язучы буларак, мин һәрберсе 30ар табактан торган 15 том күләмендәге, күптөрле жанрларга караган әсәрләр язган кеше булып чыктым — әкиятләр, хикәяләр, пьесалар, миниатюралар, мәкаләләр, романнар, мәзәкләр, тарихи шәхесләребез турында документаль язмалар, төрекчәдән тәрҗемәләр, сценарийлар... Кулга тотып карарлык 27 китап чыгарганмын, 19 пьеса язып, аларның 18ен Татарстанның, Русиянең, Финляндиянең, Американың төрле театрларында куйдырганмын. Һәм, әлбәттә, Коръән-и Кәримнең аятьләрен татарчага тәрҗемә итеп, голәма кулына тапшыра алуымны да үземнең җитди хезмәтем дип саныйм.

— Тукай әйтмешли, син бит әле коеп куйган әдип кенә түгел, режиссер педагог та, актер да...

— Чыннан да, мин өч театрның баш режиссеры булып икешәр ел эшләдем, 25 спектакль куйдым, артистлыкка укуым юкка чыкмады: беркайчан да мин сәхнәдән, телевизор экраныннан, радио эфирыннан «төшмәдем», 1100ләп радио-телевизион тапшыру, дистәләгән шәхеснең иҗат кичәләрен әзерләдем, институтта, театр училищесында җәмгысе 6 курс укытып чыгардым. Шәкертләрем әдәбият-сәнгать өлкәсендә җигелеп эшли, иҗат итә, шөкер.
— Сер булмаса, кемнәр инде алар, сине остаз дип хисаплаучылар?
— Алар күп инде, күп, әмма арада Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе режиссер Фаил Ибраһимов, Татарстанның халык артисты Хәния Фәрхи, атаклы «Мунча»чы Шәмси Закиров, фәннәр докторы Гали Арсланов, шагыйрь Мөхәммәт Мирза һ.б. кебек халкыбызга билгеле шәхесләр дә бар.
— Шулкадәр гайрәт һәм вакыт сарыф ителгән. Шуның әҗере нәрсә булды: данмы, рәхмәтме? Әллә...
— Рәхмәт көтмим. Сүккәннәренә дә исем китми. Мактасалар да очынмыйм — Айга сикермим. Вакыт тар, эшләп калырга кирәк. Әдәбияттагы, сәнгатьтәге үз урынымны мин бик яхшы беләм. Ул урыннан мине беркем дә, беркайчан да бер генә карышка да аска төшерә алмый. Бар шундый бәндәләр, андыйлар кешегә аяк чалудан тәм таба. Бер журналда озак еллар мөхәррир булып утырган берәү үзенең пенсиягә китүенә багышланган мәҗлестә әйткән, имеш: «Мин бәхетле кеше, чөнки мин олы кешеләргә каршы көрәштем, Аяз Гыйләҗев белән Нурихан Фәттахның бер җөмләсен дә журналда бастыртмадым», — дигән. Абруй казанган бу язучыларның әсәрләреннән укучыларны мәхрүм итүне ул бәхеткә саный икән, минем аларга ярдәм итүем бәхетсезлек була алмый. Кешеләргә зыян-зәхмәт кылудан тәм табу — ул авыру дәрәҗәсендәге көнчелектән килә, андый көнчелек садизм белән янәшә яши. Бигрәк тә гаепсез һәм талантлы кешеләргә зыян салу — җинаять.
— Ага кеше, әңгәмәбез бу юлдан кереп киткәч, әйтим инде: ни өчен соң кайбер бәндәләр гөнаһсыз һәм гаепсез кешеләргә зыян салырга омтыла? Әллә соң риясыз кешеләрнең, вакланып тормыйча, бокстагыча әйтсәк, «ответный удар» биреп тормаганын алдан ук белгәнгә күрәме?
— Бу гамәл ике генә очракта була. Моны рухи хасталыгы булган кеше эшли яки көнчел кеше. Гаепсезләрне батырган бәндәләр арасында иң күбесе көнчелләр. Ленин да бөтен сәләтен, акылын патшаны бәреп төшереп, үзе патша булыр өчен генә революция ясарга кулланган! Ягъни, аның гамәлләренең асылында көнчелек яткан. Сталинның гарип һәм кимчелекле булуы мескенлек чиренә, аннан соң бөеклек хасталыгына әверелгән һәм ул үзеннән өстен шәхесләрне һәлак итә барган. Халык параноикларны үстерә тора һәм үзе шул параноиклардан куркып яши тора.
— Каян килә соң бу актив хасталык, әйтергә кирәк, хәрам юллар белән хакимлеккә омтылу хасталыгы?
— Империячеллек варисларыннан һәм татар маңкортларыннан. Як-ягыгызга карагыз, күзәтегез: караклар, шизофрениклар хакимияткә үрмәләргә маташа. Кайсысы, Азияне аркылы таптап узып, Һинд океанында пычрак итеген юарга хыяллана, кайсысы татарларны Монголиягә сөрергә котырта, кайсысы Гитлер, Сталин тәртипләре, ягъни суеш-асыш, изеш урнаштырырга план кора.
— Шулай да, каян килә ул чын талантны изү теләге?
— Горурлыктан!..
— ?
— Әйткәнемчә, сүз күпчелегебез аңлый торган горурлык турында бармый. Балаң өчен горурлану, халкың өчен горурлану — башка. Бар — зыялы горурлык, бар — зыянлы горурлык. Синең горурлыгың башканың гадел горурлыгын сыта икән, бу горурлык — зыянлы горурлык, ул шовинизмга, бөеклек чиренә, садизмга, гаделсез гыйсъянга, хаксыз кан коюга китереп чыгара. Андый зыянлы горурлыкның нигезендә тәкәбберлек, башкаларга кимсетүле караш, көнләшү ята.
— Анысы син дә фәрештә түгелсеңдер, көнләшү, көнчелек хисе синдә дә бардыр?
— Көнләшү, көнчелек хисе булмаган адәм юк. Башка кешенең хәләл байлыгына, чибәрлегенә, сәләтенә, уңышына, дәрәҗәсенә кызыгу һәр бәндәгә хастыр. Илһам Шакировның данына мин дә кызыгам, әмма аны хөрмәт итәм. Рудольф Нуриевнең куәсенә мин дә кызыга, соклана идем. Ләкин аларны хурлау вәсвәсәсе миндә булмады. Кызыгу хисе көнчелек хисен уятса, эш харап. Сәләте булмаган кешенең сәләтле кешедән көнләшүе — олы җинаятьләр чыганагы. Уртакул һәрвакыт көнчел була. Әдәбиятны уртакуллар басып алды түгелме? Кеше яза дип кенә кайбер бәндәләр әдәби әсәрләр язарга алынды: гадәттә, андыйлар, калын-калын китаплар бастырса да, олы язучы булып китә алмый. Шулай ук урысча уйлап, татарча язарга тырышып кына да әдәбият ясап булмый. Гомеркәйләрең буена номенклатур система табагыннан ашап ятканнан

соң, халык күңелен кузгатырлык әсәрләр язып булмый. Көнчелектән кузгалган бу агым әдәбиятта зыянлы гамәл булып кала бирә.
— Рабит агай, син ярсу тәнкыйтьлисең кебек. Әллә алардан син дә көнләшәсеңме?
— Рәхмәтле Фәрваз Миңнуллин булыр-булмас ун галимгә тора иде, авыр туфрагы җиңел булсын. Мәрхүм Илдус Ахунҗановның мәкаләләре диссертациягә торырлык әсәрләр иде. Равил Рахманиның җан җылысы белән язылган тәнкыйть мәкаләләрен бик хөрмәт итеп, кызыксынып укыйм. Синең мәкаләләрне дә...
— «Кыңгыраулы» шәхес буларак, синең үзеңә дә тәнкыйть шактый эләгеп тора.
— Әле генә исемнәрен атаган шәхесләр мине тәнкыйтьләсә, мин аларга гомерем буе рәхмәт укыр идем. Гадел булса, тәнкыйте өчен мин дошманыма да рәхмәт әйтергә әзер. Иҗатымны матбугатта нигезле, дәлилле һәм системалы рәвештә тәнкыйтьләгән кеше юк. Мактаган кешеләр дә әллә ни күп булмады. Шулай да «Сөембикә» кыйссасын — Аяз Гыйләҗев, Лена Шагыйрьҗан, Мөхәммәт Мирза, Рөстәм Мингалим, Фатих Урманчиевлар, «Юл буенда зәңгәр чәчәк» белән «Алып батыр маҗаралары»н Миргазиян Юныс, Рәниф Шәриповлар хуплап, иң яхшы әсәрләр рәтенә куеп яздылар, рәхмәт.
— Боларның барысы да үзләре — язучы, ә рәсми тәнкыйть ни өчен сине күрми?
— Бүгенге рәсми тәнкыйтьнең күрүеннән Аллам сакласын. Алар минем иҗат принципларымны аңлар дәрәҗәдә объектив түгел дип уйлыйм.
— Тәнкыйтьчеләргә артык усал караш түгелме бу?
— Тәнкыйть моңа кадәр яшәп килгән фикри агышны үзгәртердәй куәтле, дәлилле булырга яки моңа кадәр мәгълүм булмаган нәрсәләрне ачып салырга тиеш. Безнең тәнкыйть ачмый да, япмый да. Рәшит Әхмәтҗанов, Зиннур Насыйбуллин, Булат Сөләйман, Эдуард Мостафин, Кадыйр Сибгатуллин кебек гаҗәеп моңлы шагыйрьләр иҗатларына тиешле бәясен алмыйча дөнья куйдылар. Алар үзләренең яхшы шагыйрь икәнлекләрен яхшы белә иде, яхшы булып та күрмәгәннәренә үпкәләгәндәй, иртә киттеләр кебек. Олы тәнкыйть аларны күрмәдеме, «обоймага кергәннәр» турында диссертацияләр язып, вакытлары калмадымы? Әллә моңа башка сәбәпләр бармы?
— Шушы урында әйтәсе килә: ә син үзең шушы кимчелекне бетерер өчен нәрсә эшләдең? Нигә шул талантлар турында язмыйсың?
— Һәр өлкәнең үз белгече, үз узаманы бар. Мине инде болай да, Батулла теләсә кая тыкшына, дип сөймәүчеләр җитәрлек. Курчак театрында баш режиссер юк — эшлә, диделәр. Алмаш кайтканчы эшләдем. Тинчурин театрына баш режиссер кирәк диделәр — эшләдем. Телевидениегә саф татарча сөйли белүче кирәк иде — 1963 елдан бирле сөйлим. Турысын әйткәндә, мин гомерем буе бушлыкны тутырырга атылдым. Кадрлар җитешмәгәч, вазифама кермәсә дә, шул эшкә алына идем. Театр һәм әдәбият турында мин язган мәкаләләр-сценарийлар ике том тәшкил итә. Азмыдыр бу, күпмедер — әмма бар.
— Соңгы арада сиңа нигезсез тәнкыйть аеруча каты эләкте шикелле...
— Элек тә эләгә иде. Буш яткырмадылар. Эшләмәгән кешене сукмиләр, эшләмәгәннәр эшләүчеләрне сүгә. Борынгы бабаларыбыз әйтмешли, көчек өрә торур, кәрван йөрә торур.
— Синең иҗатыңа карата дөрес тәнкыйть булдымы?
— Аллага шөкер, булды. Ләкин матбугатта түгел, үзара, дусларча — Равил Фәйзуллин, Нурихан Фәттах, Габделхәй Сабитов, Рөстәм Мингалим, Зоммер Гыйләҗев кебек шәхесләр мине гел орышып торды, бигрәк тә әсәрләремнең теле мәсьәләсенә аларның әче, әмма дөрес тәнкыйтьләре булды. Мин аларга чиксез рәхмәт укыйм. Алар миннән язучы ясады. Тәнкыйть әнә шулай булырга тиеш, үстерергә тиеш, үтерергә түгел!
— Дөрес булмаган тәнкыйть тә булдымы?
— Анысы да булды. Мин гомерем буе наданның хуплавыннан, талантның хурлавыннан курыктым.
— Син бөтен нәрсәгә «кагыласың», шуңа күрә сиңа да «кагылалар» бугай. Син «Урыннары җәннәттә булсын» исемле зур документаль китап язып тәмамлагансың икән. Телевидениедән, радиодан сөйләгәннәрең дә документаль әсәрләрме?
— Әлбәттә, минем алдашырга, тарихны бозып күрсәтергә хакым юк. Бар шундый шәхесләр, алар чыннан да олы эш башкара, шәхесләр турында, аларның кимчелекле яклары турында мәгълүмат, ягъни «компромат» туплый, башкаларның хаталары җирлегендә үзен яхшы итеп күрсәтер өчен, сөймәгән кешеләрен нигезле дә, нигезсез дә тәнкыйть утына тота. Андый мәгълүматның да кыйммәте бар, әлбәттә, чөнки ул мәгълүмат аның үзен дә, тәнкыйтьләнүченең дә холкын ачарга ярдәм итәчәк. Мин дә бит, бик борынгы заманнардан исән калган документларны туплап, татарның тарихи шәхесләре турында китаплар чыгардым: «Тузга язмаган хәлләр», «Сөембикә», «Кылдан нечкә, кылычтан үткен», «Туфан», «Такташ»

исемле әсәрләр. Әле тагын дүрт томын чыгарасым бар. Мин шул документлар аша татар халкының бөеклеген күрсәтергә тырышам. Әлбәттә, татар халкының хаиннәре турында да язарга кирәк. Ләкин хаин турында язганда да син хакыйкать ягында булырга тиешсең.
— Хакыйкать, дигәннән, син, Татарстанның мөстәкыйльлеген яклап, урамнарда йөргән кеше, ике тапкыр Әлмәткә протест акциясенә барган кеше...
— Әйе, булды заманалар, мәйданнарга чыгып сөрән салдык, кан да коелды, йөрәкләр дә ертылды, ачлыкта да утырды милләт каһарманнары. Заманалар узды, көрәш ысуллары үзгәрде. Ләкин көрәшнең ысуллары урамда йодрык селкү генә түгел бит әле. Кеше күзенә күренмичә, татарның гарипләндерелгән тарихын сәламәтләндерергә тырышып-казынып ятучылар азатлык өчен көрәшмимени? Йодрык селкү куәсе бар кешегә дә бирелмәгән. Син шовинизмга каршы йодрык селкисең икән, моның өчен халкыңның бугазына басып рәхмәт таләп итмә. Әмма тарих, бераз үзгәреп булса да, кабатлана. Милли азатлык өндәрләренең кайберләре «идегәйчелек», «тунны утка ягу» кебек имәнгеч сәясәткә кереп китте.
— Ага кеше, нәрсә ул «идегәйчелек»? Без Идегәйне милли, тарихи каһарман буларак беләбез, аның белән горурланабыз.
— Дөрес, Идегәй бабабыз каһарманнар каһарманы. Әгәр ул шулай булмаса, халыклар (казакълар, кыргызлар, башкортлар, нугайлар) аның турында дастаннар чыгармас иде, аны җиде йөз елга якын хәтерендә сакламас иде. Әмма бар — дастан каһарманы Идегәй, бар — тарихи шәхес Идегәй. Ул, бер яктан караганда, изге кеше, икенче яктан караганда... Туктамыш белән Идегәй арасында шәхси гауга чыккач, ватанының дошманы Аксак Тимер ягына зур гаскәре белән чыгып, үз ватанына каршы орышкан һәм үз ватанына яулап алучы җәлладны алып кергән кеше — Идегәй. Шушы сугышларда Туктамыш та, Идегәй дә һәлак була, ватан җимерелә, шәһәрләр корый, татарның куәте кими, шуннан соң дошманнар куәтләнә. Мәшһүр Идегәебез гамәле Алтын Урда солтанатының таркалуына, халкыбызның кара тәкъдиргә ия булуына, дошман дәүләтләренең аеруча көчәеп китүенә сәбәп булып тора. Вак үпкә, шәхси мәнфәгать Ватан мәнфәгатеннән өстен булса, ил мөстәкыйльлек яулый алмый.
— Бәлки, бу бүгенге күзлектән генә шулайдыр, ул заман өчен башкача булгандыр?
— Бәлки... Бүгенге «Идегәйләр», кемгәдер ачу итеп, туннарын утка ташлады инде. Берсе, Президентка үч итеп, татар халкына биш йөз ел буена патша хакимияте дә эшли алмаган зыянны башкарган коммунистлар башлыгы белән кочаклашты. Икенчесе, еллар буе Татарстанда депутат булып, җитәкче урыннарда утырып, соңыннан Мәскәүгә посып, үзен балда-майда йөздергән үз ватанына — Татарстанга зәһәрен чәчә. Өченчесе элек кылган яхшылыкларын каплардай яманлык эшли. «Казак, казачие войска» дигән сүзләр Идегәй заманыннан ук килә, «казак-кацак-качак» сүзе, үз илендә файдалы кеше була алмаган, үз ватанында абруй казана алмаган, әмма ватаныннан куылып, качып китеп, үчлек-көнчелек белән күрше дошман илгә ялланып, үз ватанына каршы сугыша торган нәҗес кешеләргә, җыен этрәк-әләмнән тупланган җәза гаскәрләренә карата кулланылган. Бүгенге татар казаклары (кацаклары), Мәскәүгә сыенып, шул ук нәҗеслекне башкара.
— Рабит агай, ә менә татарның яңа байларына карата синең мөнәсәбәтең ничек?
— Элеккеге вакытта урыс сәнгате дәүләттән күп акча алып та, Савва Морозовлар, Третьяковлар, Шереметьевлар хисабына да тернәкләнгән. Татарның икенче Ренессансы (1776–1930), патша хөкүмәтеннән сукыр тиен дә ала алмыйча, әнә шул татар байлары һәм халыктан җыелган мая хисабына күтәрелгән. Без гел байларны сүктек, шул сүгелгән байлар булмаса, татар әллә кайчан дөмеккән булыр иде инде. Татарны Хөсәеновлар, Рәмиевләр, Акчуриннар, Гаспринскийлар кебек юмарт байлар яшәткән, мәдрәсәсен, театрын, мәктәпләрен, матбугатын шулар тоткан. Ходай урыннарын җәннәттән әйләсен! Аларның күңелендә «Милләт өчен!» дигән сихри-изге куә булган. Кая бүгенге Хөсәеновлар, Акчуриннар, Бубилар?
— Батулла үз иҗатын ничек бәяли? Әйтик, син кайсы әсәрең киләчәк буыннарга барып җитәр дип уйлыйсың?
— Халык мең елдан соң Тукайны онытмаса, Батулланың «Кылдан нечкә, кылычтан үткен» кыйссасы онытылмас. Татар халкы Сөембикәсен онытмаса, Батулланың «Сөембикә» кыйссасы онытылмас. Татар халкы Такташын, Туфанын, Сибгатен, Бакыен, Тинчуринын, Исхакыен онытмаса, Батулланың алар турында язган китаплары да онытылмас, иншалла. Татар халкы әкияттән туймаса, Батулланың «Алып батыр маҗаралары» һәм башка әкиятләре һич онытылмас!
Нефть, «КамАЗ», райком секретарьлары турындагы самосвал-самосвал романнар, поэмалар, пьесаларның күбесе инде авторыннан алда ук үлде. Ул әсәрләр хәзер кәгазь чүбе — макулатура. Номенклатурадан макулатурага бер адым! Язучылары үлгәч, аларны калкытучылар булырмы икән? Менә язучының фаҗигасе кайда, дустым! Заяга узган гомер, зыянга язылган әсәрләр.

Җансыз әсәрләр теге дөньяда язучысыннан җан сораячак. Каләмгә тотынганда, һәр иҗатчы әнә шул турыда уйларга тиеш. Җансыз әсәр язу — иң олы гөнаһларның берседер, мөгаен. Еллар буена иҗатчыларны җансыз-төссез язарга көчләделәр. Кабергә иңүгә үк, андый язучыларны Нәнкир белән Мөнкирдән алда үз әсәрләре ботарлый башлаячак.
— Коточкыч җәза!
— Иҗатчы шуңа әзер булырга тиеш.
— Бер олы шәхес: «Демократия заманы килгәч, барысы да батыр булып китте, мин КГБ белән да көрәштем, дип, үзен милләт каһарманы буларак күрсәтергә тырышучылар күбәеп китте, мин язучылар арасыннан КГБ «кыйнаган» ике генә кешене беләм: алар Нурихан Фәттах белән Салих Баттал», — дигән иде.
— Фәттахны Табеев җитәкчелегендәге партия хакимияте кимсетергә тырышты, КГБ түгел. Батталга эләкте, анысы дөрес. Әмма иң каты кыйналганы Тәүфикъ Әйди булды.
— Син үзең дә бер генә юлдан йөрүче «маршрутлы трамвай» булмадың кебек?..
— Мине КГБ офицерлары берничә тапкыр «Черек күл»гә чакыртып та, ул бинадан тыш, серле бүлмәләрдә дә «эшкәрттеләр». Зарланып сөйләвем түгел, бәлки, чыннан да, алар шулай итеп мине коткарып калганнардыр. Һәрхәлдә, олы дәрәҗәләр алып, пенсиягә киткәч, аларның һәрберсе «сине төрмәдән мин коткарып калдым» дип сөйләде. Ничек кенә булмасын, үзем өчен түгел, шәһит киткән даһиларыбыз өчен мин НКВД-КГБга рәнҗүдән туктамаячакмын. 37 нче елларда НКВДга җыен әтрәк-әләм, надан, үчлекле, көнчел, башка өлкәләрдә сәләтсез, әмма кеше таларга, кеше кыйнарга атлыгып торучылар кереп тулган кебек тоела миңа. Тинчуринны бер ел буена изеп кыйнаган надан ынкывыдышник Исхак Гатин «совет идеясенә, коммунизмга хезмәт итәм» дип башына китермәгәндер, әмма садистларча кыйнау, кыйналган, атылган «халык дошманнары»ның малын талау, аларның фатирына кереп утыру аның төп максаты булган. Белмәгәннәр белеп торсын: Исхак Гатин, атаклы галим Гомәр Галине һәм аның хатыны Хәрирә ханымны зинданга атып, аларның фатирына үзе кереп утыра, аларның җиһазын, малын үзенеке итә, галимнең бай китапханәсен сатып көн күрә. Шушы ук җәллад, Тинчуринны алып киткәннән соң, аның хатыны Заһидә ханымны урамга куып чыгарып, сигез герман фотоаппаратын (ул вакытта дөнья бәясе), алтын ятаганын (хәнҗәрен), инкрустация белән эшләнгән, дөнья бәһасе торган ау мылтыгын һәм башка малларын талап ала. Шул фатирга Хлопушин исемле кеше кереп утыра. Шунысы кызык: шушы җәлладны, кеше талаучы Исхак Гатинны кылган җинаятьләре өчен хөкемгә тартмыйлар, бары тик партиядән генә чыгаралар да, тагын җаваплы урынга утыртып куялар. Карга күзен карга чукымый шул. Бу канечкеч палач, дүрт сыйныф белемле, сержант кисәге Тинчуринны имгәтеп ташлаучы садист булып тарихка кереп калачак. Шундыйлар НКВДда, КГБда аз булган дисәгез, ялгышырсыз. Шамил Усмановны кем имгәткән, кем үтергән? Җамал Вәлидине кем имгәткән, кем үтергән? Мохтар Мутинны кем этләрдән талатып үтергән? Бер Исхак Гатин гына түгелдер бит? Димәк, НКВДда бу эшләр системага салынган, аларның ысулы-асылы шул булган. Халык нәфрәтеннән котылырга теләп, ГПУны — НКВДга, НКВДны КГБга алыштырып кына, исем үзгәртеп кенә асыл үзгәрдеме?
— Синең яраткан язучыларың кемнәр?
— Шаукымга бирелеп, үз талантларын үзләре имгәткән кешеләр бар. Таланты булып та гел «кызыл» әсәрләр генә язып харап булды алар. Кызыл афәтнең салпы ягына салам кыстырып, китабының беренче битенә бер-ике «кызыл» әсәр куеп, яхшыларын саклап калганнар да бар. Шөкер, кызыл шаукым мурыннан котылган Әмирхан, Исхакый, Галәү, Баттал, Туфан, Сибгат, Еники, Фәттах, Афзал, Рәшит Әхмәтҗан, Роберт Әхмәтҗан, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләм, Туфан Миңнуллин, Рөстәм Мингалим кебекләребез әдәбиятыбызның умырткасы булудан туктамады.
— Инде килеп, татар язмышы, аның киләчәге турында... фаразларың нидән гыйбарәт?
— Кайберәүләр кебек, «татар бетә, татар бетте, татар юк ул» дип оран салып кына татарны коткарып булмый. Андый сөйләшүләр коткы тарату төсен алмасын иде! Илбаш янына төпле, яңача фикерле киңәшчеләр кирәк. Татар байлары «Милләт өчен!» дип яшәрлек тәрбиягә ия булырга тиеш. Әдәбият-сәнгать кешеләре җитәкчеләрнең, байларның күңеленә юл таба белергә тиеш. Байларның маясын милләт мәнфәгатьләренә кулланырлык дәрәҗәдә алар белән рухан якынаю булырга тиеш. Бу эшнең башында сәнгатькәрләр үзләре торырга тиеш. Җыламаган балага имезлек каптырмыйлар. «Сәнгатькәрләр һәм малтабарлар» вакыфы булдырылырга тиеш. Рухият белән матдият берләшсә, без таулар ишәчәкбез әле, Аллаһы боерса. Авыл кешесенә (гомумән, Татарстанга) үз малына үзе хуҗа булырлык хокук яуларга кирәк. Мәгариф системасын тамырыннан үзгәртергә кирәк. Буталыштан чыгарга татарда көч бар әле.
— Син күп пьесалар язган кеше, нигә Батулланың яңа пьесалары сәхнәдә күренми? Театрлар сине кире кагамы әллә?
— Яхшы пьесаң булса, барыбер куялар аны. Театрларга үпкәм юк. Мин хәзер пьеса язмыйм.

«Яхшы пьесам бар, театр куймый, мине драматург буларак, Исрафилов, Сәлимҗанов кына үтерде» дип сөйләп йөрүче бичараларны аңламыйм мин. Исрафил куймаса — Марсельгә бар, анысы куймаса — Минзәләгә йөгер, алары да алынмаса — Чаллыга чап, Әлмәткә йөре. Пьесаң яхшы булса, аларның барысы да сине берьюлы инкарь итә алмый бит инде.
— Яңа гасырның ярты елы узып та китте инде. Шул арада Батулла ниләр кыла алды икән дип, мин матбугатка күз аттым һәм аның шундый эшчәнлегенә тап булдым: бу йөзьеллыкны ул Һади Такташ исеме белән башлап җибәргән, шөкер. Мәгълүм булганча, «Урыннары җәннәттә булсын» сериясеннән «Такташ» исемле китап чыкты. Матбугатта төрле мәкаләләре басылган. Коръән аятьләренең татарчасын радиодан укып, тапшырулар биргән, Такташ турында телевизион сценарий язган. «Идел» журналының 1 нче санында тәнкыйтьче Фатих Мөсәгыйть турында әдәбият тәнкыйтьчеләре көнләшерлек «Карчыга» исемле күләмле нәсер бастырган. Илһам Шакировның бөтен иҗатына анализ бирүне максат итеп, язучы буларак сценарий язып, режиссер буларак аны сәхнәгә үзе куйган, артист буларак кич буе халыкка Илһамның иҗаты турында үзе сөйләгән. Әле яңа гына төрекчәдән зур гына бер әдәби әсәр тәрҗемә итеп бетергән. Син өч һөнәр иясе: язучылыгыңа, артистлыгыңа, режиссерлыгыңа син беркайчан да хыянәт итмәдең! Аз түгел! Машалла, Бату агай! Шулай дәвам итәргә язсын!
— Амин!
*«Мәдәни җомга», 13 июль, 2001*

**ЯЗМЫШ ЭШЕ**

Кайбер кешеләрнең киләчәктә нинди даирәдә хезмәт итәчәге әйтерсең лә язмыш тактасына алдан ук язылып куелган була. Мансур Мозаффаров 1902 елда Казанда туа. Әтисе вафатыннан соң малай әнисе, танылган шагыйрә, кызлар мәктәбендә укытучы Маһруй Мозаффарова тәрбиясендә үсә, бик кечкенәдән үк китап кибетендә йомышчы малай булып эшли башлый. Композиторның истәлекләренә караганда, Казанда Габдулла Тукайны, Салих Сәйдәшевне очратулары аның бала чагының ак, шатлыклы хатирәләре булып күңеленә сеңеп калган. Ун-унбер яшьлек Мансур «Болгар» кунакханәсендә яшәгән Тукайга гәзитләр китерә, бөек шагыйрьнең: «Малай, мин бит бүген фәрештәләр белән сөйләштем», — дигән тылсымлы сүзләре әйтерсең аның кайчан да булса сәнгатькә хезмәт итәсен алдан белеп әйтеләләр... Кем белә, бәлки, бу «Туган тел» яки «Тәфтиләү», «Зиләйлүк»нең дөньяга килгән чагы булгандыр?
Башлангыч белемне ул мәдрәсәдә ала. 1916 елда Учительская школага керә. Әле Октябрь инкыйлабына кадәр үк, татар халкының профессиональ музыка сәнгате яңа оешып, үсеп кенә барган бер заманда, яшь музыкант «Сәйяр» труппасына килә, ягъни труппа каршындагы ансамбльдә эшли башлый. Әмма ярым һәвәскәр, ярым профессионал булып йөрү яшь музыкантны канәгатьләндерми. 1919 елда ул Казан музыка училищесының кларнет классында укый башлый. 1923 елда исә М.Мозаффаров Мәскәү консерваториясенә укырга китә. Тик авыруы сәбәпле, ул консерваториянең композиторлык факультетына караган этнография бүлеген 1931 елда гына тәмамлый.
Шулай ук язмыш эшедер инде, яшь композитор иҗат эшчәнлеген халык җырларын эшкәртүдән башлый. Мисалга М.Мозаффаров эшкәртүендә популярлашып, халыкның гаять зур мәхәббәтен казанган «Сибелә чәчәк», «Галиябану», «Зиләйлүк» һ.б. көйләрне искә алу да җитә. Халык җырларын композитор фортепианога кушылып җырлау өчен дә, аккомпанемент белән хор яисә хор өчен генә, шулай ук кыллы квартет белән башкару өчен дә эшкәртә. Мәсәлән, ике скрипка, альт һәм виолончельдән торган кыллы квартет өчен татар халык җырлары темаларына ун пьесадан торган цикл төзи.
Музыка белгече К.Таҗиева билгеләп үткәнчә, «профессиональ композиторларыбызның беренче буыны өлешенә гаять җаваплы бурыч — татар профессиональ сәнгатенең нигез ташларын салу бурычы төште. Алар халыкның музыка традицияләрен җирлек итеп алып, музыка сәнгатен бик кыска тарихи вакыт эчендә моңарчы күрелмәгән биеклекләргә күтәрергә, халык җыручылыгының милли стихиясен классик музыка сәнгате жанрлары һәм формалары белән синтезлаштырырга, идея-эчтәлеге һәм сәнгатьчә кыйммәте, халыкчанлыгы ягыннан киләчәк буын музыкантлары өчен таяныч һәм этәргеч булырлык әсәрләр язарга, формасы, стиле һәм музыкаль теле белән яңа заманга аһәңдәш, яшь сәнгать алдына куелган максатларга лаек рухи хәзинәләр тудырырга тиеш булдылар». Мансур Мозаффаров бу олуг бурычны лаеклы үтәп чыкты.
Кече жанрдагы вокаль музыка төре булып саналган романска Мансур Мозаффаров әле 30 нчы елларда ук мөрәҗәгать итә. Мәскәү консерваториясендә укыган чорында А.С.Пушкин

шигырьләренә язылган иң яхшы җырга конкурс игълан ителә. Яшь татар композиторлары да бу конкурста яңа әсәрләре белән катнашалар. М.Мозаффаровның «Җырлама син, иркәм» романсы арада иң уңышлылардан берсе дип танылa. Музыка белгечләре бәяләвенчә, бу әсәр Пушкин мирасына тирән үтеп керүе һәм аны милли музыка стилендә гәүдәләндерүе белән аерылып тора, эмоциональ эзлеклелеге, тонда бөтенлеге, көйнең табигый агышы, интонацияләрнең нечкәлеге белән сокландыра. М.Мозаффаровның әлеге романсын кайбер музыка белгечләренең Балакирев, Римский-Корсаков кебек рус композиторларының Пушкин шигърияте белән рухланып язган әсәрләре янәшәсенә куеп бәяләве бик күп нәрсә турында сөйли булса кирәк. Шунысы да әһәмиятле: М.Мозаффаров Пушкин шигырьләренә романслар язуын 40 нчы елларның ахырында да дәвам иттерә. Бу чорда классик поэзия әсәрләренә мөрәҗәгать итү профессиональ музыкабызның сурәтләү чараларын баету, речитатив стильнең мөмкинлекләрен киңәйтү ягыннан да әһәмиятле булды.
М.Мозаффаровның әле 30 нчы елларда ук иҗат ителгән җырларының байтагы бүгенге көндә дә яши бирәләр. «Җиләк җыйганда» (М.Җәлил шигыре), «Сайра, сандугач» (М.Садри шигыре), «Яшь егетләр, яшь кызлар» (Ә.Ерикәй шигыре) җырлары интонация төзелешендәге яңалык, якты һәм дәртле аһәңнәре белән халыкның рухына хуш килделәр. Композиторның 50–60 нчы елларда иҗат иткән вокаль әсәрләре исә татар музыка үсешендә үзенә бер сәхифә тәшкил итә. Бу чорда ул утыздан артык җыр яза, аларның иң яхшылары оркестр белән башкару өчен эшкәртелгән. Әлеге җырларда композиторга хас иҗат стиленең иң яхшы сыйфатлары бергә җыелган: тирән эчтәлек тә, ачык аңлаешлы аһәң дә, кеше күңеленә тирән үтеп керә торган ихласлык һәм инсафлык та бар аларда. Композиторның җыр өлкәсендә озак еллар туктаусыз эшләве гүзәл нәтиҗәләргә китерә: җыр иҗатында үзенә аерым яңа бер төр — уйланулар дип атарга мөмкин булган жанр туа. Әйе, татар музыкасында яңа вокаль стиль барлыкка килү дигән сүз иде бу. Яңалык композиторның җыр текстларын сайлавында да ачык күренде: ул югары гражданлык рухы бөркелеп торган, туган ил, аның гүзәл табигате, яшәешнең мәгънәсе хакында тирән уйлануларга корылган шигырьләргә мөрәҗәгать итә. С.Хәкимнең «Кайда да йөрәктә», «Башка берни дә кирәкми», М.Мазуновның «Туган як», Г.Зәйнашеваның «Мин тормышка гашыйк», «Менәргә иде Урал тауларына» әсәрләренә язылган җырлар әнә шундыйлардан. Аларга тирән гражданлык хисе, лирик-фәлсәфи яңгыраш, киң һәм салмак хикәяләү интонациясе, акыртын темп, кырыс, сабыр һәм тыенкы хисләр хас.
М.Мозаффаров — татар музыка сәнгатенең яңа төре — опера сәнгате өлкәсендә дә сизелерлек эз калдырган композитор.
Опера сәнгатендә беренче адымнарын гына атлаучы башка халыкларда да опера жанрын үзләштерү сүзле музыкаль әсәрләр аша барганлыгы мәгълүм. «Галиябану» операсын иҗат итү дә татар театрындагы шул катлаулы күчеш процессының бер мисалы иде.
1943 елда М.Мозаффаров үзенең икенче операсын — «Зөлхәбирә»не тәмамлый. Бу әсәрен дә ул халык моңнары чыганакларына таянып иҗат итә. Әмма «Галиябану»да халык көйләре әсәрнең тукымасына кертелеп, турыдан-туры файдаланылган булса, икенче операда принципиаль яңалык кулланыла. Монда бер генә халык көе дә юк диярлек, әмма шул ук вакытта ул — чын милли формага корылган әсәр, сурәтләүнең классик чаралары монда халык моңнары, рухы белән сугарылган. Операның драматургиясендә симфонияләштерү методларына зур урын бирелә.
М.Мозаффаров симфоник музыка өлкәсендәге беренче тәҗрибәләрен 30 нчы елларда ук ясый. Аның бу тәҗрибәсе дә халык җырларын тирәнтен өйрәнүдән башлана. Аерым көйләрне, мотив һәм борылышларны әсәрдә турыдан-туры файдалану этабы аша үтеп, интонация закончалыклары, эчке табигате белән халык көйләренә аваздаш, әмма тулысынча оригиналь булган темалар тудыра. 50 нче елларда композитор халкыбызның сөекле уллары Габдулла Тукай һәм Мулланур Вахитов истәлегенә багышланган симфоник поэмаларын яза. Һәр ике поэманың да эчке драматургиясе гаҗәеп киеренке, һәр икесе дә мелодик материалга бай. Автор халык көйләре интонациясеннән кыю файдалана. Мәсәлән, Г.Тукайга багышланган поэмада без шагыйрьнең яраткан җырларыннан берсе «Әнкәм кабере янында» дигән җырның көе мотивларын ачык ишетәбез.
Болардан тыш М.Мозаффаров 50–60 нчы елларда «Туган ягым» исемле симфоник поэма, симфониэтта, скрипка һәм оркестр өчен ике концерт иҗат итә. Шулай итеп, инструменталь музыка иҗатын даими төстә җыр белән бергә бәйләп алып баруы, классик сәнгать тәҗрибәсен милли музыка белән органик рәвештә куша белүе композиторны югары иҗади казанышларга алып килә. Аның исеме татар профессиональ музыкасы тарихында тирән эз калдырган С.Сәйдәшев, С.Габәши, Н.Җиһанов, Җ.Фәйзи, А.Ключарев, З.Хәбибуллин һ.б. композиторлар белән бергә телгә алына.

Композиторның татар музыкасына керткән өлеше югары бәяләнде. Ул — Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык артисты. Татар музыкасының классигы Мансур Әхмәт улы Мозаффаров 1966 елда вафат була.

*«Казан утлары», март, 2002*

**«ТАЛАНТЛЫ СИН, КЕШЕ ТУГАНЫМ!»**

Танылган язучы, Г.Исхакый исемендәге премия лауреаты Ф.Сафинның өч китаптан торган «Саташып аткан таң» романы — тарихи әсәр. Тормышта яшәп киткән реаль шәхесләрне әдәби әсәр җирлегендә сурәтләргә алынуы белән автор шактый кыюлык та күрсәтә. Әсәрдәге геройлар язмышы, вакыйгалар агышы, тирән фәлсәфә, җанны кузгатырлык кичерешләр, фактик материаллар белән роман тарих сабагын, ачы хакыйкатьне күрсәтеп бирә.

Минем бәләкәй генә шигъри җаным олы дөньяга Хәсән ага Туфан күзләре белән карый. Нигәдер, үзем дә аңлата алмыйм, Факил Әмәк турында язарга алынгач та сөекле шагыйрем турында, аның әдәбият сагында торырга омтылуы хакында уйлап куйдым. Ышанып әйтә алам, Хәсән Туфан Сибгат ага Хәким белән киңәш-табыш итешкәннән соң, әдәбиятка көчле агым булып килеп кергән, татар прозасын олы язмышлы каһарманнар белән баеткан Факил Әмәк иҗатына сөенеп: «Бәрәкәте белән булсын, канәтем!» — дип әйтер иде сыман. Исемнәрдә мондый параллелизм китерүнең сәбәбе бар (иҗатта түгел!): әйткәнемчә, Хәсән ага — яраткан шагыйрем, кумирым, Факил Әмәк исә — таланты каршында баш игән прозаигым һәм... горурланырлык якташым. Ул безнең күрше генә авылдан — Әмәкәйдән. Кыскасы, аларның берсе — рухи остазым, икенчесе — рухи туганым!..

Сафин Факил Миңнемөхәммәт улы 1954 елның 2 гыйнварында Мөслим районының Әмәкәй авылында алтынчы бала булып дөньяга килә. Кечкенәдән әдәбият-сәнгать белән кызыксына. Мондый омтылыш тәрбияләнүдә әти-әнисенең укымышлы, элеккечә әйтсәк, гыйлем ияләре булуы тәэсир иткәндер, күрәсең. Әтисе Миңнемөхәммәт агай инкыйлабка кадәр үк мәдрәсәдә әтрафлы белем ала. Әле атеистик коткы котырган чорда ук, 60 нчы еллар ахырыннан башлап бүгенге көнгә кадәр үз төбәгендә муллалык вазифасын башкарып килә. (Факилнең инсафлы, зыялы шәхес булып формалашуы юктан гына түгел икән ләбаса!) Әнисе дә борынгы муллалар нәселеннән.

Факил Әмәк — һәр катлаулы шәхескә хас булганча, бормалы юллар узган, бай биографияле язучы. (Кем әйтмешли, язучы ул, барыннан да бигрәк, биография!)

Факил Мөслим районы Күбәк урта мәктәбен тәмамлагач, колхозда механизатор булып эшли башлый. Минзәләдә шоферлык һөнәрен үзләштерә. 1972–1974 елларда армия сафларында хезмәт итә: Ерак Көнчыгышта, Кытай чигендә дә иҗат эшен туктатмый. Армиядән кайту белән райондагы иң зурлардан саналган «Михайловка» совхозында комсомол оешмасы секретаре, бераз соңрак Иске Карамалы мәдәният йорты директоры вазифаларын башкара. Әмма югары белем алу теләге барыннан да көчлерәк булып чыга һәм Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә. Керә... дип әйтүе генә җиңел! Укырга китәргә җыенганын белгәч, ул чордагы җитәкчеләр аңа бернинди дә документлар бирмиләр. Кулда — хәрби билет, култык астында — бер кочак шигырьләр. Аның университетка кабул иткәндәге бөтен документлары шуннан гыйбарәт була. Укуны тәмамлагач, диплом яклаганда ук аспирантурада калырга үгетлиләр. Диплом эше студентларның фәнни конкурсында җиңүчеләр исемлегендә була. Ләкин егет гаилә хәлләре буенча, авылда төпләнеп калырга уйлый.

Шулай итеп, ул Мөслим районы Октябрь авылында укытучы булып эшли башлый. Гаилә корып җибәргәч, туган авылына кайтып, әдәбият, тарих фәннәре укыта. Ләкин 1981 елда, Октябрь мәктәбендә эшләүче укытучыларның соравы буенча, директор итеп билгеләнә. Тагын берничә елдан районда иң эре саналган Тат. Бүләр урта мәктәбенә директор итеп җибәрелә. Ләкин язмыш Факил Сафинны 1984 елда Чаллы шәһәренә алып килә. Ул КамАЗның автомобильләр җыю заводында баш конвейерда слесарь-җыючы, бригадир, мастер булып эшли. Эш дәверендә 1 класслы мастер дәрәҗәсенә ирешә, КамАЗның Мактау тактасына кертелә, Минавтопром буенча җиңүче була. Язмыш Ф.Сафинны гел бөтереп кенә йөртә: ул яңадан мөгаллимлек эшенә кайта, 24 нче һәм 18 нче мәктәпләрдә тарих укыта. Шәһәр тарихында беренче мәртәбә 8 нче классларга кадәр «Татар халкының тарихы, әдәбияты, мәдәнияте» дигән яңа фән-дәресләр укыта башлый. Шушы елларда аның исеме шәһәр матбугатында күренә башлый. 1990 елда Факил Сафин, Әмәк тәхәллүсе алган язучы, шагыйрь шәһәрдә үз чорында данлыклы исем алган «Таң йолдызы» газетасына баш мөхәррир урынбасары булып эшкә килә, 1991 елда исә «Аргамак» журналының

җаваплы сәркатибе итеп сайлана.
Исеме танылып кына килгән яшь язучыга өлкәнрәк буын әдипләр зур ышаныч баглыйлар. Танылган язучы Газиз Кашапов: «Күңелеңдә булганны яз, каршылыклар күп булачак әле ул», — дип фатиха бирсә (Нинди күрәзәчелек! Факил Әмәкнең тормыш юлы күп очракта башкалар китереп өйгән каршылыкларны җиңә барудан гына тора.), күренекле шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин: «Син — шагыйрь. Үзеңне хөрмәт итәм, иҗатыңны яратам. Берүк чор ыгы-зыгысына ияреп ваклана күрмә», — дип (Факил ваклыклардан өстен тора белә) аркасыннан сөя.
Бүген Факил Сафин — күренекле әдип, шагыйрь, мәртәбәле сүз остасы. Алай гына да түгел, иҗтимагый актив һәм үз кыйбласына турылыклы кеше буларак, ул Чаллы шәһәрендә чыга торган «Мәйдан» журналының оештыручысы һәм баш мөхәррире дә. Чаллы югары уку йортларында студентларга дистәләгән лекцияләр укыган мөгаллим, беренче шәһәркүләм балалар иҗат түгәрәкләрен оештыручы, «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенең җитәкчесе булуын, күпсанлы шигырьләргә көйләр язучы үзешчән композитор икәнлеген дә искә алсак, бу кешенең эрудициясенә, көченә, тырышлыгына хәйран каласың. Ул дистә ел эчендә бер-бер артлы «Соңгы көз» (1992) һәм «Гөлҗиһан» (1998) повестьларын, «Биек тауның башларында» (1998) романын һәм «Саташып аткан таң» (2002–2003) роман-трилогиясен иҗат итте, «Сәфәр» (2002) шигырьләр җыентыгын бастырып чыгарды. Шул рәвешле лаеклы рәвештә олпатлар мөнбәреннән урын алды.
Һәр чор үз әсәрен тудыра.
Хәтерлим, заманында Мөхәммәт Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» әсәре тын кырмыска оясын тузгытып җибәргәндәй бер әсәр булган иде. Факил Сафинның «Соңгы көз» повесте да гавам көзгесендә әнә шундыйрак эз калдырган әсәр булды: чөнки ул тоталитар режимны — димәк, гомуми коллыкны рәхимсез рәвештә фаш итте. Әйе, «Тора-бара бөтен власть беренче секретарьлар, өлкә, шәһәр, район башлыклары, завод-фабрика, колхоз-совхоз җитәкчеләре кулына күчте. Алар аерым булып оештылар. Тирә-юньнәрен куштаннар, ялагай бәндәләр белән уратып алдылар. Кода-кодагыйлык, ришвәтчелек, мораль һәм җенси бозыклык, эчкечелек чәчәк атты. Үзләре генә шулай яшәсәләр бер хәл иде. Алар карьеристлар һәм әләкчеләр, һәртөрле җинаятьчеләр өчен уңай шартлар, җирлек тудырдылар. Туры сүзле, намуслы кешеләргә яшәү нык кыенлашты, аларның бер тиенлек кадере калмады. Гади хезмәт кешесенә тәмам көн бетте» (Ф.Миңнуллин. «Балта явызлар кулында»).
Факил Әмәкнең «Соңгы көз» әсәре бу нәүбәттән Аяз Гыйләҗевнең «Балта кем кулында?» әсәре белән аваздаш булды. «Соңгы көз» повестеның төп герое Тимерхан Заманов — шул тоталитар системаның шактый зур кодрәтенә ия вәкиле. Үз төбәгендәге чикләнмәгән властьны аңа партия мәктәбендә бергә укыган сабакташы — КПСС өлкә комитетының беренче секретаре «бирә». Повестьтагы барлык каһарманнарның эчке һәм тышкы дөньялары, кыланмышлары һәм эш-гамәлләре Замановка бәйле рәвештә ачыклана; шуңа күрә дә аларны Замановка «буйсынучылар» яки «буйсынмаучылар» дип атарга мөмкин булыр иде. Тик ул үзе дә «ирекле» кош түгел: аның кул астында кешеләр ул кылган җәбер-золымнарга ничек итеп тешен кысып түзсә, үзеннән югарыда утыручы түрәләр каршында ул үзе дә мескен хәлдә — ул аларны сыйлый, көйли, чөйли, яраклаша, ялагайлана. Чөнки системасы шундый. Мондый система яшәгәндә, беркем дә тулы вә тигез бәхетле була алмый; алар — түрәләр! — намусын, горурлыгын сату бәрабәренә ниндидер ләззәт-рәхәтләкләр алса да, ахыр чиктә барыбер бәхетсез кешеләр. Чөнки алар да система коллары!
Тимерханның әтисен 30 нчы елларда, социализмны астан җимерә дип, нахакка кулга алалар. Әнисе ашлык тапшырырга киткән җиреннән кайтмый. Яшьтәшләре, мәктәп укучылары Тимерханны «халык дошманы» малае дип кагалар, кимсетәләр. Сабый чагыннан ук «халык дошманы» малае буларак, Тимерхан рухи гариплек кичереп, горурлыгы кимсетелгән кеше булып үсә. Шуңа да яшьлегендә акыл, киңәш бирүче Бәйрәмгали бабайның: «Син, улым, кешеләргә беркайчан да ышанма. Дус-ишләрдән сак бул... Үзеңә ышан, нык бул, үҗәт бул! Хәзер әрсезләр заманы. Туры килсә, тимер арканны да тешләп өз. Юашны тиз юешлиләр. Гаделлекне эзләп тә җәфаланма — гаделлек юк ул дөньяда! Мәгәр минем әлегәчә күргәнем булмады. Кем көчле — шуның сүзе үтә, кемнең кулында — шуның авызында! Өермәдәй бөтерел, еландай боргалан! Башыңны койрыгыңнан, койрыгыңны башыңнан эзләсеннәр. Шул чагында яши алырсың», — дигән өйрәтмәсе аның яшәеш рәвешенә, тормыш итү принцибына әверелә. Бәйрәмгали бабай киңәшләрен исеннән чыгармаган «халык дошманы» малае колхоз рәисе дәрәҗәсенә күтәрелү өчен күп көч, зур тырышлык сарыф итә. Заманов, сүз дә юк, эшлекле кеше. Ул — гаярь, тырыш җитәкче. Хуҗалыкны алып бара белә. Шул ук вакытта ул үтә дә хәйләкәр. Эшне шундый итеп оештыра ки, авылдашлары аның алдында үзләрен йә һәрдаим гаепле сизеп йөриләр, йә булмаса, һич уйламаганда, колхоз рәисенә бурычлы булып калалар. Чөнки заманасы

шундый.
Социализм, гомумән, күз буяучылыкка корылган икән, Заманов аның «идеаллары»н осталарча тормышка ашыручы. Әйтик, Заманов җитәкләгән колхозда нинди дә булса төзелеш эшләре башлана икән, бөтен тирә-юнь шау-гөр килергә тотына. Мәсәлән, авылның "яңару" күренешен генә күз алдына китерик. Таза нарат йортлар «өске» урамда гына төзелә, чөнки анда авыл түрәләре яши, «аскы» урамда йортлар черек усактан салына, юллары батып үлмәле, монда хәерчелек хөкем сөрә. «Өске» урам социализмы белән «аскы» урам социализмын Шәмсетдин агайның төпчек улы үзенчә бик төгәл аңлатып бирә: «Прастуй гына әйткәндә, «социализм» дигәне — Суарның аскы урамы; «нык үскән социализм» дигәне өске урам була инде. Бөтен җитәкчеләр шул үзәк урамда яши... Тик социализмның да юлында бер охшашлык бар: тегендә дә, монысында да гаделлек юк. Кемнең кулында — шуның юлында, кем көчле — шул җиңә».
Тимерхан Заманов ничек кенә гайрәтле булмасын, үзе дә командачыл бюрократик системаның, үзеннән югарыда утыручыларның колы. Үз чиратында, Заманов үзеннән түбәндәгеләр белән бик оста һәм шәфкатьсез идарә итә белә. Үзенең колхозында Заманов — бердәнбер хөкемдар. Ул үзе тирәсенә куштаннар туплаган. Әйтик, баш агроном Фәйзи, авыл советы рәисе Әнүр, парторг Инсаф «хөкемдар»га берсүзсез буйсыналар, аңа ярарга тырышалар. Кул астында эшләүче кечкенә түрәчекләр белән Заманов дорфа, тәкәббер. Чөнки шунсыз аны «ихтирам итмәячәкләр», ул «айт» дигәндә «тайт» дип калтыранышып тормаячаклар. Кем әйтмешли, аның иртәнге планлаштыруны үткәрү күренешен, чорның сурәте буларак, «кинога» төшерерлек: «Белгечләр иң элек баш агроном Фәйзи Солтанов янына керәләр. Төгәл алты тулуга, кыр казлары кебек тезелешеп, рәис бүлмәсенә юнәләләр. Гадәти генә керү түгел бу, үзенә күрә бер церемония! Сафның башында — Фәйзи Солтанов, аның артыннан баш зоотехник Хәсән Әгъләмов, партия оешмасы секретаре Инсаф Җиһанов, авыл советы рәисе Әнүр Сәйфиев, баш инженер Ясәви Бариев, аннары башкалар. Рәис бүлмәсендә утырганда һәркайсының үз урыны. Керүчеләр, түргә узып, рәиснең дымсу, салкынча кулын кысканнан соң, урыннарына барып утыралар. Аларга рәис күз дә салмый, кәгазьләр караштырган килеш илтифатсыз гына якынайган шәүләгә кулын суза».
Әйе, хакимият — аяусыз көч, усал, явыз, башбаштак көч. Тимерхан Заманов моны бик яхшы аңлап эш итә. Шуңа күрә дә ул корбаннар эзли, кеше намусын изеп үтү аңа берни дә тормый. Повестьта иң беренче корбан — Замановның никахлы хатыны Зөлхиҗә. Әсәрдә тетрәндергеч бер күренеш бар: «Ә Зөлхиҗәсе Тимерханның хатын-кыз затына һәвәслеген күрмәмешкә салыша иде. Һай, күп булдылар алар яшәгән гомерендә. Хатыны вафаты алдыннан үз-үзенә сөйләнгәндәй итеп: «Эчемдә гомер буе утлар янды. Кешеләргә сиздермәс өчен йөрәк каным белән сүндердем. Шул алып китә гүргә», — дип, күз яшьләрен сөртеп алган иде. Тимерхан эндәшмәде. Иңенә җылы бишмәтен салып, ишегалдына чыгып китте».
Кансызлыгы, имансызлыгы, кабахәтлеге, хәйләкәрлеге ягыннан Заманов Ф.М.Достоевскийның «Җинаять һәм җәза» романындагы Свидригайлов образыннан ким түгел. Әткә эт үлеме дигәндәй, аларның үлемендә дә охшаш мотивлар юк түгел. Ә аның «свидригайловлыгы» тагын бер күренештә ачык чагыла. Ул хатыны каберенә килеп «баш ору гадәтеннән дә зур тамаша ясый. Һәр елның 15 октябрендә мәктәп укучылары көзге уңыш җыярга басуга чыккан көнне Заманов дистәләгән күз озатуында зират капкасы каршына килеп туктый. Кабер янында Тимерханның кылган эш-гамәлен, эшләреннән бүленеп, йөзләрчә укучылар һәм укытучылар карап-күзәтеп торалар. Ул күздән югалганчы озатып калалар. Әйе, Замановның һәр кылган эше макталырга, хупланырга тиешле, хәтта аның хатыны Зөлхиҗә каберен зирәт кылуын да кешеләр күреп, бәһаләп торырга тиеш. Тик шунысы гаҗәп: бу минутларда Тимерханның миеннән «Зөлхиҗә!» дигән уй ялгыш та үтмәде».
Икенче бер корбан — Гөлчирә. Өч яшьлек кызның — Гакыйләнең — әнисе, абзар артында баганага сөялеп үкси:
«Исрафилкаем, теләсә ни эшләт. Тимерхан... кара йөз... мыскыл итте... кабахәт!..
Тимерханның исемен ишетүгә... ир хатыны янына чүгәләде:
— Нигә шыр акырасың?.. Персидәтелнең исемен әйтмәй генә аңлатып бир, дөньяны сасытасың бит...»
Тәнкыйтьче М.Вәли хаклы язып үткәнчә: «Халыкны мондый хәленнән чыгару өчен күпме кирәк?! Хәтта үзенең хатынын көчләү белән ризалашкан һәм каршы бер сүз дә әйтә алмаган кешеләрне, чыннан да, кеше итү өчен әле никадәр көч салырга кирәк булачак милли әдәбиятка».
Корбаннар, корбаннар... юллар, юллар...
Чираттагы корбан — Гөлчирә белән Исрафилның кызлары Рәхилә...
«Кыз үксүеннән туктады, әрнеп:
— Безнең гаиләнең бәхетен урлаган кеше син. Инде минем дә башыма җиттең... Ни йөзем белән

өйгә кайтыйм, кеше күзенә күреним.» — диде?
Моны «свидригайловщина» димичә ни дип атарга мөмкин соң?!
Ф.Сафинның «Гөлҗиһан» повесте — актуаль проблемаларны чагылдырган, тормышчан образларга бай әсәр. Беркемгә дә сер түгел: шагыйрьләр үз иҗатларында шигырь гармониясен, шигырь үлчәмнәрен аеруча сизгер тоючан. Әгәр дә шагыйрь чәчмә әсәр язуга алына икән, ул, ирексездән, үзе дә сизмәстән, проза әсәрендә шигырьгә хас югары поэтика кануннарын куллана башлый һәм әсәрдәге образлылык чын мәгънәсендә камиллеккә ирешә. Чәчмә әсәр укыганда «җырлап тора» башлый, күңелгә рәхәтлек бирә, укучыда фикер өермәсе кузгата. Теленең табигый агышы, гыйбарә-төсмерләргә бай булуы, сыгылмалы рәвеше белән «Гөлҗиһан» повесте хәзерге татар прозасының бер казанышы булып тора. Моны зәвыклы һәм таләпчән укучы да тиз сиземләп алды. Әсәр китап булып басылып чыккач ук, 1999 елда республика күләмендә иң күп укылучы китап исеменә лаек булып, I Дәрәҗәле Диплом белән бүләкләнде һәм язучы Чаллы шәһәрендә Ел язучысы исемен алды.
Әсәрнең үзәгендә — сугыштан соңгы авыр тормыш кичергән, әмма рухи сынмаган, хис-кичерешләргә бай татар хатыны язмышы. Әсәрнең сюжеты да төп герой Гөлҗиһан тирәсендә үрелеп бара. Гөлҗиһанның тормышын тасвирлаганда, автор кеше күңеленең матурлыгын, изге җанлы булуын катлаулы вакыйгалар, уйлап чыгарылган каршылыклар аша түгел, ә бәлки гади, тормышчан хәл-әхвәлләр эчендә ача. Гөлҗиһанның уңганлыгын, матурлыгын, гадилеген, шаянлыгын тасвирлау белән бергә, Ф.Сафин аны уратып алган, тормышыбызда яшәп килгән аерым тискәре күренешләрне дә онытмый. Шул ук вакытта әдәп, әхлак, гаилә проблемаларын да күтәрә. Гөлҗиһан чын күңелдән кешеләрне, тормышны ярата; ул ярдәмчел, кешеләргә игътибарлы!
Гөлҗиһан — колхоз рәисе кызы. Ул бик яшьли ятим кала. Әтисе исән булса да, кыз ата назын күрми: «Сугыштан кайтканнан бирле әтисенең балалары белән иркенләп, җайлап сөйләшкәне булмады. Әниләренең үлеменә дә балаларын гаепле санаган кебек». Ләкин авырлыкларга карамастан, яшь, гүзәл Гөлҗиһан киләчәккә өмет, ышаныч белән карый. Тормышында авырлыклар очраганда, Гөлҗиһан саилче карчыктан отып алган җырны көйләргә ярата:

Бер кайгыга батам, бер юанам —
Миндәйдер күп дөнья йөзендә.

Ахырда яшьлек, мәхәббәтне сагыну хисе йөрәктә бераз томалана барганда, яратмыйча кияүгә чыккан ире Әухәткә күңеле ияләшә төшкәндә, йөрәктә яшәү дәрте — берәр малай үстерү теләге тернәкләнеп килгәндә, язмыш Гөлҗиһанны тагын бер авыр сынау алдына куя. Табигатьне, чисталыкны яраткан, намуслылыкны үзенә юлдаш иткән мәрхәмәтле җан иясе кичереп булмаслык шәфкатьсезлек — хыянәт белән очраша. Әле кайчан гына: «Һәр кеше үз тиңен эзли... Фәймә миңа тиң түгел», — дип йөргән Әухәт язмышын башкача хәл итә: «Без ни... Фәймә белән ниттек... Горькийда ирле-хатынлы яшәдек. Аңа өйләндем. Авырлы инде ул... Без инде, Гөлҗиһан, кискән ипи ябышмас, әйбәтләп кенә аерылышыйк».
Шушындый авыр минутларда да Гөлҗиһан сабыр булып кала белә, кычкырып елап җибәреп, күрше-күлән алдында да, Фәймә белән Әухәт алдында да үзен сынатасы килми, көчле рухлы булып кала. Бары эчтән генә: «И дөнья, нигә мәрхәмәтсез син бәндәләреңә?» — дип кенә сыкрана.
Әйе, Гөлҗиһан — шәһәр цивилизациясе алып килгән рухи шапшаклыклар белән пычранмаган ихлас-саф, беркатлы-кундәм, эшчән-тырыш саф татар авылы хатыны. Дөньяга дәгъва кылып, кычкырып-акырып йөрми, үз эшен тиешенчә башкарып килә; шуның белән ул Сәкинә, Фәймә, Гөлзадәләрдән өстен тора һәм шушы сыйфатлары белән укучы күңелендә ихтирам уята.
Факил Сафин каһарманнарның кешелек сыйфатларын тулырак ачу өчен мифик геройлардан оста файдалана. Әйтик, Гөлҗиһанның тормышында иң авыр вакытларда аның янында каяндыр, әйтерсең лә күктән иңгән кебек, бик тә ягымлы һаман да шул саилче карчык пәйда була. Әнисе үлеменнән соң да, газиз баласы яшәү белән үлем арасында ятканда да, Әфүзә күп еллардан соң кайтып төшеп, ташлап киткән малае Шамилне даулап йөргәндә дә, аның янына шушы саилче карчык килеп чыга: «Ходайдан аерылмагыз, балалар, — диде. — Аллаһ рәхмәтеннән ташламасын бәндәләрен. Исән кеше өметтән аерылмасын. Кешене өмет яшәтә».
Берни белән дә башкалардан аерылып тормаган бу татар хатыны, нәкъ менә Татар хатыны, тормыш итәргә гаҗәп тә үҗәт, нинди генә югалтуларга да карамастан, ул яшәргә тырыша, үзеннән соң да тамырларын калдырырга тели. Бу нәүбәттән, бу сыйфатларның Хәсән Сарьянның «Бер ананың биш улы» әсәрендә Ана образына салынган фикерләр белән уртаклыкны әйтү урынлы булыр. Өч улын югалткан Маһисәрвәр дә, Гөлҗиһан кебек үк, кайгыларга сабыр гына түзә. Бу образларның икесенә дә яшәү көче, диннән килгән Коръәни

сабырлык хас. Аларны саклап килгән көч тә шул дини тәрбиядер әле, мөгаен. Кыскасы, Гөлҗиһан — чын мәгънәсендә татар хатыны образы, шуның белән ул татар әдәбиятындагы Аналар образы галереясын тутырып тора.
Факил Сафинның татар җанын тетрәткән тагын бер әсәре, ул да булса «Биек тауның башларында» романы. Алдан ук әйтеп куярга кирәк: бу әсәр киң җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгендә булды һәм язучыга бу әсәре өчен лаеклы рәвештә Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге бүләге бирелде. Әсәрдә сүз 90 нчы елларда күпләребезнең бәгырьләрен телгәләгән фаҗига — мәгънәсез Чечен сугышы, әле үсмерлекләреннән дә чыгып җитмәгән егетләребезнең һәлак булулары, армия хәлләре, экстремаль хәлләрдә адәм балаларының бер-берсенә булган мөнәсәбәтләре, беренче мәхәббәттән өзгәләнүләре тасвирлана. Әйе, бу роман егерменче гасыр ахырында татар дөньясы, аның аерым шәхесләре, милләт кичергән кайгылы вакыйгалар турында. Бу хакта әдип бер әңгәмәсендә: «Бу турыдан-туры халык өстенә ишелеп төшкән фаҗига генә түгел, ә Рәсәйдәге милләтара сәясәтнең ни дәрәҗәдә гарипләндерелгән булуы хакында. Һәм шул сәясәт аерым бер милләткә генә, бу очракта Рәсәйнең чечен халкына каршы алып барган сугышның кайтавазы гына түгел, ул башка милләтләргә дә йогынты ясый... Минем исә шушы сәясәтнең гап-гади татар гаиләсенә тәэсирен күрсәтәсем килде», — дигән иде.
Яшәү рәвешебез кушканча, башта пионерда, аннары комсомолда тәрбияләнеп, Совет иленә, аның армиясенә дан җырлап, гадел хезмәт белән көн күрүче авыл кешеләре гаиләсендә туып үскән, үз гомерендә әле туган авылыннан башка җирне күрмәгән үсмер-солдат Шәфкать, гаскәри хезмәткә алынгач, кырыс чынбарлык белән йөзгә-йөз очраша. Юк, туган авылын, әнисен, әле унсигез яше дә тулмастан, кичтән генә (мулла никахы белән генә) өйләнеп киткән хатынын сагынып елап утырмый ул. Күңеленең үксүе бүтәннән, тормышның миһербансызлыгыннан чарасыз егет. Аның туган авылында кешеләр мондый түгел бит! Алар туры сүзлеләр, каты куллылар, гаделләр — тик миһербансыз түгелләр. Факил Сафин әдәби әсәрләренең тууы хакында болай дип яза:
«Әдәби әсәр образлары төрлечә туа. Кайберәүләре гел прототиплардан гына туганнары була. Автор тудырган уйдырма геройлар гына да булырга мөмкин. Әлеге романны мин 1994 елның декабрендә үк, Чечен иленә Рәсәй гаскәрләре бәреп кергәч тә яза башладым. Мөселманга каршы корал күтәрүгә мәҗбүр ителгән татар егете кичерергә тиешле хисләр бик тетрәндерде. Чөнки «Бүлгәлә һәм хакимлек ит!» сәясәтен башка милләт куллары белән гамәлгә ашыралар. Шуңа күрә, табигый ки, минем геройларым да автор хыялында туган уйдырма геройлар».
Ләкин шунысы ачык, геройлар уйдырма булсалар да, әсәрдә бернинди дә ясалмалык юк. Әсәрдән аңлашылганча, самими авыл егете Шәфкать тормыш авырлыкларын, яшәү өчен көрәшне ничек алып барырга кирәклеген, армиянең нинди җитди фаҗигаләргә китерергә мөмкин икәнен әле аңлап та җиткерми.
Бөек рус әдәбиятының XIX гасыр әсәрләреннән күренгәнчә, Россиядә солдатка гомер-гомергә кадер-хөрмәт булмавы мәгълүм. Һәм Ф.Сафинның бу әсәрен укыгач, моның шулай икәнлегенә тагын бер тапкыр ышанасың: «Яшь солдатларның күзләре керфек тә кагып алмаслык дәрәҗәдә киереп ачылган, алардан көлтә-көлтә шикләнү-шөбһәләнү, хыялланыр дәрәҗәдә курку чәчелеп тора... Алар кая куйсаң, шул якка ташланырга әзер хайван көтүе хәленә килеп җиткәннәр иде... Шәфкать тагын шунысын сизеп алды, ишек төбендә бар көчләренә көрәшкән бу шашынган күзле егетләрнең һәркайсы эчләреннән ярсый-ярсый елыйлар, шушы тар ишек төбенә шәрә килеш китереп бастырган язмышларын, бар дөньяны ләгънәтлиләр иде кебек».
Шушындый гайре табигый шартларда армиядән исән-сау әйләнеп кайту күп көч, сабырлык таләп итә, чөнки армиянең үзенең катгый һәм аяусыз законнары бар. Иң мөһиме — бер уставта да каралмаган «ясалма» кануннарны яхшы белү һәм аны берсүзсез төгәл үтәү. Шушы кануннарга буйсынмаган өчен Шәфкатьнең җанын нык телгәлиләр, аңа аеруча взвод командиры ярдәмчесе өлкән лейтенант Головастиков каныга. Шәфкать мондый җәберләүләргә түзәргә тырыша. Армиядә дә шәфкатьле кешеләр бөтенләй үк юк түгел икән. Кече сержант Веремеевның: «Түз, түз, сине өйдә көтәләр. Шулар хакына кагу-сугуларны да үткәреп җибәрә бел», — дип үгетләве аңа көч вә дәрман бирә.
Факил Сафин әсәрдә сагыну-җирсү хисен зур художникларча бирүгә ирешкән. Бу хис Шәфкать образын төгәлрәк ачарга, аның кичерешләрен тагын да тәэсирлерәк тасвирларга ярдәм иткән: «Шәфкать нигәдер үз авылын, Имәнле Тау ягыннан искән ачы җилне искә төшерде һәм тамак төбенә ачы төер килеп утырганын сизде. Юк, ул җилне юри генә «зәһәр» диләр бугай. Шулкадәр йомшак, рәхәт булып исә бугай ла ул Имәнле Тау җиле. Туган як җиле бит ул, ягымлы, битләрне иркәләп исә торган туган як җиле».
Шушы сагыну хисе Шәфкатькә яшәү көче бирә!
Факил Сафин кайчагында шундый тәэсирле «куе» буяулар куллана ки, тәннәр чымырдап куя.

Әйтик, табутта аның урынына частька килгәннең беренче көннәреннән үк Шәфкатькә рәхим-шәфкать күрсәтмәгән капитан Хасистовның (фамилиясенә игътибар итик!) күмергә әйләнгән гәүдәсе кайтып төшү күренеше үзе генә дә ни тора...
Факил Сафин — татар әдәбиятының борынгы традицияләренә тугрылыклы язучы. Ул Шәфкатьнең сөекле хатыны Раушанияне шундый югарылыкка күтәрә ки, ирексездән борынгы бабаларыбызның яудан кайтуын көткән тугрылыклы хатыннарның изге образлары күз алдына килеп баса. Әйтик, иренең Чечен илендә әсирлектә икәнен телевизордан күреп белү белән үк, һич икеләнмичә, Раушания юлга чыга. Биредә символик мәгънәгә ия бер яшерен агым бар — Сөләйман исемле чечен егете әти-әнисен, туганнарын дошман һөҗүменнән якларга, Раушания исә «дошман булып басып кергән», әмма әсирлеккә төшкән ирен кайтарырга ашыга.
Мең газаплар белән сугыш барган җиргә килеп җитеп, ирен таба алмый тилмереп йөргәндә, пулялар яңгыры астында чиләк тотып яралыларга суга дип барган җиреннән ул Шәфкать танкының корбаны булырга тиеш була, чөнки капитан Хасистовның боерыгы шундый: юлда очраган бер генә җан иясен дә аямаска!
Ә тормыш язмышларны үзенчә хәл итә! Күңел, җан һәм тән берлеге үзен сиздергән, күрәсең, Шәфкать, каршындагы шәүләнең Раушания икәнлеген шәйләп алганнан соң, танкын ташлап аңа ташлана, ә капитан Хасистов кулына күчкән танк, Шәфкать белән Раушанияне юкка чыгарырга өлгергәнче, минага эләгә...
Әйе, үлем яхшы кешеләрне генә сагалап йөри, дисәк тә, кайчакта ул яхшы кешеләрне дә читләтеп үтә икән. Чөнки алар — Шәфкать белән Раушания Яшәүгә мәхкүм ителгәннәр, алар бит бу якты дөньяга бәхетле булырга килгәннәр һәм алар шуның өчен бергә кушылдылар да! Изге җаннар озак яшәргә тиеш!
Кыскасы, тарих кабатлана тора. Әле кайчан гына булып узган Әфган сугышын меңнәр вә миллионнар «бу сугыш ялгыш булган икән» дип бәяләделәр... Ә Чечен сугышы?! Ул да кешелекнең чираттагы ялгышы түгелмени?! Ялгышы, әлбәттә. «Биек тауның башларында» әсәрендә Факил Сафин моны нәкъ шулай итеп ачып бирә дә инде.
Әйе, Факил Сафин бүгенге татар әдәбиятының күренекле прозаигы булып танылды. Аның иҗаты күзгә күренмәс җепләр белән Г.Ибраһимов, Г.Исхакый, Ә.Еники, А.Гыйләҗев, М.Мәһдиев, Х.Сарьян, Ф.Садриев иҗатлары традициясенә килеп тоташа.
Бу нәүбәттән Факил Сафинның иҗаты күп кенә күзәтүләргә этәрә. Иң начар роман шул: әгәр укучы аның ни белән бетәсен белгертә алмаса (ә Факил Сафин әсәрләренең азагын көтеп аласың). Бу сүз уйнатуда чынлап та дөреслек юк түгел. Романның иң зур уңышы шунда ки, ул, укучының күңелендә кызыксыну белән бергә, кичерешләр, ярдәм итәргә ашыгу хисләрен дә уятырга тиеш.
Сүз дә юк, әдәбият реаль тормышка әйләнгеч юллардан алып килү чарасына әйләнергә тиеш түгел. Шушы мәгънәдә без әдәби әсәр белән чынбарлык арасындагы үзара бәйләнешләрне өйрәтергә тиешбез. Теләсә нинди роман, баштарак ул ничек кенә кызык тоелмасын, чынбарлыкны чагылдырмый икән, ялган һәм кызганыч язмышлы. Шуңа күрә дә без әдәби әсәргә, бу очракта роман белән повестька, тормыш һәм яшәеш күзлегеннән чыгып бәя бирергә мәҗбүрбез.
Бер француз әдәбиятчысының билгеләп үтүенчә, кешелек һәрвакыт яңа аллалар эзли. Һәртөрле йола, гореф-гадәтләрне, яшәеш кагыйдәләрен онытмаган хәлдә. Тормышта бары тик эволюция генә реаль. Шуңа күрә дә шушындый бәрәкәтле яшәеш тәҗрибәсеннән баш тарту — үзе үк ахмаклык һәм, һич югы, беркатлылык булыр иде. Романчы буларак (Факил Сафин нәкъ менә романчы буларак фикер йөртә), аның «күңел күзен» реаль чынбарлык кына түгел, ә бәлки тирәнтен яшерелгән, беренче карашка күзгә бәрелеп тормаган уйдырма чынбарлык та җәлеп итә. Дөресрәге, ул реаль чынбарлык җирлегендә икенче бер чынбарлык иҗат итә. Болай дигәндә, ирексездән Ф.А.Достоевскийның А.С.Пушкинга һәйкәл ачылганда ясаган чыгышында әйткән сүзләре хәтергә килә: «Дөньялыкны матурлык коткарыр!» Ә талантлы әсәр һәрвакыт тудырылган матурлык ул!

*** * ***

...Шулай бервакыт якташыбыз шагыйрь Зөлфәтнең эш бүлмәсендә сөйләшеп утырганда, Факил Сафин ниндидер тантана белән: «Мин озак вакытлар Мөслим ягы шигъриятендәге «Бермуд өчпочмагы»ның кайчан да булса өченче почмагы да пәйда булырга тиеш дип уйлап йөрдем. Ике почмагы ул — Зөлфәт белән Харрас Әюп! Менә, ниһаять, өченче почмагы да булды, монысы син, Наис абый!» — дигән иде.

Шушы фикерне дәвам итә калсак, инде болайрак дип әйтергә мөмкин булыр иде: Мөслимдә прозаикларның да үзенчәлекле «өчлеге» хасил булды. Алар — Фоат Садриев, Флүс Латыйфи һәм Факил Сафин. Димәк, Мөслим төбәгенең иҗади сурәте хәзергә тәмам өлгереп җитте. Әмма әдәбият мәйданында һәркемгә дә урын җитәрлек. Кем әйтмешли, үз дөньяларын тудыра алырлык талантлар гына туа торсын...

...Факил Әмәк турындагы язмамны мин Хәсән ага Туфанны искә алып башлап киткән идем, сүземне дә олуг шагыйрьнең (әйтерсең лә шушы очракка атап язылган!) бер шигыреннән өзек белән тәмамламакчы булам:

Талантлы син, Кеше туганым! —
Сәләтлесең һәрбер иҗатка;
Дөнья дигән Бөек китапка
Языла бара хезмәт юлларың.
Талантлы син, Кеше туганым!

*P.S.* Ә ошбу китапка урнаштырылган «Саташып аткан таң» роман-трилогиясе тирән фәлсәфә, җанны кузгатырлык кичерешләр, әдәбиятта моңарчы күтәрелмәгән фикер һәм тема катламнары, фактик материалларның муллыгы белән аерылып тора. Шәхес һәм Дәвер, Әхлаклылык һәм Гаделсезлек, Намус һәм Хыянәт, Хыял һәм Чынбарлык, Мизгел һәм Мәңгелек, Мәхәббәт һәм Нәфрәт, Тугрылык һәм Яраклашу. Әсәрдә күтәрелгән бу проблемаларга укучы үзе бәя бирер һәм нәтиҗә чыгарыр дип ышанасы килә.

*Ф.Сафинның «Саташып аткан таң» романына кереш сүз.*
*Татарстан китап нәшрияты, 2003*

## ТУГАН ЯКНЫҢ КИТМӘС КОШЫ

Без еш кына: «Шагыйрьлек профессия түгел!» — дибез. Бәлки, бу чыннан да шулайдыр. Ләкин, алай бик гади икән, нигә соң әле көндәлек эше итеп әдәбиятка хезмәт итү юлын сайламаган, чын мәгънәсендә әдәбият хадиме, телисез икән, әдәбият корбаны булырга теләмәгән кайберәүләр дә гомерләре буена «җыру» чыгаралар? Хикмәт шунда ки: әйе, шагыйрьлек профессия түгелдер, әмма ул, ышанып әйтергә мөмкин, күңел балкышы, әйләнә-тирәне үзенчә кабул итүнең гыйбрәтле бер билгесе, халәте рухиянең тәэссорат чишмәләре исән-сау икәнлеген искәртеп торучы тынгысыз кыңгырау буларак, һәркемне әсир, сәйях итәргә сәләтле могҗизаи бер көчтер, тылсым иясedер. Чыннан да, шигърияттнең «тозлы бал» тәмен татып караган, күкрәгендә «илһам камчысы»ның татлы эзләрен тойган кешеләр, гадәттә, аңарга — үтә дә нәзберек холыклы Ханымга хыянәт итмиләр, дөресрәге, хыянәт итә алмыйлар. Чөнки ул синең бөтен барлыгыңны биләп ала; чөнки Иҗат — ләззәтле газап! Ф.М.Достоевский сүзләре белән әйтсәк, үз теләгең белән газап чигүдән дә бөегрәк ләззәт юк ул! Корифейлар өчен генә түгел, ә бәлки көне буе завод-фабрикаларда яки басу-кырларда тир түгеп кайтканнан соң җан сурәтен ак кәгазьгә төшерү өчен кулына каләм алган күп, бик күп әһле иҗат өчен дә бу изге хис таныштыр дип уйлыйм.

Бүгенге татар әдәбиятын менә шушындый Иҗат эшен икенчел шөгыле итеп яшәүче каләм ияләреннән башка күз алдына китерүе дә кыен. Миңа калса, алар татар әдәбияты күперен иңнәрендә күтәреп баручы үзәк баганаларга терәк булып хезмәт итәләр.

Марсель Гыймазетдинов — шундый иҗаткярләрнең берсе иде. «Шигырь язу минем һөнәр түгел» дисә дә, аның кулыннан каләме төшкәне булмады. Ул — җир кешесе! Халык әйтмешли, ул кендегеге белән җиргә берегеп үскән. Шигырьләре дә изге туган туфрактан шытып чыкканнар. Аның шигырьләре аяз иртәләр шикелле үтә күренмәле, саф, самими; авыл өйләре тәрәзәседәй якты өлгеле, ачык хисле шигырьләр дияр идем мин аларны.

Яз Кояшы җирдә.
Гөрләвекләр
Язгы ташкын булып йөгерә.
Якты көннең якты бизәкләрен
Алып була хәтта өлгегә...

Татарстан радиосыннан ясаган бер чыгышында ул үзенең иҗаты турында фикер йөртеп болайрак дигән иде:

— Мин Менделеевск районында колхоз рәисе булып эшлим. Билгеле инде, ярты гомерем басу-кырларда үтә. Яз уянып кына килгән бер мәлдәме, яисә җәйге иртә-кичләрдәме, йә булмаса көзгә кергәчме — кырлар түренә карап уйланып торасың да, ирексезләп күңелгә шатлык хисләре тула һәм үзең дә сизмәстән: «Матур бу дөнья!» — дип куясың. Мондый чакларда

тормышның вак-төяк мәшәкатьләре бердән онытылып китә, иркен сулыш белән яшисе килә башлый. Һәм мин шул уй-хисләремне, кодрәтемнән килгәнчә, кәгазьгә төшереп барырга тырышам.
Ак кәгазьгә төшкән ак хисләр!.. Әйе, шундый бер мизгел өчен генә дә яшәргә ярый бу дөньяда. Марсель Гыймазетдинов моны яхшы аңлап яшәде. Әгәр ул:

Китәсем юк сездән аерылып,
Ишетәсезме, басу-кырларым!
Гомеремне сезгә багышладым,
Сезгә булсын туар җырларым, —

дип әйтә алган икән, монда бернинди дә арттыру юк, бу чыннан да шулай иде. Шигырьләре — моның ачык дәлиле. «Гомерен басу-кырларга багышлаган шагыйрьнең» җырларына әле башаклар шавы, тургайлар моңы килеп кушыла («чыксам әгәр иркен басуларга, тургай җыры чыңлый колакта»); анда «буразналар кояш назлавыннан кара икмәк кебек күренә»; кырларда аның «йөрәккәе бәйгедәге аттай җилкенә» башлый. Ул тормышның тәмен белеп яшәде, ул оптимист иде.

...Ак томаннарга төренеп,
Тездән чык ярып кайтам.
Сагышларым — якты сагыш —
Гомеремне озайта.

Кыскасы, Марсель Гыймазетдинов авыл тормышының бай палитралы сурәтен тасвирларга омтылды, авыл кешесе — игенчегә мәдхия җырлады.
Җырлады дигәннән, аның бик күп шигырьләренә төрле композиторлар тарафыннан матур-матур көйләр язылуның сере дә әнә шунда, шигырь нигезенә җыр хасиятләре салынуда түгел микән әле? Ни генә булмасын, без бүген Марсель Гыймазетдиновны бик күп популяр җырлар авторы буларак беләбез. Аның «Аккош канат кагына», «Килмисең син көлеп», «Язлардан алалмыйм күземне», «Туган якның китмәс кошлары без» кебек җырлары эстрада сәхнәсеннән төшми диярлек. Шагыйрь:

Язгы күкрәү кебек,
Яздай карый көлеп —
Эреп аксын салкын кышлары.
Без — җилкенеп очкан,
Зәңгәр күкне кочкан,
Туган җирнең китмәс кошлары,
Яз ясаучы китмәс кошлары, —

дип язган иде. Шөкер, нәкъ менә шулай, «туган якның китмәс җырчы кошы» булып, җирдә яз ясап яшәргә язды аңарга.

*«Казан утлары», декабрь, 2003*

## БЕЗ — БАЛАЧАК ИЛЕННӘН...

*(Үзем турында үзем)*

«Без — барыбыз да балачак иленнән!..» — дигән бер фикер иясе (ялгышмасам, атаклы француз язучысы, киң танылу тапкан «Нәни принц» повестеның авторы Антуан де Сент-Экзюпери, ахрысы). Шуның кебек, мин дә «балачак иленнән» Яшәү дигән олуг сәяхәткә чыккан алтмыш яшен тутырып килүче «сабыймын». Күпме күзәткәнем һәм ишеткәнем булды, шул ук вакытта еллар биеклегеннән торып раслый алам: Кеше дигән Олуг җан иясе үзенең барлыгын тоеп яши алган хәлдә, хиссеми фикерләү рәвешен югалтмаган очракта, картаймыш көннәрендә дә балачак хатирәләреннән аерыла алмый икән — Яшәүнең, ягъни фәлсәфи мәгънәдә тереклек итүнең тотрыклы вә эзлекле тоташ бер асыл хәрәкәт икәнлеге шуның белән аңлатыладыр да, күрәсең. Шулай булмаса, яшәүнең бөтенләй кызыгы калмас иде, мөгаен.
Көннәрдән бер көнне, истирахәт кылып сөйләшеп утырганда, әткәй мәрхүм (ул һәр сүзенә диярлек халык әйтемендәгечә, «улым сиңа әйтәм, киленем син тыңла» дигән кебегрәк эчке бер мәгънә салырга ярата иде), сиксән яшьлек ил карты: «...кызык бу дөнья, иртән ни-нәрсә ашаганымны онытуым мөмкин, ә бала чакта ниләр булганын, уйнап-көлеп йөргән чакларымны кичәге кебек әле дә яхшы хәтерлим», — дигән иде. Ул вакытта мин әткәй-картның, иртәгесе көнен онытып торып, еракта, бик еракта калган хатирәләрен барлап-сагынып утыруына, дөньяга күзе ачылганда күңеленә сеңеп калган бизәк-картиналарның җуелмас булуына хәйран калып тыңлап торган идем.

Кем әйтмешли, мин дә бүген иртәнчәк ни ашаганымны оныткан хәлдә дә бер гөнаһсыз бала чагымны, яшьлек елларымны сагынып яшим: «Тәгәрәп-аунап буй үскән туган илем, исәнме, чәч кузгатып җай искән таңгы җилем, исәнме, йөгереп-йөгереп туктаган, яулык болгап сыктаган нәзкәй билем, исәнме?!»

Әмма минем рухи уянуым, егетлеккә атлаган көннәрем, әйләнә-тирәдәге Олы дөньяга шигъри күзләр белән карый башлавым, кайдадыр язып үткәнемчә, Хәсән ага Туфанның көндәлек мәшәкатьләрне бар нәрсәдән өстен күреп, «өстән» җибәрелгән җәзалардан тәмам гаҗиз булып яшәп яткан татар мохитенә кабаттан әйләнеп кайткан көннәренә туры килде. Әле дә хәтерлим, 1964 елда булса кирәк, безнең авыл китапханәсенә Хәсән аганың шигырьләр җыентыгы кайтып төште. Мөдир булып эшләүче Мирфәез абый, рухи остазларымның беренчесе, шигырьләр языштыруымны һәм гомумән китап белән кызыксынуымны искә алып булса кирәк: «Менә, Наис энем, бу бөек шагыйрь белән дә танышырга кирәк сиңа», — дип, шәмәхә тышлы, әле буяу исе дә бетеп җитмәгән калын гына бер китапны кулыма тоттырды. Мин исә, кош тоткан кебек йөгерә-чаба өйгә кайтып кердем дә, йотлыгып, шигырьләр укырга керештем. Йә Хода, нинди таныш булмаган сихри дөнья бу, нинди тылсым бар бу шигырьләрдә — болар моңарчы мин укып белгән Тукайныкына да, Җәлилнекенә дә, Кәримнекенә дә бер дә охшамаган лабаса! (Дөрес, Тукайның зурлыгын хәзер дә аңлау һәм аңлатып бетерү кыен анысы; бу Бөек рух иясенең халык күңелендәге урынын Шәхес һәм Гавам галактикалары киңлекләрендә генә билгеләргә мөмкиндер, мөгаен.) Шул рәвешле мин, әдәбият укытучылары күрсәтмәсеннән башка гына үзем өчен яңа бер шигъри дөнья ачтым, һәм шулай килеп чыкты ки, алар минем ул дәвердәге халәте рухыма туры килгәннәрдер, ахрысы: Хәсән аганың күңелемә бикләгән һәр яңа шигырен һәр очрашкан кичемдә «нәни мәгъшукама» яттан сөйли торган булып киттем, алай гынамы соң — мин аңа Туфанга ияреп «сеңлем» дип яратып эндәшә торган идем. Аңлашылса кирәк, Туфан укылып беткәч, үземнең шигырьләргә күчә идем. Нишлисең, мәҗбүрият!..

Хәсән ага белән күзгә-күз очрашу исә 1967 елның җәй айларында район үзәгендә чыга торган «Авыл утлары» газетасының редакциясе бинасында булды (бу вакытта инде мин редакциядә эшли башлаган идем): Хәсән ага, Ә.Еники, Г.Бәширов, Ф.Хөсни кебек бер төркем күренекле әдипләр белән берлектә, Мөслим җирлегендә әдәби атналык уздырырга килеп төшкән иде. Көннәрдән бер көнне алар, әдәбият сөючеләр белән очрашырга дип, редакциягә дә кереп чыгасы иттеләр. Әдәби мәҗлесне, әлбәттә, Хәсән ага Туфан үзе алып барды. «Тере» классикны мин бүлмә уртасында корсагын киереп утыручы мич артыннан гына басып тыңлап тордым: какча гәүдә, озын-ябык чырай, тавышы бераз тонытрак икән; әмма күзләре тере вә ягымлы... Менә ул бер кәгазь битен кулына алды да укый башлады:

Бертуктамый шаулый арышлар
Мин үтәсе юллар өстендә;
Басу юлы — тузанлы юллар
Балачактан калган танышлар.
Бертуктамый шаулый арышлар.

Вә, бәрәмәч, бу минем шигырьдән түгелме соң?

Менә Хәсән ага «Арышлар шаулый» дип аталган шигыремне укып бетерде дә, башын бер кырыйгарак салып: «Кызык... Кызык кына... Минемчә дә, минемчә дә түгел... Бу егет өметле генә күренә, минем аның үзен күрәсем килә, монда булса, әлбәттә», — дип җанланып китте.

Мин, «качып» торган җиремнән, кыенсынуымнан бүртенеп халык уртасына чыгып баскан мәлемдә, үземне Гавриило Державин каршында имтихан тоткан лицеист Пушкин хәлендәрәк тойдым бугай һәм Хәсән аганың «тагын берәр шигырь укы әле, канәтем» дигәч, үсендереп җибәрүенә буйсынып, авыз эченнән, көрмәкләнә-көрмәкләнә: «Сентябрь малае эзенә сентябрь яфраклар коя», — дип мыгырданып алдым.

Әмма бу вакытта инде мин, эчтән ничек кенә каушап калуыма да карамастан, беренче чын Остазым — әле яңа гына Казан тикле Казан университетын тәмамлап, безнең Үрәзмәт мәктәбе балаларына әдәбият (һәм соңыннан аңлашылганча, тормыштагы әдәп) сабаклары да бирергә килгән хәлфәм Рәдиф Гаташтан «дәресләр» алырга өлгергән шәкерт идем.

Шуннан соңгы дәвердә Рәдиф Гаташның «Мөслим эпопеясы» турында күп язылды, күп сөйләнде; шулай да, Мөслим халкына ул алып килгән шигъри зилзиләнең уртасында кайнаган бер «кошчык баласы» буларак, җае чыккач бер-ике кәлимә сүз әйтеп китмәкче булам.

Гомумән алганда, Рәдиф абыйның безгә биргән «дәресләре» (турыдан-туры мәгънәсендә дә, кыеклатып әйтсәң дә) моңарчы без белгән педагогиканың бер калыбына да сыймаслык дәрәҗәдә сәер иде. Менә ул олы-олы атлап класска килеп керер, керә-керешкә класс журналын өстәлгә чөеп җибәрер (әлбәттә, ул дәрес беткәнче ачылмаячак), аннары башларыбыз өстеннән күзлек аша күз йөртеп алыр да, артистланыбрак: «Утырыгыз, тәкъсирләр!» — дип сөрән салыр,

һәм шуннан соң дәреснең «рәсми» өлеше дәвам итә; дәвам итә дип инде, ул мәҗбүрият йолаларын йөгертеп узуга ук тәмамланып та куя. Шуннан соң башлана инде тамаша: йә ул, — бала-чагага кызык кына булсын, узган сабакны гына сорамасыннар, — тавышын баса төшеп, кичә генә язган шигырьләрен укый, яки алдагы көндә берәр француз йә инглиз романыннан өзелеп калган искитмәле вакыйгалар тезмәсен ялгап китә; инде дә булмаса — безгә (укучыларына!) тын гына утырырга куша да өстәлгә капланып шигырьләр язарга керешә. Шигырьне мондый да бирелеп, күпереп торган чәчләрен тузгыта-тузгыта язса да бер Такташ кына язгандыр. Әйе, яза алгандыр... Һәрхәлдә, безгә шулай тоела иде.
Чыннан да, мәктәп елларында безгә Рәдиф абый Гаташ кына түгел иде, ул үзебезнең «Такташ» та иде бит... Әйткәнемчә, аның «дәресләре» «кыңгыраудан кыңгырауга» хәтле генә бармады, алар (якыннары, каләм тибрәтергә хыялланган алгысак җаннары өчен) тәнәфесләрдә дә, мәктәп ишегалдында да, кичләрен төркем-төркем булып урам әйләнеп йөргән вакытларда да, бергәләп кызлар озатканда да... тагын әллә кайларда дәвам итте. Кем әйтмешли, без урам буйлап корыны бушка аударып йөрмәдек бугай — үзебезчә фәлсәфә саттык, бәхәсләштек, уйнадык-көлдек... һәм хәлфәбезнең дөнья әдәбиятыннан хиссеми кыйссаларын уйга да, (буйга да) сеңдереп тыңлап үстек. Менә шундый «лимитсыз» дәресләр барышында без — күпләр, бик күпләр! — бер башка үсеп китеп, туган авылыбызның болын-кырларыннан арырак та Олы дөнья көтеп торганлыгын тоеп яши башлыйбыз: кара аны, Хис дигәнең яшь күкрәккә сыймаса да Хыялга сыя икән ләбаса... Рәдиф абый расписаниедән тыш үткәргән «дәресләрендә» без беренче тапкыр Байрон, Гете, Шиллер, Мицкевич, Петефи кебек шагыйрьләрнең иҗатларыннан үрнәкләр белән таныштык, Бальзак, Стендаль, Мопассан, Гюго һәм Дюма кебек дөнья әдәбияты классиклары иҗатыннан кереш дәресләре үттек. Әйтергә кирәк, ул бигрәк тә гыйсъянчылык һәм хыялый матурлыкка корылган француз әдәбияты һәм сәнгате мирасын белә һәм үз итә иде булса кирәк. Шулай булмаса, хәтердә ич, ул Франциянең Сезанн, Моне, Мане, Ренуар кебек һәм башка, һәм башка импрессионистик рәссамнары турындагы фикерләрен безгә — сала малайларына — очына-очына җиткерә барыр идемени. Юк, болар коры вәгазь генә түгел иде, олы кешенең, үзе әйткәнчә, «яшь иптәшкә» киңәш-табыш бирүе иде. (Җәяләр эченә генә әйтеп китим булмаса, шушы рухи эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак, «Дуслык» дигән күмәк җыентыкта (1965) Рәдиф абыйның шигырьләре дә урнаштырылган иде. Без аның корректурасын кулдан-кулга йөртеп укып чыктык. Мәҗмуганың редакторы Рәис Даутов тарафыннан язылган хат-юлламадагы үсендерүле юлларны укып, хәлфәбез белән бергә без дә сөенештек. Безнең укытучыбызны Казанда да яраталар икән ләбаса!)
Аннары XX гасырның 60 нчы елларында Франциянең бик тә популярлашып киткән «Фанфан-Тюльпан» дигән кинокартинасы турында башта класслардагы дәресләрдә «ликбез» сәгатьләре үткәннән соң, авылга нәкъ шул кино килгәч, аны кат-кат (халык соравы буенча!) карый торгач, Рәдиф абыйның үзе кебек үк, Жерар Филип белән Джина Ллоллобриджидага гашыйк булып йөрдек түгелме соң? Ә Гамлет ролен кабатланмас Иннокентий Смоктуновский башкаруындагы «Гамлет» картинасы белән булган мәрәкә үзе генә дә ни тора?! Ул вакытта, кино куеп, киномеханиклар авылдан авылга күчеп йөри торган иде. «Гамлет» артыннан ияреп йөри торгач, без дә Үрәзмәттән шактый еракта урнашкан Әмәкәй авылына ук барып чыктык. Ә кайтышлый, Бүләк урманын чыккан вакытта, без барыбыз да агач кылычлар белән коралланган «Гамлет»лар идек: әй кылычлашабыз, мин сиңайтим, әй «фехтовать» итәбез, Урта гасыр рыцарьларың бер кырыйда торсын!.. «Атның азгыны тайга иярә» дигәндәй, мондый «яу йөрүләрнең» башында, әлбәттә, Рәдиф абый үзе торыр иде. Әйе, авылдан авылга йөреп концерт-спектакльләр кую да, шигъри кичәләр үткәрү дә, Евгений Онегинга «суд» ясаулар да — берсе дә калмады бездән; ләкин аларның барысы да рухи эчтәлекле, тәрбияви мәгънәгә ия булган эш-гамәлләр булган икән.
Менә шигырь уты кабызып йөри торгач, Такташ әйтмешли, уйнап кына башланган эш чынга ашты лабаса: Рәдиф абыйның йөзләгән укучысы арасыннан (Үрәзмәт мәктәбендә ул укыткан чагында, ягъни 1964–1965 уку елында, шигырь белән җенләнмәгән укучы бала юк иде; әйе, Үрәзмәт урта мәктәбе чын мәгънәсендә шигъри Мәккәгә әверелгән иде) өч профессиональ язучы чыкты — Зөлфәт, Фәрит Гыйльми; язучы дип санасак — мин бәгъзегез... Бер мәктәптән, бер ел эчендә бит бу!..
...Ниндидер бер эчке символик мәгънәгә ия түгелмени: Рәдиф абый белән минем беренче очрашуыма быел нәкъ кырык ел тулды. Бүгенге көндә без аның белән «Казан утлары» журналы редакциясендә кара-каршы утырып эшлибез. Хәлбуки, утырган урыннарыбыз «кара-каршы» булса да, Рухи кыйблабыз бер юнәлешкә — Шигъри-әнкә тарафына юнәлгән, һәрхәлдә, мин шулай дип беләм... Кайчак көннәр буена сузылган моназарадан шул аңлашыла: менә бүген, олыгайган көннәребездә дә, баш очыбыздан нинди генә рәхимсез зилзиләләр очып үтмәсен,

Яшәү дигән Олуг вә Гадел хакыйкатькә хыянәт итмичә, күкрәгебездә Шигырь утын саклаган хәлдә балачак илендә кала алганбыз икән, шаять.
Йә, бала булып — үзең булып кала алу үзе бер бәхет түгелмени?!

*«Ялкын», февраль, 2005*

**ЭЧТӘЛЕК**

Яраттыра торган иҗат. *Р.Гаташ*

ШИГЫРЬЛӘР


Кабатлана... ............
«Сулар! Күпме яшьләр түктем сезгә карап...» ...........
«Шундый дымык, тонык иртәләрдә...» .............
Кайтсам... ............
Теләү ............ ....
Озату ............ ....
Исә җилләр... ...........
Болгар ташларына .........
«Сәйләннәр өзек — чәчелгән!..»
«Һәрбер халык...» .........
Коррида ............ ..
Төш ............ ....
«Таудан гына йөгереп төшәсе дә...» ............ ....
Көз — моңлы күз .........
Мин чыгамын юлга... .......
Бәлки... ............ ..
Яшәү тамыры ...........
Кылганнар йөгерә... ........
«Мин җәйләрдән көзгә кереп киләм...» ............ ..
«Апрель...» ............
«Барыбер...» ............
Төнге сулар ............
«Апрель керә җанга өмет булып...» ............ ...
Арышлар шаулый .........
Сагыну ............ ...
Хушлашу ............ .
Аккош күле ............
«Артта кала утлар...» .......
Кавырсын хат ...........
«Ак болытка язып салган идем...»
Югалды ............ ..
«Хәсрәтемне генә түккән идем...» ..............
«Кипкән чәчәк килеп чыкты беркөн...» ............ .
«Ага гына Вакыт...» ........
Сүнгән йолдызлар .........
«Баш өстемнән очып узды казлар...» ............ ...
«Сөрән салып узды киек казлар...»
Син — очар кошым! ........
Очрашырбыз ............
«Көн-таң атса ява...» ........
Әрем ............ ....
«Үткәннәрнең асылмалы, алтын...» ............ ...
«Йөгем дә юк ат арырлык...» ...
«Минем өчен...» ..........
«Ян!.. Янылмый. Ян!..» ......
Әнкәй төше ............
Әнкәйгә ............ ..
Кызыма хат ............
«Еллар үтеп, юллар югалса да...»
Бер халәт ............ ..
Син — бер генә... .........
Мәхәббәт эволюциясе .......
«Атылып кердең...» ........
«Дулкыннар ярны кыйныйлар...»
«Төн. Яңгыр. Салкын. Караңгы...»
«Пәри кызы» турында әкият ...
Бәбкә саклаучы кызга .......
Сукыр яңгыр ............
Төнге учаклар ...........
Табигать баласы ..........
«Үтеп киткәч, бер карама икән...»
«Юлымның мин тауга менгән төшен...» ............ ..

«Теләсәң дә булмый — онытып булмый...» ............
Якты сын ............ .
И мәхәббәт! ............
Тормыш гөлләре ..........
«Гомер чигеп кенә яши Кеше...
«Киткәнсең юкса... Көләсең...» ..
«Төтеннәре туры чыкканнарның...» ........... ...
«Урман. Тын. Шомлы уфылдый...» ..............
«Әйтәсең кайчак: «Тузгыттың...»
«Сүрелде көннең күзләре...» ...
«Шәраб залларына кереп кенә...»
Циркта ..............
Күмелгән эзләр ..........
Төш .................
Соңгы чабыш ...........
«Басмадан чыга идең син...» ...
«Мең дә бер кичә» .........
Качак ................
Көзге бизәкләр ...........
«Өркәч-өркәч кар көртләрен сыйпап...» ..............
Яшәү агачы ............
«Авылымның зират башында ук...» ...............
Көз. Кич .............
«— Юк, кайталмам әле быел яз...»
«Җиде ятны сөю, бәлкем, язык...»
«Туу — ул сәбәп кенә...» .....
«Кем әйтте?..» ...........
«И-и», — дисәң, башлар иелә...»
«Алмадым да... (аңладың ла!)...»
«Бу өйдә күптәннән...» ......
«Буран да буран...» ........
«Беләсеңме, Зөлфәт, Мәсеготнең...» ..............
«Гел турыдан гына ярганнарның...» ..............
«Аһ, китәсе килми синнән, Казан...» ...............
«Чалгылар тагын чормага...» ...
«Атлар тугарылган. Кабык арба...» ...............
«Китүдән дә кайту авыррак...»
«Эскерт өстендәге Айның...» ...
«Алиһәләр кунды кочакларда...»
«Кичкә авышкан вакыт...» ....
«Алдыма өзелеп төшәләр...» ...
«Бер эзгә басу кыендыр...» ....
«Эндәштеләр дә киттеләр...» ...
«Әйләнеп карыйсың: тирәңдә...»
«Төн кундым Гаташның...» ....
«Янымда юк берәү, җанымда...»
«Түмәр бүләк иттең...» ......
Күтәрелик күккә парлашып ....
«Кырын-кырын гына сугылып үтә...» ...............
«Ераклардан килгән тавыш сыман...» ..............
«Бу юлларның чиге булыр микән?..» .............
«Сүнсә дә көннең күзләре...» ...
«Дәфтәреңнең соңгы битләрен дә...» ...............
«Юлымда ятып eладым...» ....
«Бу юлдан — мин дә үткән...» ..
«Ишекме?... Ачык ич ул!..» ....
«Яңгыры үтте чылатып...» ....
«Морҗам ярык иде...» .......
«Йоклама!» дигән шикелле...» ..
«Иртәсен ачылды пион...» .....
«Үләр идем... Булмый! Сезнең өчен...» ..............
«Күкләреңне терәп торыр чакта...»
«Авырдым көн буе...» .......
«Йөзәсең — йөзәр чагыңда...» ..
«Кем себерер бу юлларны...» ...
«Тау тау инде... Тауларның...» ..
«Чигелде җилләр җилендә...» ...
«Болыты белән төшәр дә...» ....
«Киләсең дә бер китәсең...» ....
«Бу сәгать йөри дә йөри...» ....
«Иттифакый дуслар арасыннан...»
«Кереп утыра идең: «Ни хәлең бар...» ...............
«Киләсең дә китеп барасың син...»

«Килүең дә авыр булды, — дидең...» .............
Аккош күлендә ..........
«Акчасы ни, бакчасы ни...» ....

ЭССЕ-ХИКӘЯЛӘР
Әткәй белән сөйләшү .......
Ма-ту-у-у!!! ............
Сөембикә манарасына ай куйган егет турында хикәят ........
Бер йотым су ............
Боз өстендә ялгыз малай .....
Авырта!.. .............
Бәхет орлыклары .........

МӘКАЛӘЛӘР
Юлчы юлда сынала ........
Тәлгәшләрдә сусыл җимешләр
Гөрләвекләр яз алып килә ....
Бәхетле булу кыенмы? ......
Бәхеткә юл — гел алда ......
Учак җылысы ...........
Йөрәк шагыйре ..........
Башны салларга салып... .....
Җәяүле күбәләк ..........
Кояшлы тауга күтәрелү ......
Ерактан килгән — еракка китәр...
Каеннар яктысында ........
Яшьлек хатирәсе .........
Их, жидень!.. ............
Ул тормышны ярата иде ......
Гомер учагының ялкыны .....
Аккош күлендә утлар... ......
Авыртуы булып калды ......
«Әйдә, халыкка хезмәткә!..» ...
Сүз гаме .............
Шигырь тамыры ..........
Туксанынчы еллар әдәбияты ...
Халаты ак, күңеле пакь ......
Оясында ни булса... ........
Күңел кошының биек очышы ...
Тамчы күзендәге сурәтләр ....
Вакытым тар, шуңа күп эшлим...
Язмыш эше ............
«Талантлы син, кеше туганым!»
Туган якның китмәс кошы ....
Без — балачак иленнән... .....

Литературно-художественное издание

**Гамбар** Наис

(Гамбаров Наис Гимранович)

КОРЕНЬ  ЖИЗНИ

Казань. Татарское книжное издательство. 2007
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Гамбәр** Наис

(Гамбәров Наис Гыйлмран улы)

ЯШӘҮ ТАМЫРЫ

Мөхәррире *Х.Г.Әюпов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н.П.Клипова*

Корректорлары *Г.Х.Сундукова, Г.М.Хәбибуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 24.07.2007. Форматы 70×108 1/32.
Офсет кәгазе. «Times» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 15,40. Шартлы буяу-оттиск 15,75.
Нәшер-хисап табагы 15,94. Тиражы 2000 д. Заказ С-842.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет JahatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.